# казан утлары

6

ИЮНЬ • 1977

# КОТЛЫЙБЫЗ!



Г. Г. АФЗАЛОВ.



И. Ш. ХӘКИМОВА.



В. И. БЕСПАЛОВ.

*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы, Габдулла Тукай исемендәге Республика премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, 1977 ел өчен Габдулла Тукай исемендәге республика премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирү турында карар чыгардылар:*

*Шагыйрь Гамил АФЗАЛГА (Афзалов Г. Г.) — «Айлы кичләр» һәм «Борылам да карыйм» дигән шигырь китаплары өчен;*

*Кинорежиссер В. И. БЕСПАЛОВКА — «Кырлай», «Татар гармуннары», «Нәҗип Җиһанов музыкасы» дигән музыкаль телефильмнар өчен;*

*Солистка И. Ш. ХӘКИМОВАГА — М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында Ф. Яруллинның «Шүрәле», Ә. Бакировның «Су анасы», П. Чайковскийның «Аккош күле» балетларында төп рольләрне башкарганы өчен.*

*Тукай премиясе лауреатларын чын күңелдән котлыйбыз һәм аларга яңа иҗат уңышлары телибез.*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

6
ИЮНЬ
1977

## Бу санда

М. ӘМИР. Без бәләкәй чакларда. Повесть . . . 3
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр . . . . . . . 70
Р. ИШМОРАТОВА. Язмышлар. Повесть . . . . 77
Н. АРСЛАНОВ. Алтын кояш. Шигырьләр . . . . 114
Ф. ХӨСНИ. Җуля — кайгылы эт. Хикәя . . . . 122
В. БАГРЯШЕВСКИЙ. Чуал. Хикәя . . . . . . . 127
КРОНИД ОБОЙЩИКОВ. Татарстанга хат. Шигырь . 133

ОКТЯБРЬНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Р. МУСИН. Киләчәккә атлый Казан . . . . . . 135
М. МИНШИН. Ташкын. Очерк . . . . . . . . 143

СӘНГАТЬ

К. ТАҖИЕВА. Татар музыкасы классигы . . . . 152

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

И. АНДРЕЕВА. И. Франко әсәрләре Татарстанда . 159

Ф. ТУЙКИННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Э. ШӘРИФУЛЛИНА. Илебез — кадерле җиребез . 163

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

Ф. САФИН. Рәшит Гәрәй лирикасы . . . . . . 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Замандаш турында . . . . 173
Р. ГАНИЕВ. Жорж Сандның романтизмы . . . . 175

ТӨРЛЕСЕННӘН

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Заман таләбе . . . . . . 177

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

**«Панчатантра»** . . . . . . . . . . . . . . . **181**

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Г. АФЗАЛ. Сәфәргали сәфәрдән кайтты** . . . . **186**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . . **188**

**Р. АБДУЛЛИН** музыкасы, **Р. ВӘЛИЕВ** шигыре.
**Иделем акчарлагы** . . . . . . . . . . . . **192**



Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.



Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**



Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 2/III-1977 ел. Басарга кул куелды 12/V-1977 ел. ПФ 06066. Кәгазь форматы $70\times108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 85044 экз. Заказ Б-92. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1977 ел.

**Мирсәй Әмир**

# БЕЗ БӘЛӘКӘЙ ЧАКЛАРДА

АВТОБИОГРАФИК ПОВЕСТЬ

## Автордан

Тарих язмыйм. Гадәттәге автобиография дә түгел. Бу китапта мин башымнан кичкәннәрнең һәм өлешчә үз колагым белән ишетеп белгәннәрнең тарих китапларында яки рәсми биографияләрдә язылмый үтелә торган детальләрен хикәя кылырга тырышам. Бу язмалар фәкать тормышта булган һәм күңелемдә билгеле эз калдырган фактик материалларга нигезләнгән. Тик кайбер шәхесләрнең исемнәрен генә беркадәр үзгәртергә туры килде.

Заманыбызның экрандагы тизлек белән үзгәрә, яңара баруын, ягъни безнең буын белгән авыл тормышы, аның үзенә хас гадәт-йолалары, кием-салым, өй җиһазлары, эш кораллары якын киләчәктә ерак тарихка әйләнеп калу ихтималын күздә тотып, этнографик детальләргә дә күбрәк урын бирелде.

Тагы шуны әйтәсем килә: кичә турында бүген язам. Автор буларак, кайчандыр башымнан кичкән вакыйга яки күреп үткәргән шәхесне искә төшерү уңае белән туган уй-тойгыларымны, әйтәсе килгән фикерләремне изһар итәргә кирәк булганда, мотлак образлар теле булсын дип тормадым, ачыктан-ачык публицистика алымына мөрәҗәгать иттем.

Мондый «иркен кылану»ны әдәби прозада нинди жанр кабул итә ала соң? — Повесть!.. Дөрес, соңгы елларда бездә повестьны башлыча бәләкәй роман сыйфатында шәрехләү гамәлгә кереп бара. Ләкин болай чикләү дөрес булмас иде. Тарихта һәм хәзерге әдәбиятта күренгәнчә, повесть — прозада иң киң күңелле жанр. Һәм ул шулай булып калыр да. Күпкырлы әдәби практика аңа тараерга ирек бирмәс. Шуңа ышанып, әсәрнең жанрын автобиографик повесть дип билгеләдем дә.

Бу беренче китапта тормыш юлымның туган авылымда үткән чоры сурәтләнә. Стәрлетамак, Авыргазы, Казан чорларына багышланган икенче китап өстендә эшләү дәвам итә.

1976

# ПАТША ИСӘН ЧАКТА

## 1

### ДИН ДӘРЕСЕ. ШКОЛА. ҖИРГӘН ТЕЛЕ. БИРГИДЕЛ. НУРУЛЛА МУЛЛА. УЧИТЕЛЬ



— Инналлаһо гафуын йөхиббель-гафу!.. Татарчасы ничек?

Бер малайдан сорады мулла, белмәде. Икенче малайдан — белмәде. Өченче малай да әйтә алмады.

— Кем әйтә ала?

Мин кул күтәрдем.

— Әйтеп бир шуларга!

— Иннә — хакыйкатьтә, аллаһо — алла тәгалә, гаф-уын — гафу итүчедер, йөхиббе — сөядер, әлгафу — гафу итүчене.

— Афәрин! Яңакларына сугып чык шул утын агачларының! Икенчеләй укып килсеннәр.

Ник кул күтәрдем көненә төштем. Нишләргә белми каушап, хәрәкәтсез торам.

— Кушканны үтә, Мирсәяф! Нәрсә көтәсең?

Иптәшләремә карыйм. Әнә, кырыйдан беренче булып Габделхәй тора. Бик күп көлүчән малай. Көлгәндә, тавык кытаклаган кебек, кыт-кыт көлә. Дөнья гыйлеме дәресләреннән, рус теленнән безнең арада иң яхшы укучы. Аеруча хисаптан шәп. Кайвакытта хәлфә үзе чишә алмаган мәсьәләләрне дә чыгарып куя. Ә менә «Йөз дә бер хәдис»тән шундый җинел җөмләне татарча әйтә алмый тора... Аның янында — Хөсәен. Якын дустым. Узган ел без аның белән бергә рус школасына кергән идек. Җитәкләшеп бардык, алдылар. Йөрибез. Русча рәтләп аңламыйбыз, шулай да бик тиз иялəшеп, рус малайлары белән аралашып барабыз. Алар бездән татарча өйрәнергә тырыша, без алардан — русча. Эшләр бик әйбәт китмәкче иде, тик һәр көнне, өйгә кайтыр алдыннан, бөтен классны тәпи бастырып, «славянский» уку йоласы бар. Учителебез безгә, татар малайларына, бу сәгатькә калмаска да рөхсәт иткән иде, ләкин, куып чыгармагач, безнең китәсе килми: славянский уку ничек була икән — кызыксынабыз. Учитель артыннан бөтен бала бергәләп безгә аңлашылмый торган чиркәү телендә ниндидер «урыс догасы» укый. Безнең дә кушылып китәсе килә бит шунда. Хәтта «аминь» дигән җирендә кушылып киткәнебезне сизми дә калабыз. Тагын да хәтәррәге, укып беткәч, бөтен бала берьюлы «чөбен куа» башлый. Аларга ияреп, төртенеп карыйсы килә бит! Учитель өйрәткәнчә, өч бармагымны, очларын тигез китереп, бергә укмаштырганмын, уң кулымны чак тыеп торам. Шулай бер атна узды. Рус малайлары белән көрмәкләшеп уйнарга, русча көрәшергә генә түгел, сөйләшергә, әрләшергә дә өйрәнеп барабыз. Безнең өчен иң шәбе: теләсә ни көнне, теләсә ни вакытта рус урамына чыгып йөри алабыз. Югыйсә, әти-әнисеннән яки абыйсыннан башка рус урамына чыккан татар малаена көн юк: кыйнап кайтаралар. Татар урамына чыккан рус малайларының да хәле шундый. Әйе, рус малайлары белән тату яшәү әйбәт булыр иде дә, менә тиктомалдан алар белән бергә «чөбен куасы килү» күңелне борчый.

Бервакыт шулай, иртәгә урыс атнасы дигән көнне славянский дәресен аеруча дәртләнеп уздырдылар. Без, әлбәттә, үзебез рус догасын укымасак та, соңыннан чукынмасак та, бөтен малайлар белән бергә

басып торабыз. «Аминь»нан соң чукыну да тәмамлангач, барлык малайлар белән шау-гөр килеп урамга чыктык. Хөсәен белән икәүләп Агыйдел ягына таба, рус урамыннан түбәндәрәк урнашкан татар урамнарына төшеп барабыз. Хөсәен никтер сүзсез. Гадәттәгечә букчасын селкә-селкә йөгерми дә.

— Нишләдең, Хөсәен? Нигә балтасы суга төшкән кеше кебек барасың әле?

— Малай, әллә яхшы чакта ычкынабызмы бу школадан?

Сагая калдым.

— Нигә?

— Рус малайлары чукынган вакытта минем дә чукынасы килә башлады, әй. Чак тыелып торам. Тәкать тотар хәл юк.

Йөрәгем жуу итеп китте. Я хода! Бер мин генә түгел икән, Хөсәен дә...

— Әхмәй хәленә төшкәнче, таябызмы әллә?— ди Хөсәен.

— Әхмәй нишләгән?

— Чукына! Уйлап та бирми.

— Кит аннан?!

— Күз алдымда төртенеп күрсәтте. Үзе көлә. Нәрсәсе бар аның чукынуның, ди, молитвасын укымагач, ди...

Әхмәй — хәллерәк кешеләрдә вак-төяк эшләр башкарып йөрүче ятим малай иде. Безгә караганда бер-ике яшькә олырак та иде бугай. Берникадәр вакыт рус байларында эшләп йөргән, диләр. Дөрес, ул — яңа мөселман малае. Алай дисәң, дин тоту ягыннан алар иске мөселманнардан бер дә ким түгел.

— Менә сиңа рус малайлары белән чуалып йөре! — дидем мин Хөсәенгә.— Сихерлиләр, димәк?! Авызыңнан иманың күгәрчен булып очып чыгып киткәнен сизми дә калырсың [1].

Шул көннән соң мин дә, Хөсәен дә рус мәктәбенә бармас булдык...

Ничек итеп шундый якын дустыңның яңагына сукмак кирәк? Начар укучы да түгел бит әле!.. Аның янында — Закир. Мещан очыннан. Миңа караганда шактый зур, калын гәүдәле, кып-кызыл битле малай. Бер сукканыңны биш итеп кайтармый кала торган түгел. Нишләргә? Ә мулла көтә. Берәүгә дә сукмыйча гына котылып булмас төсле. Дүртенчегә әнә Хөсәеннән ике малай аша гына тагын бер Закир тора. Юк, монысы — Әхмәтзакир. Озын чәчле башын түбән игән. Өстендә дә киртек якалы, арттан ерык чабулы купшы бишмәт. Кунакка килгән кала малае кебек киенеп йөри. Арада иң начар укучы. Хет дин сабагын белер иде, ишан хәзрәт баласы бит! Пожалый, моның яңагына берне бирсәң дә ярый. Шәрикләрем хуплаячак кына. Малайлар гына түгел, укытучылар да яратмый аны. Җибәрим берне яңагына... Юк, кыюлыгым җитми, кулым күтәрелми...

— Я, Мирсәяф!— ди мулла.— Нәрсә көтәсең? Ник дәшмисең? Әллә мулла абзыеңны тыңламыйсыңмы? Адайса, киресенчә эшлибез, мулла кушканны тыңламаган өчен, алар сине яңакласын!

Мин бу шартка сүзсез риза булырга әзер идем. Хөсәен кинәт телгә килде. Шактый ачулы итеп, боерган тавыш белән:

— Я, сук инде тизрәк!— диде дә яңагын миңа таба сузды.— Мә!

Төшенәм: миңа ярдәмгә килергә ашыга. Югыйсә, үзе миннән дә уңайсызрак хәлдә калачак бит. Кыюланыбрак киттем, ачусыз, дәртсез генә итеп булса да, яңагына берне чәпелдәттем.

[1] Шундый риваять сөйләнеп йөри иде: бер ятим башкорт малае күп еллар рус арасында байларга ялланып эшләп йөргән, имеш. Үсеп, буйга җиткәч, моңа күзе төшкән маржа кызын вәгъдә итеп, чукынырга үгетли башлаганнар. Егет риза булган. Ни гомер рус арасында йөреп, бисмилла әйткәнем дә юк, миндә барыбер иман әсәре калмагандыр инде, дигән дә чукынган бу. Чукынуы булган, авызыннан ак күгәрчен сыйфатында иманы чыгып та киткән ди. Шуннан соң зарый-зарый елаган ди дә бит мескен егет, эш үткән булган шул инде.

— Утыр!— диде мулла, кырыс кына.— Җебегән! Шулай сугалармыни? Менә ничек кирәк!— диде дә, чалт итеп, Әхмәтзакирның яңагына ялтыратып алды.— Бу сиңа атаңның абруен төшергән өчен, ахмак!— дип куйды ул аңа.— Утыр, Хөсәен! Утырыгыз сез дә! Карагыз аны, моннан түбән болай укымый киләсе булмагыз!..

Дәрес сәгатьләре үтеп, урамга чыккач, башка акыл керде: «Эх,— дип уйлыйм эчтән генә,— шунда бит әйтәсе калган мулла абзыйга, алла гафу итүчеләрне сөядер, дигән бит Мөхәммәт галиәссәләм, гафу итик бу малайларны, диясем калган. Мөгаен, ачуы басылган булыр иде». Соңыннан килде шул бу акыл. Гомер буема котыла алмадым шушы кимчелектән, валлаһи! Була җыелышлар, бәхәсле мәсьәләләр буенча чыгышлар ясыйм. Ә иң кирәкле сүзләрем соңыннан исемә төшә. Була очрашулар. Кайвакыт мәкерле сораулар бирәләр. Җавапсыз да калмыйсың. Шулай да җавапның иң шәбе, тапкыры соңыннан күңелгә килә, эш үткәч. Татар акылы төштән соң дигәннәре шул, күрәсең, инде...

Хәер, кем белә? Бәлки шушы кимчелегем каләмгә тотынуыма сәбәп булгандыр. Нигә? Әйтик, башында үзеңчә кызыклы гына фикерләр туа яки кешеләр сөйләшкәнне тыңлаганда күңелеңә әһәмиятле уйлар, тәкъдимнәр килә. Сүзгә катнашырга, башыңда, күңелеңдә булганнарны кешеләр белән уртаклашырга кирәк икәнлеген дә сизәсең. Ә менә нәкъ үзең теләгәнчә итеп әйтеп бирергә нәрсәдер җитми. Кыюсызлык дигәнен җиңеп, сөйләргә батырчылык итсәң дә, соңыннан, әйтәсе килгән сүзләреңнең яртысы әйтелми калганлыгын күреп, үкенәсең, үрсәләнәсең. Берни эшләр хәлең юк. Ә язу — башка эш. Монда синең авызыңа карап тормыйлар. Кирәкле сүзне тапканчы, хет сәгатьләр буе уйлап утыр. Иң шәп сүз соңыннан исеңә төшә икән, бик әйбәт, язганыңа кире кайтып өсти аласың...

Ә теге көнне...

Ул көнне миңа дәресләр беткәч тә бик күңелсез булды. Сабакташларым каршында үземне гаепле хис иттем. Хәтта кичен Герман тавына да бармадым...

— Герман тавы?

— Мещан очы?..

Беләм, бу битләрне укыгач, күп кенә иптәшләрдә, мөгаен, башка сораулар да тугандыр. Әйтик, ул нинди школа? Татар авылында? «Яңа мөселман» дигәнең кемнәр?

Хикмәт тә шунда шул. Җиргән гадәти генә түгел, гаҗәп кызыклы авыл булган икән ул. Вакытында мин шундый авылда яшәүнең кадерен белмәгәнмен, аның кызыклы кешеләрен, катлаулы тарихын өйрәнүгә әһәмият бирмәгәнмен. Шулай да аның үзенчәлекләре турында миңа бу китабымда кайта-кайта сөйләргә туры килер әле. Хәзергә артык җәелмичә, шуларын гына әйтим: ул бик зур авыл. Анда дүрт төрле халык яши: руслар, татарлар, чувашлар, мордвалар (без аларны мукшылар дип йөртәбез). Татарлар үзләренә, чувашлар үзләренә аерым урам-урам булып яшиләр. Ә руслар белән мукшылар — аралаш. Якынрак белеш яки, Җиргәнчә әйтсәк, знаком булмаса, без аларның кайсы мукшы, кайсы рус икәнен аермыйбыз да. Чөнки мукшылар күбесенчә үзара да русча сөйләшәләр. Бары да диярлек татарчаны да белә. Тик аны бик үзләренчә итеп, үзгәртеп сөйлиләр. «Кая киттең?» дип сорыйсы урында, «Кая киткән?» диләр. «Кая бардың?» урынына — «Кая барган?» Татарлар да төзәтеп тормый, аларга яраклашып, «Урманга киткән», «Базарга барган» дип җавап кайтара. Сорау бирергә туры килсә дә, аларга җиңелрәк аңлашылсын өчен, үзләренчәләштереп сорыйлар: «Нихәл, Кужма ләләй, синеке картаймаган? Авырмаган?»

(Янәсе: нихәл, Кужма агай, бик картаймыйсыңмы әле, чирләмисеңме?) Һәм үзара бик яхшы аңлашалар.

Чувашлар турында әйтәсе дә түгел: һәр чуваш үз теле өстенә чатылдатып русча да сөйли, татарчаны да үз ана теле дәрәҗәсендә диярлек белә. Хәтта үзара сөйләшкәндә дә татарча гына сөйләшеп йөрүчеләре бар. Андыйларын яңа мөселман дип йөртәләр. Христиан диненнән ислам диненә күчкән чувашлар. Өлкәннәрнең әйтүенә караганда, ул хәл бик үк борынгы заманда да булмаган. Безнең әти-әниләр яшь чакта (ягъни үткән гасыр азакларында) алтмышар-җитмешәр яшьтәге чувашлар, ислам динен кабул итеп, үзләрен-үзләре сөннәткә бирә торган булганнар. Шундыйларның берсе Фазулла Хаҗи дигән кеше. Үтә диндар кеше булган, Мәккә чаклы Мәккәгә барып, хаҗ кылып кайткан зур бай иде ул, заманына күрә зур кирпеч заводы хуҗасы иде.

Телләренә килсәк, чувашчаны онытмаган булсалар да, үзара татарча гына сөйләшәләр иде. Ләкин ярылып яткан чуваш акценты белән. Ягъни безнең телнең үзенә генә хас булган «кы», «гы» «ң», «һ» авазларын тиешенчә әйтеп җиткерә алмыйлар иде. Хәер, тиешенчә үк әйтеп җиткерергә тырышмаганнардыр да инде, бәлки кирәк тә тапмаганнардыр. Ни өчен дисәң, болай да бик яхшы аңлашып була. Өстәвенә Җиргәндә яши торган татарларның үз араларында да урам яки тыкрык саен диярлек бер шивә. Хәтта янәшә күрше булган ике йортта ике төрле сөйләүче гаиләләр дә бар.

Җиргәннең руслары, мукшылары булсын, чувашлары, татарлары булсын, кайчандыр үткән гасырларда төрле яклардан җыелган кешеләр. Без бала чакта ук инде бабай булган кешеләрнең әйтүенә караганда, кайчандыр Самар губернасыннан кырык йорт мукшы килгән Җиргәнгә, Сембер губернасыннан егермеләп йорт чуваш, Казан ягыннан егерме биш гаилә татар килеп урнашкан.

Бу кадәресенең дөреслегендә шигем юк. Әле мин белгәндә дә бер кешене Казан Якуп дип йөртәләр иде. Йортлары безнең абзыйларга каршы урам аша гына. Башка бер кешедә диярлек булмаганча, өй артларындагы бакчада алма үстерәләр иде. Җиргән җиренең сөрмә кебек кара туфрагы, бөртекле ашлык яки яшелчә өчен уңдырышлы булса да, җимеш агачлары үстерергә бик үк кулай булмаган, күрәсең, алмалары, Идел яки Кама буе авылларындагы кебек, күкрәп утырмый, җимешләре сирәк була, булган кадәресе дә эреләнер-эреләнмәс, пешәр-пешмәс бала-чага кулына кереп бетә торган иде. Миннан бер генә яшькә олырак малайлары бар иде, Габделхәй исемле. Суыр баласы дип кушамат тактылар. Чөнки ул һәр вакыт тавыш-тынсыз гына капка төбенә чыгып баса да, урамда берәр кеше күренсә, ялт кире кереп китә, күренгән кеше үтеп киткәч, яңадан чыгып баса торган иде. Шулай да тора-бара мин ул малай белән таныштым. Хәтта бервакыт якын дуслар булып киттек. Җәй көне иртән мин әле йокыдан тормаган булам. Ул безнең капка төбенә килә дә сак кына тавыш белән «Мирсәйө-өф!» дип кычкыра. Сүзе дә аңлашылмый, «Йө-өү...» дигән авазы гына ишетелә. Шулай да мин сикереп торам. Рәтләп ашау-эчү юк, кулга бер телем ипи тотам да урамга чыгам. Икәүләп Агыйдел буена төшеп китәбез.

Габделхәй үскән саен кыюлана, батырлана барды. Ярышып таш аткан чакларда иң ерак ыргытучы ул була, бер генә малай да аткан ташын Биргиделнең[1] аргы як ярына төшерә алмый, ә Габделхәй төшерә иде. Тора-бара хәтта ул бераз усалланып та китте. Куркып үткәргән көннәренең үчен кайтарырга теләгәндәй, яшьтәш малайларын җәберли, кыерсыта башлады. Кызыклы гына бер шуклыгы да исемдә калган.

[1] Ни өчен Биргидел? — алдарак аңлатылыр.

Беркөнне шулай һич уйламаган-көтмәгән җирдән ул мине сыйларга кереште.

— Әйдә кибеттән прәннек алып ашыйбыз!— ди миңа.

— Ә акча?

— Кичә миңа әни ун тин биргәние, менә!

Карыйм, чынлап та кулында акча. Бер тиен генә дә түгел, ун тиен көмеш! Безнең яшьтәге малайлар кулына гомердә эләкми торган ак акча. Менә нинди юмарт икән аның әнисе!.. Шунда ук кибеткә очтык. Түбәтәй тутырып прәннек бирделәр, аның янына шактый гына чикләвек белән конфет та өстәлде. Бик тиз очына чыктык без бу сыйларның. Шундый тәмле булып калды, әйтерлек кенә дә түгел. Телләребезне теш араларында йөртеп, авызда калган прәннек валчыкларын йотабыз.

— Эх,— мин әйтәм,— тагы әзрәк булса!

— Туктале,— ди Габделхәй,— әни миңа үткән атнаны да биргән иде, югалмаган булса...— Бармагы белән күнчек төбендә казынып, китереп тә чыгарды.— Менә, таптым!

Карыйм, тагын ун тиен көмеш! Тегенең артык исе китмәгән була. Ә мин шатлыктан үрле-кырлы сикерәм... Икенче кат түбәтәй тутырып алган тәмле сыйларыбызны ашап бетерергә өлгермәдек, безне әни эзләп тапты. «Мәсәлим малае белән Казан Якуп улы уңга-сулга акча сибеп, типтереп йөриләр, кем аларга шундый юмартлык күрсәткән?»— дип ишеттереп тә өлгергәннәр икән. Мин Габделхәй әнисенең юмартлыгы турында аңлатып та бетерә алмадым, Шәрифәттәй үзе килеп житте. Мәсьәлә шунда ук ачылды: Габделхәй минем әнинең мич куышына акча куеп торганын күреп калган да шуны чәлдергән икән. Унар тиенлек ике көмеш тәңкә! Моның өчен малайга өендә ни күрсәткәннәрдер, белмим. Казан Якупныкылар мондый мәсьәләдә бик кырыс намуслы кешеләр иде, һәрхәлдә, җәзасыз калдырмаганнардыр. Әмма шунысын хәзергә кадәр оныта алмыйм: бу вакыйга уңае белән бөтен күрше-күлән шау-гөр килде. Кеше әйберенә тияргә ярамау турында үгетләүләр, әрләүләр, гыйбрәт итеп сөйләүләр, мыскыл итеп көлүләр җәй буена сузылгандыр...

Әнә шулай тәрбияләүләр иде безне. Бала-чаганың кырын эшен күргән кеше аны игътибарсыз калдырмый, мотлак ата-анасына житкерә иде. Алай гына да түгел, урамдамы, базардамы, Идел буендамы күренгән балага һәр ир кеше үзен ата, һәр хатын-кыз — ана хис итә, берәр ярамаган эш өстендә күрсә, баланы кисәтүне, хәтта кыланышына карап, колагын борып китүне үзенең бурычы саный һәм бернинди ата да, бернинди ана да үз баласына каты сүз әйткән я җәза биргән өчен аны гаепле санамый, аңа ачуланмый иде.

Бала тәрбияләү турында бернинди китап укыганнары юк иде безнең әти-әниләрнең, «Взрослым о детях» дигән тапшырулар да юк иде ул заманнарда. Шулай да мин белгән малайларның бер генәсе дә бозык юлга кереп китмәде.

Мин авылдан киткәннән соң Казан Габделхәй гади крестьян булып үскән, авылдашлары белән бергә колхозга кергән, Ватан сугышы елларында ут эчендә илен саклаучылар сафында булган, аннан соң, Уфа — Оренбург юлы салынгач, Җиргән станциясенә кереп, гомеренең азагына кадәр тимер юл эшчесе булып эшләгән.

Бусы Казан Якупныкылар турында булды. Тагын бер кешене «Дәген Якуп» дип йөртәләр иде. Ни өчен андый кушамат?— аңламый идем. Әнидән сорап карадым.

— Аларның бабалары «дәген-дагын» дигән сүзләр кыстырып сөйли торган булган,— дип җавап бирде әни.

Ни өчен кыстырганнардыр ул «дәген-дагын»ны, барыбер аңламаган идем. Еллар үтеп, үсеп буйга житеп, Казанга килгәч аңладым. Редакция тирәсендә була башлаган беренче танышларымнан журналист

Фазыл Мобарәкшин — «Кызыл яшьләр» газетасының шул еллардагы редакторы — шулай «син дәген», «мин дәген», «ул дагын» дип сөйли торган кеше булып чыкты. Татарстанда шулай сөйләшә торган аерым кешеләр генә түгел, авыллар, кантоннар бар, имеш. Димәк, безнең авылдагы «Дәген Якуп» нәселе дә кайчандыр шушы яклардан килеп чыккан булган.

Тел үзенчәлекләренә карап, авылыбызның тарихи тамырларын күзәтү шушы көнгә кадәр дәвам итә. Мәсәлән, «Чәч тә баш китереп» дигән гыйбарәне мин безнең авылга гына хас сүз дип йөри идем. Баш белән чәч кебек икесе бер бөтен тәшкил итә торган әйберләрне яки бер гаилә булып яшәргә тиешле кешеләрне бер-берсеннән аерып, таратып, туздырып бетерүне аңлата торган бу сурәтләү чарасын, кабиләчелек булыр дип шикләнеп, үз әсәрләремне язганда кулланмый килгәнмен. Көтмәгәндә бу сүзне Гомәр Бәшировның «Намус» романында очраткач, зур бер ачыш ясаган шикелле куандым.

Тагын күптән түгел генә Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» повестен укыганда «сайбата» дигән сүзгә тап килеп, шулай булдым. Минем ул сүзне үзебезнең авылдан башка беркайда да ишеткәнем, әдәбиятта да очратканым юк иде. Хәтта Стәрлетамакта чагымда иптәшләр арасында шундый сүз ычкындыргач, миннән көлгәннәр иде: янәсе, нинди мәгънәсез сүз ул! Шуннан соң мин аны, акылга саерак кешегә карата әйтелә торган бу мәгънәле сүзне, язганда түгел, сөйләгәндә дә кулланмый идем. Баксаң, безгә кайчандыр Казан губернасыннан, Арча, Тәкәнеш якларыннан иярәп килгән сүзләр икән алар. Димәк, без әдәби телебезнең сүз хәзинәсен баету эшендә кыюсызлык күрсәтеп киләбез. Бу мәсьәләдә кайчак әдәби тәнкыйтебез дә чикләнгәнлек күрсәтә. Тегe яки бу әсәрне укыганда тәнкыйтьче үзенә аңлашылмый торган берәр сүз очратса, сагая кала. Аны сүзлектән эзләп, анда да очратмаса, кабиләчелек дип бәяләргә, язучыны әдәби телне чүпләүдә гаепләргә ашыга. Халкыбызның иксез-чиксез тел хәзинәсендә, үзенчә, мәгънәле дип, әһәмиятле дип тапкан берәр сүз яки гыйбарә очратасың икән, күпчелек укучы белми торган булса да, әдәби телгә сыймый дип, куркып торма, куллан. Уңышлы булса, укучы аны бик тиз кабул итәр һәм ул әдәби тел бакчасында тамырланыр, чәчәк атыр. Уңышсыз булса, анда да әллә ни куркыныч юк, тавыш-тынсыз гына корыр, төшеп калыр. Аңа карап бакчабызга әллә ни зыян килмәс.

Билгеле, безнең авылга Казан губернасыннан гына түгел, башка яклардан килүче татарлар да аз булмагандыр. Мишәрчә сөйләшүчеләр дә житәрлек иде бездә, типтәргә тартым телле кешеләр дә бар иде. Бөтенләй татарлашып киткән башкортлар да булган икән, ләкин сөйләшүләренә карап, без аларны татарга саный идек. Безнең нәсел кайсы якларга барып тоташадыр, кызганычка каршы, ачыклый алганым юк. Шунысын әйтә алам: әдәби китаплар укый башлагач, Галимҗан Ибраһимов телен мин, бернинди сәерлек күрмичә, нәкъ безнең үз өебез теле кебек кабул иттем. Шул ук вакытта Тукай теле дә миңа ят тоелмады. Дөрес, «галибанә», «игътикат», «мөмтаз» кебек аңлаешсыз яки, аңлашылса да, безнең авылдагыча әйтелмәгән «тугъры», «угыл», «булмыш», «иде» кебек сүзләр дә еш очрый иде аларда, ләкин мин аларны читсенмим, бары «китапча әйтелгән сүзләр» дип кенә кабул итә идем.

Соныннан белдем: безнең авыл телендә русчадан кереп татарлашып киткән сүзләр дә бик күп икән. Мәсәлән, лутче, хуже, срук, тәки, настоящий, прастуй, почин, и, сразы, сруды, знамо, тоже, нишу, пожалый, хыт, почти, нәчәлник кебек сүзләрнең руслар белән уртак икәнлекләрен мин үсә-үсә, укый-укый гына белдем. Болар әле искә төшкәннәре генә, махсус эзли башласаң, алар шактый жыела торгандыр. Чынлап та безнең авылда «фәкать»кә караганда тулько, «мәҗбүри яки мотлак»ка

караганда әбәзәтелне, «гади»гә караганда «прастуй», «мөддәт»кә караганда «срук», һичшиксез, татарчарак исәпләнә һәм яхшырак аңлашылалар да. Соңгы елларда гына Горький өлкәсендәге мишәр авылларында йөргәндә ул сүзләрнең бары да диярлек, нәкъ безнең авылдагыча, татар сүзе булып йөрүләрен күрү дә миңа кызык һәм мәгънәле тоелды. Үз авылым турында язганда мондый сүзләрне «курыкмыйчарак» кулланган урыннар очраса, укучыларым ачуланмас дип беләм...

Чувашлар белән мукшылар турында, алар үз телләре өстенә русчаны да, татарчаны да яхшы беләләр, дигән идек. Бу мәсьәләдә татарлар ничек соң?

Хәзергесен әйтмим, мәгәр ул заманда, кагыйдә буларак, ягъни миңа таныш булган бер-ике тимерче малайларын исәпкә алмаганда, мукшы телен дә, чуваш телен дә белмиләр, ә русчаны ирләр бары да диярлек сукалый иде.

«Сукалый» дип мин хәзер әйтәм. Ә ул заманда мин аларны русча бик шәп сөйлиләр дип белә идем. Мәсәлән, этинең руслар белән очрашканда бер дә сүзгә аптырап тормавын күреп, соклана һәм горурлана идем. Их! Мин дә үскәч шулай сөйләшә белермен микән?.. Хәтта этинең русча әйткән бер җөмләсе гомергә онытылмас булып хәтеремдә калган. Арбага утырып, печәне җыеп алынган болын юлыннан узып бара идек. Дуңгыз көтүе очрады. Каты борыннар, мыркылдый-мыркылдый, болынны сөреп йөри. Эти юл буенда басып торган көтүчегә каты гына тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Сматри как луга пуртиш! — һәм, ачуын басарга теләгәндәй, үз атыбызга чыбыркысы белән кизәнде.

Көтүченең дә ачуы килде, ахрысы, этигә җавап бирүен бирмәде, әмма гамьсез генә җир сөреп йөргән бер дуңгызга озын чыбыркысы белән зәһәр генә сыдырып алды. Көтү яныннан узып киткәч, этидән сорадым:

— «Сматри как луга пуртиш» нәрсә дигән сүз?

— Күзең чыкканмыни, кара, чабынны боздырасың бит, дип әйттем мин аңа,— дип аңлатып бирде эти.

Еллар үткәч, инде үзем рус теленең серләренә бераз төшенә башлагач, аңладым: русчаны бик шәп белә дип йөргән кешеләрем дә «сукалаганнар» гына икән. Шулай да руслар белән сөйләшергә туры килгәндә берсе дә диярлек аптырап тормый иде алар. Хәтта русчаны бөтенләй белмәүчеләрдән көләләр, алар турында төрле мәзәкләр чыгаралар иде [1].

Хатын-кызлар белән балалар исә, Җиргәндә яшәсәләр дә, русчаны бөтенләй белмиләр иде. Үз авылыбыздан чыгасы булмаганга, ирләр шикелле Мәләвез яки Стәрлетамак, Уфа яки Оренбург базарларына барып йөрмәгәнгә, алар өчен русча белүнең, күрәсең, кирәге дә булмагандыр. Чынлап та, чувашлар белән мукшылар гына түгел, Җиргәннең русларына кадәр татарчаны белгәч, нигә аларга «кафер теле»? Һәрхәлдә, татарларның тел мәсьәләсендә башка авылдашларыннан болай «артта» калулары аларның мокытлыгыннан килгән хәл түгелдер дип беләм...

Башка халыклар белән чагыштырганда сан ягыннан күпчелек булмасалар да, Җиргән татарлары үзләренең мөстәкыйльлекләрен бик нык саклап килгәннәр. Хәтта әнә башкалар алар белән ныграк хисаплашырга тиеш булган: аларча сөйләшергә өйрәнгәннәр. Моның, әлбәттә, социаль сәбәпләре бар.

---

[1] Шул вакытта ишеткән мәзәкләрдән файдаланып, «Русча хат» дигән хикәя дә язганым бар.

Беренчедән, шактый зур байлар күп булган бездә. Татарның миллионерларыннан берсе, Уралдагы алтын прискалары хуҗасы Закир Рәмиев (ул ук татар әдәбиятының классиклары җөмләсенә кергән күренекле шагыйрь Дәрдмәнд) шушы Җиргән авылында туган. Дөрес, аларның гаиләсе Закир бала чагында ук авылдан киткән. Һәрхәлдә, шундый данлыклы кеше Җиргәнгә фәкать туар өчен генә килмәгәндер. Болай да байлар җитәрлек иде Җиргән татарлары арасында. Тире-яры белән сәүдә итүчеләр, көтү-көтү аяклы мал куучылар, итчеләр, агач товар сатучы, өй бурасы ясатучылар. Болары инде гади сатучы гына түгел, үзләренә күрә предприятие хуҗалары, промышленниклар...

«Биргидел» дигәнебезне дә шуларга бәйләп аңлату уңайрак булыр. Агыйделнең төп үзәне безнең авылдан бер километр чамасы көнчыгыштанрак — Җиргәнтау буйлап уза. Анысын Аргыйдел дип йөрибез. Аңардан аерылып чыккан тармак Җиргәннең янында ук, хәтта түбәнгәрәк урамнардагы йортларның каралты-куралары кагылып ага. Монысы Биргидел дип йөртелә. Ул элек бик кечкенә булган. Язгы ташкын вакытларында гына бер дулап алган да, җәйләрен бик бәләкәй инеш кенә булып ага, корырак елларда төп үзәннән бөтенләй аерылып та кала торган булган. Өстәвенә, зур Иделдән аерылган җирендә кирегә борылып, кирәкмәгән җирләрдән урап, кәкре булып аккан. Югарыдан, Нөгеш якларыннан сал кайтартучы агач байларына бу ошамаган. Биргиделне үзләренә хезмәт иттерү өчен, табигать иҗат иткән елга тармагы белән генә канәгатьләнмичә, югарыданрак канал казытып, турыга Яңа ерым ачканнар. Нәтиҗәдә Биргидел зурайган, саллар авылның янына ук килә башлаганнар. Саллар килеп туктый торган урын пристань дип йөртелә иде. Пристаньда яңа гына өеп куелган бик күп өй буралары була, без, малайлар, анда йомычка җыярга йөри идек.

Биргидел киң күңелле булып чыкты. Ул агач байларына хезмәт итеп кенә калмады, авылның, бигрәк тә бала-чага белән яшьләрнең һәм хатын-кызларның, иң яраткан урыны булып әверелде. Бала-чагага су керү, балык тоту, каз көтү өчен шуннан да кулай, шуннан да ямьле урын бар идеме икән дөньяда? — шулай тоела иде безгә. Хатын-кызлар шунда кер чайкарга төшәләр, сагыз кайнаталар, су коеналар, комда ауныйлар.

Агыйдел буйлары ямьле самавар агартырга.
Аналардан туган матур йөземне саргайтырга...

Бу җырны, һичшиксез, Җиргән кызлары чыгарганнардыр кебек тоела миңа. Шулай ук:

Агыйделдә ак балык, без үзебез вак халык.
Без үзебез вак булсак та, хәйран кала күп халык! —

дигән җырны да Җиргән татарлары чыгарганнардыр кебек... Аларга хас булган күркәм тыйнаклык та, беркатлы горурлык та бик әйбәт әйтеп бирелгән бу гади җырда. Шул ук вакытта аңардан безнең авыл кешеләре өчен бигрәк тә характерлы булган җорлык, шаянлык рухы да аңкып тора. Әйе, бар иде безнең авыл кешеләре арасында күкрәк сугып горурланырга яратучылар. Ни белән генә мактанмыйлар иде бездә? Кем нинди яктан үзен өстен саный? Берәүләр сабан туйларында көрәшерлек гайрәте я икешәр потлы герне йон туп урынына чөеп уйнатырлык куәте белән масая, икенче берәүләр нинди дә булса һөнәре белән... Аты белән мактанучылар кирәкме, эте беләнме — атап саный китсәң, очына чыгасы түгел. Хәтта хатынының юанлыгы белән мактанучылар да бар иде бездә. Бабалары белән булмаса, балалары белән,

гомумән нәсел-нәсәп белән, байлык белән мактанучылар турында әйтәсе дә түгел...

Мактану, әлбәттә, бер караганда әйбәт гадәт саналмый. Шулай да минем ул гөнаһсыз сыйфатны байларга гына биреп бетерәсем килми. Байлыклары белән масаючылар булган кебек, байлыкка төкереп каравы, «ач тамагы — тыныч колагы» белән үзен өстен санаучылар да күп иде бездә.

Байлык — ярлылык?

Бай — ярлы?

Октябрь безгә аларның килешү белмәс ике сыйныф икәнен аңлатты. Аның шулай икәнлеген күп гасырлар буенча тормыш үзе дә күрсәтеп килгән иде инде. Шулай да ул ике сыйныфны бер-берсеннән аеруның, ягъни сыйнфый көрәшнең никадәр катлаулы, никадәр четерекле мәсьәлә икәнен тиешенчә күз алдына китерү өчен күпме юллар үтәргә туры килде. Дөнья күләмендә әле дә бөтен кискенлеге белән дәвам иткән, безнең илне дә (ягъни антагонистик сыйныфларга инде чик куйган Советлар Союзын да) тыныч калдырырга теләмәгән ул аяусыз көрәшнең серләренә бүген дә кирәгенчә төшенеп бетү җиңел түгел безгә. Ә теге елларда?!.

Байлар да җитәрлек иде безнең авылда, ярлылар да. Ярлы белән бай арасын тоташтырып торган урта хәлле хуҗалыклар, «югарыга карап фикер йөртә, түбәнгә карап шөкер итә» торган кешеләр катлавы барыннан да күбрәк иде. Һәм ул катлаулар һәртөрле туган-тумачалык, кода-кодачалык, уртак иман, дини әдәп, милли гадәт җепләре белән бер-берсенә шул кадәр нык һәм чуалчык итеп бәйләнеп беткәннәр, аларны аерып алу да мөмкин түгел кебек иде. Соңрак, большевик ораторларның сәяси нотыкларын ишетә яки эчтәлеге сыйнфый көрәш вакыйгаларына нигезләнгән әдәби китапларны укыштыра башлагач, байларның, руханиларның явыз кара көч икәнлекләре, яхшы кешеләрнең хезмәт халкы сафында булулары бик ачык күренә башлады безгә. Тик алар үзебезнең авылдагы мин белгән кешеләр турында түгел кебек тоела иде миңа. Чынлап та, син үзең ярлы гаиләдән булып та, бай дигәнең, сатучы яки мулла-мәзин дигәнең син көн саен күреп, сәлам биреп үтә торган яхшы күршең булса? Алай гына да түгел, ул сиңа хәтта әтиең яки әниең ягыннан әзрәк туган тиеш тә кеше булса?.. Яки син аның малайлары белән бергә укысаң, аларга карата берниндн дошманлык хис итмичә, бергә уйнап, бергә тау шуып, бер үк Иделдә су коенып та йөрсәң? Ишегалларына кергән чакларда әниләре сиңа, үз малайлары белән беррәттән, берәр пәрәмәч тә тоттырса? Хәтта кайвакыт, артык миһербаны килеп, малаеның юньләп ямау да күрмәгән өр-яңа иске бишмәтен берәр фәкыйрь балага бүләк итү кадәр юмартлык күрсәтсә?.. Ничек инде андый кешене ярлы халыкның явыз дошманы дип уйлыйсың! Бай булса ни! Нигә бай булмасын, ходай бәхет биргәч? Баерга кем теләмәс? Бай авызыннан чыккан сүзгә кем колак салмас икән? Дөрес, тәүфыйксызлар, начар, усал кешеләр күп инде ул байлар арасында. Алай дисәң, фәкыйрьләрдән юкмыни тәүфыйксызлар? Монда эш байлыкта яки ярлылыкта түгел, алла эше дип карый идек без ул чакта. Ходай кешенең холкын нинди итеп яраткан бит, дип уйлый идек.

Ходай?

Байлыкка табыну хисен уятучы төп сәбәп — ярлылык, җитешсезлек үзе булса, аны байларга хөрмәт хисенә әверелдерүдә ислам дине һәм аның руханилары зур урын тоткан. Безнең авылда исә дин дә бик нык тамыр җәйгән иде. Яңа мөселманнарны кушып исәпләгәндә, авылыбызда өч мәхәллә, ягъни өч мәчет булса, мулла-мәзиннәр саны, указлы-

указсызлары белән бергә, дистәдән арта иде. Ул мәчетләр тирәсенә тупланган мөтәвәллиләр, биш вакыт намазның берсен калдырмый үтәп баручы мәчет картлары, суфилар... Безнең эти-әниләргә яшь чакларында ижек укытып башларын әйләндергән бохарый хәлфә бар иде әле. Шулар өстенә тагын ишан хәзрәт!

Атаклы Сәхиулла ишан булган Җиргәндә. Әни сөйләве буенча хәтерлим: җеназасына әйләнә-тирәдәге барлык авыллар җыелган. Изге мәетне көрәк белән түгел, кул белән күмгәннәр. Янәсе, саваплы эштән бер генә кеше дә мәхрүм калырлык булмасын... Заманында аның тарихына багышлап, махсус китап та чыгарылган.

Минем өчен иң кызыгы шул булды, китапның азагы мондый юллар белән тәмамлана иде:

Үлгән хәзрәттән калса кәрәк бер хәләф,
Ая дәрвиш хезмәтендә улма хилаф,
Мөрит ара мактанышып ормаек лаф,
Хвалиться не годится дирләр имди.

Бусы нәкъ Җиргәнчә килеп чыккан. Баштан ахырынача гарәп һәм фарсы сүзләре белән тулы китапка русча гыйбарә килеп кергәе аны ничектер җанландырып, җир тормышына якынайтып җибәрә. Шуның белән бергә бу юллар аша мөритләр арасында мәрхүм ишанның хәләфенә, ягъни аның урынына калган улы Әхмәдуллага ышанычсыз карауучылар, аның нәрсәсе бездән — гади бәндәләрдән артык соң дип «лаф оручылар» да булганлыгы аңлашыла.

Шулай булуы гаҗәп тә түгел. Әхмәдулла ишан мин белгәндә яшәгән кеше. Фанатик мөритләре каршында гына түгел, гади алла колы булган бик күпләр карамагында да ул изге иде әле. Мин аның үзен түгел, бары җеназасын гына күреп кала алдым. Ә өйләрен беләм, еш кына алар яныннан үтеп йөри идем. Рәшәткә коймасы урамга чыккан искиткеч матур бакча эчендә утырган гүзәл зәңгәр йортның мине аеруча хәйран калдырган җире — тәрәзәләре иде. Зур, биек рамны бүлеп-нитеп тормыйча, бер генә өлге итеп куелган тоташ пыяла. Кайдан тапканнар диген! Шундый хәтәр өлге ничек ватылмый тора диген!.. Ул серле йортның эч ягында нинләр эшләнгәне турында соңыннан ишетеп белгәннәремне хәзер тәфсилләп язып тору яңалык булмас иде.

Шулай да ишанның яшь хатыны Сабира абыстай искә төшкән чакларда мине уйландыра. Ярлы башкорт гаиләсендә туып-үскән матур, мәһабәт сынлы, әлифне таяк дип белмәс дәрәҗәдә надан булса да, искиткеч зирәк акыллы, тапкыр һәм откыр кыз баланың ишанлык-мөритлек шартларында үзендә булган эчке көчләрне яхшы эшкә юнәлдерергә зәмин тапмыйча, ничек итеп ялган вәкарьле абыстайга әйләнеп китүен, бер үк вакытта гади кешеләрнең уена да килмәс дәрәҗәдә азгын, бозык тормыш алып баруын гәүдәләндергән катлаулы, үзенчәлекле бер әдәби образга прототип була алыр иде Сабира абыстай. Аның үз авызыннан чыккан бер генә сүзе дә ни тора!

— Җиргәндә адәм рәтле ирләрдән мин башын әйләндерә алмаган бер Нурулла мулла гына калды,— дигән ул.

Билгеле, монда бер дәрәҗәдә арттырып әйтү дә бардыр. Абыстай күзлегеннән «адәм рәтле» күренгән ирләр җөмләсенә, әлбәттә, ишан йорты белән кунакка йөрешерлек дәрәҗәдә бай кешеләр яки гыйлем әһелләре керә торгандыр. Шулай да аның бу сүзләре Нурулла мулланы тасвирлау өчен бик характерлы.

Нурулла мулла Җиргән руханилары арасында заманына күрә алдынгы фикерле кеше булуы белән аерыла иде. Җиргәндә дөнья гыйлемен укытуга нигезләнгән җәдит мәктәбе аның тырышлыгы белән барлыкка килгән. Аның ук инициативасы белән кызлар мәктәбе ачыла.

Шушы мәктәпләр җирлегендә авылыбызда яңа фикерле мөгаллим-мөгаллимәләр, мәгърифәткә омтылучы яшьләр пәйда булган.

Бу адымнар исә, ул заманда мулла булган кешедән алдынгы фикерле булу өстенә, батырлык, фидакарьлек, тәвәккәллек тә сораган. Мәсәлән, Нурулла мулла кайтарткан беренче укытучыны — Исхак хәлфәне, балаларга җәгърафия гыйлеме укыткан өчен, ягъни Җирне шар кебек дип, «көфер» сөйләгәне өчен, авыл кешеләре тотып кыйнаган. Яңа янаулардан куркып, Исхак хәлфә безнең авылдан китәргә мәҗбүр булган. Ә мәктәп калган. Исхак шикелле үк Җирне түгәрәк дип өйрәтүче яңа укытучы кайтартырга кирәк булган. Бу мәсьәләдә халык белән уртак тел табу ул заманда яңа фикерле мулладан башка, ай-һай, мөмкин булыр иде микән?

1915—16 нчы еллар арасында шул ук Нурулла мулла авылыбызга учитель кайтартып, татар балалары өчен русча укыту мәктәбе ачты. Безнеңише, русча укырга кызыгып та, иманына зәгыйфьлек килүдән куркып, рус школасына барырга җөрьәт итә алмый йөргән малайлар өчен бу бик шәп булып чыкты. Иске фикерле муллалар, артык тәкъвә булып киткән мәчет картлары һәм авылга үзләрен хуҗа хис итүче кара байлар җәдит мулланың бу эшенә тиз генә фәтва бирергә ашыкмаганнар. Ниһаять, балаларын русча укытырга теләүче ата-аналар авылның төрле катлау кешеләре арасында да барлыгын искә алып, әмма ләкин балаларның күңеле каралып китмәсен өчен, рус сабагын укырга керешүдән элек, аларга һәр көн иртән бер-ике сәгать дин дәресе укыту шарты белән ризалык биргәннәр.

Дин дәресен бу эштә инде күп тәҗрибәсе булган Гатаулла хәлфә укыта иде. Һәр вакыт чиста һәм җыйнак итеп төзәтелгән чем-кара сакал-мыеклы, алсу-ак чырайлы, зифа буена килешеп торган ап-ак чалмалы, яхшы киемле бу кеше башта безгә ягымлы күренде. Ләкин аңа карата уянган хөрмәт тойгысы бик тиз арада куркуга әверелгән иде.

Шуның дәресендә инде мин, белдекле булып, иптәшләрем каршында уңайсыз хәлдә калдым. Без ул вакытта «Йөз дә бер хәдис» дигән китапны үтәбез, ягъни Мөхәммәт галиәссәләмнең йөз дә бер хикмәтле сүзен эченә алган гарәпчә китапны укып, ул сүзләрнең безнеңчә нинди мәгънә аңлатуын өйрәнә идек. Татарчага күчергәч, аларның күбесе пәйгамбәр сүзе дә түгел, гади халык мәкале кебек яңгырый, араларында бик мәгънәлеләре дә килеп чыга, тормыш өчен кирәкле акыллы киңәшләр дә очрый һәм минем өчен алар хәтердә калдырырга да җиңел тоела иде. Әлеге дәрестә исә, хәлфәбезнең педагогик таланты шундый булгангадыр инде, сабагымны белүем шатлыкка булмады. Рус теле дәресендә дә күңелем күтәрелмәде.

Рус теле укытучыбыз Стәрлетамактан килгән бер татар иде. Без аңардан русча язарга өйрәндек, укырга өйрәндек. «Жил-был у бабушки серенький козлик», «Встань поутру, не ленись!», «Что ты спишь, мужичок?», «Письмецо от внука получил Федот», «Буря мглою небо кроет...» кебек шигырьләрне ятладык. Ләкин рус телен белү дәрәҗәбез бик чамалы булып чыкты: дөрес итеп сөйләшергә яки язарга түгел, кеше сөйләгәнне яки русча китапларда язганны тиешенчә аңларга да җитми иде.

Бу кадәресе өчен, әлбәттә, укытучыбызны гаеплисем килми. Рус теле, гомумән, аны сабый чактан ук авыз итмәгән кешегә җиңел генә бирелми торган катлаулы телдер, күрәсең. Ихтимал, үземдә дә гаеп бардыр: беренче мәктәптән соң гомер буена өйрәнеп тә, мин аны бөтен нечкәлекләре белән үзләштереп җиттем дип әйтә алмыйм әле.

Ә менә дөньяга караш һәм әдәби әсәрләрнең шигъри мәгънәсен аңлату ягыннан укытучыбыз үзебездән күп ерак китмәгән булгандыр, ахрысы. «Первая книга», «Вторая книга» дигән дәреслекләрдән ятлаган шигырьләрнең авторлары кемнәр булуын мин күп еллар үткәч кенә белдем һәм аларның нечкә эстетик мәгънәләрен дә бик соңга калып аңладым. Укытучыбыз белән бергәләп, бер хикәягә ничек «анализ» ясавыбызны мин әле дә елмаеп искә алам. «Богатый купец и бедный сапожник» дигән хикәя иде ул. Кыскача эчтәлеге: подвалда ярлы итекче тора, өске катта — бай сәүдәгәр. Төннәрен итекче җырлый-җырлый итек тегә, шакылдый, сәүдәгәргә йокларга бирми. Аптырагач, сәүдәгәр итекчегә мул гына итеп акча бирә һәм әйтә: төнлә эшләмә, йокла, ди. Ярлы бик шатланып, байга рәхмәт әйтеп, акчаны алып кала. Бер көн тавышы чыкмый моның, ике көн... Өченче көнне сәүдәгәр янына менә дә: «Мә акчаңны,— ди,— бушка килгән байлыкны саклап, йоклый алмый ятканчы, миңа тыныч күңелем белән җырлый-җырлый эшләп утыру күңеллерәк!»— дип, акчаны кире байга калдырып, подвалына төшеп китә...

Бергәләп тәрҗемә итә-итә хикәяне укып чыккач, учителебез сорый бездән:

— Поняли?

Хор белән җавап бирәбез:

— Поняли!

— Как по-вашему, сапожник правильно поступил?

Хор белән җавап кайтарабыз:

— Сапожник дурак был!

Укытучыбыз әллә үзе дә шулай уйлый, әллә, боларга барыбер төшендереп булмас дип шикләнә, безне раслап куя:

— Правильно.

## 2

### ӨЕБЕЗ. ПЫЧАК. САГЫЗ. ТАРАКАН ТАШЛАУ. ИШЕК АЛДЫБЫЗ. ӘТИ СУГЫШКА КИТКӘЧ.

Мәктәптән кайткач, төшке чәйне эчәм дә мәдрәсәгә йөгерәм. Анда мин дүртенчедә идем инде. Яшьтәшләремнән бер сыйныфка алда бара идем. Сәбәбе шуннан дип беләм: миңа кечкенәдән китап күрергә туры килде. Дөрес, бай түгел идек, хәтта ярлы идек. Ни дәрәҗәдә ярлы булганыбызны мин соңыннан, үсеп җитеп, инде кеше булып, адәм рәтле тормышның нинди икәнен үзем татып белә башлагач кына аңладым. Кечкенә чакта исә фәкыйрьлегебезне сизми дә идем шикелле. Нинди ризык эләксә — шуны, кайчан эләксә — шул вакытта, күпме эләксә — шул кадәр ашарга һәр вакыт йотлыгып әзер тору, ямаулы кием, искедән бозып тегелгән «яңа» бишмәткә дә очынып шатланулар миңа бик табигый хәл булып күренә иде. Тугыз аршинлы бүрәнәдән салынган өй. Аның дүрттән бер өлешен диярлек мич алып тора. Мич авызына каршы почмак, түшәм ягы ачык калдырып, такта белән генә бүленеп алынган. Ул як үзенә күрә аш өе, хәзергечә әйтсәк, кухня хезмәтен үти. Без аны «бүлмә» дип кенә йөртәбез.

— Әни кайда?

— Бүлмәдә.

— Пычак кайда?

— Бүлмәдә...

Пычак димәктән... «Кайсы пычак?» яки «нинди пычак?» дип сорау юк, әлбәттә. Чөнки ул бөтен өйгә берәү генә. Ипи кисәргә дә шул, бәрәңге әрчергә дә, ит турарга да, шикәр ватарга да, чыра телергә дә шул берәү. Чарлый-чарлый уртасы ашалып беткән нечкә билле, агач саплы каты пычак. Олылардан бушаган минутларда ул һаман минем кулда була — чырадан я юкагачтан ни дә булса ясап азапланам. Үземне белә башлаганнан бирле шулай. Иң яраткан уенчыгым — пычак иде. Иң татлы хыялым һәм иң зур теләгем — бәләкәй генә пәкегә тиенү иде. Теләгемә ирешкән чакларым да булмады түгел. Нинди дә булса берәр апа тиеш кызны кияүгә биргән чакларда җизни тиеш кешедән калай саплы кечкенә пәкеләр дә эләккәләде. Ләкин ни хикмәттер, пәке миндә бер көннән дә артык тормый югала иде. Пәри урлый иде аны. Әмма пәри урлаганчы шул бер көн эчендә дә кулымны өч-дүрт тапкыр кисәргә өлгерә иде. Нинди пәри урлаганын үзем эти кеше булгач, малаем да үзем кебек пәке ярата башлагач кына (ягъни, энисе белән үзем дә «пәри»гә әйләнгәч кенә) аңладым. Ә теге нечкә билле пычакка пәри тими, кайвакыт өйдә үзем генә калган чакларда яшергәләсә дә, эни кайту белән табыла иде. Шул пәри урламау аркасында ул пычак минем бармакларны канату белән генә тукталмады, үземне борынсыз калдыра язды. Яши башлау юлымда беренче булып исемдә калган вакыйга да шул булса кирәк. Өч-дүрт тирәсендә чагым булгандыр. Түр якта, ян тәрәзә төбендә әлеге пычак белән чапкалап, чырадан нәрсәдер ясарга маташып утырам. Бүлмәдән эни тавышы ишетелде: «Китер пычакны!» Сикереп тордым. Иң элек сәке буйлап бүлмә коймасына кадәр йөгердем. Аннары сәкегә ялгап мичкә таба сузып куелган сандык өстенә төштем, сандыктан сикергәндә ничектер җайсызрак басып, егылып киттем дә битем белән идәнгә капландым. Кулымдагы пычак сырты белән идәнгә, йөзе белән нәкъ минем борын өстенә туры килгән бит. Күпме кан коелганын, төзәлүе озаккамы барганын хәтерләмим. Мәгәр борыным сыртында кыйгачлап сузылган яра эзе әле дә бар. Ябыга төшкән чакларымда аеруча ачык беленә. Шундый истәлекле пычакны ничек онытмак кирәк!

— Түр як дигәнебез?

Анысын да без, «түр як» дип, тутырып әйтеп тормыйбыз, «түр» дип кенә йөртә идек. Түрнең дә түр өлешен аркылысы олы кеше сузылып ятарлык киңлектәге сәке били. Сәке өстенә эни үзе суккан чүпрәк палас җәелгән. Аның да түрендә буйдан-буйга тар гына итеп сырылган корама юрган сузылган. Анысын түр юрганы дип йөртәбез. Уң як почмакта — түшәк-ястык, төрлесе-төрле төстәге эреле-ваклы мендәрләр. Алар бик пөхтә итеп, һәркайсы кабара алган чаклы кабартылып, берсе өстенә берсе өелеп куелган. Бала-чага онытылып шаярганда ул өем ишелеп китсә, кунак килергә була. Шуңа күрә тиз генә кире җыелып, янадан матурлап куела. Ләкин киләсе кунак белми каламы, мендәр ишелгән саен килми.

Идән өлеше дә артык ямanlарлык түгел. Сул як стена буенда, бер башы белән сәкегә терәлеп, кечкенә өстәл тора. Өстәл өстендә—поднос. Подноста җиз самавар һәм берсе-берсенә охшамаган өч-дүрт пар чынаяк. Шул өстәл астына кереп, башымны эз генә дә имичә, иркенләп атлап йөргән чагымны хәтерлим. Бәлки хәтерләмәс тә идем, бервакыт өстәл читенә башым бәрелә башлады. Элегрәк бәрелми иде. Иелеп керә башладым. Нигә керәм? Сагыз эзләп. Бездә сагыз чәйнәү гадәте бар иде. Чәйнәп туйгач, һәркем үз сагызын авызыннан ала да, йомарлап, өстәл тактасына ас яктан ябыштырып куя. Олылар моны куллары белән үрелеп кенә эшли, ә миңа керергә туры килә. Өстәл тактасының ас ягы сыланып калган кара сагыз таплары белән катып, чуарланып беткән булуын мин генә күргәнмендер.

Сагыз чәйнәүне мин әле дә фәкыйрьлек билгесе дип тә, начар гадәт дип тә карамас идем. Ашаганнан соң кирәк кадәр генә чәйнәп алсаң, хәзерге кешеләргә дә зарар итмәс иде, дип уйлыйм. Бик рәхәт бит ул сагыз чәйнәү! Күңелне ачып җибәрә. Үзе тәмле. Бигрәк тә каен тузыннан кайнатылган кара сагыз. Бөтен тешләре тәмам өлгереп җиткән кызлар яки яшь киленнәр арасында аны аеруча килештереп, чыртлатып, авызыннан сулар китерерлек тәмле итеп чәйнәүчеләр була.

Тәмле, күңелле булу өстенә, файдалы да дип беләм мин сагызны. Тешләрне, яңак мускулларын ныгыта. Чамасын белеп, гигиена шартларын китереп файдаланганда (ягъни, тузанлы өстәл астына яки стенага ябыштырып сакламасаң, теләсә кем авызыннан алып капмасаң), аш сеңдерергә дә булыша. Безнең өйдә, мәсәлән, сару кайнаганнан иң яхшы дару — сагыз исәпләнә иде. Минемчә, халык андый гөнаһсыз гадәтләрне бер дә юкка гына уйлап чыгармый. Америкалыларның да резин сагыз чәйнәп йөрүләре наданлыктан яки әдәпсезлектән генә килгән гадәт түгелдер дип беләм...

Түр ягыбызның идән өлешендә шул бер өстәл белән сандыктан һәм талдан бөгеп ясалган ике утыргычтан башка хәтердә калырлык әллә ни юк. Иртә-кичләрен мич буенда зур гына тас тора, аның янында — комган. Юыну, коену, тәһарәт алу эшләре шунда башкарыла.

Сәке, идән хәлләре шундый — ярамаслык түгел. Ә менә түшәмгә карасаң! «Ничек курыкмый торалар бу өйдә?» дип уйларлык. Бигрәк тә сул як стена кырындагы түшәм тактасы көянтә кебек сыгылып төшкән. Ничек матчага эләгеп торгандыр ул черек такталарның башлары, алла белсен! Яз җитеп, түбәдәге карлар эри башласа, бигрәк тә атналар буе туктамыйча көзге яңгыр яуган көннәрдә, түбә-түшәм үтәли өй эченә шабырдап су ага. Әйе, тама гына түгел, ага! Андый чакларда өйнең ике як читендә булган әйберләр түр яктан да, бүлмә яктан да уртага — бүлмә тактасы буена өелә. Өй хуҗаларына эш җитәрлек, олысына да, кечесенә дә: су аеруча шәп аккан урыннарга куелган чиләк, тас, ялгаш, коштабак, тәлинкә кебек савытлар әледән-әле тулып тора, чыгарып түгәргә генә өлгер...

Куелган савытлардан читкә аккан су да җитәрлек, әлбәттә. Идән астында яшәүче тычканнар ни күргәндер! Бу яктан иң җайлы урыннарны сайлаган мич асты сандугачлары — чикерткәләр, мич башы һәм морҗа буйларында яшәүче таракан көтүләре турында әйтеп тормыйм...

Хәер, таракан турында сүз чыккач, ничек әйтми узасың! Шул тараканнар аркасында бит инде, кышкы чиләдә, атналар буенча урамга чыгарга зар булып, өйдә ятарга туры килгән иң күңелсез көннәрдә безгә көтелмәгән бәйрәм әләгә иде. Андый көннәрдә таракан ташлый идек без. Ягъни өйдә тараканнарның үзләрен генә калдырып, бөтен гаиләбез белән күршегә күчәбез. Ишеге тутырып ачып куелган салкын өйдә песнәкләр бәйрәм итә: катып идәнгә, сәкегә, мич башларына коелган таракан белән сыйланалар. Ә безгә күрше өендә бәйрәм. Атналар буенча күрешә алмау аркасында, бер-берсен сагынышкан ике гаилә балалары куанычыбызга чыдый алмый үзара котырып чыгабыз. Кеше янында әниләр дә миһербанлырак була, юкка-барга әрләп, сугып тормыйлар. Артык шаулашып, аларга үзара тәмләп сөйләшеп утырырга комачаулый башласаң гына кычкырып куйгалыйлар. Чамадан тыш азгынланып китеп, савыт-саба ватсаң инде — анда, әлбәттә, кеше алды дип гафу итү юк, әләгәсе әләгә.

Көннәр үтә суык булганда, ике-өч көннән, әз генә йомшаграк торса, дүрт-биш көннән кире үз өебезгә кайтабыз. Ләкин бәйрәм бетми әле: инде күршеләр безгә күчә. Ишекле-түрле өзлексез йөгерешүләр, сәке асларына, мич башларына, кадакка эленгән кием артларына кача-кача гөрле уйнаулар, кичләрен әкият сөйләшүләр, табышмак әйтешүләр, сәке өстендә барың бергә тәгәрәшеп, малаен-кызын аермастан,

МИРСӘЙ ӘМИР ◆ БЕЗ БӘЛЭКӘЙ ЧАКЛАРДА ◆

кочаклашып йоклаулар... Белмим, әниләргә ничек тоелгандыр, әмма безгә! Әй, күңелле була иде дә соң таракан ташлаган чакларда!.. Юк, бөтенесен дә хәтергә төшерә башласаң, сабый чак истәлекләренең очына чыгу мөмкин эш түгелдер ул. Һаман шул кечкенә өй эчендә азапланам. Ә бит авыл кешесенең дөньясы, хуҗалык даирәсе өй эче белән генә бетми. Тизрәк йортка, ягъни ишегалдына чыгасым килә.

Чыпта белән тышланган ишекне ачып җибәрүгә — турыдан-туры табигать кочагына чумасың. Ә табигать бик чуар холыклы бит ул. Кышкы чилләдә булса, ишек ачылган саен, кибән чаклы салкын пар кыяфәтендә бүселеп өйгә керә дә ашыга-ашыга түргә уза. «Рөхсәтсез керә, түргә уза» дигән табышмакны да, мөгаен, безнеке кебек өйдә яшәүчеләр чыгаргандыр. Буранлы-давыллы чакларда, ачып җибәрүгә үк, шул ук табигать ишегеңне кулыңнан тартып ала да ябарга ирек бирми азаплый. Читәннән генә булса да өйалды кебек нәрсәбез дә юк иде шул.

Аның каравы, җәйнең ямьле көннәрендә ишегебез тәүлек буена диярлек тутырып ачып куелган хәлдә тора. Үз ишегалдыбызга гына түгел, бөтен урамга ямь биреп торган байлыгыбыз — читән буйлап тезелгән бөдрә таллар иде. Кем утырткандыр ул өянкеләрне, кайчан утырткандыр, мин белгәндә алар биек-биек булып үскән, яшел болыт кебек ябалдашлары бергә тоташып, күкрәп утыралар иде инде. Ләкин бу гүзәл тал-тирәкләргә кешеләрдән бигрәк каргалар кызыга иде. Көннәр җылынып, чана юлларында ат тизәкләре өскә чыга башладымы, көт тә тор: килеп тә җитәләр, таң тишегеннән карылдашырга да тотыналар. Иртән торып чыгуыңа өянке башларында берничә оя әзер. Ләкин безнең әни бер дә яратмый иде аларны. Озын колга белән төртеп төшерергә үзенең буе җитмәсә, Кәҗә Хәйрүшне ярдәмгә чакыра.

Хәйрулла — артлаш күршебез малае. Бергә уйнап үстек. Бер-ике яшькә олырак булгангадыр инде, ул миннән көчлерәк тә, шәбрәк йөгерә дә, дөньяны да күбрәк күргән иде. Агыйделдә боз кузгалу белән, әтисенә ияреп, Нөгеш ягына — салга китә иде ул. Аннан безгә бүләк итеп төз, озын тал чыбыктан ясалган бик матур кармак саплары алып кайта иде. Аның өстенә читтә күргәннәре, Агыйдел буйлап сал агызып кайтканда очраган кызыклар турында сөйли, без аны кызыксынып тыңлыйбыз.

— Эх, күрәсе иде шул Нөгеш якларын!..

Аеруча хәтердә калган ягы — Хәйрүш төрле каралты башларына менәргә, агач башларына үрмәләргә бик ярата иде. Карга. оясы туздырырга дисәң, аны куш! Бер-ике тиен акча да тоттырсалар, оя дигәнең нинди биеклектә булса да аңардан котыла алмый инде...

Ә менә келәт янындагы өянке куышына оялаган сыерчыкларыбыз әйләнеп кайткан саен очынып шатлана идек без. Сыерчыкларыбыз! дим. Алар чынлап та безнеке иде. Ни өчен дисәң, бу ояга бик хаклы рәвештә кайтып керәләр. Үзләре юкта законсыз кереп урнашкан әрсез чыпчыкларны ничек куып чыгаруларын, хәтта, мәгез иске-москыларыгызны! дигән кебек, чыпчыклар җыйган чүп-чарны ачулана-ачулана чыгарып ыргытуларын мин шатланып, кызыксынып карап тора идем. «Шул кирәк сезгә!— дим чыпчыкларга,— икенчеләй кеше оясын басып алмассыз... Әзергә-бәзер!..»

Өйдән чыгуга яки урамнан килеп керүгә күзгә ташлана торган икенче байлыгыбыз — бөтен ишегалдыбызны каплап алган өр-яңа хәтфә палас шикелле ямь-яшел бәбкә үләне иде. Сыерыбыз көтүдән кайткан араларда гына аны таптап та, ашап та өлгерә алмый иде,

күрәсең, хәтфә паласыбыз көннән-көн күперә генә бара иде. Без аның өстенә ашаулык җәеп чәй эчәбез, җылы төннәрдә шунда ятып йоклыйбыз. Кыр эшләре өзелеп торган араларда әни янына күрше солдаткалар җыела, һәркайсы, нинди дә булса кул эше тоткан хәлдә, шул хәтфә палас өстендә көннәр буена ләчтит сатып утыралар...

Хуҗалыгыбызның кайчандыр хәллерәк дәрәҗәдә булганлыгы турында сөйләүче каралтылар да бар иде безнен ишегалдында. Ләкин алар миңа байлыгыбыз булып түгел, ярлылыгыбыз булып күренә иде. Ян тәрәзәгә каршы — кечкенә келәт. Келәткә ялганып, артка таба сузылган сарай. Аның икенче башы абзарларга барып тоташа. Мин белгәндә алар бары да тузган, искергән иде инде. Баганалар кыйгайган, читән стеналар чүккән, салам түбәләр черегән... Ә бит аларның яңа чагы булган! Димәк, кайчандыр без бик үк ярлы булмаганбыз. Гаҗәп тә түгел. Әтиебез ярыйсы урта хәлле гаиләдән. Өстәвенә, әниебез дә ни житте семьядан түгел, кибет тотучы Гыйлаҗ бай кызы. Чордашларының әйтүенә караганда, аны кыз чагында «Матур Хәнифә» дип йөрткәннәр. Шундый кызны әнисе үги булган өчен генә теләсә кемгә бирмәсләр. Ни өчен соң аларның хуҗалыгы алга бармаган гына түгел, һаман түбән тәгәрәгән? Моның төп сәбәпләреннән берсе, минемчә, шунда: әтинең шактый күп гомере солдат хезмәтендә узган. Иң элек действительный хезмәттә өч ел йөрткәннәр. Аннары, үзе юкта шактый какшап өлгергән хуҗалыкны инде юлга салам дигәндә, япон сугышы башлана. Анда ике елдан артык нужа чиктереп кайтаралар. Өстәвенә, Әхмәтша абзыйсыныкы кебек уллары — ярдәмчеләре юк. Көтеп алган беренче балалары кыз булып туа. Аның артыннан туган Мансуры да, Мөхтәре дә сабый чакларында ук үлеп китәләр.

Ул арада беренче бөтен дөнья сугышы башлана.

Шунысы хәтеремдә калган — кичкырын иде. Аулак өй итептер инде, әни янына күршедән бер-ике хатын кергән, үзара сөйләшә-сөйләшә кул эше тотып утыралар. Абайламый калдым, кемдер тәрәзәдән нәрсәдер кычкырып узды. Аны ишетүгә әни дә, тыныч кына сөйләшеп утырган күрше хатыннар да кычкырып еладылар да җибәрделәр. Һични аңламаган хәлдә, бу коточкыч хәлдән нишләргә белмичә, тирән аптырашта калуым хәтеремдә. Олылар елаганны ишетү һәр вакыт мине шомландыра, куркыта иде. Ни булды боларга? Нинди хәвефле хәбәр ишеттерделәр! Соңыннан белдем: әтинең сугышка алынуы турында хәбәр иткәннәр икән.

Шулай итеп, әтиебез, тугыз яшьлек Мәрьямен, җиде яшьлек Мирсәяфын, өч яшьлек Мәдхиясен, дүртенчегә, әле туарга өлгермәгән энебез Талханы бер әни өстенә калдырып, герман сугышына китеп барды. Тормыш юлымны ачыграк белә башлавым шул беренче бөтен дөнья сугышы елларына туры килә. Шуңа күрә бу язганнарым да күбрәк шул чорга карый.

Мин белгәндә хуҗалыгыбызда бик күп нәрсә житешми иде. Үз коебыз юк, суга Әхмәтша абзыйларга яки әбиләргә йөрибез. Мунча ягарга кирәк булса да — аларга. Балта, пычкы, тимер сәнәк кебек көн саен кирәк булып торган коралларны да күршеләрдән сорап торырга мәҗбүр идек.

Әйткәнемчә, ул вакытта миңа бу хәлләр бик табигый тоела, үзебезне бервакытта да ярлы дип уйламый идем. Бусы да гаҗәп түгел. Ул заман өчен без чынлап та артык ярлы булмаганбыз. Авылыбызда бездән ярлы семьялар да житәрлек иде. Безнең, ичмасам, атыбыз белән сыерыбыз бар иде әле. Әти сугышка киткәч, атыбыз Әхмәтша абзыйларда калды. Алар аны, үз атлары белән беррәттән, кирәк

җирләренә җигәләр, безнең дә азмы-күпме ашлыгыбызны чәчеп, җыешып бирәләр.

Әти өйдә чакта ук кыр эшләренең нәрсә икәнен күрә башлаган идем инде. Сугыш башланасы елның язы булгандыр. Әти белән икәүләп кырга бодай чәчәргә чыктык. Иң кыены — гадәттәгедән иртә тору булды. Кичтән бик дәртләнеп яткан булсам да, иртән татлы йокыдан аерыласым килмичә, әнигә карыша башладым.

— Ашлык чәчәргә барасыз бит, улым, тор инде.

— Әй, бармыйм ла...

— Бармыйсың?! — диде әни ниндидер шелтә катыш гаҗәпләнү белән.— Тилердеңме әллә син? Яз көне беренче кат ашлык чәчәргә бару иң зур шатлык бит ул! «Бармыйм», имеш! Ничек оялмыйсың? Мине алып баручы булса әле!..

Әнинең шул кадәр исе китеп гаҗәпләнүе йокымнан айнытып җибәрде. Чыннан да оят булып китте миңа. Җиңел генә тордым. Юындым. Куана-куана, үземчә әзерләнә башладым. Нигә куанмаска? Әни шулай диде бит. Иң зур шатлык диде!

Ничек итеп әни мине шул кадәр нык ышандыра алды — хәзер дә аңлап җитә алмыйм. Ул көннән соң миңа татлы йокымнан уянып эшкә чыгарга туры килгән чаклар күп булды. Нинди читен булса да, чыдыйм, әни сүзләре хәтеремә төшә дә, үземне шатланырга мәҗбүр итәм, һич югында, шатланган булып күренергә тырыша идем. Шунысы кызык: күп вакытта үзеңне көчләп шатлану бик тиз арада чынлап шатлануга әверелә иде.

Җир өстенә килеп җиттек. Әти, атны тугарып печәнгә кушкач, бодай чәчәргә керешге. Беренче учларыннан ук бодай белән бергә кап-кара җир өстенә каты итеп пешерелгән ап-ак күкәйләр тәгәрәтте. (Янәсе бодайларыбыз шул күкәйләр кебек эре булсын.) Мин аларны бүрегемә җыеп алдым. Әти миннән бүтән бер эш тә эшләтмәде. Дөрес, әти җитәкләгән атка атланып, җирне бер-ике әйләндем. Аны да үзем ялынгач кына рөхсәт иткән иде.

Әти киткәч, Әхмәтша абзыйның уллары — я Закир абзый, я Хөсәен абзый — атыбыз янына мине дә кыр эшләренә алып йөри башладылар. Алар әти түгел иде инде, иркәләп тормадылар. Сабанда булсын, тырмада булсын — алдан барган атка атланып йөрим. Аны инде берәү дә җитәкләми: дөрес йөртү дә, тиешенчә тизлектә атлату да минем өстә. Җир башына җитеп, атым кинәт борылган чакларда егылып төшсәм, җәлләү билгесе күрсәтү юк. «Җебегән! Атлап барган ат өстендә утыра алмыйсың!» — дип әрлиләр генә. Ат буразнадан аз гена читкәрәк атласа да, баштан сыйпамыйлар: «Күзең чыкканмыни?!» Бавыргалык, сагылдырык кебек берәр сбруйның исемен белмәсәм, көләләр, мыскыл итәләр: «Мөлдермәне дә белмисең, миңгерәү!» Ләкин мин мондый сүзләргә артык рәнҗемим, шулай тиеш күрәм, кыен булса да, күңелгә авыр булса да, бары үземне генә гаепле саный идем. Иң үзәгемне өзгәне — безнең атны үгисетүләре иде. Сабанда аны һәр вакыт төпкә — буразнага җигәләр. Сабан тотып баручының каеш очлы чыбыркысы күбрәк аңарга эләгә. Эшкә барган-кайткан чакларда да арбага безнең Турат җигелә. Ә үз атларының берсе прәшкәдә, икенчесе бөтенләй буш килеш ял итеп кайта. Туратыбызны җәлләп жылыйсыларым килсә дә, берни әйтә алмыйм. Эчемне бушату өчен, кайчак әнигә кайтып зарланам, ул да берни әйтә алмый. «Алай булса, Туратыгызны үзегез карагыз, җирегезне үзегез сөрегез!» — дисәләр, нишләрсең?.. Монысы өчен дә рәхмәт...

Нәтиҗәдә ун яшемә җиткәндә мин көчемнән килгән кыр эшләрен ярыйсы үзләштергән, төрле сбруй исемнәрен дә әнәсеннән җебенә кадәр белүче, ат өстенә кеше ярдәменнән башка менеп атлана һәм, малайлар белән кем узардан ярышып, җан-фәрманга чабып йөри

ала торган малай идем инде. Шундый кырыслык белән эшкә, дөнья күтәргә өйрәтүләре өчен абзыйларымны бары рәхмәт хисе белән генә искә алам.

Шулай да Закир абзый белән Хөсәен абзый — икесе ике төрле кеше иделәр. Закир абзый белән рәхәтрәк иде миңа. Ул Әхмәтша абзыйның олы улы. Баланы бала итеп карый белә. Кирәк вакытта юату сүзләренә дә саранланмый. Без аны болай да ярата идек. Кышкы озын кичләрдә ул безнең янга кереп утыра, төрле кызык сүзләр сөйли, искиткеч фокуслар күрсәтеп, безне шаккатыра торган иде. Ләкин миңа кырга аның белән чыгарга бик сирәк туры килде. Күбрәк Хөсәен абзый белән йөри идек.Хөсәен абзый яшь иде әле. Каралыр яшькә дә житмәгән, кәләш тә алмаган егет иде. Шуңа күрә мине үзе белән тиңрәк саный идеме, бала дип, ташлама ясаганы сизелмәде. «Туганыңа да ярамый» торган туры сүзләрне күбрәк аңардан ишетә идем.

Революциядән соң ул, бәхет эзләп, Ташкент ягына чыгып киткән. Хәзер алар икесе дә бу дөньяда юк инде. Закир абзыйның малайлары менә дигән колхозчылар. Араларында Ватан сугышы каһарманнары да, колхоз алдынгылары да бар. Бигрәк тә олы улы Сөләйман этисенә тарткан. Тирә-ягына бер көтү бала-чаганы җыеп алып, Ватан сугышы фронтларында күргәннәрен сөйләргә ярата.

Хөсәен абзый эзләп барган җирендә бәхетен тапкан. Гомеренең ахырына кадәр Сәмаркандта «Һөҗүм» фабрикасында эшләгән. Бу турыда мин аның өлкән улы Әмир Әмировтан ишеттем. Ул күптән түгел Мәскәүдә укып, техник фәннәр кандидаты булып кайтты. Хөсәен абзый гомумән үз фамилиясенең патриоты булып чыккан. Әмир бабай хөрмәтенә өлкән улына аның исемен биргән. Мине дә сагынып искә ала торган булган һәм хәтта бер улына Мирсәяф дип исем кушкан. Үзем күрмәгән адашым һәм энем хезмәт сөюче өметле егеткә охшый, «Правда» газетасында мактап, рәсемен басып чыгардылар.

## 3

## БАЙЛЫГЫБЫЗ. МАРҖА КЫЗЫ. ҺАҖӘР АПА. ӘНИ ӨЙДӘ ЮКТА. СОЛДАТКАЛАР. АЧЫКСАЛАР КАРЛЫГАЧНЫҢ БАЛАЛАРЫ...

Еллар үткәч аңладым: иң зур байлыгыбыз — бөдрә таллар да түгел, бәбкә үләненнән тукылган хәтфә палас та, гомергә онытылмас матур истәлек булып калган сыерчыкларыбыз да, хәтта атыбыз-сыерыбыз да түгел,— әниебез үзе булган икән!

. Әни?!

Балалык елларымны аңардан башка күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Теге пычак калдырган истәлектән элек иде микән, соң микән — анысын ачыклый алмыйм — уракка барган идек. Күрәсең, йоклатып калдырган булганнардыр, арба янында бер ялгызым әнине эзләп йөргәнем хәтеремдә. Арыш арасына кереп киткәнмен. Куе булып, биек булып үскән арыш. Аның башакларын күрү өчен миңа каерылып югары карарга кирәк. Ә югарыда аяз күк йөзеннән башка берни күренми. Я янып торган кояшка тап булып, күзләрем чагыла. Арыш урманын кулларым белән ике якка аера-аера алга атлыйм.

— Ә-н-и-и!

Берни ишетелми, берни күренми. Кире арба янына кайтмакчы булам, арба да юкка чыкты. Кайсы якка борылсам да — арыш... арыш... арыш... Инде әни дип тә кычкырмыйм, үксеп елый-елый, һаман каядыр

барам. Арыш урманының читенә барып чыгасым килә. Ә аның чите юк та юк... Күпме адашып йөргәнмендер, һәрхәлдә, миңа бик-бик озак тоелды. Ниһаять, алдымда арышлар сирәгәйгән кебек тоела башлады. Шунда ук каршыма бер әни килеп чыкты. Үз әнием түгел. Миңа нидер әйтә, сүзләрен аңламыйм. Елама дип әйтә бугай. Ә мин туктый алмыйм, һаман үксеп елыйм да елыйм. Ул мине күтәреп алды. Арыш арасыннан алып чыгып, арба янына алып килде. Безнең арба түгел. Арба янында басып торган бер бәләкәй генә кызга күзем төште. Сап-сары чәчле, ап-ак битле кыз. Миңа карап тора. Еламый да, көлми дә. Мин дә елавымны оныттым. Күземне алмыйм сары чәчле кыздан. Каяндыр үз әнием килеп чыкты. Мине алып китә башлады. Китмик, дип еларга тотындым. Әни көлә. «Бу безнең арба түгел,— ди.— Әйдә үзебезгә, әтиең янына»,— ди.

— Бәбине дә алып китик.

— Бәбине әнисе бирми, үземә кирәк әйтә,— ди әни. Үзе тагы көлә, теге әнигә нидер сөйли. Анысы да көлә. Ә мин һаман елыйм.

— Апкайтый-й-ык!..

— Ярар, апкайтырбыз,— ди әни.— Маржа кызы матурмыни, улым?

— Ә?

— Бәби матурмыни?

— Матур.

— Без сиңа ул маржа кызыннан да матуррак бәби алып кайтырбыз әле.

«Маржа кызы» дигәне бик ачык хәтеремдә калган. Бу сүзне беренче ишетүем булгандыр, күрәсең.

Шуннан соң күпме вакыт үткәндер, белмим. Бер көнне чынлап та бәби алып кайттылар.

— Менә, улым,— ди әни,— тәти бәбине апкайттык.

Бәби миңа нинди булып күренгәндер, анысы һич хәтеремдә калмаган. Мәгәр, бу бәби кирәкми, теге уракта күргән кызны алып кайтыгыз, дип ярсып-ярсып елавым хәтеремдә. Шунда гаҗәп бер хәл булды. Әни: «Ярар, алайса, бу бәбине чыгарып ташлыйбыз, син сораган бәбине алып кайтабыз,— диде дә,— менә шулай, менә шулай,— дип сөйләнә-сөйләнә, күз алдымда бәбине таска салды. Аннары тышка чыгарып, түгеп керде,— Әнә, кәкәй бәбине чыгарып түктем, хәзер тәти бәбине алып кайтабыз»,— диде.

Күп тә үтмәде, тәти бәбине алып та кайттылар: «Менә ул син сораган бәби!»— Әниңнең кулында инде чынлап та мин арыш кырында күргән матур, ягымлы бәләкәй кыз иде. Ничек моңа ышандыра алды мине әни, хәзер дә аңламыйм. Ләкин ул вакытта мин бу хәлгә чын күңелдән ышандым.

Серле бәби — яңа туган сеңелем Мәдхия булып чыкты. Аның белән арабыз дүрт яшькә якын иде. Димәк, бу — 1910 нчы ел тирәсенә, ягъни мин өч белән дүрт арасында булган чакка туры килә.

Алтыга җиткәндә мин каләм тота башлаган идем инде. «1913» дип үз кулым белән язуым хәтеремдә. Дөньяда ел исәбе дигән нәрсә барлыгы турында ишетүем дә шул елдан башлана торгандыр. Әни дә, әти дә гыйлем эстәүгә, укыган кешегә бик зур ихтирам белән карыйлар, үзләренең балаларын да укымышлы кеше итеп үстерү турында хыялланалар иде. Хыяллары бик үк өметсез булмаган, күрәсең, өлкән кызыбыз Һаҗәр апа турында шундый бер истәлек бик ачык хәтеремдә калган.

Беркөнне ул мәктәптән эш алып кайтты. Язу эше. Үзе белән бергә укучы ниндидер бай кызының аңардан шигырь күчертеп аласы килгән. Дәфтәрен дә биреп җибәргән. Гадәттәгедән бәләкәй күләмле, ялтыр кара тышлы, искиткеч матур, өр-яңа дәфтәр. Прәме кулга тотарга куркыныч! Бу хәл әниненң күңеленә бик хуш килде. Димәк, аның кызы

үзенең шәрикләре арасында иң матур язучылардан санала. Өстәвенә, андый эшне бай кызлары, әлбәттә, бушка гына эшләтмиләр.

Һаҗәр апабызның кинәт кадере артып, дәрәҗәсе күтәрелеп китте. Әни өстәлне чиста итеп, үзе җыеп алды. Апабыз, кулларын юып, язарга утырды. Ләкин капыл гына язып китә алмады.

— Ай, өстәл селкенә, ай, идән селкенә дип, көйсезләнергә тотынды. Безгә идәндә йөрү тыелды.

— Тик кенә утырыгыз! Сәкедән төшәсе булмагыз!..

Һаҗәр апага сәке селкенүе дә ошамады.

— Ай, боздыралар инде, әни! Тый әле шул кортлыларыңны!..

Әни безне бүлмәгә куды. Анда да кыймылдамый гына утырырга кушты.

— Карагыз аны, кортларыгыз кыймылдамасын! Һаҗәр апагыз шигырь күчерә. Бер генә хәрефен боздырсагыз да, муеныгызны астыгызга китерермен! — Әни бу эшкә шул кадәр зур әһәмият бирде, әйтерсең бөтен гаиләбезнең язмышы шул шигырь күчерергә генә бәйләнгән иде инде.

Һаҗәр апаның бу кадәр ачык истә калган башка якларын хәтерләмим. Озакламый аны кияүгә бирделәр. Ахрысы, бәхетле булып чыкмады, бала китерергә дә өлгермичә, үлеп китте.

Бу вакытта Мәрьям апа да кызлар мәктәбенә йөри иде инде. Аның белән безнең ара ике яшькә дә тулмый, шуңа күрә мин үземне аның белән тиңрәк күрә идем. Хәтта мин аңа «апа» дип тә, икебез дә олы кеше булып, бер-беребезне еллар буена күрми торгач кына, анда да әле беренче мәлдә хат аркылы гына әйтә башладым. Ә бала чакларда... Үзара килешеп, бергә уйныйбыз, күп мәсьәләләрдә уртак тел табабыз. Еш кына арабыз бозылып әрләшеп киткән чакларыбыз да була. Әрләшүебез нидән гыйбарәт? Авызларыбызны булдыра алган кадәр ямьсез кыяфәткә кертеп, бер-беребезне үчекләшәбез. Исем аташабыз.

Кайвакыт ике арада чыккан бәхәс үчекләшүләр яки исем аташулар белән генә хәл кылынмый, эшләр кул хәрәкәтенә барып җитә. Мәрьям апа, ачуына чыдар хәле калмыйча, я кулымнан, я иңбашымнан, я битемнән үк каты итеп тотып ала. Тоту дигәне тоту гына түгел, я чемету, я тырнау булып чыга. Ә мин чатырдап аның чәченә ябышам. Мондый чакларда, кулына чыра тотып, бүлмәдән әни килеп чыга.

— Җитәрегез!

Аның сүзе закон. Әгәр шунда әни килеп чыкмаса! Канга батышып бетәр идек микән? Алла сакласын!.. Шуны сизенеп булса кирәк, без әни өйдә юкта сугышмый идек. Уйныйбыз, шаярабыз, көлешәбез, иркенлектән файдаланып, ду киләбез. Күбесенчә берәр нәрсә ватмыйча туктамыйбыз. Анда да икебез бер сүздә. Өченчегә сеңелебез Мәдхия бар. Ул әле кечкенә, безне тыңлап кына тора. Аны рәнҗетмибез. Шулай да юмалап кына кисәтеп куябыз: «Әнигә әйтмә, туганым, яме?..»

Ләкин әйтүнең кирәге юк. Кайтып керү белән, кыяфәтләребезне күреп, әни үзе сизеп ала:

— Нәрсә ваттыгыз?..

Кайвакыт әни өйдә юкта берәр нәрсә ашыйсыбыз килеп китә. Ләкин нәрсә ашарга? Бәрәңге пешерү — озак. Шикәр — санаулы. Иң яхшысы — суган. Уактан өзелми торган утлы көлгә суган күмәбез. Тиз дә пешә, искиткеч тәмле дә. Өстәвенә ул, озын бауга тезелгән килеш, бүлмә стенасында эленеп тора. Йөзләп баш бардыр. Аны кем санап торсын! Мәдхиянең үзенә бер баш пешереп бирәбез. Кара аны, әнигә әйтмә!.. Ләкин бу турыда да әйтүнең кирәге калмый. Әни, кайтып керү белән, борынын күтәрә төшеп, әз генә җыерып ала да, кырыс кына тавыш белән:

— Тагын суган күмдегезме? — дип сорый.

Әнинең борынының сизгерлегенә хәйран кала идек без.

Мәрьям апа мәктәпкә йөри башлагач, арабыз сизелерлек яхшырып китте. Мин аңа хәзер, сабак укучы булгач, хөрмәт беләнрәк карыйм, аның әлифбалары, дәфтәрләре белән кызыксынам, ул да хәзер үзен олырак кеше хис итә, минем кызыксынуым аңа ошый, ул рәхәтләнеп, хәтта үзенең өстенлеге белән бераз мактанып та булса кирәк, миңа китапларын, дәфтәрләрен күрсәтә, үзе белгәннәрне миңа да өйрәтергә тырыша иде.

Апаның өйрәтергә, минем өйрәнергә тырышуларыбыз бушка китмәгән, күрәсең, мин, мәктәпкә кергәнче үк, укый да, яза да белә идем инде. Әти сугышка киткән елның көзендә сабакка төштем, ягъни мәдрәсәгә йөри башладым...

Мәдрәсә хакында язарга керешкәнче, әтидән башка ничек дөнья көтүебез турында тагын берничә сүз әйтәсем килә.

Җәй көннәрендә, кыр эшләреннән бушап торган араларда, әни янына күрше солдаткалар керә, җыйнаулашып ишегалдына — каз үләне өстенә чыгып утыралар. Куллары туктаусыз ни дә булса эшли: оек бәйли, тегү тегә, чигү чигә, ямау сала, телләре берөзлексез такылдый. Мин алар сөйләгәнне тыңлап торырга ярата идем. Шунда алар тирәсендә үләндә аунаган булам, пычак белән юнып, берәр нәрсә ясаган булам. Кызыграк нәрсә сөйләгән чакларында мавыгып, онытылып китәм, күрәмсең.

— Кара, кара, — ди шунда берсе, миңа игътибар итеп, — тыңлап торуын гына кара, авызын ачып!

— Нишләп утырасың монда? — ди әни зәһәрсез генә ачуланып. — Әниләр сөйләшкәнне тыңлап торырга ярыймыни шулай бәләкәй кешегә, оятсыз!

Алар абайлап алганчы мин инде байтак сүзләрен ишетеп өлгергән булам. Тик ни өчен «оятсыз»? — аңламыйм. Гомумән миңа күп сүзләре аңлашылмый иде аларның. Бик ачык хәтеремдә: нинди дер бер солдатка турында ире юкта бала тапкан дип сөйләделәр. Шуңа исләре китте. Кайсы әрләп я каргап искә ала тегене, ләгънәт, ди, оятсыз, ди, җир бит, ди. Кайсы кызгана, мескен, ди, күрәсе булгандыр инде, ди, язмыш, ди. Алла сакласын, ходай күрсәтмәсен, ди... Башыма уй килә шунда: нигә аңа бу кадәр исләре китә икән? Ире юкта бала тапса ни булган соң? Безнең әни үзе дә бит әнә Талханы әти солдатка киткәч тапты. Нигә соң моңа берәүнең дә исе китмәде? Гаепләмәделәр дә әнине, алай кызганмадылар да. Хәтта аны, үз итеп, хөрмәт итеп, берәр табак манный боткасы пешереп кертүчеләр булды әле. Күзенә май салып! Әнигә генә түгел, барыбызга да җитәрлек итеп!

Ниләр генә сөйләми солдаткалар! Кемнәр колагын бозып солдаттан калган, кемнекеләр духтыргамы, писыргамы акча төртеп, ак билет алган. Кемнекеләр ранни булган. Нинди дер карун байларны тетеп ташлыйлар. Муллаларга, ишанга тел тидерәләр, хәтта патшага!.. Сүз патша тирәсенә барып җиткәндә кинәт пышылдауга күчәләр:

— Рәте юк дип әйтәләр ди безнекенең, герман патшасы каршында ни коралы, ни хәйләкәрлеге... Янараллары солдатларны җәдрә астына тыгып кына тора, ди, барабанга көлтә тыккан кебек.

— Чү! Акрын, алла сакласын!

— И-и, син бигрәк тагы! Монда шайтан ишетәмени?

— Алай димә, шымчылары бөтен җирдә колак салып йөри диләр. Патшага тел тидергәнеңне ишетеп калсалар, алла сакласын, башың Себердән кайтмас!..

Пышылдап сөйләшү белән генә тынычланмыйча, тирә-якларына ялт-йолт каранып алалар. Тагы миңа күзләре төшә.

— Бу комсыз колак нәрсә тыңлап тора монда?

— Бар, зурлар сөйләшкәнне бәләкәйләргә ишетергә ярамый, бар, кит! Әнә Габдрахман сине эзләп йөри анда.

Миннән шикләнәләр. Ә мин берни аңламыйм. Шулай да патша чаклы патша турында шикле сүзләр ишетү шомландыра. Ничектер уйландыра башлый. Уйланмаслык та түгел шул: киемнәребездә ямаулар күбәя баруын, мич башыбызда тараканнарыбыз үрчүен исәпкә алмасаң, арткан җиребез юк. Яңа бишмәт яки яңа пима турында сүз кузгатсаң, әнинең җавабы бер генә:

— Әтиең кайткач!

— Әти кайчан кайта?

— Мир булгач!

— Мир кайчан булыр соң?

— Анысы патша кулында...

Ләкин патша мир булдырырга ашыкмый. Ашау-эчү яклары да такырая бара. Әни безгә чәй янында берәр лампачи гына бирә башлады. Шикәргә караганда бәрәкәтлерәк, ди. Чынлап та, шатырдатып чәйнәргә ашыкмасаң, әни кушканча, суырып кына эчсәң, берсе өч чынаякка җитә. Башта безгә ул бәйрәм сые булып тоелган иде дә, тора-бара төшенеп алдык: тәмлесен тәмле, сүз дә юк, тик шикәрләп чәй эчкәннән соң суырып йөрсәң генә сый икән ул лампачи.

Кыш көннәре сөт-катык мәсьәләсе дә авырлаша. Кар төшү белән диярлек, сыерыбыз ташлата, ягъни саудырмый башлый. Бозаулаганчы, дөресрәге, кырда үлән ачылганчы аның үзен туйдырып чыгарга кирәк. Шулай да ашарыбызга җитми дип әйтерлегебез юк. Әни көн саен умач пешерә. Бәрәңге тураган умачка сызык та кыздырып салсаң, итле токмачларың бер якта торсын!..

Сызык димәктән...

Беркөнне әни бабайларга китте. Ягъни үзенең әтиләренә. Анда алар куй мае эреткәннәр икән. Көне буе эшләшкән өчен, әнигә бер иләк сызык тоттырып җибәргәннәр.

Көлеп кайтып керде әни.

— Ачыктыгызмы? — ди.

— Ачыктык, ачыктык!

— Менә, күрәсезме:

Ачыксалар Мәсәлимнең балалары,
Иләк белән сызык ташый аналары...

Барыбыз да кычкырып көлеп җибәрдек. Кызык булып китте. Күптән түгел генә Габдулла Тукаев шигырьләрен укып утырган идек. Беребез дә онытмаган:

Ачыксалар карлыгачның балалары,
Чебен-черки тотып кайта аналары.

Шуны үзенә борган. Әнинең бу шаянлыгы безгә бик ошады. Ләкин шигыренә караганда да сызыгы ошый төшкәндер, ахрысы: иләккә ябырылдык. Кара көеп, шытырдап торган сызыкларны туң килеш авызыбызга озатырга тотындык. Әни узынырга ирек бирмәде.

— Җитте,— диде, — бу килеш ашамыйлар аны, эчегез авыртыр...

Безгә ул шул килеш тә бик тәмле иде. Ләкин әни аны җыеп куйды. Көн саен табага берәр кашык кына салып, аңа суган да кушып, бик каты кыздырып, инде табакка сосылган умачка китереп сала. Котыбызны алып, «чаж-ж-ж» иткән тавыш чыга. Умачка нур кереп китә. Чырайсыз яшькелт шулпа өстенә карасу-алтын тәңкәләр сибелә. Авыздан сулар китереп, өйгә майда кызган суган исе җәелә...

## 4

## ӘНИ. БИЛНАК. КӨТҮЧЕ. ПЕШКӘН КАЙМАК. КУЯН ДӘРТЕ.

Тамак ягы бер хәл. Итле аш, шикәрле чәй кебек сыйлар эти сугышта йөргән елларда сагындырып кына эләккәли торган булса да, ипи белән бәрәңгедән өзелгән чагыбызны хәтерләмим. Ә менә утын мәсьәләсе?!. Дөрес, авыр заманның рәхимсез салкыннары безне катырып үтерә алмады. Хәтта әйтерлек чиргә сабыштырган чаклары да булмады. Булган кадәресе дә, бәлки, какшатудан бигрәк, чыныктыра гына төшкәндер. Әнигә рәхмәт! Вакытында балалык белән әйтелми калган, шуңа күрә гомер буена күңелдә бөтен килеш сакланган олы рәхмәт тойгысы! Нинди генә авырлыклар күрмәде ул безне өшетмәс өчен!

Утынны бездә башлыча Иделдә боз тоткач ташыйлар. Ә кышын кар ерып урманга керү?! Юк, хатын-кыз яки бала-чаганың гына кулыннан килә торган эш түгел бу! Биргидел белән Аргыйдел арасында шактый зур тугай бар. Биргиделнең аръягында булгач, аны бер сүз белән «аръяк» дип кенә йөртәләр.

Аръякта бик күп булып зелпе, эт шомырты куаклары үсә торган иде. Су читләрендә, уйсу урыннарда, вак-вак күл буйларында — сары тал. Безне, бала-чаганы, кызыксындырганы — шул зелпе төпләрен каплаган җир җиләге, тал араларында үскән карлыган, кара бөрлегән куаклары була; төрле урынга сибелгән юа, каз тәпие, куян тубыгы, балтырган, шома көпшә кебек тәмле үләннәр дөнья байлыгы булып күренә иде безгә. Дөнья үзебезгә калгач, әз генә булса да үсә төшкәч аңладым: хуҗалык өчен аръякның төп кыйммәте мал җибәрергә мул үләнле болын булуында, каралты-курага читән өчен һәркемгә җитәрлек күләмдә зелпе куаклары, сары тал үстерүендә булган икән. Алай гына да түгел, Аргыйдел аръягындагы Җиргәнтау имәнлегенә яки аннан да ары — бояр урманына барып йөрерлек хәле булмаган ятимнәр һәм гомумән ярлы-ябагай өчен утын чыганагы да булган икән.

1915 елның көзе иде. Җир туңган, урамнарда көзге яңгырлардан калган күлдәвекләр дә каткан, ләкин әле кар төшмәгән чак иде. Үз атыбызны Әхмәтша абзыйлардан сорап алдык та, әни белән икәү аръякка — фәкыйрьләр урманына — зелпегә киттек. Ридуанга[1] атны әйбәтләп, юлда тугарылып изаламаслык итеп, Әхмәтша абзый үзе җигеп бирде. Барабыз. Турат лүрт-лүрт юрта, ридуан тәгәрмәчләре туң юл өстеннән дыңгыр-дыңгыр тәгәри. Мин, Хәнифә җиңгинең олы улы, йортта атасы урынына калган ир-ат — сигез яшьлек Мирсәяф, дилбегә тотып барам. Ридуанның алгы үрәчәсенә тотынып, аягүрә басканмын. Кулымда чыбыркы.

— На-а-а, әйдә-ә!..

Биргидел ташлыгына килеп кергәч, әни дилбегәне үз кулына алды. Бу урында Идел бераз кыңая төшеп, чуер ташлар өстеннән сай гына булып чылтырап ага. Ялан аяк булганда биредән балакны бөтенләй сызганмыйча чыгып була. Шуңа күрә бу урынны «Сай туры» дип йөрибез. Ярты чакрым чамасы гына үрдәрәк — икенче юл. Анысы «Актирәк турысы» дип йөртелә. Анда инде тирәнрәк, җәяүләп кичәргә кирәк булса, балакны бот төбенә кадәр сызганырга туры килә. Тынычрак аккангадыр инде, тирәнрәк булса да, ул турыда су өсте боз белән капланган. Боз әле калын түгел. Өстенә керсәң, хәтәр тавышлар чыгарып чытырдый, чатнап-чатнап китә. Шулай да без, малайлар, куркып тормыйбыз, хәтта курка-курка булса да, аның өстендә шуып уйнарга яратабыз. Хәер, артык куркырлык эш юк. «Көзге боз көзгедәй булса

[1] Ридуан — көлтә, печән, чыбык утын кебек күләмле әйберләр ташый торган йөк арбасы.

да күтәрә» дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Күтәрмәгән суратта дә батып уларлек урын түгел. Салкын суга чумып чыгудан гына әллә ни булмый. Аның каравы, бозы ни тора! Затлы пыяла кебек чиста боз. Аның үтәли аста йөзеп йөргән балыклар аермачык күренә. Ул аның шомалыгы! Кечкенәрәк чуер ташны кәшәкә белән сугып җибәрсәң, әллә кайларга олага. Яр читенә барып бәрелмәсә яки туңмаган урынга туры килеп, суга чапылдамаса, күздән югалганчы, матур булып зыңлаган тавыш колакка ишетелми башлаганчы туктый алмый. Кичә генә шунда уйнап йөрдек. Тик бу турыда әнигә әйтте юк. Иртәрәк әйләнеп кайта алсак, бәлки бүген дә кичкырын чыгармын әле...

Ком аралаш кырчын ташка тәгәрмәчләребез батып, ридуан ярыйсы гына авырайса да, Сай турыдан юрттырып диярлек аръякка чыгып киттек.

Аръяк — үзе бер дөнья. Аның һәркайсы үзенә бер исем белән атап йөртелә торган төрле урыннары бар. «Салабаш күле», «Актирәк төбе», «Гөрләвек», «Караяр», «Мещан кәртәсе», «Озын күл»... Ә иң ерак почмагы, Иске ерым белән Яна ерым арасында бүленеп, утрау булып калган җире — Исәнбикә дип атала. Зелпенең иң шәп урыны шунда инде. Күп тә, эре дә. Зелпе генә түгел, ару-ару гына карама да очрый анда, колгага ярарлык усак та... Шунда таба юл тоттык. Барып җиттек. Әни тотынды балта белән зелпе кисәргә, мин киселгән агачларны арба янына ташып торам. Ридуаныбызны шыплап тутырып, төяп куйдык. Инде кайтып китәргә генә калды. Ләкин әрәмәлек арасындагы тар юлдан кайтыр якка кире борылу турында алданрак уйламаганбыз икән. Борылырга җайлы урын эзләп алга барганда каршыбызга бер атлы килеп чыкты. Арбасына безнең кебек үк зелпе төягән. Юл бирергә урын юк. Тукталдык. Ул да.

— Кая китеп барасың болай, кире якка?

Әйтеп бирдек.

— Ай, килен,— диде теге,— керүеңнән элек чыгуыңны уйла дигәнне бер дә ишеткәнең юкмыни синең?

— Сөйләмә инде, әтисе дә әйтә торган иде дә бит...

— Кая, алайса, тырышып карыйк, — диде абзый кеше, куе булып үскән әрәмәнең кайсын егып, кайсын кисеп, бераз юл ачкандай итте. Аннары Туратны авызлыгы яныннан ук тотып, үзе җитәкләде дә арбаны бора башлады. Әллә капылрак борды, әллә арбабыз шундыйрак булды, ридуаныбыз юлга аркылы килеш алгы күчәрдән аерылып, төште дә калды.

— Бәй, — диде абзый кеше, — ничек болай бик тиз чыкты бу? Шундый кыска кендек буламы?

Карасак, кендегебез, чыккан гына түгел, сынган, имеш... Күптән чатнаган булган икән ул.

— Бушатырга туры килер.

Йөгеннән бушап, алгы күчәрдән аерылып калган ридуанны янга алып тордык. Абзый кеше үз йөге янына юнәлде. Хәзер инде аңа кайтып китсә дә була — юлын буып торган арба юк. Әни белән тын алырга куркып, карап торабыз. Менә ул атын җитәкләде, чөңгереп кузгатты. Ашыкмый гына безнең арба яныннан узып китте. Әнә, инде атын ашыктыра да башлады. Әни түзмәде, нидер әйтергә теләп, аңа таба борылды.

— Нәбиулла абзый!

Абзый кеше аны бөтенләй ишетмәгәндәй атлавында булды. Әни, үз күзләренә ышанмагандай, һаман аның артыннан карап тора иде әле. Мин, кыен хәлдә калуыбызны сизенеп, нишләргә белмичә, «Әни!» дип кычкырып җибәрдем.

— Чү!..

Абзый кеше куе әрәмәлек арасына кысылган юл буйлап шактый

җир үткәч, арбасын юл читендә очраган кечкенә аланга чыгарып туктатты да кире безгә таба борылды.

— Курыкма, килен,— дип сөйләнә-сөйләнә килә иде ул,— ятимнәрне ташлап китәргә ярыймыни? Хәзер рәтләрбез арбагызны.

Ул, башка үткенчеләр килеп чыкса дип, юлны буып тормас өчен, шулай арбасын читкә алган икән. Ул шактый озак азапланып, агачтан юнылган чөй дә кушып, кендегебезне рәтләп бирде. Арбабыз хәзер кайтыр якка карап тора иде инде. Нәбиулла абзый безгә йөгебезне төяшеп тә бирмәкче иде, әни үзе килештермәде.

— Анысын гына үзебез дә булдырырбыз,— дип, аңа рәхмәтләр әйтте.

Бу кешене мин ул вакытта белми идем әле, тора-бара белдем: бик күп һөнәр иясе булып чыкты. Бөтен авыл сабынга зар булган елларда тигәнәк көле белән сабын кайнатып йөрде ул. Мәктәпләрдә язу карасына кытлык башлангач, имән каерысыннан кара ясап сатты. Тагы мин белмәгән бик күп һөнәрләре бар дип сөйләделәр. Җитмеш төрле һөнәр иясе булуының хикмәте шунда: ул ел саен чыгып килә торган стена календарен бер дә калдырмый укып бара икән, календарь биргән акыллы киңәшләргә бик чынлап колак сала, ул өйрәткән хикмәтләрнең кирәк дип тапканнарын барын да эшләп карый икән. Календарь өстенә гәзит тә укый диләр иде аны. Сугыш хәлләре, Әрәчәй эчендәге вакыйгалар, дөнья куләмендә булган яңалыклар турындагы хәбәрләрне күбрәк аңардан ишетәләр иде.

Үзебез генә калгач, йөгебезне элеккесенә караганда да әйбәтләбрәк яңадан төяп, кайтырга чыктык. Арбаны бора алмый җәфалану, кендегебез сыну азаплары шунда ук артта калып, онытылды. Алар хәзер үзләренә күрә җиңү шатлыгына әйләнгән иде инде. Шул шатлык белән канатланып булса кирәк, абайламый калганбыз: килгәндә чыккан Сай турыга бара торган юл белән китмичә, Актирәк юлына төшкәнбез. Бу юл безне әлеге — өстен боз каплаган кичүгә китереп чыгарды. Тукталып калдык. Яңадан Сай турыга күчү өчен, кире борылырга, шактый зур әйләнеч ясарга кирәк. Әнинең кире борыласы килмәде. Күтәрсә, боз өстеннән чыгып китәрбез, күтәрмәсә — тирән җир түгел, ат-арба авырлыгы белән ваттырып үтәрбез, дип уйлады, күрәсең, дилбегәне үз кулына алды да, тәвәккәлләп, атны кузгатып та җибәрде. Үзе берни дәшми, авыз эченнән генә дога укыймы, теләк телиме — иреннәре кыймылдый. Турат сак кына адымнар белән боз өстеннән атлап бара, дагасы ярыйсы икән — таймый. Ридуан тәгәрмәчләре дә җиңел генә тәгәри. Мина кызык. Янәсе, кара син бозның ныклыгын! Ат белән арбаны күтәрә! Утын төягән арбаны әле! Өстәвенә, ике кеше утырган! Ә без, күзгә чебеш кебек малайлар, шуның өстендә шуып уйнап йөрергә курыккан булабыз. Аны да әниләргә белдермәскә тырышабыз. И-и-и, болай булгач!..

Ләкин мактаулы бозым суның читендә — сай җирдә генә шулай нык булып күренгән икән. Әз генә тирәнгәрәк керү белән ат тояклары астында чатырдап чатный, сыгыла башлады. Турат, икеләнгәндәй, тукталып калды. Әни, бу шомлы юлны тизрәк үтеп котылырга теләгәндәй, аны ашыктыра төште. «На-а, куркак!» — дип, озын чыбык белән арт санына сугып та алды. Ат алга омтылып ике-өч атларга өлгермәде, боз уелып төште. Турат хәзер тездән су эчендә иде инде.

— На-а-а, Турат! Әйдә, малкай, на-а-а!

Ат карышмады. Үзем дә хәлне аңлыйм дигәндәй, гайрәтләнеп, алга омтылды, кушаяклап сикереп, ватылмаган боз өстенә басты. Боз, тиз генә бирешергә теләмәгәндәй, бераз вакыт шатырдап, сыгылып торды да, ат авырлыгын күтәрә алмыйча, тагын уелды. Су тирәнәя төште. Арбабыз да хәзер дүрт тәгәрмәче белән дә су эчендә иде инде. Ат тагын бер тапкыр гайрәтләнеп боз өстенә сикереп карады, ләкин алгарак сикереп басарга аны арба җибәрми иде инде. Шулай итеп, без, атыбыз

һәм утын төялгән арбабыз белән, дүрт яктан да боз белән киртәләнгән су эчендә тордык та калдык. Чигенер җаебыз да юк, борылыр чамабыз да... Ә алда — ике урам киңлеге тоташ боз җәелеп ята...

Коточкыч хәлдә калуыбызны аңлыйм. Ләкин берни эшләргә кулымнан килми. Әнигә нинди дә булса киңәш бирергә түгел, сорау бирерлек тә чамам юк. Әни дә аптыраушта. Күзләре белән кемнедер эзләгәндәй, хәрәкәтсез генә алга карап торды. Аннары арт якка борылып карады. Тирә-якта бернинди адәм заты күренми. Кайдан күренсен? Бу бит хәзер ташланган юл, моннан беркем дә йөрми. Хәтта бүген боз өстенә уйнарга чыккан малайлар да юк...

Берәр җирдән өметле аваз ишетелмәсме дигәндәй, әни сагаеп, тынып калды. Аны күреп, мин дә тындым. Безне аңлагандай, Турат та хәрәкәтсез. Ниндидер шомлы тынлык. Кинәт, йөрәгемне ярып, көчле гудок...

— У-у-у-у!..

Клеменков тегермәне улый.

Авылыбызда күптән түгел генә ишетелә башлаган бу хәтәр тавышка без һаман ияләшеп җитә алмый идек әле. Ул тәрәзә пыялаларын зырылдатырлык көчле тавыш белән кинәт үкереп җибәрүгә, йөрәк урыныннан кузгалып, тетрәнеп китә. Улаган саен көчәя барган тавыш колак элләрен кычыттыра...

Ләкин бу дәһшәтле тавыш бер вакытта да минем ачуымны китергәне юк иде әле. Каладан да, заводтан да, тимер юллардан да еракта булган, Агыйделнең дә пароходлар йөрми торган җирендә утырган безнең авыл өчен (ходай иркендәге күк күкрәүне искә алмаганда), эт өрү, сыер кычкыру, ат кешнәүдән дә көчлерәк тавыш ишетмәгән Җиргән өчен, яңа иде ул. Гомуми тынлык эчендә бер генә булгач, ул аеруча хәтәр яңгырый, үзенең дәһшәте, мәһабәтлеге белән мине сокландыра, хәтта авылыбыз өчен горурландыра да кебек иде. Янәсе, әнә нинди бит ул безнең авыл! Аның тавышы хәзер үзебезгә генә түгел, күрше-тирә авылларга да ишетелеп тора. Кала кебек!

— Тамагыңа таш кергере! — дип куйды әни.

Мәһабәт гудок тавышына карата мондый ачы каһәрләү сүзләрен олы яшьтәге кешеләр авызыннан моңарчы да күп ишетә идем. Тик аңа нигә болай ачулануларын аңламыйм, бары тавыш яратмаучы картлар мыжыклыгы дип кенә уйлый идем. Бу юлы әнигә кушылып, минем дә ачуым килде. Нәрсәдер аңлагандай булдым.

Клеменковның Җиргәндәге иң зур бай икәнен белә идем инде. Базар мәйданында зур таш кибете бар. Рус урамындагы иң шәп өй — аныкы. Почмакка салынган таш кладовое бөтен тыкрык буенча сузылган, әллә тагы бер җир буе бардыр. Биргидел буендагы пристаньнары тагы! Өстәвенә, әнә быел шул ук Биргиделнең аръяк яры буена кирпечтән зур пар тегермәне салып җибәрде. Өч ташлы! Он тартуы гына җитмәгән, шунда ук такта яра торган заводы да эшли. Исебез китеп, карап торганыбыз бар: кочак җитмәс юан нарат бүрәнә, тимер юл буйлап, пычкылар арасына кереп китә, ә дигәнче унлап-унбишләп тактага әверелеп килеп чыга. Тегермәнгә дә, такта заводына да — икесенә бер моржа. Мәчет манарасыннан биегрәктер! Кычкыртып җибәргән чагында янында булсаң, бер мәлгә бөтенләй саңгырауланып каласың...

Күпме байлык кирәк мондый тегермән салырга? Безнең этиләр сугышта нужа күрә. Ә Клеменков? Мөгаен, безнең этидән яшьрәктер әле. Гел өр-яңа киемнән генә йөри. Башындагы бүреге генә дә ни тора! Нинди җәнлек тиресеннәндер, башка беркемдә юк андый шәп малахай...

Белмим, ул вакытта байлык-ярлылык турында бу дәрәҗәдә үк ачык фикер йөртә алдыммы икән? Ләкин мин шуны тойдым. Кайдан да булса ярдәм кулы сузылмасмы, берәр өметле аваз килмәсме дип як-ягыбызга караганда, гудок тавышы безне мыскыл иткән кебек булып ишетелде.

Тегермән бу урыннан чакрымга якын еракта булса да, яр буйларын каплаган ялангач әрәмәләр аша үзе күренмәсә дә, тын һавада тавышы нәкъ колак төбендәге кебек яңгырый. Ул безгә, әлбәттә, бернинди ярдәм итә алмый, киресенчә, көн үтеп, кич булуын гына исебезгә төшерә. Менә хәзер төн килер, иртәнгә кадәр атыгыз-арбагыз белән бергә бозгаябышып катарсыз, дия кебек. Чынлап та, көн караңгыланырга тора. Һава салкыная. Боз өстенә чыккан су күзгә күренеп катып бара.

Гудок, үз тавышына үзе соклангандай, бик озак улап торды. Тәмам күңеле булып туктаганнан соң да, минем тыным бетмәде әле дигәндәй, тагы бер үкереп куйды.

— Үз башыңа улагыры! — диде әни. Башка берни дәшмәде. Аптырап, йөзенә карыйм. Җитди. Аның шундый кызганыч хәлдә калуын күреп, елыйсым килә башлады. Ләкин җаным-тәнем белән тоям: еларга һич ярамый. Әнигә тагын да начар булачак. Еларсың, елаганың өчен ачуланса я кыйнаса — бер хәл. Әгәр үзе дә елап җибәрсә?.. Чү! Ул ниндидер бер нияткә килде. Дилбегәне миңа бирде.

— Мә, улым, мин әйткәч, атны куарсың. Мә чыбыркы. Җәлләмә, каты тот!

Утын арасына кыстырып куелган балтаны суырып алды. Ридуан читеннән бозга сикерергә омтылды да тукталып калды. Курыкты, ахрысы... Юк, курыкканнан түгел икән, пимасын сала башлады. Бик матур кара пимасы бар иде. Җыйнак кына итеп басылган булу өстенә, куныч читләренә тар гына кама да тотылган иде. Ул аның бирнәгә килгән пимасы булган. Әни аны кадерлегә генә киеп, бик күп еллар буена матур килеш саклап килгән. Хәзер инде, искергәч, камалары пеләшләнеп бетеп, асларына олтан да салынгач, көндәлек эшкә кия башлады. Әле кар яумаган булса да, көн салкын, җир туң булганга, утынга да шуны киеп килгән иде... Нигә сала ул аны? Боз өстенә ялан аяк төшмәкче буламы? Чынлап та, ул ялан аяк калды.

— Әни, нишлисең син?

— Бүтәнчә булмый, улым...

Һәм ул өстенә су чыккан бозга сикереп тә төште.

— Бик әйбәт, — диде, шатлангандай итеп, — мине күтәрә икән әле.

Йөгереп ат алдына чыкты да бозны балта белән чабып кисәргә тотынды. Аны арба сыярлык киңлектә ике як читләп чабып, юл ача башлады... Шаккатып карап торам, юлның әле бер ягына күчә, әле икенче ягына. Сусыз җирләргә басканда бозга ябышкан табаннарын чатырдатып куптарып ала... Бик күп бит әле аңа чабарга! Ничек ул тиклe бозны берүзе кисеп чыгар? Арыр бит ул...

— Әни, мин дә төшәм!

— Тик кенә утыр! Дилбегәңә кара! — Шундый кискен итеп әйтте әни бу сүзләрне, миңа яңадан авыз ачарга да урын калмады... Шул минутлардагы әнине кызгануларым!.. Юк, кызгану гына да түгел, әллә нәрсә... Чиксез хөрмәт... Чиксез ярату... Аңа бернинди дә ярдәм итә алмавыма өзелеп җаным әрнү!.. Хәзер дә тыныч кына искә төшерә алмыйм мин бу күренешне. Әнә ул, бозны ике як читләп өч-дүрт адым чамасы кискәч, атка каршы читеннән аны балта түтәсе белән сугып, китеп-китеп төшерә башлады. Әле артык калынаерга өлгермәгән боз зур-зур кисәк булып, карап торуга җиңел генә кителә, ләкин ике яктан да тоташ бозга терәлгәнлектән, агып китә алмыйча, юлда җыелып тора иде.

— Ку атны!

Бар көчемә тырышып дилбегәне кактым, гайрәтләнеп, атка кычкырып җибәрдем.

— На-а-а! — Өстәвенә, кулымнан килгән кадәр каты селтәнеп, чыбыркы белән суктым.

Турат хәлне аңлап алды, иң элек сыңар алгы аягын болгап, җыелып яткан бозларны куды. Урыннарыннан кузгатылгач, аларның бер өлеше

агым белән боз астына кереп югалды. Ат өч-дүрт адым алга атлап, әлегәватылып өлгермәгән яңа боз-кыртә каршына килеп тукталды. Бу хәлне күреп, әни тагын да гайрәтләнә төште. Акыллы ат чынлап та эшне аңлап, әнигә ярдәм итәргә теләдеме, әллә бозлы суда аяклары өшүгә чыдый алмыйчамы — чит-читләре чабылган бозны дагалы тояклары белән үзе сугып сындыра башлады. Бу хәлне күреп, әни бик куанды:

— Әнә шулай, әнә шулай, рәхмәт төшкере хайван!

Күпме вакыт үткәндер, мәгәр без Иделне кисеп, әйе, кичеп кенә түгел, туры мәгънәсендә балта белән кисеп, бирге якка чыкканда караңгы төшеп җитмәгән иде әле. Атны көчкә туктаттым. Ахрысы, суыктан җәдәгән булгандыр, ул тизрәк кайтырга ашкына иде.

— Әйдә, әни, тизрәк утыр!

Ләкин әни арбага утырып тормады. Аның аяклары күгәрчен тәпиләре кебек кызарган, кайбер урыннарда балтыры күгәреп-күгәреп чыккан иде. Ул тизрәк пимасын киярга ашыкты.

— Аллага шөкер, болай булгач, — диде әни. — Аягы аяк, бөтен курыкканым шул булды: кендегебез чыгып, хур булмасак ярар иде дип, котым очты... Ярар, син атны тотып бар, мин йөгерим әле.

Икенче көнне Әхмәтша абзый кендекне суырып ала алмыйча, нилэр кыландырган, сихерче дип, үзалдына Нәбине әрли-әрли, әллә тагы ярты көн азапланды: агач чөйле урыннар суда бүртенеп, нygый гына төшкән булып чыкты.

Шулай да бу хәлгә озак кайгырмадык. Авыр бәладән исән-сау котылу куанычы җиңде, шатландык кына. Югыйсә, әни, салкын тидереп авырмасам ярарые дип, бик курыккан иде. Әниебезнең гомумән ятып авырганын хәтерләмим. Шулай да бик таза иде дисәм, дөрес булырмы икән? Килеп-килеп бик каты башы авырткан чаклары була иде. Ләкин ыңгыраша-ыңгыраша булса да, һаман аяк өстендә йөргәч, үз эшен үзе эшләп баргач, без аны чиргә санамый идек. Бервакыт ул сары белән авырды. Йөзе, куллары саргайды. Күз аклары лимон төсле иде.

— Ни булды сиңа, әни?

— Әтиегезне сагынудан сарыга сабыштым, — диде әни, әллә чынлап, әллә шаяртып. — Нигә? «Сагынырсың, саргаерсың, исеңә төшкән чагында» дип җырлаганны ишеткәнегез юкмыни?.. — Ни әйтергә белми торуыбызны күреп, тынычландырырга теләде, ахрысы. — Әле дә шөкер, кара-сары түгел диегез, кара-сары булса үтерә ул, — дип куйды.

Шатландык шул. Чынлап та, кара-сары булса, нишләр идек?

Авылда Галәви дигән фельдшер бар иде, әниебез аңа да күренеп тормады, кемнәрдәндер ишеткән буенча, үзе дәваланды. Җиз самавар подносын ак балчык белән ялтыратып, көзгегә караган кебек, озак-озак шуңа карап торды. Сары төс кеше йөзендәге сарыны ала, имеш. Аның өстенә тагын кемнендер киңәше белән бик күп итеп сарымсак ашады. Болай сарымсакны җене сөйми торган кеше иде, шифалы дигәч, кире какмады.

— Уф, авызларым ут яна! — дип зарлана, үзе һаман ашый иде.

Тагы нинди дарулар кулланганды́р, бу чирне дә шулай аяк өстеннән үткәреп җибәрде, сарысын коеп, әүвәлге матур хәленә кайтты.

Әйтерлек ачыкмыйча, истә калырлык ук дәрәҗәдә туңмыйча да кышны уздырдык. Җылыга чыккач, күңел күтәрелеп китте. Бер көчек алып җибәрдем. Тычкан төсле соры йонлы, ап-ак тәпиле көчек. «Актырнак» кушарга ниятләгән идем дә, әни яратмады.

— Актырнак белән авыл тулган, — диде, — лутчы Белый ног диген (үзенчә, ак тәпине русчалатып, белоножка диярга теләве булгандыр инде).

Әни чаклы әни әйтеп торгач, үземә дә ошап китте бу исем.

— Әйдә, Белый ног булсын!

Белый ногтан ул бик тиз арада Билнакка әйләнеп китте.

Тиз үсте Билнак, яхшы токымнан булмаса да, үзенә күрә зирәк эт булып чыкты. Аның акыллы ярдәмче икәнлеген мин аеруча көтү көтеп йөргәндә күрдем.

Әйе, ул елны миңа бераз вакыт көтүче булып йөрергә дә туры килде.

Әхтәм абзыйларның күршесе Тәкъва Арслан дигән бер сәүдәгәр, үзе генәдерме, тагы берничә кеше белән компания төзепме, ерактагы авыллардан бер көтү сыер кайтартты. Суярга иртә булу өстенә, озын юл үтеп шактый арыкланган малларны бераз көрәйтергә дә кирәк иде, күрәсең, махсус көтүче яллап, аларны Агыйдел буендагы тугайларга чыгардылар. Көтүчегә бер ярдәмче дә кирәк булган. Әтинең энеләреннән кайсыдыр, әни белән сөйләшеп, мине тәкъдим иткәннәр. Әз булса да акчасы килер дигәннәрдер инде.

Башта мин моңа бераз гарьләнгәндәй булдым. Ул елларда көтүчелек иң түбән һөнәр исәпләнә иде. Хәтта һөнәр дә түгел, һөнәрсезлек санала, ягъни кулыннан башка бернинди дә эш килмәгән кеше генә көтүче була дип карыйлар иде.

— Җүләр, — диде әни, — мир көтүе түгел бит, бай көтүе. Өй борынына кереп, чиратлап ашап йөрисе түгел. Җалунҗа аласың. Усал телле бичәләрдән әр ишетәсе дә юк...

«Җалунҗа» дигән сүзе җитте, артыгын әйтеп торуның да кирәге юк иде. Ләкин әни дәвам итте.

— Йоклап калган ялкау киленнәр белән әрепләшергә дә туры килмәс. Аннары килеп, син бит әле көтүче дә түгел, көтүченең ярдәмчесе генә. Көтүче дигәне дә кем! Бәкер бит, шундый акыллы егет...

«Бәкер» дә дигәч, мин инде риза булдым гына түгел, тизрәк көтүгә чыгарга ашкына башладым.

Ашкынуым юкка булмаган икән. Сыер көтү мин уйлаганга караганда күңеллерәк эш булып чыкты. «Җалунҗа» дигәне күпме булгандыр, үземә түгел, турыдан-туры әни кулына кергәч, анысы онытылган. Мәгәр көнозын табигать кочагында, ямьле тугай әрәмәлегендә йөрү рәхәт иде. Телисең икән, кычкырып җырлап җибәр. Телисең икән, сыерлар белән сөйләш. Ачуың килсә, әрлә үзләрен, теләсәң нинди авыр сүз әйт — үпкәли белмиләр. Кәефең күтәренке, күңелең йомшак чак булса, телең белән юмала, учларың белән янбашларыннан сөй.

Бәкер миңа абый гына түгел, менә дигән иптәш тә булды. Иң элек без аның белән чыбыркы ишеп алдык. Кыска саплы, озын койрыклы — менә дигән көтүче чыбыркысы! Салабаш юкәсеннән. Ягъни аръяктагы Салабаш күленә кем тарафыннандыр батырып куелган юкә кабыкларыннан тасма-тасма итеп суеп алынган сап-сары йомшак юкәдән. Очлары сүс! Прәме шартлатып туя торган түгел.

Җәй инде узып барса да, көннәр җылы иде әле, көн үзәгендә хәтта эссе дә була. Тынычлыкны иң нык бозучы — безелдәвек кигәвен иде. Янына килеп, бер урында безелдәп тора башласа, бетте, теләсә нинди сыер койрыгын чәнчеп чаба башлый. Күзе тонып, котырып, кая барганын белмичә төрлесе-төрле якка чапкан сыерларны бергә җыеп кара син! Мылтык атканнан шәп шартлый торган чыбыркың белән дә берни эшли алмыйсың, җан-фәрман тырышып синә ярдәмгә ташланган Билнагың да, кайсы хайван артыннан йөгерергә белмичә, аптырый, хәлдән тая...

Бәкернең тәҗрибәле кеше булуы безне бу бәладән бик җиңел коткарды. Көн кыздыра башлау белән көтүне су буена — туплауга төшерәбез. Сыерлар тиздән суга керәләр дә, койрыкларын селти-селти, күшәп торалар. Ә без яр буенда ял итеп, сыйланып утырабыз. Әйе, ашап кына түгел, кунактан болай сыйланып!

Көтүебездә бозавыннан аерып сатылган савым сыерлар да байтак булган икән. Бәкернең тәҗрибәле күзләре аларны җиленнәреннән таныды һәм беренче көнне ук үзенең кечкенә чиләген тутырып, савып та алды. Туйганчы җылы сөт эчтек. Хәтта Билнакка да өлеш чыкты. Икенче көнне Бәкер чиләге янына зур гына коштабак та алып килде. Миндәге кыр чәйнеге дә хутка китте. Хәзер инде без сөт эчү белән генә канәгатьләнмибез, аның каймагын гына аерып алу чарасына керештек. Моның өчен яр астыннан, ләхет уйган шикелле итеп, җирне чокып алдык та, булган савытларыбызны сөт белән тутырып, шунда тыгып куйдык. Икенче көн килүебезгә сөт өстенә бер илле каймак утырган иде.

Тагы бер-ике көн үтүгә, безгә гади каймак кына да ярамый башлады.

— Ә син беләсеңме, — диде миңа Бәкер, — иң тәмлесе — пешкән каймак инде аның!

Бик сирәк, анда да саран гына эләгә торган пешкән каймакның нәрсә икәнен белә идем.

— Их!

— Эшлибез аны, — диде Бәкер, — шушы чаклы сыерга баш булып йөреп, пешкән каймак та ашамаска, без кемнән ким?!

Баксаң, бер кыенлыгы да юк, моның өчен сөтне башта кайнатып алырга гына кирәк икән. Яр куышына кайнаган сөт утыртып киттек. Иртән килүебезгә менә дигән пешкән каймак әзер.

Шул көннән башлап, төп ризыгыбыз пешкән каймак булды. Ипи белән бәрәңгене яки тары боткасын аш төрләндереп алу өчен генә тотабыз. Ара-тирә Бәкер өсте алынмаган сөттән генә катык оетып та куйгалый. Билнак та алдыннан калганчы сөт эчә...

— Саф һава килеште сиңа, Мирсәяф, — ди миңа әни бер көнне. — Чыраең матурланып китте...

Эшнең саф һавада гына түгел икәнлеген әйтү юк, Бәкер кисәтеп куйды:

— Сөт турында син бел дә мин бел!

Суяр өчен кайтарылган бу сыерлардан сөт-май да алу мөмкинлеге хуҗаларның планына кермәгән иде, күрәсең: безгә аларны теләгәнчә саварга ирек, моңар игътибар итүче дә юк иде.

Кара көзгә кадәр рәхәтләндек пешкән каймакка. Билгеле, салкын яңгыр асларында азап чиккән көннәребез дә булгандыр. Тамак тук булгач, артык ис китмәгән, күрәсең, алары онытылган.

Кар катыш яңгырлар ява башлагач, көтүгә чыгу бетте. Озак та үтмәде, бер иртәне йокыдан торып чыгуыма күзләрем чагылды: бөтен җир өстен ап-ак кар каплаган иде. Капка төбенә чыксам, каршыма Габдрахман килә — иң якын күршебез тимерче Әхмәди малае.

— Их, малай, — ди миңа, — куян эзәрләргә шәп инде бу кар!

— Чынлап та. Әйдә, Билнакны ияртеп, аръякка чыгып әйләнәбез.

Билнак үзе дә янибызда икән, исемен ишеткәч, шатлыгыннан чиный ук башлады. Куян дигән сүз дә колагына кереп калды, күрәсең, ни кыланырга белми. Телдән әйтеп бирә алмаса да, бөтен хәрәкәтләре, кыланышлары белән аңлатып тора: «Әйдәгез, киттек!»

Көтү белән йөргән чакларда мин аны «әнә куян!» дип алдарга ярата идем. Куянны күрмәс борын ук аның исен сизә иде, ахрысы, озын колак үткән эзләрне иснә-иснә, бөтен яланны бетереп чаба иде. Мин аны, башка этләрдән күреп кенә шулай кыланадыр, куян исен сизмидер дип йөри идем, сизгән икән. Шулай иснәнеп йөри торгач, бер көнне чын куян өстенә барып төртелде бит. Кечкенә куак төбендә яткан икән. Билнак, бу хәлнең чынлыгына үзе дә ышанмагандай, бер мизгелгә аптырап калды. Атылып чыккан куян ул арада шактый ерагаеп та

өлгергән иде инде. Билнак, форсатны ычкындыруына гарьләнгәндәй, чинап елый-елый куян артыннан ташланды. Ләкин кая тегенең артыннан җиту! Ярсып кына калды этем. Тыела алмыйча, көне буена тызбыз чабып, җирне исни-исни куян эзләп йөрде.

Ау эте түгел иде ул, ләкин эткә хас аучылык хиреслеге җитәрлек иде үзендә. Әнә бит, «куян» дигәнне ишеткәч, ниләр кыланган була...

— Әйдә, Габдрахман, киттек. Билнакның да күңеле булыр.

Яңа яуган җепшек кар өстендә нинди генә эзләр юк! Тычкан эзләре дисеңме, төрле кош-корт эзләреме кирәк! Салабаш күле буенда ярылып яткан куян эзләре дә күренә башлады.

— Билнак! Кайда Билнак?!

Этебез авыл читенә чыкканнан бирле өзлексез чаба, эзләнә, борынын җиргә төрткән хәлдә әллә кайларга китеп югала да тагы яныбызга әйләнеп килә иде.

Безгә җавап урынына куаклар арасыннан аның дәртләнеп, ярсып чинаганы, шул ук минутта «пыжжык, пыжжык» итеп куян кычкырганы ишетелде.

Үзебез дә куян җитезлеге белән тавыш килгән якка ташландык.

Билнак чынлап та бер куянны эләктергән булып чыкты. Тик аны, чын куян эте кебек, басып кына ята белми, корсак астыннан капкан килеш як-якка селти иде. Ау эте булмаса да, мин килгәч, каршылык күрсәтмәде, куянны бирде. Менә дигән үр куяны! Тере. Аяк тибеп тартышырлык көче дә бар иде әле.

— Чал тизрәк! — дип кычкырды Габдрахман һәм миңа үзе ясаган чалгы пәкесен китереп тоттырды.— Мә! Тиз бул, үлеп әрәм булмасын.

— Бисмиллаһи алла-һәкпәр!..

Кайткан вакытта миннән дә бәхетле кеше бар идеме икән бу дөньяда! Куянны, ике арт аягын бергә кушып тотып, җилкә аркылы аркага асканмын да, күкрәк киереп кайтып барам.

Габдрахман да шат. Куян минеке, ләкин аның да өлеше зур бит. Иң кирәк вакытта аның үткер пәкесе булмаса, нишләр идең! Ите харамга әйләнгән куян күтәреп кайтуның шатлыгы болай ук зур булмас иде.

Ул Билнакның шатланулары! Прастуй йорт эте башы белән куян тоткан бит. Әллә кем булып кайтып килә, мактанчык. Куян исенә башлары әйләнеп, сәлам бирергә чыккан чит этләргә, очлы тешләрен күрсәтеп, ырылдап кына үтә. Җепшек кар яумаган булса, күрсәтер иде сиңа куян койрыгын!..

Әй әни шатланыр инде, әни!..

Ләкин әни бөтенләй мин көткәнчә каршы алмады.

Муены киселгән башы белән түбән салынып кайткан куянның каны агып, арт яктан бишмәт чабуымны да, чалбар балакларымны да буяп эштән чыгарган икән. Әни иң элек шуны күреп алды.

— И бала, бала! — диде. — Бу кадәр пычранмасаң, булмадымыни? Ничек чистартабыз инде хәзер бу киемнәрне? Биш тиенлек куян — ун тиенлек зыян менә шушы инде ул...

Шулай да минем, түбәм күккә тиеп кайтып кергән җирдән кинәт бик күңелсезләнеп китүемне күреп, хәлемне тиз аңлады. Куянымны мактап куйды. Үзебез тотканга ышанмыйча, исе киткән булды.

— Кем суйды?

— Үзем. Бисмилла әйтергә дә онытмадым.

— Куянны ничек тунарга икәнлеген беләсеңме соң?

— Беләм.

— Ярар, алайса, тиресен бозмыйча гына тунап бир, — диде. — Куян бәлеше ашарга Габдрахманны да чакырырсың инде.

Менә ичмасам әни! Бу сүзләре өчен күңелем аңа рәхмәт белән тулды...

Инде эретү ихтималы күренми башлагач, теге сыерларны суярга тотындылар. Андагы канлы күренешне күз алдыма китерсәм, хәзер дә имәнеп китәм. Таза-таза ирләр зур-зур сыерларны ансат кына егалар да, дүрт аягын бергә кушып бәйләп, кыйблага каратып салалар. Берсе хайванны ике мөгезеннән тотып, башын өскә таба каерып тора. Кулына зур, үткен пычак тоткан суючы киерелгән бугазны тирән итеп кисеп җибәрә. Бәреп чыккан кан фонтанын махсус чокырга юнәлдерәләр. Хайван берничә секундка тынып кала, аннары бөтен тәнен көзән җыергандай тартыла, киерелә, бәйләнгән аяклары белән тыпырчынырга азаплана. Коточкыч хырылдау тавышы чыгарып, киселгән бугаз аркылы сулыш ала. Бу хәл берничә минут дәвам итә...

Миңа имәнеч. Ләкин ниндидер кыргый кызыксыну хисе җиңә, күземне алмыйча, итчеләрнең бөтен хәрәкәтләрен җентекләп күзәтеп торам. Әлегә суелмаган сыерлар да, үзләренә чират житкәнне көтеп, бу тамашаны карап торалар. Ямьсез, имәнеч тавыш белән шомлы итеп мөңгериләр. Итчеләр шәп эшли. Суелган мал тынып җитәр-җитмәстән аякларын тез тиңентен кисеп ташлыйлар да, корсагыннан, бот турыларыннан тиресен ертып, аны тунарга керешәләр. Аннары арт аякларыннан югарыга асып, тиресен салдыралар, карынын ачып, үпкә-бавырларын, эчәкләрен алалар. Күп кенә сыерларның бозаулары чыга. Кайсы яңа яралган, әле мәче хәтле генә. Кайсылары шактый зур — инде эт чаклы булганнар. Барын да ташлыйлар. Арада тәмам зураеп җиткән, йоннары да чыккан, озакламый туарга җыенган тере бозаулар да килеп чыга. Итчеләр мондый бозауларның матур тиресенә кызыгалар, шунда ук суеп, тунап алалар да, аның да итен ташлыйлар.

Эчәк юуучы хатыннардан берсе, бу хәлне күреп, уфтанып куя.

— И ходаем! — ди. — Бозаулар көне җиткән сыерны бугазлыйлар. Саткан хуҗасын әйтер идем...

Тиле Нәкыя дигәне аңа каршы төшә.

— Сатырсың. Иреңне суярга алып китсәләр.

— Син әйтерсең.

— Әйтмичә!.. Дөньясы кан эчендә. Моның ише генәме? Адәм каны!..

— Тиле дисәң, тиле...

Кеше әйткәнгә ияреп, мин дә ул хатынны тилегә генә саныйм, аның сүзләреннән көләргә генә әзер идем. Баксаң, аның бөтен тилелеге күңелендә ни барын яшерә белмәвендә, хәтта, киресенчә, аны күпертеп әйтергә яратуында булган, күрәсең. Бәлки ул, мескен, язучы булу өчен дөньяга килгән булгандыр?

Теге вакытта, әлбәттә, башыма мондый уйлар килми, мине иң нык кызыксындырганы шул туарга өлгермәгән килеш тунап ташланган бозаулар һәм гомумән суелган малның ашарга ярамый дип, кисеп ыргытылган артык-портыклары иде. Билнак өчен бушка килгән менә дигән ризык. Мин аларны күп итеп, — әллә тагы өч-дүрт пот булгандыр, — үзебезнең келәткә ташып куйдым.

5

## КҮРШЕЛӘРЕБЕЗ. БЕРЕНЧЕ УКЫТУЧЫМ. ҖИЗНИ. ДҮРТЕНЧЕДӘ. ГЕРМАН ТАВЫ. МЕНӘ СИҢА ПАТША!

Авылның урта өлеше — күбрәге байлардан, хәлле кешеләрдән һәм мещаннардан торган урамнар — иске мәхәлләгә карый. Имамы да мәхәлләсенә юш килгән: иске фикерле, кадим карашлы Гыйният мулла. Безнең ише малайларның аеруча ачуын китергән тагын бер гадәте оныттылмаган: минем белән бер яшь чамасында улы бар, мулла шуны үзе

белән ашка алып йөри иде. Янәсе, үзенә алмаш хәзерли, малаен мулла булырга өйрәтә тора. Тегесен әйт син! Кара төлке Гыйният мулланың үзенә ошамаган сигез-тугыз яшьлек сары малае әтисе белән бергә өлкәннәр мәҗлесенең түренә менеп утыра. Берәүдән дә тартынмыйча, нәфсесе теләгән сыйларны сорап алып, туйганчы ашый, өстәвенә, зур бәйрәм көннәрендә малайлар янына чыгып мактана: «Кичә уникe кешегә ашка барганыек, бүген унсигез җиргә», дип шапырына... Кызык иттеләр үзен: «Бәлеш төбе» дигән кушамат тактылар.

Иске мәхәлләнең мәзинен дә «Карт мәзин» дип кенә йөртәләр иде. Минем аның исемен белгән чагым да булмады. Зур ак сакалы белән тавышы гына хәтеремдә. Аның азан әйтүен яратып тыңлый иде халык. Ул чынлап та азанны нечкә, ләкин саф ирләр тавышы белән, бөтен шартын җиренә җиткереп, сузып, тыңлаган саен тыңлыйсы килерлек матур итеп, көйләп әйтә иде. Аның тавышы безнең мәхәлләгә дә ишетелә, бигрәк тә иртәнге я кичке тынлыкта еpактан килгән аваз тагын да моңлырак булып яңгырый иде. Ә безнең мәзиннең, яшь булса да, әлләни моңы юк, азанын дорфарак тавыш белән хиссез генә итеп әйтә, үзе болай карап торуга да руханидан бигрәк кара мужикка охшый төшә; һәр мәет аның кулы аркылы үтсә дә, ягъни әледән-әле теге дөнья белән эш итә торган кеше булса да, күбрәк бу дөнья турында кайгырта, йорт-җиренә, хуҗалыгына ябышып ята иде. Шундыйлыгы турында халык телендә йөргән бер кызыклы гына сүз дә колагыма кереп калган. Иртәгә җир бүләсе көнне мәзинебез, бер төркем халыкка мөрәҗәгать итеп, хатынының бүген-иртәгә бала табарга торуын әйткән, җан башыннан җир бүлгәндә шул туачак баласын да исәпкә алуны сораган, имеш. Ләкин мәхәллә кешеләре бер-берсенә карап елмайганнар гына. Арадан бер җоррак теллесе әйтеп тә куйган.

— Син, мәзин, — дигән, — лутчe тизрәк өеңә кайт та остабикәңне абзар башыннан сикерт!

Булса да булгандыр, безнең мәхәллә күбрәк фани дөнья кешеләреннән, дин әһелләренә карата артык исе китми торган кара халыктан тора иде.

Жиргән авылын көнбатыштан көнчыгышка таба аркылы кисеп, сусыз елга чокыры уза. Яз көннәрендә ул бик хәтәр елга төсен ала. Ярларыннан чыгып, урамнарга җәелеп, котырып ага. Мондый вакытларда аны исеме белән әйтеп, «Каен колка» ташуы дип сөйлиләр. «Колка»сы ни дигән сүздер, аңлашылмаганга булса кирәк, без, малайлар, аны Каен күркә дип йөри идек. Әүвәлрәк безнең авылның көньяк очы шул Каен күркә белән чикләнгән. Шулай булганлыгын зират күрсәтеп тора. Зират янында тимерлек тә бар иде. Тора-бара, халык ишәйгәч, Каен күркә аръягына чыгып утыра башлаганнар. Әкренләп шактый озын ике урам барлыкка килгән. Ул як, мин белгәндә инде бик күп өйләре искереп беткән булса да, Яңавыл дип йөртелә иде.

Безнең өй иске авылга керә. Каршыбызда гына — тимерлек. Тимерлек артындагы калкулыкта — каберлек. Берәр кеше турында «тимерлек артына киткән» дисәләр, бу инде «ул кеше вафат» дигән сүз була. Зираттан өстә — рус урамы. Олы урам дип тә йөртәбез. Чөнки ул олы юл буйлап сузылган. Олы урамнан да ары — арткы урамнар. Анда — башлыча — мукшылар.

Сул яктан янәшә күршебез — тимерче Әхмәди йорты. Ләкин каршыдагы таш тимерлек аныкы түгел. Аның тимерлеге авылдан читтә — Биргидел буенда, агач алачык. Семьясы зур. Габдрахман исемле улы белән бергә уйный идек. Әлеге, минем белән бергә куянга барган малай. Ачуланышкан чакларда мин аны такмаклап-такмаклап әтисенең кушаматы белән мыскыллый идем:

Тугыз бармак-Әхмәди,
Атаң арыш чәчмәди,
Анаң урак урмады,
Ашарыңа булмады...

Арыш чәчмәсәләр дә, мин үзем аларны ярлыга санамыйм, тимерлекләре миңа бик зур байлык булып күренә иде. Габдрахманга ияреп, еш кына бара идем мин аларның тимерлегенә. Осталарның, кызган тимердән очкыннар чәчрәтеп, төрле корал ясауларын сокланып карап торам, кайвакытта өргеч басарга кушсалар — аны үзем өчен бәхет саный идем. Габдрахманга исә, бу «бәхет» көн дә эләгә, хәтта ул аның кадерен дә белми иде шикелле. Болай үзе бик үткен, зирәк малай иде ул. Тимерлектә үзе генә калырга туры килгән чакларында иске чалгыдан чакма, пычак кебек әйберләр әтмәлли, хәтта ачыла-ябыла торган пәке дә ясый иде. Аның өстенә тагын, үзе минем хәтле генә булса да, русча да белә, мукшыча сөйли башласа да теле-телгә йокмый. Хәер, аның урынында булсам, бәлки мин дә белер идем. Ул бит, җәен-кышын дигәндәй, шул тимерлекләреннән кайтуы булмагач, анда әтиләренә ияреп килгән рус малайлары белән дә, мукшы, чуваш малайлары белән дә көн саен очрашып тора, алар белән уйный, сөйләшә. Ә безнең рус малайлары белән очрашуыбыз еракtan торып бер-беребезгә таш атышудан ары китми.

Балалык дустым Габдрахман турында алдарак тагын искә алырга туры килер әле. Янып торган алсу йөзле, җитез хәрәкәтле бу малайның йөрәгемдә гомергә онытылмаслык яра калдырган фаҗигасе турында язмый булдыра алмам дип уйлыйм. Ә хәзергә аның белән эшләгән бер шуклыгыбызны гына хәтергә төшереп үтик.

Бакчага төштек. Кем бакчасына диген? Мәзиннекенә! Мәзиннең өе урамның безгә каршы як рәтендә, нәкъ мәчет турысында. Бәрәңге, яшелчә бакчасы артка — зират тыкрыгына барып чыга. Шул тыкрык буйлап, шыпырт кына бакча турысына килеп җиттек. Кичкырын. Якынтирә — тып-тын. Бакчалар, өйләр арасыннан азан әйткән тавыш ишетелде. Безнең өчен ул азан түгел, ә мәзиннең өйдә юклыгы турында хәбәр. Габдрахман читән аша бакчага кереп китте. Мин, бу хәтәр эшебезне яман күзләрдән саклап, тыш якта калдым. Каяндыр бер кыз килеп чыкты. Кәримә исемле, матур гына, акыллы гына кыз. Бозау куып килә. Аска карап кына узып китте. Мине бөтенләй күрмәде дә кебек. Куркыныч кеше түгел дип уйлаган идем, күргән икән. Ни арада әләкләп өлгергән диген! Бер минут үтмәгәндер, Габдрахман, кулына яфрагы-ние белән йолкынган биш-алты төп кишер тотып, читән аша төшүгә, тыкрык почмагыннан атылып, Шәмсетдин килеп чыкты — мәзиннең күршесе, «Кара тәкә» дип йөртәләр. Кирегә борылсак... каршыбызда озын җирән мыек — Габделгани абзый! Уңга да, сулга да юл бикле булгач, киртә аша сикереп, зират эченә кереп киттек. Башка вакыт булса, кичке эңгер-меңгердә каберләр арасына кереп китәргә куркыр идек әле. Ә бу юлы! Күзгә берни күренми. Биек, куе булып үскән үләнне, шайтан таякларын ерып, кабер калкулыкларына абына-сөртенә, каядыр йөгерәбез. Кара тәкә белән Мыек — безнең арттан... Тоттылар. Әрләми-сукмый гына мәзиннең ишегалдына алып килделәр. Икебезне янәшә бастырып куйдылар. Янибызга хатын-кыз, бала-чага җыелды. Аю күргәннәрмени! Бары да исләре китеп безгә карап торалар.

Сәгыйть тә шунда, мәзиннең улы.

Берме-икеме яшькә олырак булса да, гәүдәгә миннән кайтышрак бу малайның мәзин гаиләсеннән икәнлеге ничектер сизелеп тора иде.

— Без татар түгел, — ди иде ул милләт турында сүз чыккан чакларда. — Без мөселман!

Аеруча хәтердә калган ягы: карбыз теләнергә оста иде. Безнең авыл мукшылары арасында, Агыйдел аръягыннан җир алып, бакча чәчү

практикасы бар иде. Җәй азакларында алар, арбаларына карбыз-кавын төяп, татар урамнары аша үз өйләренә таба узалар, ә без, татар малайлары, кычкырып теләнә-теләнә, алар артыннан йөгерәбез.

— Ләләй, карбыз бир әле!..

Ләләйләргә (ягъни мукшы агайларга) кызык иде, күрәсең, соравыбызны кире какмыйлар, йөкләренә өяләмә итеп тутырылган эреле-ваклы карбызлар арасыннан иң кечкенәләрен сайлап, безгә тәгәрәтеп җибәрәләр, безнең кем өлгерештән карбызга ташлануыбызны тамаша кылып кәефләнәләр. Гадәттә алар беребезне дә буш итмәскә тырыша, юашрак, кыюсызрак малайларга хәтта чакырып алып тоттыралар...

Малайлар арасында исә, мөмкин кадәр үзен мескен күрсәтеп, чын теләнче осталыгы белән сорый белүче дә, тәгәрәтеп җибәрелгән карбызларны эләктереп алуда иң шәп өлгерлек күрсәтүче дә Сәгыйть иде. Ул, башка малайлар шикелле, бер карбыз белән генә канәгатьләнми, эләктергәнен тиз генә читән буендагы кычыткан арасына яшерә дә, тагын арба артыннан йөгерә, бакчачы рус урамына борылып күздән югалганчы тынычлана алмый иде.

Бер көнне без, аның белән икәүләп, Аргыйделгә балыкка киттек. Ике Идел арасындагы аулак юл өстендә эре-эре карбызлар төягән бер арбага тап булдык. Арба янында безнең кадәр генә башкорт малае. Кучәрләре сынган да икән, этисе, атка атланып, авылга киткән.

Ике татар малае килеп чыккач, теге курка калды бугай, сораганыбызны да көтмичә, һәр икебезгә берәр карбыз тоттырды. Йодрык кадәр генә түгел, бала башы хәтле карбызлар! Көтелмәгән шатлыктан кәефләнеп, ары киттек. Күп тә узмадык, Сәгыйть тукталып калды.

— Нигә без болай бик тиз китеп бардык әле? — ди миңа. — Шундый юмарт, әйбәт малайдан нигә тагын берәр карбыз сорамадык?

Кире әйләнеп килдек. Малайның чырае караңгыланды.

— Атаем да килеп етер инде,— дип мыгырданырга тотынды. Шулай да, ачуыбызны китерүдән курыкты бугай, теләмичә генә булса да, безгә тагын берәр карбыз бирде.

Киттек. Хәзер инде Сәгыйть баягы кебек шат түгел. Карбыз саклаучы малайның караңгы чырай күрсәтүенә ачуы килгән.

— Кара син аны, нинди эре торган була. Талап алмаганның кадерен белми. Биш-алты карбызын алып, үзен кыйнап китсәк тә, нишли алыр иде ялгыз башы? Яхшылыкның кадерен белмәгән өчен, әйдә тагы барып берәр карбызын алабыз!

Мин моны килештермәдем. Сәгыйть үзе генә барырга кыймады. Ары киттек. Аргыйделгә җиткәндә генә каршыбызга өч-дүрт малай килеп чыкты. Бары да зурлар. Сорашып та тормадылар, кулларыбыздан карбызларыбызны сугып төшерделәр дә, ваткалап ашый да башладылар. Сәгыйть елый-елый тегеләрне каргарга тотынды.

— Юлбасарлар,— диде,— кеше малын талаган өчен ходай тәгалә барыбер җәзасыз калдырмас! Хәрәм ризык тамагыгызга аш булып түгел, таш булып барсын! Күргәнегез-күрмәгәнегез шул булсын! Теге дөньяда биш итеп түләрсез, җәһәннәм кисәүләре!..

Бәләкәй генә малайның шундый килештереп каргана белү тегеләргә кызык тоелды, күрәсең — көлделәр генә. Сәгыйть үзе әйтмешли, кыйнап китсәләр дә нишли алыр идең?..

Әнә ул хәзер хәйран калган кыяфәттә безгә карап тора. Көлми дә, еламый да. Шулай да бөтенләй дәшми кала алмады:

— Менә хәзер эти кайтыр,— диде,— кирәгегезне бирер...

Кайтты. Каршыбызга килеп басты. Эшнең нәрсәдә икәнен белде. Ник бер генә сүз әйтсен шунда. Нә үгетләп, нә әрләп. «Кирәгебезне» бирүе шул булды: берәр тапкыр чигәбезгә сукты. Каты суккандырмы, йомшакмы — анысы хәтердә калмаган. Әмма гарьлеге зур булды. Ни хәтле кеше карап торганда бит!

Ул вакытта Кәримәгә бик ачуым килеп йөргән иде. Зурайгач, акылга утыргач, мин аны күңелемнән гафу иттем. Маладис кыз булган икән ул. Җәлләмәгән дә безне, үч алырлар дип, куркып та тормаган, үзенә «әләкче» дигән яман ат тагарлар дип тә борчылмаган...

Уң як күршебездә — мәчет. Ике арада рәшәткә белән киртәләнгән зур гына бушлык. Мәчет бакчасы дияргә дә була. Тик анда куе, биек булып, бакча үләне генә үсә. Иң матур чагында аны мәзин чабып ала... Мәчет белән бер ишегалдында — мәдрәсә.

Күршедә генә булгач, мәдрәсәдә торучы ялгызбаш хәлфәләр безгә йомышка-фәләнгә дә кергәлиләр, әни исә аларның үтенечләрен кире какмаска тырыша: ипи пешереп бирә, керләрен юа иде.

Беренче укытучым Һидаят хәлфә булды. Тегермән-елга дигән башкорт авылыннан чыккан матур ак чырайлы, аз гына җирәнсу кара мыеклы чибәр егет иде ул. Кигән киемнәре дә бик шәп: ап-ак күлмәк, кап-кара кыска бишмәт, (пиджакны бездә шулай диләр иде), аягында ботинка, ботинка гына да түгел, штиблет. Минем карамакта хәлфәләр гомумән бары да бик яхшы киенә, алар миңа иң бай кеше булып күренә иде.

Һидаят хәлфә безнең авылга үзе белән бергә кечкенә энесен дә алып килгән иде. Уңайлырак фатир тапканчы дип, ул аны безгә урнаштырды. Ничек сыеп торганбыздыр — хәзер гаҗәпләнәм. Мәгәр ул вакытта миңа бик яхшы иптәш булды. Хәлфәнең энесе белән бергә булгач, мәдрәсәгә — ят малайлар арасына барып керү бер дә куркыныч тоелмады. Хәлфә дә мине танып, үз күреп кабул итте.

Мәдрәсәдә беренче булып күзгә бәрелгән нәрсә — кара такта һәм аяклы счет иде. Боларның яңа мәдрәсә, ягъни җәдид мәктәбе билгесе икәнлеген мин соңыннан — зурраклардан ишетеп белдем. Ә парталар искечә — тәбәнәк иде әле. Аның янына аяк бөкләп, берни дә җәелмәгән как идәнгә утыра идек. Ләкин иске мәдрәсә калдыклары парта белән генә бетсә, бер хәл буласы икән. Һидаят хәлфәбез үзе карап торуга шундый чибәр, ягымлы булса да, хәтәр кызу канлы кеше булып чыкты. Дәрес биргән вакытта берәр малайның игътибарсыз утырганын яки күршесе белән сөйләшкәнен күрсә, кисәтеп-нитеп тормый, кулындагы дүрт кырлы правиласы белән шап итеп тегенең башына кундыра. Тәртип бозучы бала арткы партада булып, сугарга буе җитмәсә, кулындагы акбур белән җибәрә. Әз генә дә ялгышмый: бармак башы кадәр акбур шук малайның нәкъ маңгаена барып тия. Кече атна көннәрендә шәкертләрнең кулларын, колак эчләрен карый. Тырнагын җитү булса, бармакларыңны өскә каратып тота да, тырнак очларыңа правиласы белән суга. Керле булса, колагыңны да борып куя. Малайлар хәер биргән вакытта өстәлгә кемнең нинди акча салганын күзәтеп тора. Ничек белгәндер, нинди күрәзәлеге булгандыр, әгәр берәр бала әтиәниләре биреп җибәргән хәер акчасының бер я ике тиенен яшереп калса, аны шунда ук фаш итә...

Кем уйлаган, бүгенге көндә бөтен дөньяны шаулаткан безнең КамАЗ төзелешенә шул кызу канлы хәлфәнең нинди дә булса бәйләнешы булыр дип?

Һидаят Сәгъдиевнең революция елларында кызыл гаскәр сафына китүе, аннары Башкортстанның дәүләт эшлекләре җөмләсендә йөрүе хакында ишеткән чакларым булды. Стәрлетамактанмы, Уфаданмы Җиргәнгә кунакка кайтып йөргән чакларын да беләм. Үзен күрдемме-юкмы, мәгәр малае хәтеремдә. Тәлгать исемле шук кына, курнос кына малай иде. Өстенә кесәле-билбаулы итеп, фабричный киндердән тегелгән күлмәк, ботларына кыска штан киеп йөремәсә, бәлки онытылган да булыр иде.

Шушы китапны язып утырганда (ягъни Һидаят хәлфәне якыннан күргәнем юкка инде алтмыш елдан артык вакыт узгач) безгә, якташ итеп, өстәвенә әнисе ягыннан Фәүзия апасына әзме-күпме кардәш тиеш икәнлеген дә искә төшереп, шул Тәлгать килеп керде. Инде пенсия яшенә җитүенә карамастан, бөтен хәрәкәтләрендә, йөзендә-күзләрендә, сөйләгән сүзләрендә тормыш дәрте кайнап тора. Мәскәүдәге менә дигән җитеш тормыштан, хатынын һәм буй җиткән ике улын да алып, КамАЗ төзелешенә килгән икән.

Мәскәү институтын тәмамлагач, төзүче-инженер сыйфатында ул озак эшләргә дә өлгерми, сугыш башланып китә. Курск-Орлов ныгытмаларында сугыша Тәлгать, Гомель, Жлобин, Варшава калаларын азат итү сугышларында катнаша, ниһаять, Берлинга барып җитә.

Сугыштан соң нинди генә төзелешләрдә катнашмый ул! Данлы Салават каласы, андагы химкомбинат. «Дуслык» нефть үткәргечләре, газ трубалары... Иртыш-Караганда каналы, Саратов ГЭСы, Тольятти, ниһаять — КамАЗ!

Шәһәр төзүгә баглы йомышлар белән Казанга килгән саен ул безгә төшә, үзе белән бергә өебезгә җилле-давыллы КамАЗ сулышын алып керә...

Тәлгатьтән мин әтисе турында да сораштым. Һидаят Сәгъдиев чынлап та Кызыл Армия беренче оешкан көннәрдә үк үзе теләп фронтка китә. 1919 нчы елда Коммунистлар партиясенә керә. Петроград фронтында аерым башкорт бригадасының комиссары сыйфатында Юденичка каршы сугыша. Гражданнар сугышыннан соң, яңа гына оешкан Башкорстан җөмһүриятенең беренче мәгариф комиссары була. Соңыннанрак, махсус курсларда укып кайтып, Башглавсудта эшли. Утызынчы елларда мәгариф эше буенча Кыргызстанга җибәрелә.

Шәхсән үземә Һидаят хәлфәнең усаллыгы тимәде. Энесе безнең өйдә торганга гына түгелдер, гонаһсы булса, ул үзенең энесен дә аямый торгандыр, хәлфәнең ачуын китерерлек шуклыклар эшләмәгәнмендер. тормый иде. Дәрескә күңел бирүче, сабагын белүче, тәртип бозмаучы балаларга карата ягымлы иде ул. Минем, күрәсең, тәртип ягым ярыйсы Ә сабагымны белү ягыннан... Башкалар мәдрәсәдә өйрәнгәнне мин өйдән үк белеп килгән идем инде. Хәлфә моны күреп алды. Сабакка төшүемә бер атна үтүгә, мине беренче сыйныфтан икенчегә күчереп утыртты. Татар мәктәбендә яшьтәшләремнән бер сыйныф алда баруым шуннан башланды.

«Миңа кечкенәдән китап күрергә туры килде» дигәнем Мәрьям апаның дәресләкләрен генә күздә тотып әйтелгән сүз түгел. Бәдретдин җизни дигән кешебез бар әле.

Стәрлетамак шәһәрендә әнинең апасы бар иде. Без аны бәләкәй абыстай дип йөри идек.

Бәдретдин Гыйбадуллин, аның ире, үз заманының ярыйсы күренекле кешесе булган. Стәрлетамак халкы аны, үз итеп, Бәдри учитель дип йөри иде. Заманында аны якыннанрак белгән кешеләрнең сөйләвенә караганда, ул Башкорстанның Кабак авылында, күп балалы ярлы крестьян гаиләсендә туган. Яшьтән укуга дәртле булып, җәяүләп Оренбургка киткән. Бәхетенә каршыдыр инде, патша хөкүмәте тарафыннан чит халыклар (инородецлар) өчен махсус учительская семинария ачылган чакка туры килгән. Аны шунда алганнар. Анда укып чыккан кешеләр, чит халык балаларын русчага өйрәтү генә түгел, аларны бөтенләй руслаштыру буенча эш алып барырга тиеш булгандыр. Иң башлап, семинарияне тәмамлап чыгучыларның үзләренә христиан диненә күчәргә тәкъдим ителгән. Ләкин күпчелеге мөселман динендәге кешеләрдән торган укучылар арасында бу тәкъдимгә риза булучылар бөтенләй

диярлек табылмаган. Бу хәлне күреп, патша хөкүмәте семинарияне беренче чыгарылышыннан соң ук яптырган диләр.

Бәдретдин дә, әлбәттә, чукынмаган. Ләкин ул, Россия шартларында чорының алдынгы культуралы кешесе булу өчен, ягъни үз халкың арасында аң-белем тарату эшләре алып бару өчен, рус телен белергә кирәклеген яхшы ук аңлап чыккан һәм үзенең бөтен көчен татар-башкорт балаларын русча укытуга багышлаган. Иң элек аны бер башкорт авылына җибәргәннәр. Бернинди мәктәп күрмәгән надан авыл кешеләре балаларын капыл гына русча укыта башлауга куанмаганнар гына түгел, киресенчә, куркуга төшкәннәр. Патша мондый эшне яхшылык белән эшләмәс, кафер итәргә ниятләмиләрме? Учитель тоттырып кайтарган грифель тактасын да күргәч, артык сабырлары калмаган, балаларын мәктәпкә җибәрүдән бөтенләй баш тартканнар.

Тагы нинди юллар үтәргә туры килгәндер, мәгәр аның эшчәнлеге балалар укыту белән генә чикләнмәгән. Мин белә башлаганда Бәдретдин җизни Стәрлетамак шәһәрендәге «Каләм»[1] ширкәтендә китап чыгару, китап сату эшләре белән дә шөгыльләнә иде.

Эти сугышта чакта әниебез шул бәләкәй абыстайларга кунакка барып кайтты. Тәмле-тәмле кала күчтәнәчләре дә алып кайткан булгандыр, әлбәттә. Ә менә гади киндер капчыкка тутырып, бик күп китап алып кайтуы онытылмый. Китапларның, әлбәттә, барысының да исемнәре хәтердә сакланмаган. Авторлары турында әйтәсе дә түгел. Шулай да, әни төртеп күрсәткәнгәдер инде, Бәдретдин җизнинең үз исеме кергән китапларга игътибар ителгән. «Асылмыш кунак», «Шерлок Холмс» дигән китапларның тышына Б. Гыйбадуллин исеме язылган, ул аларны татарчага тәрҗемә итеп чыгарган иде.

— Менә монысы Рәифә апаң язган китап,— диде әни.

Анысы «Ертанач» дигән бик кызыклы әкият китабы булып чыкты. Тышына чынлап та «Рәифә Гыйбадуллина» дип язылган иде.

Бәдретдин Гыйбадуллин катнашы белән чыгарылган китапларның сәер бер үзенчәлеге хәтердә: аларда, ул заман китапларына хас булган бисмилла урынына, «Таш илә атканга аш илә ат» дигән мәкаль язылган була иде. Моның серен еллар үткәч, беркадәр укыганның соңында, Бәдретдин җизнинең үзен күреп тә белә башлагач, аңладым: ул Лев Толстойны бик яратучы, аның фәлсәфәсе белән яшәргә тырышучы кеше булган икән.

Исемнәрен ташка басылган китап тышында күргәч, Бәдретдин җизни үзе дә, аның олы кызы Рәифә дә миңа буй җитмәс югарылыкта, бөтенләй башка бер дөньяда — байлар, патшалар дөньясында яшәүче кәрамәт ияләре булып тоелдылар.

Әни алып кайткан китаплар арасыннан тагы: «Бичара колның тормышы» («Хижина дяди Тома»ның тәрҗемәсе икәнлеген соңыннан белдем), «Ләкләк белән суалчан», «Зилзилә», «Су анасы», «Таз малай», «Шаян Фәһим», «Яз тамчылары», «Суматра сыртланы», «Кеше», «Башкорт кызы Маһинур» исемлеләре; «Г. Тукай диваны» һәм тагын берничә шигырь, җыр китаплары хәтердә калган.

Шулар өстенә тагын «Ак юл», «Ан», «Кармак», «Чүкеч», «Ялт-йолт» журналларының аерым саннары бар иде.

Мәрьям апа да, мин дә, дөньябызны онытып, шул китапларга ташландык. Әни үзе дә читтә калмады. Ул язу яза белми, ә китап укырга бик ярата иде. Тик ул бу күңелле эшкә безнең кебек үк дөньясын онытып бирелә алмый, безне дә, артык мавыгып, үз өлешебезгә төшкән өй эшләрен дә онытып җибәрә башласак, тыярга мәҗбүр була, яхшылап

---

[1] «Каләм» ширкәте һәм Б. Гыйбадуллин турында «Казан утлары»ның 1976 елгы 3 нче санында П. Гәрәй мәкаләсе басылды.

әйтүгә генә аерыла алмасак, кулыбыздагы китапны тартып ук ала торган иде.

Дүртенчедә укыганда мин иске мәхәллә мәдрәсәсенә күчкән идем инде. Мөгаллимебез Гариф хәлфә иде. Аның турында шунысы исемдә калган: читтән килгән чибәр егет иде. Ярдәмчесе Һади хәлфә белән бер бүлмәдә тора иде. Өйләнеп, бабаларына күчте.

Гариф хәлфә бик пөхтә киенеп йөри, балалар янында үзен эрерәк тота иде. Шуңа булса кирәк, аның ярдәмчесе Һади якынрак иде безгә. Малайларга аеруча ошаган ягы шул булды: имтихан вакытларында кемгә нинди сорау биреләчәген алдан әйтеп куя иде. Дөрес, ул моны бик озак ялындырып эшли, коры үтенүләргә генә эреп төшми, баерак, хәллерәк малайлар, акчалата булсын, әйберләтә булсын, төрле бүләкләр вәгъдә итә башлагач кына бераз йомшаргандай була, ниһаять, өлкән хәлфәгә дә, муллага да, хәтта эти-әниләребезгә дә бу турыда берни сиздермәү шарты белән, сер саклау турында кат-кат антлар иттереп, үтенечебезне канәгатьләндерергә риза була иде. Һәм, ул сүзендә торган кебек, без дә серне нык тотабыз, аны бирәүгә дә чишмәү үзебез өчен дә бик әйбәт иде.

Үзенә нинди сорау биреләсен алдан белеп килгән шәкерт, нинди мокыт бала булса да, аптырап калмый инде. Ул аны дәреслегеннән кырык кат укып, ятлап килгән.

Күпчелеге кара надан этиләр өчен балаларының бөтен халык алдында әнә нинди «четерекле» сорауларга чатнатып җавап бирүен үз колаклары белән ишетеп тору — уен эшмени? Хәлфә өчен дә дан! Мәхәлләсендә шундый хәлфә тоткан мулла өчен дә мәртәбә!..

Без укыган җәдит мәктәбе, эти-әниләр укыган иске мәдрәсәләр белән чагыштырганда, әлбәттә, бик зур алга китеш булган. Дүрт ел эчендә без анда бик әйбәт итеп укырга-язарга өйрәндек. Ике икең — дүрт, җиде җидең — кырык тугыз булганлыгын, җирнең түгәрәк икәнлеген, Кояшның Җир тирәли түгел, Җирнең үзенең Кояш тирәли әйләнгәнен белдек, кыскасы, хисап, җәгърафия фәннәрен заманына күрә ярыйсы гына үзләштердек. Шуның белән бергә без, бер сүзен аңламаган хәлдә, гарәпчәне, җиренә җиткереп, нәкъ тәҗвит күрсәткәнчә укырга өйрәндек. Бер сүзен аңламаган хәлдә, әфтиякне укып чыктык, коръәнгә төштек. Бер сүзен аңламаган хәлдә, биш вакыт намаз укырга өйрәндек. Үз халкыбызның тарихын өйрәнүебезне хәтерләмим, әмма «Тарих-ислам», «Тарих-әнбия» китапларын укыдык...

Шулар өстенә тагын әнә русча уку өчен махсус ачылган школаның да беренче сәгатьләрендә дин сабаклары...

Гатаулла мулла дәресеннән күңелем кырылып чыккач, тиз генә кәефем ачылмады. Иптәш малайлар каршында үземне ничектер гаепле хис итә идем. Герман тавына да барасым килмәде...

Герман тавы дигәнем шул: безнең авылда кайдандыр — сугыш барган яклардан күчеп килгән берничә семья Австрия кешеләре — качаклар булды. Нужадан йөрсәләр дә, күрәсең, бик үк ярлыдан булмаганнардыр: зуррак өйле, хәллерәк кешеләргә урнашкан иде алар. Җиргәндә зур-зур байлар шактый булса да, ике этажлы йорт салдырган кеше юк иде әле. Бердәнбер ике катлы өй булса, ул да Кисәкәй абзыйларныкы иде. Качак гаиләләрнең берсе шул Кисәкәй абзыйларда торды. Бездән ерак булмагач, шулары белән күбрәк очраша идек. Рита, Тамара исемле ике кызлары, Рустик дигән бер малайлары бар иде. Бөтенләй безгә ошамаганча, кыска штан, җиңсез күлмәк киеп йөри торган, төскә-биткә ап-ак матур булган бу балалар беренче җәйдә үк диярлек татарча сөйләшергә өйрәнделәр. Балалары гына түгел,

эти-эниләре дә. Тик алары ватып-җимеребрәк сөйли, әмма Рита белән Тамара да, Рустик та татардан аергысыз иделәр. Без алардан әзрәк нимесчәгә дә өйрәнә башлаган идек тә, алар татарчаны бик тиз үзләштергәч, өйрәнү дигәнебез кызык өчен генә кайбер аерым сүзләрне отып калудан ары китә алмады.

Шушы балалар өчен этиләре Кисәкәй абзыйларның бәрәңге бакчасында бик зур итеп кардан тау өйделәр. Кыш көннәрендә бәләкәй чанага яки боздан ясалган чуманга утырып тау шуу авылда әүвәл-әүвәлдән бар уен инде ул. Тик без күбесенчә табигать үзе ясаган таулардан яки чокырлардан файдалана идек. Кайвакыт үзебез өеп ясасак та, ул бик кечкенә чыга, артык шома да булмый. Ә тегеләр ясаган тау!.. Аны күрүгә башта хәйран калып, карап торасың әле. Абзар башыннан да биек итеп өелгән. Ике як читенә тип-тигез итеп, карның үзеннән кисеп, баскыч ясалган. Сөзәгрәк кенә булып, әллә кая хәтле сузылган өсте көзге пыяласы кебек шома. Үзе киң тагы! Үзе тау беткәч тә тигез җир буйлап, бәрәңге бакчасының иң артына кадәр барып җиткән.

Үзем күргәнче үк аның турында малайлардан ишеткән идем инде. «Герман тавы» дип, исем дә кушып өлгергәннәр иде. Иң элек ул тауда Тамаралар, Рустиклар шуган. Алар белән бергә эти-эниләре дә... Үз бакчаларында булгач, Кисәкәй абзый кызлары да читтә калмаган. Аннары инде, тауга якын килергә түгел, бакча эченә керергә дә икеләнеп, читән аша гына карап торучы башка малайларны дәшеп алганнар.

Мин килеп күргәндә аны бер көтү малай сырып алган иде инде. Икешәре-өчәре бергә янәшә ятып шуучылар дисеңме, тәпи баскан килеш, бии-бии, сикерә-сикерә, егыла-тора шуучылар дисеңме — ни генә кыланмыйлар! Шунысы кызык: герман тавыннан шуу өчен бәләкәй чана да кирәкми, чуман да. Кайсы астына әрҗә тактасы салып утырган, кайсы — гади чыпта. Кайсының астында бишмәт чабуыннан башка берни юк... Бары да шуа! Иң шәбе — аякларына чабата кигән малайлар. Кайберәүләре юри суга басып, табаннарына боз катырып алганнар. Андыйлар таудан төшеп җиткәч тә туктый алмыйча, бакчаның иң артындагы читәнгә үк барып бәреләләр. Ул андагы шау-шу! Нәрсә әйтеп булса да кычкырмаган кеше юк. Кычкырмый мөмкин дә түгел: очкан кош җитезлеге белән шуып барганда күңелгә тулган шатлыкка, рәхәткә чыдар хәл юк. Кычкырасы килә, кешеләрне үзеңә каратасы килә. Иллә мәгәр бу германнар да эт кешеләр икән! Ничек иренмәгәннәр диген? Бала-чага өчен бит!..

Ул кышны мәктәптән соң Герман тавына чыкмый калган көн булса да, сирәк булгандыр. Эниләр берәр йомыш кушып кына эшне бозмаса, анда бармый мөмкин түгел иде кебек. Яз якынлашып, көннәр җылыта башлаган булса да, тау бирешми, кичләрен аның яны гөрләп тора иде әле. Шулай да теге көнне минем анда барасым килмәде. Икенче көнне дә школага барырга гадәттәгечә атлыгып тормадым. Югыйсә, дәресләр башланганчы малайлар белән бераз күңел ачып алу өчен, мөмкин кадәр иртәрәк барырга тырыша идем.

Дәрес башлану минутын гына чамалап килдем. Ничек каршы алырлар, кичәгене искә төшермәсләрме? дип, икеләнә-икеләнә генә кердем...

Бу ни хәл?

Гадәттәгечә, көн дин дәресе белән башланырга тиеш иде. Гатаулла хәлфә бик төгәл килә торган иде. Ә бүген?!

Дәрес башланыр вакыт җиткән. Школа эчендә ниндидер ыгы-зыгы. Миңа игътибар иткән кеше дә юк. Мулла бөтенләй күренми. Учитель юк та юк инде, аның дәресләре мулладан соң... Малайлар нәрсәгәдер алгысыган, ярсыганнар. Бер төркем кара такта янына өелешкән. Идәнгә карап нидер кыйланалар. Каты-каты әрләү, каргау сүзләре әйтәләр.

Яхшы ук кына сүгенү сүзләре дә ычкына. Әллә берәр карак тоткан-нар? Әллә берәрсен күмәкләшеп дөмбәсләләр инде? Идәнгә дөп-дөп китереп тибәләр...

Якынрак килдем. Төркемнең уртасына уздым. Карасам... идәндә — патша!..

Класс бүлмәсенең түр стенасында пыялалы рам эченә куелган патша рәсеме тора иде. Күз ияләшеп беткән булгангадырмы, мин аңа карамыйм да, игътибар да итми идем. Патша чаклы патша портретының адәм хуры булып идәндә ятуын күргәч, игътибар иттем: стенада торгандагыга караганда күп зур икән ул. Ука-чуклы погоннар, әллә нинди кәнәтилләр белән бизәлгән. Хәзер инде малайлар аның җирән мыегы өстенә шәмәхә кара белән озын итеп яңа мыек өстәгәннәр, пеләш маңгаена мөгезләр ясаганнар. Калын-калын итеп төпләнгән һәм баскан саен юеш эз калдыра торган киез итекле яки чолгау урап киелгән чабаталы аяклар, кем узардан ашыгып, патшаның башына, авызына, күкрәгенә тибәләр. Арада үткерлеге, усаллыгы белән аерылып торган бер малай (Динислам исемле иде бугай) аз гына карлыккан, ләкин күпме кычкырса да бетми, һаман көчле, усал яңгырый торган гыжылдавыграк тавыш белән патша рәсеменә җикерә:

— Җитәр! Күп каныбызны эчтең! Күптән шул кирәк сиңа! Мә! Дәмек!..

Менә сиңа патша! Исеменә тел тидерергә ярамый торган, алладан да куркынычрак зат!..

Мулла бөтенләй килмәде ул көнне. Учитель үз вакыты җиткәч килде. Школадагы мәхшәрне күреп, аптырап калды. Аннары патша рәсемен аяк астыннан алып, мич астына тыкты. Үзе дә бу хәлгә әзер түгел иде. Күрәсең, бернинди дә аңлатма бирә алмады. Патша төшерү безнең эш түгел, дигәнрәк мәгънәдә җавап биреп, укытуын көндәгечә дәвам иттерергә теләде. Ләкин малайларның тыныч кына утыра алмавын, укуның бөтенләй рәте китүен күреп, өйләребезгә кайтарып җибәрде.

Шуннан китте инде...

# СВОБОДА — ХӨРРИЯТ

## I

### НИГӘ ҺАМАН МИР ЮК? ӘТИ КАЙТТЫ. ДУС. ЯЗ, УЛЫМ!

Патша төшерелгәннән соң безнең өчен гомергә онытылмаслык яңалык шул булды: күпме вакыт үткәчтер, ике мәхәлләдәге мәктәп балалары бергә җыелып, укытучыларыбыз җитәкчелеге астында урам буйлап җырлап йөрдек. Кайбер җырлары да хәтердә.

Атты таң, нурлы таң, илебезгә
Хөррият кояшы балкыды.
Якты бәйрәм көне килде безгә,
Яңа, шатлыклы дөнья туды...

Икенче бер җырдан мондый юллар истә калган:

Тырышыгыз, балалар, кайгыртыгыз милләтне.
Иттифак бул, балалар, сез пәйгамбәр өммәти.
Өммәти-и-и, өммәти,
Сез пәйгамбәр өммәти!..

Шунысы да истә: үзебезнең татар урамнарында йөреп кенә калмадык, олы урамга да күтәрелеп, чиркәү каршындагы базар мәйданына барып җиттек. Рус школасында укучылар да чыккан икән, контор кар-

шында (волость идарәсе йортын татарлар шулай дип йөри иде) алар белән очраштык.

Ул көнне мәйданга җыелган халык арасында балалар белән укытучылар гына түгел, авыл кешеләре дә күп иде. Руслардан да, татарлардан да. Гади мужиклар гына түгел, арада муллалар да, поплар да бар иде. Зур-зур байлар да, өсләренә погонсыз шинель, башларына соры папаха кигән карт-карт солдатлар да, чая-чая солдаткалар да күренә иде.

Контор болдырына чыгып-чыгып сөйләүчеләр күп булды. Ул андагы шау-шу, андагы тантана! Шатлану, куанышу! Көмнәрнедер әрләү, янау сүзләре!.. Бары да яңа иде миңа, җан тетрәткеч көчле иде. Ләкин мәңге җуелмаслык булып күңелгә сеңеп калганы өч кенә сүз булгандыр. Өч тә түгел, ике.

— Революция!

Һәм ике телдә яңгыраган бер үк сүз:

— Свобода! Хөррият!

Татарлар сөйләгәндә күбесенчә ул ике сүзне бергә кушып, «Свобода-хөррият!» дип әйтәләр иде...

Ул сүзләрнең «азатлык, ирек» дигән мәгънәдә икәнен без аңлый идек инде. Патшаны тиргәргә ирек. Патша кул астында изелеп килгән татар халкына теләгәнен собраниедә чыгып әйтергә — ирек!.. Солдаткалар әрсезләнеп китте. Кайда җае килсә, шунда: «Нигә ирләребезне һаман кайтармыйлар? Нигә һаман мир булмый?» дип кычкыра башладылар...

Безнең кебекләр күңеленә аеруча хуш килгәне: шул көннәрдән башлап, малайларга бөтен авыл буенча гизәргә ирек ачылды. Теләсәң, рус урамында йөр, теләсәң, чуваш араларына барып чык — тигән кеше юк. Рус малайлары татар урамнарына төшә икән — аларга да бәйләнмибез. Әүвәле рус урамнары белән татар ягы арасындагы тыкрыкларга җыелып, кара-каршы таш атыша, кайвакыт якага-яка килеп сугыша да торган идек, ул гадәт тә бетте. Рус малайларына түгел, хәтта дуңгызга да тими башладык. Югыйсә, татар урамына чыккан дуңгызга көн юк, аны тәмам хәлдән тайдырганчы кыйнап, этләрдән талатып кайтара торган идек. Бу кыргый кыланыштан безне зурлар да тыймый, хәтта кайбер абзыйлар үзләре безгә катнашып китә, бернинди гаепсез хайванга кулыннан килгән кадәр каты итеп таяк белән сугып калу, я булмаса аңа таш яки кирпеч белән тондыру савaплы эш исәпләнә иде. Рус урамына чыккан татар кәҗәләренең дә язмышы шундый: рус малайлары аларны күңелләре булганчы кыйнап, муеннарына, койрыкларына, мөгезләренә иске чабаталар, ташландык себеркеләр тагып, адәм хуры итеп кайтаралар иде. Уйлап карасаң, гаҗәп хәл бит! Әйтерсең шундый кыргый гадәтләргә турыдан-туры патша хәзрәтләре үзе өйрәтеп торган! Ул тәхеттән төшү белән халык күзгә күренеп үзгәреп китте. Димәк, дин, милләт аермаларына карамастан, төрле халыклар үзара тату, дус яшәргә зар булып килгәннәр.

Патша төшерелгәч, байларның да борыны төшәр кебегрәк сөйлиләр иде. Юк, исләре китмәде. Хәтта, киресенчә, күкрәкләрен киеребрәк йөри башладылар. Клеменков тегермәне һаман элеккечә гүли, волостьта да әллә ни үзгәреш юк, эш башында да һаман шулар диләр. Кибетләр ачык. Базар мәйданындагылары да, татар урамындагылары да үкертеп сату итәләр...

Кибет эшләгәнен шуннан беләм, беркөнне әни мине керосин алырга җибәрде. Урамнарда карлар бетеп, арба юлы төшкән вакыт. Иөгерәатлый китеп барам. Кулымда шешә. Сәхәү тыкрыгында бер арбалы күренде. Карыйм, сыңар ат җигелгән ящик арбага ике кеше утырган. Берсе безнең Закир абзый. Икенчесе ниндидер солдат. Башында кар-

туз, өстендә тонык яшел күлмәк. Юньләп игътибар итәргә өлгермәдем, Закир абзый, мине күреп, кычкырып та җибәрде:

— Әнә Мирсәяф!..

Солдат елмайды. Шунда мин аның ярыйсы озын һәм оч-очлары әз генә бөтерелеп тә җибәрелгән җирәнсу мыегы барлыгын да күреп алдым. Һәм ни өчендер адымымны тизләтә төштем.

— Мирсәяф, тукта! Кил монда. Мона, этиеңне алып кайттым!

Аптырап калдым. Ул арада солдат арбадан сыргып төште дә миңа таба ашыга башлады. Нәрсә булды шунда миңа — белмим. Оялуыма, каушавыма чыдый алмыйча, атылып, кибет ягына таба чаптым. Артымнан килдеме эти, берәр нәрсә әйттеме — күрмәдем, ишетмәдем. Әйләнеп карарга көчем җитмәде.

Кибеттә, гадәттәгечә, кемдер нәрсәдер үлчәтеп тора, бернечә ир-ат эшсез ләчтит сатып утыра иде. Йомышымны әйтергә ашыкмыйча, бер читкә бастым да, сатучы бушаганны көтеп, дәшми генә торам. Ләкин уйланып, акылымны башыма җыеп торырга ирек бирмәделәр, урамнан тагы бер кеше керде. Иң элек күзе миңа төште.

— Мәсәлим абзый малае ич бу! Нишләп торасың монда? Этиең кайтты бит!

Үзара гөрләшеп алдылар.

— Җибәрегез тизрәк,— диде берсе.— Малайның йөрәге урынында түгел. Әтисен күрергә очынадыр.

«Әтисе кайткан малай» буларак, үземне гаепле кеше сыман сизәм, нигәдер ояла идем. Көч-хәл белән йомышымны әйтә алдым...

Теге кеше дөрес әйтте, йөрәгем урынында түгел иде. Тик тизрәк этисен күрергә очына, дигәне? Юк, эти белән очрашырга ашыкмадым, гомердә булмаганча, әкрен атлап кайттым. Ничек итеп этигә күренергә? Ничек аның белән күрешергә? Аңа нәрсә дип әйтергә?..

Нәрсә бу? Нинди халәт?— шушы көнгә кадәр юньләп аңлап җитә алганым юк. Өч ел көттем бит мин этиемне. Үләр чикләргә җитеп сагынган чакларым була иде. Азмы төшләремдә күрдем мин аны? Эти кайткач тегеләй итәрбез, болай итәрбез, анда барырбыз, монда барырбыз, дип, азмы хыялландым? Бөтен шартын китереп әгузе-бисмилласын әйткәннән соң, бер дә иренмичә, аз гына да авырсынмыйча, чын күңелдән әлхәмен дә укып, «вәлә да-аллин, амин» дип куйганнан соң: «И ходаем, эти тизрәк кайтсын иде, и ходаем, эти тизрәк кайтсын иде» дип, алладан тели-тели йокыга киткән кичләрем аз булдымыни?..

Менә, теләгем кабул булды, эти кайтты. Ә мин?.. «Әтием!» дип аның кочагына атылу кая! Янына барырга, күзенә күренергә кыюлыгым җитми. Оялу дисәң?.. Сагынган, яраткан кешең белән күрешү нигә оят булсын? Курку дисәң, тагы аңлашылмый. Ул да бит мине сагынып кайткан. Әллә мин аның каршында гаеплеме? Юк бит, куркырга бернинди урын юк. Менә шулай, оялырга урын юк җирдә оялып, юктан куркып, каушап тору үзе оят түгелмени? Уйлап карасаң, шулай да бит, андый вакытта уйлап карап буламы соң? Уй кача андый вакытта. Бары тик, эссе бизгәк шикелле, бөтен тәнеңә кабынган мәгънәсез кайнар тойгы ялкыны гына кала. Табигать күзлегеннән караганда, бәлки аның бер мәгънәсе бардыр. Ләкин нормаль хәлме ул, чирме — шушы көнгә кадәр ачыклый алганым юк.

«Шушы көнгә кадәр», дим. Чөнки гомер буена бетмәде миндә ул өянәк. Олыгая килә кими барса да, бала чактагы кебек үк көчле булмаса да, хәзер дә бөтенләй бетте дип әйтә алмыйм. Социаль чиргә санап, аңа каршы көрәшергә тырышып караган чакларым да булды. Ярлы гаиләдә үсү, байлар — «бәхетлеләр» каршында үзеңне ким күреп йөрү... Алай гына да түгел, тамыры ерактанрак килә торган — халкыбызның гасырлар буена кимсетелеп, милли изелү астында яшәве, өстәвенә, ислам дине тарафыннан мигә сеңдереп киленгән коллык ка-

нуннары кебек сәбәпләр эзләдем. Аларның тискәре ролен әле дә инкарь итә алмыйм. Ләкин шигем бар. Ни өчен дисәң, бер үк шартларда яшәгән, хәтта бер үк гаиләдә, бер үк анадан туып үскән адәмнәр арасыннан да төрле табигатьле кешеләр чыга. Берәүләре минем кебек тартынучан, оялучан, берәүләре баладан ук ут чәчеп торган үткен характерлы. Шунысы юандыра: мондый табигатьле булуым миңа эшемдә, хезмәтемдә намуслы, кешеләргә карата гадел, гражданлык бурычларыма турылыклы булырга бер вакытта да комачауламады.

Шулай да, чамадан тыш булганда, оялчанлык, тартынучанлык әйбәт сыйфат түгел, дим. Без яшәп үткән тормыш шартларында бигрәк тә. Үзеңне матди яктан тиешенчә тәэмин итү өчен билгеле дәрәҗәдә эрсезлек, шәхси мәнфәгатең өчен нинди рәвештә булса да активлык күрсәтмәсәң, үзеңә закон нигезендә тиешле булганны да алу читен чаклар булмадымыни? Дөрес, үтә эрсезлекләре белән, үзенә тиешеннән артыгын да алып, гадәтчә генә киенгән ак чырайлы, намуслы кешеләр арасында затлы мехка чумып, йөзләрендә алсу нур балкытып йөрүче танышларыма кызыгып караган чагым булмады. Киресенчә, андыйлар миндә һәр вакыт күңелсез уйлар гына тудыра. Шул ук вакытта ил матди авырлык кичергән чакларда — ашау-эчү, көнкүреш кирәкләре һәркемгә үлчәп кенә бирелә торган көннәрдә, тиешлесен дә ала алмыйча, билбавыңны кысыбрак буарга мәҗбүр булып, моны үзеңнең тыйнаклыгың, үтә намуслы булуың белән акларга тырышып йөрү дә егетлек түгел, әлбәттә.

Тагы шунысы бар: синең кыюсызлыгыңны ялгыш аңлаучылар була. Озак вакытлар бергә булырга туры килгән якын танышларымның үз авызларыннан ишеткәнем бар, беренче күргән вакытта алар мине кайсы бик эре дип, кайсы астыртын-усал кеше дип уйлаганнар. Яшь егет чагымда мин яннарына барырга куркып йөргән чибәр кызлардан кайберәүләре, инде әби булгач, миңа серләрен ачтылар: «Егет чакта сез бик эре, һавалы идегез,— диделәр миңа.— Безнең кебекләр сезнең янызга барырга җөрьәт итә алмый иде», дип сынымны катырдылар...

Табигатемнең гомер буена үзем белән бергә килгән, кайвакыт миңа зарары, кайвакытта файдасы тигән бу үзенчәлеге турында ни өчен болай артык җәелеп киттем әле? Ни өчен нәкъ менә шушы урында? Ихтимал, болай да бик аз белү өстенә, озак вакытлар аерылып торган әтием белән күрешү минутларында ул оялчанлыгым беренче тапкыр шулай көчле рәвештә үзен сиздергәндер...

Бу әле әтинең бөтенләй кайтуы түгел иде, шул ук атнада без аны кире озаттык. Ничә көн кунак булды, ниләр эшләде, бары шунысын хәтерлим: әти әлеге куркыныч дәрәҗәдә сыгылып төшкән түшәм тактасын алыштырып куйды; ә без, балалар, ул көннәрдә бүлмә якта, яртысын диярлек савыт-саба алып торган кечкенә сәкедә кысылышып йокладык. Әти юкта, әнинең ике ягына тезелешеп, түрдә ята торган идек.

Озакламый әти тагын әйләнеп кайтты. Бусы инде бөтенләйгә кайтуы иде. Аның кайда хезмәт итүе, нинди чин белән кайтуы турында кызыксына белмәгәнмен, күрәсең. Бары сугыштан килгән хатларның берсеннән «Житомир» сүзе исемдә калган да, погонында аркылыга тегелгән тар гына җияк барлыгы хәтеремдә. Анысының мәгънәсен әти үзе аңлатып бирде. Бар солдатның да погоны андый булмый икән, «яфәтил» погонына гына шундый аркылы җияк тегәләр икән. Димәк, әтиебез ефрейтор булган. Тугыз ел чамасы гомерен солдат хезмәтенә биргән кеше өчен зур чин түгел.

Әтинең яңа кайткан көннәре булгандыр инде, янына Әхтәм, Ахун абзыйлар (икенче анадан туган үгәй энеләре), күрше-тирәдән тагы кемнәрдер кереп утырды. Әти сугышта күргәннәре турында сөйли, вакыт-вакыт бары да катнашып, кычкырышып алалар, ара-тирә күмәк-

ләшеп көлеп тә җибәрәләр иде. Коммунизм дигән сүзне шунда, башлап эти авызыннан ишеттем. Еллар үтеп, тарих укый башлагач, төшендем: күрәсең, ул фронттан большевиклар агитациясен ишетеп кайткат булгандыр. Коммунизм турында бик дәртләнеп сөйләде. Тыңлап утыручылар да, кызыксынып, аңа кушылып киттеләр.

Ахун абзый иде бугай, этинең иң яшь энесе, каралып яше дә җитеп өлгермәгән егет, кызыгып, әйтеп куйды:

— Чынлап та,— диде,— эшләгән кешегә генә сый-хөрмәт, эшләмәгәнгә — шиш! Зерә шәп булыр иде ул, ә?

Әхтәм абзый (этинең Ахуннан өлкәнрәк энесе; бусы инде солдатта булырга өлгергән, ләкин чирләп, вакытыннан элек кайткан егет) аңа каршы төште:

— Ай-һай,— диде,— бөтен кешегә дә бертигез ашарга бирү? Күпме теләсә шул хәтле? Кияренә кием, ягарына утын? Буламы соң, җүләр! Каян җиткерсен казна гомерендә туя ашамаган ярлы-ябагайга?

— Нигә җитмәсен,— ди эти,— бөтен кеше дә тигез тырышып эшләсә, җитәргә тиеш. Җитәрлек булмаса, ул әле коммунизм да булмый. Аның өчен озак азапланырга туры киләчәк. Нигә? Влач үзе яклап торса? Җир-суга, урманнарга, забутларга, ялчыларга, көннекчеләргә байлар хуҗа булмаса?

Әхтәм абзый төпченә:

— Ә мона минем үз ашлыгымны, я берәр малымны сатасым килсә? Я үземә сатып аласым килсә?

— Юк инде, анда үзеңә башка сату-алуның кирәге калмый.

— Ничек инде?..

— Акча дигән нәрсә бөтенләй үзе кирәк булмый.

Әхтәм абзыйның коты очты:

— Акча булмый?

— Ә нигә кирәге бар аның? Ашарыңа җаның теләгәнне нәфсең сораган хәтле бушлай аласың. Кием-салым да шулай.

— Бушка?! Бөтен нәрсәгә чират торудан башың чыкмас, дүрәк. Юк, акчасыз дөньяның ни кызыгы булсын?!

— Халыкны ярлыга-байга аерган иблис — шул акча инде. Акча бетерелсә, бөтен кеше тигез булачак.

— Ай-һай!.. Ә кем булдыра соң аны, коммунизмны?

— Безнең кебекләр,— диде эти дәртләнеп китеп.— Эшчеләр! (Ул вакытта мин «эшче»не гомумән эшләүче кеше мәгънәсендә генә аңлый идем. Кырда эшлиме ул, абзардамы, өй саламы, итек тегәме, пима басамы, казык кагамы, читән үрәме — бары да минем өчен эшче иде.)

— Ай-һай, кем риза булыр икән?

— Нигә?— диде эти,— менә мин үзем язылырга ниятләп торам әле, коммунист булырга!

— Алла сакласын! —дип кычкырып җибәрде әни.— Авызыңнан җил алсын! Җүләрләнә күрмә! Балаларыңны ташлап, солдатта йөрүләрең җитмәгән, барыбызны да ятим калдырасың киләме? Тәүбә диген!

Бары да көлештеләр. Мондый «хәтәр» сүзләрне эти үзе дә бәхәстә мавыгып китеп кенә әйткән булган, күрәсең, соныннан бу турыда авыз ачканы сизелмәде. Әнинең бу мәсьәләдә карары катгый, этигә йогынтысы да көчле иде булса кирәк.

Икенче көнне үк бугай, без, эти белән икәүләп, тары чәчәргә киттек...

...Атка да улак,
Сыерга да улак,
Кәҗәгә дә бадиян,
Канбулатта Мәхиян!..

Ни мәгънәсе булгандыр бу такмакның — минем өчен ул шулай карангы килеш калды. Эти солдатта чакта кышкы озын төннәрдә безнең өйдә кызлар җыелып кич утыра торган иде. Шул кич утыруларның берсеннән колагыма кереп калган такмак. Мәгънәсез тоелса да, мина бүген әллә кайчан онытылган бер башкорт авылын күз алдыма китерергә ярдәм итте.

Җиргән турысыннан иң элек Биргиделне, аннары борам белән Аргыйделне чыккач, әз генә сулдарак, Иделнең тәбәнәк ярына терәлә язып, Канбулат дигән авыл тора. Ишетүемә караганда, йортлар саны бервакытта да егермедән артмаган бу фәкыйрь авылда бер генә калай түбәле йорт бар иде. Авылына күрә бай исәпләнгән Мәхиян йорты. Ни өчен такмакка кереп киткәндер, анысы белән кызыксынганым булмады. Шуннан ике өй аша гына авылның көньяк читендә Алтынгуҗа исемле дусыбыз тора иде.

Җиргәндә һәр татарның диярлек руслардан яки мукшылардан знакомы, чувашлардан белеше булган кебек, күрше-тирә авылларда яшәүче башкортлардан бер яки берничә дусы була иде. Дуслык шуннан гыйбарәт: базарга яки бүтән йомыш белән Җиргәнгә килгән чакларында башкортлар үзләренең татар дусларына төшәләр. Шунда атларын ашатып, үзләре дә кунак булып китәләр. Күчтәнәчкә кәрәзле бал яки кымыз алып, бичәләрен дә утыртып килгән булсалар, кунып та калалар. Эшләре ашыгычрак булганда, дуслар, базарда гына очрашып, бергәләп чәйнигә кереп чыгалар. Татарлар исә, үз чиратларында, урманга-фәләнгә яки җиләк-җимеш җыярга барып чыккан чакларында башкорт дусларына кереп кунак булалар. Хәллерәк татарлар үзләренең сугымга билгеләп куйган терлекләрен дә, яздан көзгә кадәр дуслары карамагында калдырып, үләнгә һәм яфракка чиксез бай булган башкорт болыннарында симертеп кайтаралар. Сугым суйган көннәрдә бер-берсен кулламага чакырышалар...

Алтынгуҗа агайның өе кара мунча кебек кечкенә иде. Авылның иң читендә. Каралты-кура түгел, киртәләп алынган ишегалды да юк. Урам якка караган кечкенә сынар тәрәзә. Яньчелеп, җимерелеп беткән кабык түбә. Давыллы яңгыр вакытларында ни күргәндер ул өй, кышкы салкыннарда?.. Белмим. Мина аны матур җәй көннәрендә генә күрергә туры килә иде.

Эти белән шуңа килеп төштек. Алтынгуҗа агай үзе өе янындагы бүкән өстендә туздан тырыс үреп утыра иде. Без килеп туктауга, гадәтенчә, ашыкмый гына урыныннан торды, этинең сәламен алды һәм шунда ук, өе ягына борылып карамыйча гына:

— Һин! Самавырды яңарт! — дип кычкырды.

Эти аңа, самавыр кирәкмәс, тизрәк эшкә тотынырга вакыт, дисә дә, кулы белән кояшка ымлап, әнә бит, җәй үтеп бара, дияргә теләсә дә, Алтынгуҗа агай үз сүзеннән кайтырга теләмәде.

— Бәй, канса елдар күрмәгән дусты сәй эчерми ебәрергә ни! Булмай. Ярамай!

Озакламый өйдән тыйнак кына булып хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Самавыр әдер!

Өйнең, читтән генә булса да, үзенә күрә өйалды кебеге дә бар иде. Анда кыек астына эленгән берничә пар каен себерке һәм курыс бәйләмнәреннән башка байлык күренмәде. Өй эче тагын да ярлырак иде. Җир идән. Берни ябылмаган как сәке өстендә калай самавар кайнап утыра, самавар алдына нинди төстә икәне дә беленмәслек алама ашъяулык җәелгән. Борыны кителгән чәйнек тә, саплары төшкән ике пар чынаяк та кырык җирдән чатнап, калай тасмалар белән коршалып беткәннәр. Фәкыйрьлек тагын да ныграк күзгә бәрелә төшсен диган-

дәй, Алтынгужа агайның бичәсе бөкре дә иде. Тик утырган чагында да эһ, эһ итеп тора...

Күзем самавар турысына түшәмнән асып куелган һәм бу минутта ялкау гына кыймылдап торган ялгыз кыбырнамага төште. Алар элек күп булган, ахрысы, хәзер инде башкаларының тузан кунып юанайган җепләре генә селкенә. Кайчандыр алар бары да бөтен булгандыр, төрлесе төрле төстәге матур кәгазьләрдән киселеп, урталарыннан җепкә асылган түгәрәк бизәкләр, кайнар самавардан күтәрелгән пар белән хәрәкәткә килеп, күңелле уйнаклашканнардыр, бу кечкенә өйгә үзләренә күрә ямь биреп, аның ярлылыгын яшереп, кыбырдашып торганнардыр.

Алтынгужа агайның бичәсе кайдандыр төйгән балан түбе, кипкән шомырт кебек сыйлар китереп чыгарды, ашъяулык өстенә бер чите сындырып алынган кара гына төче күмәч куйды да, эһ-эһ килеп, чәй ясарга тотынды. Әти, барыбызга да чынаяк җитмәгәнен күреп булса кирәк, миңа чыгарга, атларны карап торырга кушты. Бөкре апай: «Утырһын, утырһын, берәй сынаяк эсһен», — дигән булса да, артык каршылык күрсәтмәде. Шулай да бер кисәк төче күмәч сындырып тоттырды. Нәрсә онынннан пешерелгән булгандыр, әмма асты-өсте көлгә буялып беткән ул төче күмәч миңа гаҗәп тәмле тоелды.

Әти белән Алтынгужа агай алдан ук сөйләшеп, килешеп куйган булганнар, күрәсең, сатулашып тормадылар, тиз генә чәй эчеп алдылар да юлга чыктык. Без тары чәчәргә китеп барабыз, Алтынгужа агай безгә үзе саткан җирне күрсәтергә бара.

Өч кеше өстенә, арбага тимер сабан, ике тырма, бер капчык тары һәм азык-төлек белән савыт-саба да салынган булуга карамастан, Турат җиңел-җиңел генә юртып китте. Прәшкәгә кола бия дә җигелсә, Туратка җиңелрәк булыр иде дә, әти аны, Әхмәтша абзыйларныкы булганга күрә, җигәргә яхшысынмады, тәртә янына бәйләп, буш кына җибәрде: сабанга җигәргә биреп торулары өчен дә рәхмәт!

Канбулаттан караганда бөтенләй өстебезгә авып килгән Җиргәнтауның Агыйделгә барып бәрелгән чите киртләчләнеп-киртләчләнеп күтәрелгән биек-биек кызыл ярга әйләнеп китә. Шул таба барабыз. Уң ягыбызда тауга кадәр җәелгән тугай — чәчәкләр белән чуарланган ямь-яшел болын. Сул ягыбызда — Агыйдел. Ул, безнең белән ярышкандай, бу турыда ашыгып-ашыгып ага, тауга якынлашкан саен агымын тизләтә барып, безне узып-узып китә. Арба астында — тип-тигез сузылган өч сызыктан торган бернинди сикәлтәсез болын юлы. Юлаучылар аз булгангамы, язгы дымы кибеп җитмәгәнме — аны әле тузан басып өлгермәгән. Ике як чите дә, уртадан салынган тояк сукмагы белән кара каеш төсле ялтырап яткан тәгәрмәч эзләре арасындагы буш урыннары да ямь-яшел. Арба төбендәге ярыклар үтәли алар Агыйделгә караганда да ашыгыбрак артка таба агалар кебек...

И кызык та соң бу дөнья! Хәтта арба астындагы күренешне дә карап туя торган түгел. Әллә янда әти булгангамы икән?

Әтигә мин ияләшеп җиткән идем инде, аның белән бергә шушы юлга чыгуыма чиксез бәхетле идем...

— Ошында! — диде Алтынгужа агай һәм, юртып барган ат адымга күчү белән, арбадан сикереп төште дә үлән арасыннан тауга таба атлап китте.

Без юлсыз болын өстенә яңа эз салып, арбабыз белән аның артыннан борылдык.

Тау инде бик якын булса да, бу җирләр аның итәге түгел иде әле. Тау итәгенә чыгу өчен тугай ярын менәргә кирәк. «Яр» дигәнем, шактый текә булса да, сөзәкләнебрәк күтәрелгән һәм куе әрәмә белән

капланган калкулыктан гыйбарәт. Бу калкулык кырында җәелеп яткан тигез урын, юл буендагы шикелле үк әлмисактан бирле сабан күрмәгән саф болын түгел, ә бәлки кайчандыр сөрелгән-чәчелгән булып та, күп еллар сука-сабан тимәү аркасында, яңадан чирәмгә әйләнгән ту жир иде.

Әти белән Алтынгужа агай, тугай үрен каплаган әрәмәлек кырыннан бер кәжүнни әчминнек[1] жирне адымнары белән генә үлчәп алып, почмакларына казыклар кактылар.

— Булды, — диде дусыбыз. — Игелеген күрегез...

Өч-дүрт көн яттык без әти белән шул бер әчминнек жир өстендә. Гадәттә мондый чирәм җирләрне ачканда сабанга дүрт ат җигәләр. Ә бездә — ике. Үлән тамырлары белән үрелеп, калын киез шикелле булган җир бирешергә теләми, бик авырлык белән генә киселә, гади басу туфрагы кебек төрән астында уалып калмый, тоташ кәс тасма булып, кара ягы белән өскә әйләнеп кенә ята бара. Ике-өч әйләнгән саен тукталып, атларны ял иттерә-иттерә эшлибез. Әти кыр эшләрен бик сагынып кайткан булган, күрәсең, бер дә кабаланмый, Агыйдел буеның саф һавасына, гүзәл табигатенә сокланып туя алмагандай, ял итә-итә, бу көннәрне күрүенә шөкрана кыла-кыла эшли.

Чынлап та, андагы гүзәллекләр сокланып туя торган түгел иде. Тугай тавын каплаган тоташ әрәмәлек аклы-аллы зелпе чәчәкләре белән бизәлгән. Шомырт инде чәчәген койган, шулай да күләгәлерәк урыннарда салмак-салмак ак тәлгәшләр күп әле. Тугай тавының өстендә күзләрнең явын алырлык булып күренгән аллы-гөлле тубылгы чәчәкләре әле дә күз алларымнан китми. Ул андагы хуш исләр! Шулар янына тагын кошлар сайравы!.. Өйдә чакта гомердә болай иртә уянмый торган идем. Ә монда! Арбага терәп корылган яшел куыш эчендә! Әле яктырырга да өлгермәгән, ә мин уяу. Әллә тагы мең төрле кошлар берсеннән-берсе уздырырга тырышып сайрашалар. Һәркайсы үзе белгәнчә сайрый, үзе теләгәнчә кычкыра. Тик берсе дә артык түгел. Берниндн сайрауга охшамаган тартай тавышы да, кәккүк кычкыруы да күңелләрне эретеп яңгыраган нәфис сандугач моңнарын тыңларга комачауламыйлар, хәтта шулары булмаса, сандугач сайраулары бу кадәр моңлы да ишетелмәс иде кебек...

Бу тойгыларым турында мин, өйгә кайткач, әнигә сөйләдем. Әни мине ихлас күңелдән тыңлады. Яратып, аркамнан сөеп куйды һәм йомшак кына итеп, хәтта ниндидер сер әйткәндәй, тавышын акрынайта төшеп:

— Син, улым, аларны яз! — диде.

Нәрсә әйтергә теләде, аңламадым. Яз, имеш! Кемгә языйм мин аны? Нигә?.. Әнидән сорамадым. Үзе шуннан артыгын әйтмәде, ачусыз гына тавыш белән әтигә үпкәләгән булды.

— Мин сезне тары чәчеп яталар дип йөрим, ә сез анда бездән башка гына сахрага чыккансыз икән!

— Сезне дә алып барасы калган икән шул, — диде әти көлеп.

— Нинди тиле бу вакытта ашлык чәчеп йөри инде, — диде әни тагын ачуланмыйча гына. — Акча туздырып, орлык әрәм итеп, юкка көч түгеп, хайван ызалап...

— Хәерле булсын, — диде әти, — үкенмим. Ичмасам, туйганчы рәхәтләндем бер Агыйдел буенда улым белән. Ходай насыйп итсә, бәлки булып та куяр. Нигә? Көз бик иртә килмәсә, тары өлгерерлек кенә вакыт бар әле.

Нәкъ әти теләгәнчә, ул елны көз иртә килмәде, күрәсең, тарыбыз котырып уңды. Сабаклары буынлы камыш кебек озын, нык, таза. Башаклары олы кеше кулы хәтле булып, сыгылып-сыгылып төшкән ул

[1] Әчминнек — буйга 60, киңлеккә 10 сажин зурлыкта.

тары басуын күргән бер кеше хәйран кала: бирсә дә бирер икән ходай, тарының болай котырып уңганын гомер күргәнебез юк иде дип, гаҗәпләнү белдерәләр һәм изге теләкләр теләп китәләр иде.

— Игелеген күрергә язсын, тынычлыкта рәхәтләнеп ашарга насыйп булсын!

Игелеген күрдек. Ашарга да насыйп булды. Ләкин тынычлык мәсьәләсе?

Дөрес, минем өчен, дөресрәге, минем яшьтәшләр өчен тынычлык бозарлык берни дә булмады кебек. Киресенчә, безне шатландыра, рухландыра торган яңалыклар килде авылга. Ә менә эти-әниләр, гомумән өлкәннәр өчен?

Җәй, минем күзлектән караганда, безнең хуҗалыкта әйтерлек үзгәрешсез, хәтта элекке елларга караганда матуррак та, бәхетлерәк тә узган кебек иде. Эти-әниләр белән күбрәк үзебезнең әнә шул матур тары басуыбыз тирәсендә чуалдык. Аны утарга барган булдык, карарга, урырга, алып кайтырга. Һәркемдә булган кебек, безнең ындырыбыз бар иде. Өй янында кечкенә бәрәңге бакчабыз. Өстәвенә, ул елны без кыяр да чәчкән идек. Бусы минем өчен бик зур куанычлы яңалык иде. Эти солдатта йөргән чагында ук ниятләп куйган булган икән: исән-сау кайтсам, кыяр, кишер, суган кебек яшелчәләрне үзем үстерер идем дигән. Безнең авылда руслар, мукшылар, чувашлар өй борынына яшелчә үстерә торган булсалар да, татарлар арасында ни өчендер бу эшкә ригая юк иде. Берәү дә диярлек бәрәңгедән башка яшелчә утыртмый, ул эш белән шөгыльләнеп караучы аерым хуҗалыклар булгаласа да, утырткан җимешләренең игелеген күрә алмыйлар, бакчаларына балачага төшеп, теңкәләренә тия иде.

Мәчет бакчасы белән чиктәш читән буена ике түтәл кыяр чәчтек. Каен корымы кебек кара туфрак, әйтерсең еллар буенча зарыгып, шуны гына көтеп яткан: шыттырып утыртылган орлык ике көндә тишелеп чыкты. Күз алдында өченче яфрак чыгардылар, аннары дүртенчесен, бишенчесен... Тизрәк үсү өчен нәрсәгә булса да тотынырга омтылып, озын-озын кереш җепләре суздылар. Көрлекләре, тазалыклары белән карарга соклангыч нәнечкеле сабакларны сары-сары чәчәкләр сырып алды, чәчәк төпләрендә бодай бөртеге кадәр генә кыярлар күренде. Атна үтәр-үтмәстән, алар өзәрлек булып өлгереп тә җиттеләр. Уртача эрелектәге ямь-яшел кыярлар, берсеннән-берсе матур булып, яфрак араларын тутырдылар.

— Монда бераз сатарлык та рәт бар,— диде эти.

Йөз кыяр тутырылган кәрзинне эти чиркәү каршындагы базар мәйданына — җирдән торып төрле әйберләр: балык, чабата, чүлмәк сатучылар рәтенә китереп куйды да, мине генә калдырып, үзе ни өчендер читкәрәк китте. Нишләргә кирәге миңа әйтелгән иде инде. Кәрзин өстенә капланган кижеле ашаулыкны ачып җибәрдем. Шул минутта ук яныма берничә кеше килеп тә туктады.

— Кыяр?!

Исе китмәгән кеше булмагандыр. Ул җәйдә кыярның базарда беренче күренүе иде бу. Гомер буйларына яшелчә үстергән, шуның белән сату иткән руслар, мукшылар шаккатты.

— Син кемнеке малай?— диде бер мукшы.

Әйттем.

— Вот-так татарин!.. Ничек үстергән алай?

— Эти.

— Молодец, уздырган урустан, мукшыдан да уздырган.

Руслар, мукшылар, чувашлар безнең кыярга карап гаҗәпләнделәр генә, ләкин берсе дә диярлек сатып алмады. Аның каравы, татарлар, башкортлар тын алырга да ирек бирмәделәр. Күз ачып йомганчы диярлек кыярыбызны алып та бетерделәр. Чак акча алып өлгерә

идем. Хәтта барын да алып өлгердемме икән?.. Базарга беренче булып кыяр чыгару, шуның белән халыкны гаҗәпләндерү, мактау сүзләре ишетү минем өчен генә түгел, эти өчен дә күңелле иде.

Соңыннан, еллар үткәч аңладым: бу адәм ышанмас хәл дөнья күргән этинең тәҗрибә җимеше түгел, киресенчә, тәҗрибәсезлек нәтиҗәсе булган икән. Кыяр чәчүнең безнең авылда борыннан сыналып килеп, канунга әйләнгән үз срогы булган. Бу эш белән гомер буе шөгыльләнүчеләр шул срок җитмичә чәчмәгәннәр. Ә без, әле җәй тиешенчә урнашып җитмәгәнлеген, алда кырау төшү ихтималы барлыгын исәпкә алып тормаганбыз, башкалардан берничә көнгә иртәрәк чәчкәнбез дә куйганбыз. Бәхетебезгә каршы, күрәсең, ул елны кыраулар булмаган...

Өстәвенә, көзе! Бөтен кешедән соң чәчкән тарыбызны өлгертеп, җыеп алганчы кырау күрсәтми торган шәфкатьле көз!..



## 2

## ОКТЯБРЬ ҖИЛЕ. БОЛЬШЕВИКЛАР

Көз генә булмаган икән ул, авылыбызда башланган яңа заманның, патшасыз гына түгел, хезмәт ияләре үзләре патша булып яшәр заманның җиллəп, давыллап килгән язы да булган икән.

Мондый көз килсен өчен, 1917 елның язы да кирәк булган шул. Патша Россиясенә — халыклар төрмәсенә — яхшымы-начармы хөррият алып килгән яз!

Патша законнары химаясендә үзләрен түрә хис итеп килгән, хәтта сугыш елларында кеше кебек авырлык күрмичә, кесәләрен калынайта гына барган Җиргән байлары, гомумән, авылның дәрәҗәле кешеләре катлавы, император тәхетеннән төшерелгәч, беренче мәлгә куркып, каушап калганнар. Ләкин пайтәхеттә властьның буржуазия кулына күчеп баруын сизенеп, үзләрен бик тиз кулга алганнар. Хөрриятне дә, иялəшенгән гадәт буенча, үзләре өчен генә дип белгәннәр. Аның мәгънәсен дә үзләренчә аңлаганнар, халыкка да шулай аңлатырга тырышканнар. Һәр халык үзенә аерым ирек алсын, кешеләр ярлыга, байга карап түгел, диненә, милләтенә карап бүленсен, дип барганнар. Милләтне кайгыртырга чакырып, пәйгамбәр өммәте икәнебезне кат-кат исебезгә төшереп җырланган җырлар да мәктәп балалары сафына очраклы рәвештә килеп кермәгәндер.

Безнең авылда татарлар үзләренә, руслар үзләренә (дөресрәге — мөселманнар белән христианнар) аерым урам-урам булып яшәсәләр дә, иген басулары бергә иде. Кайчан шулай бүленгән булганнардыр, өч басуда да безнең җир күршеләребез бер яктан татар булса, икенче яктан рус яки мукшы була иде.

Авылның зур байлары безнең этиләр сугышта чакта ук халыкка җирне яңача бүлеп бирергә җыенганнар. Русларга, мукшыларга аерым, татарларның үзләренә, чувашларның үзләренә аерым итеп, үлчәп тә биргәннәр. Ләкин төрле милләттән торган игенчеләр, ул вакытта әле башлыча солдаткалар, яшәп килгән тәртипне үзгәртергә риза булмаган:

— Мөгез чыгармагыз, кирәк булса, ирләребез кайткач сөйләшербез, безгә шушылай да бик әйбәт,— дип, әүвәлге җирләренә чәчә биргәннәр.

Бу кадәресен мин соңыннан ишетеп белдем. Җир күршеләребез белән ничек яшәвебез турында үзем күреп хәтердә калган бер истәлек тә бар. Шул, эти сугыштан кайткан җәйне, пар басуын сөргәндә булса кирәк, җир күршебез булган Кутлаков фамилияле рус белән берләшеп,

сабанга чактык — этиләр атларын кушып сабанга җигеп, җирләрен бергә сөрделәр. Кутлаков та үзенең улын алып чыккан иде. Яшькә минем чамалырак малай иде ул. Коля иде шикелле. Әтиләр сабан сөреп йөргәндә без аның белән күбрәк арба янында булабыз, суга барабыз, чәй кайнатабыз. Ул татарча белми, мин — русча. Шулай да бер генә минут та сөйләшми тормаганбыздыр. Күз алдыбызда яки кулыбызда булган әйберләрнең исемнәрен сорашабыз. Татарча ничек? Русча ничек?.. Ике арада сүз бетеп торган чакларда Коля русча такмаклар әйтә. Мәгънәләрен аңламагач, бары да диярлек онтылган. Колакка таныш сүзләр кыстырып әйтелгән берничәсе хәтердә калган иде дә, яхшырак аңлый төшкәч белдем, бик үк әдәпле такмак булмаганнар икән.

Сөйләшеп яки такмак әйтешеп кенә калмадык без анда, көлешә-көлешә уйнадык, шаярыштык. Көрмәкләшеп, җирдә аунаштык. Күнелле, куанычлы истәлек булып, шунысы хәтердә калган: бер-беребезне җәберләргә яки кимсетергә теләүнең әсәре дә юк иде күнелдә. Киресенчә, моңарчы якыннан күрмәгән, белмәгән хәлдә, ышанычсызга, дин дошманына санап йөргән кешенең шундый әйбәт, ягымлы булып чыгуын, аның сиңа карата яхшы теләктә икәнлеген, синең белән дусламырга омтылып торуын тою рәхәт иде. Ул минутларда Коля күнелендә дә шундый ук хисләр булганлыгында шигем юк... Гаҗәп катлаулы тойгы иде бу. Әгәр шунда әйтсәләр: рус белән тигез хокуклы булу өчен, үзеңә дә рус булырга кирәк, дисәләр, ягъни үз халкыңнан ваз кичеп, руска әверелергә тәкъдим итсәләр, риза булмау гына түгел, андый тәкъдим белән миңа якын килүчегә каршы күңелемдә ачу хисе уяныр иде. Туган атаң-анаңны оныт, син фәлән кешенең улы бул, ул бит синең атаңнан көчлерәк тә, матуррак та, баерак та, син моңа шатланып риза булырга тиеш! Мондый мәрхәмәт күрсәткән өчен, син аңа рәхмәт әйтергә тиеш, дигән кебек мәгънәсез, акылга сыймый торган тәкъдим булыр иде ул.

Ә болай! Үзең татар малае килеш калган хәлдә, руслар, шулай ук башка милләт малайлары белән бертигез хокукка ия икәнлегеңне белү, шуны бөтен барлыгың белән тоеп тору! Чын бәхет иде ул. Әйе, рус малае белән иптәш булышу — дәрәҗә иде безгә. Аның белән горурлана идек.

Шундый авылда тууым аркасында йөрәгемдә бала чакта ук уянган бу хис миндә соңыннан да кимемәде, зурайган саен үсә генә барды. Икенче милләт кешесе белән якыннан танышу һәр вакыт мине рухи яктан баетып җибәргәндәй була, күңелдә иптәшлек, туганлык, уртак гражданлык хисләре дулкынлануын тоясың. Эчке дөньяң киңәя, иркенәя төшә.

Патша төшкәннән соң сугыштан кайтучы бер безнең әти генә түгел иде, әлбәттә. Теге кайткан, бу кайткан дигән хәбәрләр әледән-әле ишетелеп торды. Көзгә таба сугыштан кайтучылар аеруча күбәеп китте. Башлыча шулар арасыннан, бөтен авылның игътибарын үзләренә җәлеп итеп, тынгысыз кешеләр пәйда булды. Күбесе өсләренә погоны алынган шинель, башларына соры папаха кигән бу кешеләрне «большевиклар» дип йөртәләр иде. Алар күп тә түгел иде әле. Татарлардан нибарысы ун-унбишләп кеше булгандыр. Ләкин бөтен авылны гөр китерергә шулар да җиткән иде. «Совет власте» дигән сүз белән Ленин исеме дә безнең авылда башлап шулар авызыннан ишетелде. Инде колак күнеп өлгергән «революция»гә «контрреволюция» сүзе өстәлде. «Аклар», «кызыллар» турында сөйли башладылар. Хәзер инде руслар белән татарлар арасында бер-берсен чит күрү онытылып, татарларның үз арасында халык икегә бүленде. Икегә генә дә түгелдер...

Бу аермалар, дуслык-дошманлык күренешләре әнә шул большевикларга кемнең ничек каравында күренде. Бөтен авылның телендә шулар иде хәзер. Берәүләр черетеп яманлый. Яманлаулары да төрлечә. Кайсылары гайрәтләнеп, бөтен кешегә ишеттерерлек итеп, кычкырып сүгә аларны; кайсылары исә, як-ягына каранып, пышын-пышын гына аларга ләгънәт яудыра: җәнҗалчылар диләр, кеше малына кызыгучы галахлар, диләр. Икенче берәүләр яклап сөйли. Аларның да кайсылары аяк терәп, берәүдән дә курыкмыйча, ачыктан-ачык әйтә:

— Гаделлек өчен тырышучы, каруннарга каршы көрәшүче батырлар,— диләр.— Эш кешесенең, җәберләнгән ярлы-ябагайның тормышын яхшырту уенда йөриләр, совет власте өчен, ягъни властьны халыкның үз кулына алып бирү өчен җаннарын аямаучы гайрәтле ирләр,— диләр. Аларга карата яхшы нияттә булуларын халык алдында кычкырып әйтергә кыймыйча, үз өйләре даирәсендә пышылдашып кына йөрүчеләр дә бар: «Ниятләре изге, ходай ярдәм бирсен үзләренә».

Күпләр исә, бигрәк тә үз көнен үзе күреп яшәүче игенче катлавы бер якка да кушылырга ашыкмый. Кайсы як хаклы?— дәшми генә күзәтә.

Ләкин дәшмәү — тынычлык билгесе түгел. Кемнең күңеле тыныч булсын? Дөньяның асты-өскә килә бит. Бөтен илнең язмышы хәл кылына. Кем файдасына хәл кылыныр ул? Крестьянга ничек булыр? Нәрсә көтәргә мөмкин ул большевиклардан?.. Аларны яманлаучыларны да үзләренчә хаксыз дип булмый. Араларында чынлап та элек-электән сугыш чукмары булып танылган, бушбугазлык белән алдырып килгән кешеләр юкмыни? Болганчык суда балык эләктерергә тырышып, үз файдаларын кайгыртып йөрүче кешедән ни көтәсең?.. Алай дисәң, күпчелеге акны карадан аера белә торган, дөньяның ачысын-төчесен татыган акыллы кешеләр бит. Баеп китә алмасалар да, эшнең, хезмәтнең тәмен белгән, халык каршында бернинди яман аты чыкмаган, җитмәсә, ничә ел сугышта — ут эчендә булып, дөнья күреп, тәҗрибә җыеп кайткан кешеләр? Хәтта сугышта батырлыгы белән дан тотып, әллә ничә көмеш тәре белән бүләкләнгән Сәйфулла да шулар арасында. Башлыклары да ни җитте кеше түгел...

Башлыклары Вәликәй Җаббаров иде аларның. Чынлап та ни җитте кеше булмаган икән ул. Шактый ачык хәтеремдә: тышкы кыяфәте белән үк башкалардан аерылып, офицерга охшап тора иде. Мәктәп алдындагы җыеннарда сөйләгән чакларында күземне ала алмый авызына карап торган чакларым булды.

— Татарча сөйләсә, татар тыңлый авызын ачып,— диләр иде аның турында,— русча сөйләсә — руслар.

Әйе, руслар. Ул вакытта мин белеп бетермәгәнмен, Вәликәй татарлар арасында гына түгел, руслар арасында да күренекле булган икән. Фронтта чакта большевиклар белән бер сафта революцион көрәштә катнашкан һәм аның белән бер чорда авылга кайткан солдатлар руслардан да, мукшылардан да байтак булган. Суркин, Пищаев, Вдовин фамилияләре татарлар арасында да еш телгә алына иде. Авылда алар бер-берсен бик тиз табып алганнар һәм революция алдында торган бурычларны ничек итеп үзебезнең авылда гамәлгә ашыру турында җыелышып сөйләшкәннәр, ничек итеп Җиргәндә совет власте урнаштыру, алпавытлар, кулаклар кулында булган җирләрне тартып алу турында планнар корганнар.

Ләкин патша төшерелгәннән соң яңадан сайланган волость идарәсендә үзәк урынны алган куәтле байлар нык тора. Россиядә Октябрь революциясе булганнан соң да Җиргән байлары властьны ярлылар, большевиклар кулына бирергә теләмиләр. Волость күләменнән вәкилләр чакырып, съезд уздырырга, байлар кулында булган җирләрне

ычкындырмас өчен, шунда үзләренең властьларын закон көче белән ныгытырга ниятлиләр.

Съезд 1918 нче елның 10 мартына билгеләнә.

Большевиклар да хәзерләнә бу съездга. Алар инициативасы белән яшерен төстә фронтовиклар, ярлылар җыелышы уздырыла. Көн тәртибенә волостьта совет власте урнаштыру мәсьәләсе куела. Эшче-крестьян һәм солдат депутатларының Җиргән волость советына тәкъдим итү өчен кандидатлар билгеләнә. Бу җыелышта Стәрлетамак өязе ревкомыннан килгән вәкил дә катнаша.

Ниһаять, билгеләнгән көн килеп җитә. Волостной земский съездга төрле авыллардан делегатлар җыела. Аларның күпчелеге кулаклардан һәм авылның хәлле катлавы кешеләреннән тора. Фронтовиклардан һәм ярлылардан сайлап җибәрелгән вәкилләр дә була.

Съезд ачылуга, большевиклар белән бергә, әлеге яшерен җыелышта катнашкан кешеләр дә килеп керә. Бу хәлне күреп, кулакларның җене кузгала.

— Сезне беркем дә сайламаган, сез самозванецлар!— дип кычкыра башлыйлар аларга.— Сезнең урыныгыз монда түгел!

— Сезне кемнәр сайлаганын да беләбез!— ди большевиклар. Съездның президиумын сайлау башлана. Земство үз кандидатларын тәкъдим итә, большевиклар — үзләренекен. Кулаклар тавыш күтәрә. Большевиклар да җавапка аптырап тормый. Китә кычкырыш. Сугышыр чиккә җитеп кызган кулаклар ачыктан-ачык яный башлыйлар.

— Долой большевикларны!

— Кыйнап чыгарырга кирәк! Нәрсә карап торабыз?!

Каннары кызган кулаклар кулларына ирек бирергә өлгерми, Федор Пищаев, револьверының көпшәсен түшәмгә каратып, атып җибәрә.

Революция дошманнарына кыска һәм ачык кисәтү булып яңгырый бу шартлау: большевиклар монда берәүдән дә куркып чигенергә килмәделәр! Исегездән чыгармагыз!..

Моны көтмәгән кулаклар аптырап, бер мизгелгә тынып кала. Аларга акылларын җыеп, яңадан шау-шу күтәрергә ирек бирмәстән, залда Вәликәйнең көр тавышы яңгырый башлый. Революция дошманнарын, кулакларны съезддан куарга чакыра ул.

— Аларның заманы үтте! — ди.— Бөтен Россиядә хәзер советлар власте! Урын юк аларга хезмәт ияләре арасында!..

Каршы яктан килгән делегатлар, эшнең кая таба баруын күреп, берәм-берәм чыгып сыза башлый.

Берничә минуттан Вәликәй большевиклар группасы исеменнән Советларның Җиргән волость комитетын оештыру съездын ачык дип игълан итә. Шул ук группа исеменнән кертелгән көн тәртибе кабул ителә. Һәм шушы съездда монархы хөкем сөргән волостное земство бетерелеп, аның урынына Эшче-крестьян һәм солдат депутатларының Җиргән волость советы сайлана. Советның беренче председателе итеп Вәликәйне — Вәлиәхмәт Галиәхмәт улы Җаббаровны сайлыйлар. Шунда ук волость советының бүлек мөдирләре раслана. Ул вакытта аларны комиссарлар дип йөртәләр: азык-төлек комиссары — Федор Григорьевич Пищаев, хәрби комиссар — Иван Афанасьевич Суркин, транспорт комиссары — Гарифулла Каганов һәм башкалар. Шул съездда бер уңайдан Җиргән авыл советы да оештырыла...

Бу мәгълүматларны мин башлыча Җиргән елъязмасыннан алдым. Хәтеремдә калганы: нәкъ шул көннәрдә авылда әлеге «большевиклар» дип йөртелгән кешеләр арасыннан кораллы отряд пәйда булды. Башта аларны дружинниклар дип атадылар, аннары Красная гвардия дип, красногвардеецлар дип йөртә башладылар.

Соры папахаларына кызыл тасма беркеткән, күкрәкләренә кы-

зыл бантлар таккан, кайсы винтовка, кайсы наган белән коралланган, кайсылары иңнәренә кылыч аскан, кылычы да булмаганы кулына каеш камчы гына тоткан бу кешеләр хәзер байларны яманлап, советны яклап күп сөйләп тормыйлар иде инде: байлыклары күзгә бәрелеп торган йортларга, нәкъ үз өйләренә кайткан кебек, рөхсәтсез-нисез барып керәләр. Хуҗасы берәр эш белән мәшгуль булса — эшеннән, ашап утырган чагы булса — ашыннан аерып, чакырып чыгаралар. Үзләренең хаклы икәнлекләренә нык ышанган күтәренке, кырыс тавыш белән авыл советының карарын әйтеп бирәләр.

3

## ҖИРӘН БИЯ. ОЛЫ ЮЛ. КАЛА

Алпавытлардан, кулаклардан алынган җирләрне халыкка бүлеп бирү, тегермән, такта яру, кирпеч заводы эше байлыкларны җәмәгать милкенә әверелдерү кебек шау-шулы вакыйгалардан соң, авылда ярыйсы гына тәртип урнашып, тормышлар үзенә күрә бер төрле җайга салынып бара иде инде. Моңарчы гомерләрен гел кешегә эшләп үткәргән көнлекчеләр яки салчылар арасында сабанга үз атларын җигеп, үз җирләренә үзләре чәчү бәхетенә ирешүчеләр дә булгалый башлаган иде. Безнең дә Турат янына җирән бия өстәлде.

Уфа белән Оренбург арасындагы олы юл өстендә утырганлыктан, безнең авыл аша әледән-әле узып торучы Кызыл гвардия отрядлары, төрле командирлар, комиссарлар, ниндидер инструкторлар, уполномоченныйлар күп була, бары да авыл советыннан олау таптыра, һәр атлы кеше атна саен диярлек олауга барырга мәҗбүр иде. Олау белән генә эш бетми, турыдан-туры Җиргәннең үзенә килгән яки үтеп барышлый бер-ике көнгә тукталган кешеләр өчен фатир да сорыйлар — бу эш тә тулысы белән турыдан-туры авыл кешеләре өстенә төшә.

Болар, әлбәттә, крестьян өчен сизелерлек мәшәкать булгандыр. Ләкин миңа, малай кешегә, бу хәлләр бик табигый, хәтта кызык тоела иде. Чынлап та, көтмәгәндә-уйламаганда күршеләреңә яки үз өеңә үк бер яңа кеше килеп төшсә, бик күңелле булып китә бит ул. Ничаклы хәбәрләр ишетәсең аңардан, әллә никадәр яңалыклар белеп каласың. Әти алар белән дөнья хәлләре, хуҗалыкка, крестьян эшенә кагылган мәсьәләләр турында сөйләшә.

Хәрби кунаклардан берсе безгә үзенең атын калдырып китте. Әтинең, шатлана-шатлана, бик очсыз эләкте малкай, дип сөйләнгәне хәтеремдә. Ләкин командир аны бөтенләй бушка ук калдырып китмәде микән әле? Ни өчен дисәң, сатарлык җире дә, сатып алырлык җире дә юк иде хайванның. Эштән чыккан арык, кабыргалары әллә кайдан саналып тора. Оча сөякләре түмгәк-түмгәк бәреп чыккан. Арка сөяге кылыч кебек, астыңа сырган бишмәт салмыйча атланырлык та түгел, өстәвенә, койрык төбендә ярасы бар. Ниндидер төзәлми торган яра. Шулай да күңелгә хуш килгән бер ягы бар иде аның: затлы нәселдән икәне әллә кайдан күренеп тора иде. Зур гәүдәле, зифа буйлы. Муены озын, командир атларына хас булганча, башын һәр вакыт югары тота. Атланыйм дисәң, иң элек арбага менеп басарга кирәк.

Арбага җигеп, Мәләвез базарына барып кайткач, әти җирән биянең тагын бер әйбәт ягын белеп, шатланып бетә алмады: адымга шәп икән хайван. Аяклар озын, атлап барганда бер ат та нярә алмый икән үзенә. Ә безнең Җиргән йөк йөртүчеләре карашынча, атның шәп чабуы яки юртаклыгы әһәмиятле түгел, адымга житез булсын! Обоз-обоз булып барган чакларда андый атны алдан җибәрәләр.

Гәүдәгә зурдан булмаса да, эшкә күндәм, карусыз, ару-талуны белми торган әрсез Туратыбыз янына әнә шул җирән бия өстәлде.

Әзрәк тәрбия күрсәтсәң, хәзер матурланып, хәтта купшыланып китәргә торган мал иде ул. Тик койрык төбендәге ярасы төзәлмәве генә борчый иде этине. Төзәлер, заманалар гына тынычлансын!

Миңа калса, замана инде тынычланып та бара кебек. Хәтта авылдагы, мәктәп тирәсендәге тормышның җанланыбрак китүе күңелле дә иде.

Мәрьям апаны, рөшдидә укып йөргән көенчә, мөгаллимә апасына ярдәмче итеп кутәрделәр. Ә укулар беткәч, Нурулла мулла аны яңа ачылган мөгаллимәләр курсына җибәрергә тәкъдим иткән. Апа бу хәлдән куркынып, «мин бит унөчтә генә» дигәч, мулла аны тынычландырган:

— Зарар юк,— дигән,— буең-сының җитәрлек, синә унсигез яшь бирергә мөмкин.— Һәм, унҗидедә итеп күрсәтеп, үзе үк гаризасын язып та биргән.

Курслар Стәрлетамакта икән. Димәк, Бәдретдин җизниләрдә торып укырга мөмкин. Болай булгач, әти-әни дә каршы килмәделәр.

Аны озатып кую үзе минем өчен истәлекле бер вакыйга булып калды.

Якын тирәдә башка шәһәрләр булмагангадыр инде, Стәрлетамакны ул елларда бездә «кала» дип кенә сөйлиләр иде.

Кала?!. Минем карамакта дөньяның җәннәте шунда иде инде. Калага бару, кала күрү — иң зур һәм иң матур хыялым иде. Мин дә барам, дип, күзләрен ачырмагач, ялынып та, елап та, үпкәләп тә аптырата торгач, этинең миһербаны килде.

— Әйдә, бер күреп кайтсын инде, күңеле булсын!

— Каланы күргәч, исе китеп егылмасмы икән соң?— дигән булды әни.

Егылды ди, егылмый ни! Түбәм күккә тиде. Калага әни белән мин китәргә булдык. Өйдә бәләкәйләр белән эти кала.

Безнең өчен бу сәяхәт Мәрьям апаны озату гына түгел, калада яшәүче бәләкәй абыстайларга кунакка бару да иде.

«Болай булгач, чынлап та кунакка барган кебек булсын,» дип, эти Әхмәтша абзыйларның читән арбасын (тарантасын) алып торды. Әлеге, инде Мәләвезгә барып сыналган җирән бияне җигеп бирде. Җиргәнтау артыннан көлеп чыккан кояш каен биеклеге күтәрелгәндә, аллага тәвәккәлләп, юлга чыктык. Ерак юлга! Кырык өч чакрым барасы! Уен түгел. Йөк йөртүчеләр бу араны гадәттә бер көндә генә үтә алмыйлар. Ярты юлда Аллават дигән авыл бар, шунда кунып чыгып, калага икенче көнне генә барып җитәләр. Дөрес, бу юлны тиз үтүчеләр дә бар. Бик шәп юртаклар турында сүз чыкканда: «Калага дүрт сәгатьтә барып җитә!»— дип мактыйлар. Бу инде әкияттәге Дөлдөлгә тиң дигән сүз.

Безнең җирән бия, әлбәттә, Дөлдөл түгел. Артык арык булмаса, бәлки сынап карарга да булыр иде. Ярамый. Эти атлатып кына барырга кушты. Онытa башласам, әни хәзер искә төшерә:

— Ашыктырма, улым. Ашыккан ашка пешкән, диләр.

Кәефләнеп, мәкальнең икенче яртысын өстәп куйдым:

— Әкрен барган — аттан узган!.. Һи-һи-һи, җәяүле кеше турында әйтелгән сүз бит ул. Ә без — атта. Атта барган ничек аттан узсын?!

— Атның нинди юк!

— Шул безнеке кебек атны узгандыр инде ул акрын баручы җәяүле.

— Телеңә салынма. Авылны чыккач та тугарып ашатырга туры килмәсен!

Атлатып бару да әйтеп бетергесез күңелле иде миңа. Авылны чыгып, бер-ике җир буе узгач та, олы юлны ике яклап, зур-зур каеннар тезелеп китә.

Олы юл!

Аның гүзәллеге, мәһабәтлеге әле дә күз алларымнан китми. Уфа белән Оренбургны тоташтырган бу юл турында Пугач заманыннан ук килә дип сөйлиләр. Могтәбәррәк аксакаллар исә, аны әби патша салдырган дип, ачыклап бирергә яраталар иде.

Кайчан салынса да салынгандыр, кем салдырган булса да салдыргандыр — ул вакытта анысына исем китми иде. Әйтерсең ул юл да, Агыйдел шикелле, таулар-урманнар, күкрәп үскән болыннар шикелле, үзеннән-үзе барлыкка килгән табигый байлык иде инде.

Хәзер килеп исем китә. Заманының нинди зур төзелешләреннән булган икән ул! Киңлеге, ике яклап тезелгән каеннарын да, канауларын да кертеп санасаң, хәзерге үлчәү белән илле метрдан да ким булмагандыр. Уртада, саргылт тасма булып, ком аралаш вак таштан түшәлгән арба юлы сузылып китә. Кечкенә-кечкенә ерганак чокырлары аша да таш күперләр салынган. Атналар, айларга сузылган көзге яңгырларда да, язгы ташкын вакытларында да өзелүне белми.

Таш-ком түшәлгән өлеш белән каеннарга кадәр булган арада киң-киң итеп канаулар казылган. Ул канаулар күптән инде яшел чирәм белән капланган. Ямьле җәй көннәрендә чирәм араларында кып-кызыл булып җир җиләге пешә. Бер як канау буйлап телеграм баганалары тезелгән, әледән-әле чакрым баганалары очрый. Алар төрле төстәге ефәктән ишелгән кебек матур итеп буялган...

Телеграм баганасы — олы юлга маяк ул!..

Безнең олы юлның маягы — телеграм баганаларыннан да биегрәк каеннар иде.

Эх, ул каеннар!

Эссе җәй көннәрендә аркаларына капчык аскан җәяүле юлчыларның, җиләкле урыннарда туктап ял итә-итә, салкынча күләгә эчендә атлап барулары!

Болары әле аның һәр бала күзенә бәрелеп торган тышкы матурлыклары. Ә безнең авыл кешеләренең гамәлендә, авылның экономикасында нинди зур урын тоткан ул. Аты-туны булган барлык Җиргән кешеләренең диярлек кышның-кыш буе, кыр эшләреннән бушап торган араларда җәй көннәре дә йөк йөртү белән шөгыльләнүләре үзе шушы олы юл аркасында түгелмени? Димәк, Җиргән кешеләре, гади авыл кешеләренә хас булганча, иген игү, мал-туар үрчетү өстенә, үзләренә күрә «эшче» дә булганнар. Әйе, хәзергечә әйтсәк, транспорт эшчеләре. Чугунканы гына түгел, автотрассаларны да, самолетны да шул юл алыштырган бит. Димәк, олы юлдан читтә — тау-таш араларында, тын урманнарда яки киң далаларда яшәүче авылларның төшенә дә кермәгән шәһәр күчтәначләре дә эләккәләгән минем авылдашларга. Әйтик, Әстерхан чикләвеге, кәҗә мөгезе, бала-чага гына күтәреп кертә алмаслык зур Оренбург карбызы, бохар кавыны кебекләр... Шәһәрдән шәһәргә йөк ташучыларның юл капчыкларына ияреп, заманның культура кисәкләре дә кайткан Җиргәнгә: календарь-китаплар кебек, Камил Мотыйгый, Мирфәйз Бабаҗанов тавышларын яңгыраткан граммофон тәлинкәләре кебек!..

Мин әле үзебезнең авыл турында гына сөйлим. Ә бит Уфа — Оренбург губерналарын казак далалары белән тоташтырган бу юл бөтен Россиянең өзлексез хәрәкәт иткән кан тамырларыннан берсе булган. Нинди байлыклар гына узмый иде ул юлдан?! Иген-тару, түшкә-түшкә ит, тире-яры, имән кайрысы, йон-ябага, сүс-мунчала, өй буралары, түбә калайлары, чәчү-уру-сугу машиналары, сабан, урак, чалгы кебек, тимер-томыр, тоз-керосин, кызыл мал кебек санап бетергесез төрдәге товарлар төялгән очсыз-кырыйсыз обозлар уза. Кагыйдә буларак, һаман атлап кына баручы ул юлчылардан тирә-якка моңсу гына булып

кыңгырау зары тарала. Меңәрләгән-меңәрләгән аяклы мал: сыер, сарык, куй көтүләре уза. Кыңгырау зарына кәрван башында баручы үгез муенына тагылган доңгырдык авазлары кушыла. Юлның нәкъ уртасыннан, барлык йөкле-йөксез арбалыларны үзенә юл саптырып, тирәякка күңелле шөлдер такмагы чыңлатып, ямщиклар йөри. Безнеке шикелле гади читән арбага гына түгел, настоящий фаэтонга икешәрләп я өчәрләп җигелгән шәп атлар, нәкъ Палеха рәссамнары сурәтләгәнчә, муеннарын дугаландырып, җан-фәрманга чабалар. Кыш көннәрендә хәтта борын тишекләреннән көлтә-көлтә пар бөркелгәнен дә күреп була.

Күпме хәрби обозлар узган бу юлдан! Азмы кан коелган бу юл өстендә? Сугышларда? Кистән тоткан юлбасарлар белән очрашуларда? Ятап-ятап булып атлаган чылбырлы арестаннарны да күргән ул. Эш эзләп, теге якка да, бу якка да үтеп торучы, аркаларына кечкенә-кечкенә төенчекләр белән зур-зур нужалар күтәргән җәяүлеләр турында әйтәсе дә түгел.

Олы юлның тузанын үзем күрдем тузганын.
Белми калдым, сизми калдым яшь гомеремнең узганын.

Җырларда җырланган, риваятьләрдә, әкиятләрдә сөйләнгән олы юл турында, аның әһәмияте, халыкка күрсәткән рәхәте һәм нужалары, ямьсез һәм гүзәл яклары турында күпме язсаң да сүз бетә торган түгел. Ә бит, Шәүкәт Галиев әйтмешли, кемнәрдер аны салганнар! Ул заманның техника дигәне соң? Уйлап карасаң, искитәрлек түгелмени?

Әнә бит, нинди гүзәл, нинди туры, нинди киң!..

Әмма кеше дигәнең нинди киң юлга да сыеп бетә алмый, күрәсең: уртадагы такыр таш юлны катысынып, читтән, каеннардан да тышка чыгып, йомшак юл салганнар. Коры көннәрдә, тузан туздырып булса да, шул ян юллардан гына йөриләр. Андый юллар урыны-урыны белән каеннардан шактый ерагаеп та китә. Тәҗрибәсезрәк кеше булсаң, тукта, әллә олы юлдан аерылып киттекме? дип шикләнеп тә куясың. Ләкин юкка. Ул яңадан каеннар янәшәсенә килә. Инеш яки тирәнрәк чокыр аркылы чыгарга кирәк урыннарда үзәк юлга, ышанычлы таш күпергә күтәрелергә мәҗбүр була.

Без дә шундый юлдан китеп барабыз. Сул ягыбызда — каеннар. Уң яклап иген басулары җәелгән. Алардан ары — Агыйдел. Ул үзе күренми, аның ярында утырган башкорт авыллары: Сабаш, Юлдаш, Нурдәүләт, Муса, Алакайлар күренә, алардан да ары — Иделне аръяклап күтәрелгән Җиргәнтау, Йөрәктаулар, урманнар... Ә алда, әле еракта, кышлаган кибән кебек кенә булып, Торатау тора.

Стәрлетамак әнә шул Торатау каршысында диләр. Торатау — безнең авылдан гына түгел, арырактан да күренә. Яныннан караганда нинди икән ул? Озакламый аны да якыннан күрәм бит дип, куанып барам. Кәеф әйбәт. Җирән бия дә, затлы токымнан икәнемне онытмагыз дигәндәй, башын югары тотып, күңелле генә атлап бара.

Менә бервакыт нәкъ без барган юлдан каршыбызга бер олау килә. Ящик арбага, аякларын ике якка салындырып, биш-алты кеше утырган. Көпшәләрен югары каратып тоткан мылтыклары әллә кайдан күренеп килә. Якынлаштык. Артык кызыксынудан зиһенем таралганмы, юл бирергә кирәклеген онытканмын бит. Җирән бия үзе белеп читкә чыгарга уйламый да. Тегеләрнең берсе мылтыгы белән ымлап аңлаткач кына дилбегәнең уң як очын тарттым.

Мылтыклыларның берсе ачуланып кычкырмакчы иде дә, кузлада яшь малай, түрдә әнисе белән янәшә унөчтә генә булса да унсигез яшь бирерлек кыз утырып барганны күргәч, ачуы басылды, күрәсең, көлеп кенә нидер әйтте. Башкалары да төрлесе төрлечә киенгән, бары да диярлек я күкрәкләренә, я фуражкаларына кызыл тасма беркеткән кешеләр — нидер әйтә-әйтә, көлешеп үтеп киттеләр.

Әни миңа акыл өйрәтергә тотынды.

— Авызыңны ачып барма, каршыга күп кеше утырган олау я йөк төягән арба килгәндә, алдан ук юл бирергә кирәк.

— Беләм инде дә, әллә нишләп онытып киткәнмен. Турат булса, үзе белеп бирер иде. Бу җирән бия әллә нинди, эре.

Мал иясенә охшамаса, харам була дигәндәй, Туратны әти үзе шулай өйрәткән иде булса кирәк: каршы очраган һәр атлыга үзе белеп әллә кайдан юл бирә торган иде.

Үзем дә бу яктан шул Туратка охшаган булып чыктым, ахрысы, каршы очраган һәр кешегә, олысына-кечесенә карамастан, юл бирергә гадәтләнгәнмен. Мондый гадәтем барлыгын мин үзем сизми дә идем, Фәүзия апагыз әйтеп бирде. Беркөнне шулай каршыбызга егет белән кызмы, ирле-хатынлы яшьләрме килә. Бер-берсен кысып култыклашканнар да, уңны-сулны күрмәстән, бик мавыгып сөйләшеп баралар. Гадәтемчә, аларга юл куеп, шактый ерактан ук уңга тайпылганмын икән. Шунда Фәүзия апагыз беләгемнән тотты.

— Нигә син теләсә кемгә юл бирергә ашыгасың? — ди.— Үзеңнән олы кеше я кечкенә бала булса бер хәл иде. Яшьләр бит. Алар сиңа юл бирсен.

Әйе шул. Бу гадәт урамда очраган кешегә юл сабып үтү белән генә чикләнсә бер хәл иде. Яшәү практикамда тормыш-көнкүреш мәсьәләсендә үзен күрсәткән чаклары да була... Хәер, кемгә булса да юл куям дип, иҗат эшемдә рухыма, иманыма каршы бара алмыйм. Бервакытта да ялгышмыйм дип әйтмим. Берәү дә хатадан хали түгел. Ә инде үз ихтыярың белән иманыңа каршы баруны зур гөнаһ саныйм. Дөнья булгач, гөнаһ эш кылган чакларым да булгандыр. Андый чакларны, әлбәттә, тормышыңның бәхетле көннәре дип саный алмыйсың. Вөҗдан газабы эчендә үткән иң авыр минутлар алар...

Ай, бу җирән бияне! Әнә кайларга алып кереп китте бит. Зарар юк, олы юлдан аерылмадым. Әнә, каеннар да үз урыннарында, таулар да. Тик Җиргән таулары кечерәеп, күздән югала бара, ә Торатау һаман үсә, зурая. Җиргәннән торып караганда кибән аркылы атландырылган бастырыклар шикелле генә булып күренгән нечкә-нечкә сызыклар тауны түбәсеннән итәгенә кадәр ярып төшкән чокырлар булып чыкты. Күз алдымда ачыла барган һәр яңа күренешкә куануымнан нишләргә белмим.

— Әни, карале, Торатау башында ап-ак кар![1]

— Алдыңа гына карап бар.

— Әни, кайда соң кала? Торатауга җиттек бит инде.

— Торатауга җиткәнче күзең күгәрер әле...

Стәрлетамак бик түбән урында утыра икән, ерактан күренми. Бервакыт биек-биек агачлар, куе-куе әрәмәләр арасыннан күккә таба сузылган озын морҗа күренде. Морҗа дип тә уйламас идем, башыннан төтен чыга. Хәйран калудан үземне-үзем онытып: «Ананны!..» дип кычкырып җибәрүем булды, мәтәлеп тә төштем. Гөнаһ шомлыгына каршы, нәкъ шул минутта ал тәгәрмәч чокырга туры килгән дә, арба кыйгаеп киткән икән. Бер җирем дә имгәнмичә, киемнәремә буялган тузанны кага-кага, кире кучерга менеп килүемне күргәч, әни көлеп җибәрде:

— Әйттем бит мин сиңа, каланы күргәч, исең китеп егылырсың дип!

— Нишләп исем китсен инде, тәгәрмәч чокырга төште ич!

— Исең китте, исең китте! Һушыңнан яздың!..

---

[1] Торатау түбәсендә җәй уртасына кадәр кар эреп бетмәгән еллар еш кына була.— М. Ә.

Мәрьям апага да житә калды.

— Каланың үзен түгел, бер морҗасын күрүгә исең китеп егылдың!

Сыннары катып көләләр икәүләшеп. Хәтта калага баргач та онытмадылар шуны. Бәләкәй абыстай миннән: «Я, кала ошыймы?» — дип сорагач, ашыга-ашыга минем өчен җавап бирәләр.

— Ошамаган кайда? Каланы ерактан күрү белән исе китеп егылды.

Инде өчәүләп көләләр. Җитмәсә, нинди кызык бар дип, эреле-ваклы өч кызлары килеп җитте. Тагын бер кат сөйләп бирделәр. Алары көләргә тотынды. Чыдап кына тор!

«Кала ошадымы?» дигән сорауга җавапны менә хәзер бирергә туры килә. Әйе, ошады. Бөтенләй икенче дөнья булып күренде миңа Стәрлетамак.

Килеп җитеп атны тугару белән, өйгә керүдән элек, капка төбенә чыктым. Урам аша каршыда гына диярлек таш мәчет. Таш! Бу инде үзе минем өчен искитәрлек күренеш. Урам буйлап уңга таба аз гына арырак — фонтан.

Фонтан! Әнә нинди икән ул. Өй дисәң, өйгә охшамаган, келәт дисәң — келәткә. Зур чүмәлә шикеллерәк түгәрәк итеп салынган бер хикмәт. Түбәсе чиркәү гөмбәзе сымаграк итеп, түгәрәкләп ябылган. Яшелгә буялган калай түбә. Үзе минем дә буй җитәрләк тәбәнәк. Янынарак барып карамый түзә алмадым. Өч ягыннан өч улак чыгып тора. Алай икән, димәк, монда суны, сиртмәле коега чиләк төшереп, тартып чыгармыйлар, фонтаннан, өргеч баскан шикелле, аның агач сиртмәсен басып суырталар икән. Чишмәдән чыккан кебек саф, салкын су агач улак буйлап чиләккә агып кына төшә. Купшы-купшы киенгән кала бичәләре, кала кызлары, көянтә-чиләкләрен күтәреп, берөзлексез килеп-китеп торалар. Иң кызыгы — бер ир кеше суга килгән. Бала-чага да түгел, мыек үстергән олы кеше! Көянтә-чиләк күтәреп! Ничек оялмый диген? Кала кызларының шуңа исләре дә китми. Көлгән кеше дә юк...

Кала күрергә дип, шунда ук урам буенча китеп тә бармакчы идем, әни чакырып алды.

Бәдретдин җизниләрнең өе турында хәтеремдә калганы — бөрау кебек итеп ясалган сары буяулы баскыч буйлап, әйләнә-әйләнә өске катка менүебез булды. Иләшә төшкәч, кирәксә-кирәкмәсә дә шул баскыч буенча менеп-төшеп йөрү минем өчен бик күңелле уен иде. Җизниләр үзләре өйнең өске катында торалар, аста — кечкенә генә китап кибете. Ни өчендер ул миндә онытылмаслык тәэсир калдыра алмаган. Югыйсә, китап күрсәм, каләм-кәгазь күрсәм, күзләрем ут яна торган малай идем кебек. Әллә җәй көне булганга артык исем китмәдеме икән?

Бәдретдин җизни үзе бик сирәк күренде. «Ертанач» китабын язган олы кызы Рәифә вафат иде инде. Буй җитеп килгән бердәнбер уллары бар иде. Киткән вакытта безне олы юлга кадәр озатып куюы гына хәтеремдә. Озакламый анысы да вакытсыз үлеп киткән булып чыкты.

1918 енче ел иде бу. Революциянең иң катлаулы чорлары. Ул, әлбәттә, Стәрлетамакка да йогынты ясагандыр, зур үзгәрешләр керткәндер. Ләкин мин аларны сизмәдем. Беренче күрүем булгангамы, ул миңа чынлап та менә дигән кала булып күренде. Баксаң, менә дигән калада электр яктысы да булмаган икән әле. Керосин лампаларының яктылыгына исем китеп карап торганым хәтеремдә. Кыскасы, минем күзлектән караганда, кала тормышы шаулап-гөрләп тора иде. Җиргәнгә әйләнеп кайткач, әтинең беренче соравы җирән бия турында булды. Ничек? Әйбәт йөрдеме? Арымадымы? Аттан бик канәгать булуыбызны күргәч, Мәрьям апаның ничек урнашуы, җизниләрнең исәнсаулыгы турында да яхшы хәбәрләр ишеткәч: «Аллага шөкер икән,—

дип куйды.— Заманалар гына тизрәк тынычлансын инде». Аны хуплап, әни дә күрсенеп куйды.

Нигә һаман шулай замана турында борчылалар? Нәрсәсе ярамый бу заманның? Сыерыбыз бар. Атыбыз икәү. Йорт тулы тавык. Әтиебез янныбызда, әни исән-сау. Бер-берсе өчен үлеп торалар.

Шундый матур җәй. Малайлар белән Агыйделгә балыкка барабыз. Юа, гурлафа, кузгалак, кымызлык, каз тәпие кебек тәмле үләннәр картаюга, куян тубыгы, төрле көпшә кебек сыйлар әзер. Аръякта җир җиләге пешә. Карлыганның каралуын да көтмибез, яшел килеш кенә шатырдатабыз. Тешләр камашып бетә.

Олы малай буларак, мин әти белән кырга, урманга барырга да өлгерәм. Утаудан да, печәннән дә калган юк.

Тормышлар шулай күңелле генә барганда...

4

## ДУТОВЧЫЛАР. БӘЛА ӨСТЕНӘ КАЗА

Ул көнне без әти белән иртәдән кичкә кадәр кырда булып, кояш баеган вакытта гына кайтып кердек. Авылда ниндидер шомлы тынлык сизенеп, күңелем әллә нишләп китте. Әни безне көндәгечә көлеп-шатланып каршы алмады. Хәтта эндәшмәде дә.

— Нәрсә бар?— диде әти.

— Алла сакласын!— дип кенә куйды әни.

Нәрсә булганын минем алда әйтәсе килмәде, күрәсең, әти дә, шуны аңлап булса кирәк, төпченергә ашыкмады. Тавышсыз-тынсыз гына ат тугарырга тотынды. Мин дилбегә белән чыбыркыны келәткә кертеп элдем дә капкага йөгердем.

— Кая чаптың?

Әни миңа бу сорауны шундый тавыш белән бирде, ул миңа сорау булып түгел, «йөрмә!» дигән әмер булып ишетелде.

— Капка төбенә генә чыгып керәм,— дидем.— Габдрахман көтеп тора.— Капкадан кергәндә чынлап та Габдрахманны күреп калган идем, миңа урамга чыгарга ымлаган да иде шикелле.

— Капкадан ары беркая китеп йөрисе булма!— диде әни.

— Мин хәзер...

— Әй, мала-а-ай, күрми калдың тамашаны!— диде миңа Габдрахман, ашыгып. Аның күзләре аларган, тавышы да куркынып, ярым пышылдап чыга иде.

— Ни булды?

— Аклар килде, малай! Атлы казаклар. Красногвардеецларны үтереп кыйнадылар, пәрәме урам уртасында.

— Кит аннан?

— Эштән чыгарып, сарайга кертеп ташладылар. Ыңгырашканнары әле дә ишетелә, әйдә барып карыйбыз...

Башка көннәрне бу йортның капкасы һәр вакыт ярым ачык тора, теләгән малай-шалай рәхәтләнеп ишегалдына кереп-чыгып йөри ала иде. Ә бүген! Ерактан ук күреп алдык,— капка төбендә ике солдат. Кулларына тоткан каеш камчылары белән үз итек кунычларына үзләре шапылдатып суга-суга, арлы-бирле йөреп торалар.

— Атлы казаклар,— дип пышылдады Габдрахман.

Атлы казак булгач, мин аларны гел ат өстендә итеп күз алдына китерә идем. Ә болар — җирдә. Яннарында атлары да күренми. Башларында — түгәрәк түбәләре киерелеп торган кызыл кыршаулы картуз. Иңнәренә кылыч асканнар. Өсләренә кигән гимнастерка, чалбарларының гади солдаттан әллә ни аермалары юк. Очлары бөтерелеп,

өскә күтәрелеп торган мыеклары белән стражникка охшыйлар. Кулларында камчылары булмаса, атлы казак дип белерлек тә түгел.

Капканың эч ягында да каравыл бар иде, ахрысы, казаклар шул якка карап ачулы тавыш белән нидер әйттеләр дә, камчылары белән итек кунычларына шапылдата-шапылдата, ары киттеләр. Алар күздән югалуга, каршы яктан бер авыл кешесе килеп чыкты. Ахрысы, безнең күрше-тирәдән булмагандыр, таный алмадым. Капка төбенә килеп җиткәч, тукталып, як-ягына каранып алды. Безне күрмәдеме, күрсә дә исәпкә алмадымы, җәлт кенә борылып, капкадан кереп китте.

Көн карангыланып барган вакытта аның шулай, як-ягына каранакарана, бу шомлы ишегалдына кереп китүе яхшы ният белән түгел икәнлеге күренеп тора иде. Габдрахман белән бер-беребезне сүзсез аңлашып, күрше ишегалды аша, сарайның ян стенасы кырына уздык.

— Алар менә шушында, — диде Габдрахман.

Колакларыбызны кирпеч стенага терәдек. Башта берни дә ишетелмәде. Аннары акрын гына ыңгырашкан тавыш килде. Ул арада ишекне ачтылар. Тынлык... Тәннәрне чымырдатып, «гөп-гөп» иткән тавыш ишетелде. Ыңгырашу авазы. Шундый үзәк өзгеч авыр ыңгырашу. Күнел сизә: бик нык кеше булса кирәк, нинди каты авыртуга да тавыш чыгармый чыдый торган кеше. Ыңгырашуы ничектер аның үз ихтыярыннан тыш газапланып чыга кебек. Һушыннан яздырганчы суктылар, күрәсең. Әллә эченә типтеме?.. Артык тыңлар хәлем калмады.

— Әйдә.

Кире үз юлыбызга киттек.

— Үч ала, — диде Габдрахман.

— Үч? Кем? Кемнән? Нинди үче бар?

— Капкорсак әйтте.

— Юан Хәлим?

Кыйнап эштән чыгарылган, аңнарын югалткан кешеләрне таш келәткә кертеп ыргыткач, капкорсак бөтен урамга ишеттереп әйткән икән:

— Үче бар кешеләр аласы үчләрен бүген алып калсыннар! — дигән. — Иртәгә без ул камунисларның исән калганнарын калага озатабыз. Теләгән кешегә төне буена кереп кыйнарга рөхсәт! — дигән.

Шунда миңа Габдрахман ул капкорсак яки Юан Хәлим дип йөртелгән кешенең ниләр кыланганын сөйләп бирде.

Көн уртасында, давыл куптарып, авылга атлы казаклар отряды ябырылган. Мәләвез ягыннан килеп чыкканнар. Олы юл буйлап, иң элек рус урамына кергәннәр. Совет йортын алганнар. Араларында Җиргән кешеләре дә булган. Монда да көтеп, әзерләнеп торучылар булган, күрәсең, бер төркем, тузынып, безнең урамга килеп төшкән. Казаклар, авыл кешеләреннән дә кемнәрнедер ияртеп, большевикларны эзләргә керешкәннәр. Өйдә туры килгәннәрен урамга алып чыгып, камчы белән яра-яра мәчет чатына алып килгәннәр. Ә монда шул Юан баш булып йөри икән. Күзләрен кан алган, кулында ярты кирпеч, ди. Көчләп китерелгән һәр большевикны башлап шул сугып ега икән. Сугып ега да өстенә менеп таптый. Күн калушы белән башына, авызына, корсагына, җан җирләренә тибә-тибә кыйный, ди. Бу коточкыч эштә аңа улы да булышкан. Габдрахман хәтта шунысына да игътибар иткән: улының большевикларны ялангач кул белән кыйнавын күреп, атасы бик каты җикергән. «Кулыңны авырттырма, дурак! — дигән.— Мә, кирпеч белән сук!» — дип, аңа да кирпеч тоттырган...

Шыпырт кына кереп яттым. Күрәсең, күп вакыт үтмәгәндер, кайда йөргәнемне төпченүче булмады. Тиз генә йокыга китә алмадым. Кулына кирпеч тоткан, күзләрен кан баскан юан кеше күз алдыма килеп аптыратты. Моңарчы миңа ул кешенең юанлыгы гына сәер тоела иде. Башкасына игътибар да итми идем. Ә ул көнне, керфекләрем кушылуга

күз алдыма бөтен кием-салымнары белән килде дә басты. Төймәләрен эләктермичә генә киеп җибәрелгән җиңсез кара камзул. Сирәк кенә кара сакал, нечкә мыек белән бизәлгән зур симез бит янында бәләкәй генә күренгән кара түбәтәй. Буйлы ыштан. Аның лампа филтәсеннән ясалган бавы салынып төшкән, балагы читек балтырына тыгылган. Нәкъ контор стенасына ябыштырылган буржуй сурәте! Тик бу, минем күз алдымдагы кеше, сурәттәге буржуй шикелле, тешләрен ыржайтып, янап кына тормый, хәрәкәт итә: кулындагы кирпече белән Бәхетгәрәй солдатларның, Сибгат, Гафият, Сәйфулла, Ярмиләрнең башларына, битләренә суга, читеге өстеннән кигән зур күн калушының каты борыны белән һушсыз яткан кешеләрнең корсакларына, күкрәкләренә, битләренә тибә...

Әтиләр дә йоклый алмый ята икән, әнинең «алла сакласын» дип пышылдаганы ишетелеп калды. Тырышыбрак колак салдым.

— Теге вакытта җүләрләнеп язылган булсаң... — дип пышылдый иде әни.— Ничек ходай саклады диген. Тәки сине дә эштән чыгарып ташлаган булырлар иде. Алла сакласын...

Әти берни дәшми иде. Бераздан әни тагы нидер пышылдады. Нәрсә әйткәне аңлашылмады, тик сүз арасында Хәлим, Нурулла мулла исемнәрен телгә алуы гына колагыма чалынып калды...

Җиргән тарихында булган ул коточкыч фаҗига турында икенче көнне дә, өченче көнне дә, аннан соң да күп ишетергә туры килде. Әнинең Нурулла мулла исеме белән берраттән теге Юанны телгә алуның мәгънәсе дә аңлашылды.

Кемдер, картлардан берәү, көпә-көндез мәчет алдында диярлек шундый вәхшәт эшләнүгә тыныч кына карап кала алмыйча, әйткән:

— Җәмәгать,— дигән,— башбаштаклык була бит бу,— дигән,— әүвәл мулла белән киңәшеп карарга кирәк иде, — дигән.

Капкорсак этеп кенә җибәргән аны.

— Яхшы чакта тай моннан, дигән, Нурулла мулла үзе бәлшәвик! Өстерәп алып чыгып, аның үзенең арт сабагын укытырга кирәк!..

«Бәлшәвик»леге шул икән: авылда совет власте урнашкан көннәрдә бер сәүдәгәр аңа киңәш итеп: «Бер әрҗә яхшы чәем бар иде, талап алмагайлары дип куркам, нишләтим икән шуны?» — дип сораган, имеш. Мулла аңа: «Фәкыйрьләргә өләш тә бир, савабыннан башка берни булмас», — дип җавап биргән, ди. Сәүдәгәргә мондый фәтва ошамаган, күрәсең, әнә кемгә ишеттергән...

Ул көннәр турында хәтеремдә калган тагын бер деталь. Авылыбызда беренче күренгән кызыл гвардиячеләр арасында бер бик яшь егет бар иде. Әле унсигезе дә тулмаган дигәннәре исемдә. Атлы казаклар катыш кулаклар, куштаннар төркеме, өй борынына кереп, качып өлгермәгән большевикларны рәхимсез аулап йөргән вакытта ул өйдә булган. Ләкин әтисе аны эзләп килүләрен көтеп тормаган, якасыннан тотып, урамга алып чыккан, бөтен кешегә ишеттереп сүгә-сүгә, үз малаен үзе кыйнарга тотынган.

— Мин сиңа әйттем, малакасус! — дип кычкырган ул. — Сүземә колак салмадың, менә хәзер җәзасын күр!..

Атасы кыйнаганны күреп, башкалар аңа кагылмаганнар.

— Шулай кирәк! Ата сүзен тотмасаң, менә шулай була ул! — дип торучылар гына булган.

Әтисе Җиргән татарлары арасында бердәнбер диярлек яшелчә үстерүче, аның өстенә җәен-кышын балык тоту белән шөгыльләнүче кеше иде. Бакчасы Идел буена төшә торган тыкрык буйлап сузылганга күрә, җәй көннәрендә миңа, көн саен диярлек, аның суганнарын күреп үтәргә туры килә, җае чыккан көннәрдә, башка малайлар белән бергәләп, читәнгә аша гына бакчаның эч ягына төшеп менгән чаклар да булгалый иде. «Агыйдел» повестендагы Тешсез Ибрай тыкрыгын тас-

вирлаганда мин шул бакчаны күз алдымда тоттым. Ләкин бакча хуҗасы үзе Тешсез Ибрайның прототибы дип әйтә алмыйм. Чөнки мин аны якыннан белми идем. Белгән булсам, һич югында, соңыннан кызыксынып танышкан булсам да яраган икән. Чынлап та бик үзенчәлекле характер иясе булган бит ул кеше. Татарлардан берәү дә шөгыльләнмәгән заманда яшелчә үстерүе үзе генә дә ни тора! Шундый дәһшәтле мәхшәр көнендә үз малаен урамга алып чыгып, халык алдында кыйнавының да мәгънәсе булган икән: ул аны красногвардеец булганы өчен түгел, рәхимсез банда кулына бирмәс өчен, малаен үтертмәс я имгәттермәс өчен шулай үзе кыйнаган дип сөйләделәр.

Болар минем үз күзләрем белән күргән яки үз колагым белән ишеткәннәрдән бала чактагы хәтергә сеңеп калган эпизодлар. Соңыннан белүемчә, тарих болай булган икән.

Волостьта совет власте урнаштырган съездда ук, Җиргәннең авыл советы сайлану белән бергә, авылда тәртип саклау, яңа гына дөньяга килгән совет властен ныгыту өчен Кызыл гвардия отряды да оештырыла. Корал җыю буенча махсус комиссия төзелә һәм, кемдә нинди корал бар, кичектермәстән, Кызыл гвардия штабына тапшырырга тиеш, дигән карар чыгарыла. Берничә көн эчендә кырык өч винтовка, өч револьвер, биш кылыч һәм беркадәр сугыш припаслары җыела. Шулар белән отрядны кораллландыралар. Волость советын һәм Кызыл гвардия отрядын тәэмин итү өчен акча, азык, кием-салым кирәк. Ярлыларга, фронтта үлеп калган кешеләр гаиләләренә ашарга да, чәчәргә дә ашлык кирәк. Боларны кайгырту хәзер совет өстендә. Байларга, сәүдәгәрләргә контрибуция салына. Кулакларда булган артык икмәкне табу һәм тартып алу өчен кызыл гвардеецлардан продотряд төзиләр. Клеменковның пар тегермәне дә шул продотряд карамагына тапшырыла. Утарын алып, җир байлыкларын ярлыларга бүлеп бирәләр. Үзе авылдан качып киткән бу алпавытның такта яру заводы белән агач сәүдәсе пристане да җәмәгать милке итеп игълан кылына. Кирпеч, күн заводлары хуҗасы Фазулла хаҗи кебекләргә карата да шундый ук чаралар күренә. ВЦИК чыгарган махсус Декрет нигезендә июнь башларында ярлылар комитетлары оештырыла...

Яңа власть уздырган чаралар авылның ярлы катламын совет тирәсенә якынайталар. Аларны кулакка каршы көрәштә активлаштыралар. Ләкин байлар каршылыксыз гына бирелергә теләми. Революция дошманнары кузгала. Оренбург далаларында атаман Дутов җитәкчелегендә ак казаклар баш күтәрә.

Май аенда Дутов шактый зур күләмдә контрреволюцион көч туплый. Бай һәм хәлле катлаудан чыккан казаклар янына Уфа губернасының көньяк төбәкләреннән җыелган кулаклар килеп кушыла. Шулар җөмләсендә Җиргән, Мәләвез волостеннан качкан кулак токымнары да житәрлек була. Дутовчылар ярдәме белән алар кулларыннан ычкынган җирләрне кире кайтарып алырга җыеналар.

Контрреволюцион көчләр, Оренбург губернасында советларны җимереп, яңа гына барлыкка килгән, әле ныгып та житмәгән яшь Кызыл гвардия отрядларына һөҗүм итә, һәм волость артыннан волость алар кулына керә бара.

Стәрлетамак өяз ревкомы үз карамагында булган көчләрне, Уфа губернасының төрле төбәкләрендә кузгала башлаган кулак фетнәләрен бастыру өчен, Кызыл гвардиягә ярдәмгә җибәрә. Җиргән кызыл гвардиячеләреннән утыз кеше үзләре теләп Чишмә ягына китәләр. Авылда отрядның көче йомшап калуын, әлбәттә, кулаклар күрә, бу турыда дутовчыларга да көне белән житкереп торалар. Июнь азакларында авылда кораллы кызыл гвардиячеләр бөтенләй диярлек булмый.

Көнбатыштан ак чехлар Стәрлетамакны ала. Нәкъ шул көннәрдә Дутов отрядлары Җиргәнгә бәреп керә. Элек авылдан качып киткән кулаклар да ак казаклар белән бергә әйләнеп кайталар.

Авылда булган кызыл гвардиячеләрнең бер өлеше штаб начальнигы Вдовин Никифор җитәкчелегендә, шул вакытта Җиргән аша узып баручы Калмыков отрядына кушылып, барлы-юклы коралы белән каршылык күрсәтә-күрсәтә, Агыйдел аръягына чигенергә мәҗбүр була. Вәликәй Яппаров һәм башка җитәкчеләр дә шулар арасында китә. Алар Свердловск ягына юл тотып, ахыр чиктә Кызыл Армиягә барып кушылалар.

Алар килү белән авылда кулаклар үз властьларын урнаштырып, үзләренең чрезвычайная комиссияләрен төзиләр. Аның председателе аклар белән кире әйләнеп кайткан алпавыт Клеменков Иван була. Членнар составына да иң эре байлар керә.

Рәхимсез һәм законсыз хөкемнәрен тормышка ашыруда аларга ярдәмгә, камчылы-мылтыклы дутовчылардан тыш, күсәк, кирпеч, сәнәк белән коралланган кулак палачлар да табыла.

Дошман тарафыннан атып үтерелгән һәм каты җәзага дучар ителгән беренче кызыл гвардиячеләрдән егермеләп авылдашымның исемнәре Җиргән тарихында саклана.

Таш стена аша ишетелгән авыр ыңгырашу авазларын гомер буе онытa алмадым. Кеше үтерү остасы булып танылган чын кулак сурәте күз алдымнан китмәде. Катлаулы көрәш күренешләре, аларда катнашкан аерым кешеләр онытылмадылар гына түгел, вакыт узган саен күңелемдә үзем күреп кичергән кебек җанлана, әкренләп әдәби формага керә бардылар. Шул чорда күңелемә сеңеп калган вакыйгалар, ниһаять, кырык елдан соң миндә «Хөррият» драмасы булып туды. Тамашачылардан берәү миннән: «Хөррият» пьесасын сез озак яздыгызмы?» — дип сорагач, мин аңа «унсигез көн» дип җавап биргән идем. Чынлап та, мин аны, Малеевкадагы иҗат йортына барып, унсигез көндә язып чыктым. Шулай да җавабым ялган булган, дөресе: мин аны кырык ел язганмын икән.

Авылда дутовчылар, аларга килеп өстәлгән ак чехлар хөкем сөргән чорда минем өчен матур истәлек калдырырлык берни дә булмады. Кешеләр ничектер үзара очрашмаска тырыша, очрашкан чакларында да иркенләп сөйләшмиләр, күпләр бөтенләй күзгә-башка күренми яши иде. Ямьле Агыйдел буйлары, җиләк-җимеш тулы урманнар шомлы урынга әйләнде. Бояр урманына шомыртка барган хатыннарга дезертирлар очраган, балан җыярга чыккан икенче берәүләргә дезертир аулаучы ак солдатлар очрап, котларын алган... кебек хәбәрләр әледән-әле ишетелеп тора иде.

Шомлы көннәр өстенә, безнең гаиләдә тагын бер күңелсезлек булды. Әлеге җирән биябез зарарланды. Хайванның, көрәеп китә алмаса да, кәефе яхшыра баруын күреп, өй эчебез белән шатланып йөри идек. Әти, Мәләвез базарына барырга җыенып, ниндидер йөк тә төяп кайтты. Арба әзер, чәй эчеп чыгасы да атны җигәсе генә калган иде. Юлга чыгу алдыннан әти аны дагалатып алырга теләде. Ерак барасы түгел, тимерлек каршыбызда гына. Дагалау станы да буш. Ике-өч минут үтүгә җирән бия станга кертеп бәйләнгән иде инде. Тирә-якка янган тояк исе чыгарып, тиз арада дагалап та бетерделәр. Дагалауны күрмәгән мал түгел иде, күрәсең, биябез тыныч кына торды. Хәер, дуласа да берни эшли алмас иде: дагалау станына кертеп бәйләнгән атка кымшаныр җай да калмый. Теләсәң нишләт! Әтинең форсаттан файдаланып каласы килде, ахрысы, хайванның койрык астындагы ярасын ныклабрак дәвалап карарга ниятләде. Тимерлек тирәсеннән бер дә өзелми торган акыллы башлардан кемнеңдер киңәше белән ачык ярага, мул гына

итеп, карболка салдылар. Бик каты әрнетте, күрәсең, тыныч кына табигатьле биябез котырып дуларга тотынды. Ләкин станок аңа бәрелергә-сугылырга да, тибенергә яки тешләшергә дә ирек бирми иде. Акыллы башлар аның дулавын хәерлегә генә санадылар: әһә, янәсе, кортларга килеште бу дару! Һәм җирән биянең шартлар чиккә җитеп дулавына, ямьсез итеп хырылдаган тавышлар чыгаруына карамастан, ярасындагы кортларын ниндидер тимер кисәкләре белән кырып төшереп, тагын карболка койдылар. Хайванның ничек газапланганын күреп, күземә яшьләр килде.

Ниһаять, аны газаплаудан туктадылар. Ул станоктан чыгаргач та тынычлана алмады. Исерек адымнар белән йөгерә-атлый үзебезнең йортка кайтты. Ишегалдына кергәч тә, кая керергә урын таба алмагандай, торган урынында тыпырчына, башларын чайкый иде. Әти ипи сузып карады, хайван аңа бөтенләй игътибар да итмәде. Басып торыр хәле калмады, ахрысы, әллә егылды, әллә шулай җайсыз итеп үзе ятты. Аякларын дүртесен дә бер якка сузып, кырын яткан хәлдә, нишләргә белми, корсагы белән җиргә ышкына, янына барырга куркыныч иде. Менә ул озын муенын сузып, башын янга таба югары күтәрде дә шап итеп җиргә бәрде. Тагы күтәрде, тагы бәрде.

Әти белән әни дә ни кылырга белми аптырашып торалар иде. Хайван башы белән җирне кыйный башлагач, әти нишләргә кирәген белеп алды:

— Пычак! — диде.

Әни каршы берни әйтмәде, күз ачып йомганчы пычак китереп житкерде. Әлеге, сабый чагымда ук минем борынга гомерлек тамга салып калдырган агач саплы, нечкә билле пычак иде ул. Әти аны ашыгып кына баш бармагына каптырып карады да кире бирде.

— Чәч пәкесен китер!

Шул ук минутта әни әтинең сакал-мыек төзәтә торган агач саплы кин чалгы пәкесен тотып килде.

Нигә шулай ашыгуларын мин ул чакта ук аңлый идем инде. Хайван зарарланса, мөмкин кадәр аны үтермәскә, җан биргәнче чалып калырга тырышалар. Болай эшләгәндә аның, ичмасам, ите хәләл була, ягъни ашарга ярый.

Җирән бияне әти вакытында чалып өлгерде өлгерүен. Ләкин итен ашый алдык дип әйтә алмыйм. Авыру ат булганга шикләнүдән түгел, юк, ашау мәсьәләсендә без шикләнү, җирәнү кебек хәлләрне белми идек. Хәтта артык арык булганы өчен дә түгел. Иң кыены — аны бозмыйча саклау мөмкинлеге юк иде. Җәйнең иң эссе вакыты. Теләсә нинди ит затына минут эчендә чебен йомырка салып өлгерә. Вак-вак кисәкләргә бүлеп, тоз сибеп, кояшка элеп караган булдылар. Тик алай гына коткарып булмаслыгын белепме, әллә бетсә дә, үкенерлек ризык түгел дип карадылармы, әти дә, әни дә аны саклауга артык әһәмият бирмәделәр. Күрше-күлән эте кереп, элгән иткә үрелгәнне күрсәләр дә исләре китми, кайбер кисәкләрне эләктереп китсәләр дә, сүз әйтмиләр иде. Күрше-күләнгә дә саранлык күрсәтмәделәр. Кыскасы, җирән биябез шулай көтмәгәндә-уйламаганда юкка чыкты да куйды. Тагын шул күптәнге Туратыбыз белән калдык.

Бу чорда безнең гаиләнең тынычлыгын бозган тагын бер хәл булса — Мәрьям апаның өйдә юклыгы иде. Кызыллар вакытында Стәрлетамакка курска җибәрелгән кыз аклар килгәндә кайтмаган иде әле. Мондый буталыш вакытында, кыз бала әллә нинди бәлаләргә юлыкмаса ярар иде дип, әти белән әни һаман куркынып тордылар.

Җәй узып бара иде инде. Беркөнне иртән йокыдан уянуыма янымда әни тора. Кулы белән миңа тавышланмаска ымлый. Ни булган.

— Апаң кайтты.

— Кайда?

— Ана бит.

Янымда гына ята икән, бүлмә стенасы буенда.

— Кайчан кайтты?

— Шаулама, йокласын.

— Уятырсың аны тиз генә!

Мәрьям апа чынлап та бик каты йоклый, сәкедән идәнгә атылып төшкән чакларында да уянмый торган иде.

Шулай да бу юлы ничектер, үзем дә сизмәстән, ихтыярсыз пышылдауга күчтем.

Апамның матурлыгын беренче тапкыр шул иртәдә күрдем. Ап-ак нәфис чыраенда алсу нур балкып тора. Нечкә генә сызылып киткән кара кашлар. Иреннәре кып-кызыл. Елкылдап торган коңгырт кара чәч — җилкә аша алга чыгарып, күкрәгенә сузып салынган калын-калын ике толым. Ул аның ап-ак тулы беләкләре... Йоклаган чагы булмаса, мин аңа карап торырга да кыймас идем. Болай да озак карап тора алмадым шикелле. Шунда да апамның хәзер инде саклап тотарга хәтәр дәрәҗәдә матурланып, өлгереп җиткән кыз икәнлеген тойдым. Әти-әниләр, күрәсең, моны миңа караганда үткенрәк хис иткәннәрдер, ул елны аны беркая да чыгарып йөртмәделәр.

Стәрлетамак турында Мәрьям апаның сөйләве буенча шуларны белдем: мөгаллимәләр курсы шәһәрнең элекке гимназия бинасында уздырылган. Ике ай ярым дәвам иткән. Төп игътибар курсисткаларның гомуми белемен күтәрүгә юнәлдерелгән. Ана теле, тарих, риязият, хикмәт (математика, физика) фәннәреннән дәрес алганнар. Укытучылар арасында күренекле педагоглар, яхшы мөгаллимнәр булган. Калага чехлар килеп, власть аклар кулына күчкәч тә, бу укытучылар үз дәресләрен дәвам иттергәннәр. Ә менә политграмотадан дәрес бирүче, ягъни Ленин, партия, совет власте һәм гомумән революция турыларында лекцияләр сөйләүче большевик укытучы Гобәйдулла Габдерәшитовны кулга алганнар, һәм әле кайчан гына лекцияләрен тыңлап йөргән яшь курсисткалар акларның аны, тарантас артына бәйләп утыртып, атарга алып китүләрен карап калганнар (мин икенче тапкыр Стәрлегә килгәндә, Бәдретдин җизниләр торган элекке Бухарский урамына «Габдерәшитов урамы» дигән исем бирелгән иде)...

Мәрьям апа ул елны укытучы булып эшләмәде. Айга-көнгә күренмичәрәк дигәндәй, өйдә генә торды. Өй эшләреннән бушаган араларында курстан алып кайткан китапларын укый иде.

Ул елны, гомумән, укуларның рәте булмады.

*Ахыры киләсе санда*

## Равил Фәйзуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Иңкүлектә килгән бер уй

Диңгезләре булган халык кол булалмый!
Һәрбер дулкын ярга бәрелеп искәртә аңа:
«Син минем күк иректе бул!
Иректе бул!!»

Зур таулары булган халык кол булалмый!
Кыялар тәкърарлый аңа һәр даим:
«Минем күк мәгърур, горур бул!
Горур бул!!»

... Ә мин менә иңкүлектә
кырмыскасы качкан түмгәк өстеннән
нәни чишмә тибешенә карап торам.
Күбәләкләр күләгәсен күрәм төптә.
Ә күңелдә —
диңгез өсләп
кыясына очкан
лачыннар.

### Җәй белән саубуллашу

Таңда күргән татлы төштәй
үтә бәхетле көннәр.
Искечә сентябрь кердe,
сәгатьләп сула гөлләр.

Кемнәрнең сагышын сөйри
торналарның чылбыры?
Кая безнең сихри төннең
чикерткәләре җыры?

Кояш булса да, җил! — диеп,
изүне төймәләдең.
Ярда йөзтүбән елый күк
балыкчы көймәләре.

Әллә җилдән, әллә гөлдән
тибрәнә пәрәвезләр...
Кашкарыйларга карыйлар
синең боеккан күзләр.

. . . . . . . . . . . . . . .

... Аерыласы килми җәйдән!
Китәсе килми синнән!
... Килер җәйләр бәхетен теләп,
дога укыйм эчемнән.

●

Кисеп йөгерәм җилләрне,
нык булсын аяк-кулым;
ярып йөзәм дулкыннарны,
киң булсын сулыш юлым;
өлкәннәрдән фатыйха алам,
уң булсын чыккан юлым;
затлы җаннарга елышам,
гел артсын яхшылыгым.

Тагын йөгерәм, тагын чабам,
ашкынам алга, янам.
Илаһи бер максат өчен
күтәреләм күк һаман.
Камиллеккә! Камиллеккә!
Гел камиллеккә табан!

... Ә Кояш күктә көлә!
«Егет, хәлеңне беләм!
Сөйләнмә ниләр генә,
сереӊ гади: бер сылуга
синең ошыйсың килә!
Бик тә ошыйсың килә!»

Әйе шул!

## Туган йортта — балалыкта

Иртәдән кичкәчә йөрим
Болынлыкта, баланлыкта!
Тугайлыкта, аланлыкта...
Йөрим тоташ балалыкта!

Арышларга башны куям,
күбәләкләр куып тотам.
Таяк тотып каршы барып,
ят көчекләрне куркытам...
Рәхәт тә соң балалыкта!

Күңелемдә бөртек кер юк.
Авыр гамьнәр юкка чыккан.
Шатлыгымның биеклеген
үлчи күктә тургай-нокта...
Рәхәт тә соң балалыкта!

Арып кайтам. Чәй өлгергән.
Өйдә тәмле исләр чыккан...
Иң татлы төшләр керәчәк —
кунам бүген Туган йортта!..

## Зәңгәрлек

Кышкы кичтә, эңгер алдыннан
бер зәңгәрлек сара дөньяны.
Һәркемгә дә бу чак киләдер дим
илаһие гына уйларның.

Шулай тиеш. Салкын карларны да
моңга өретүче төс бит ул!
Күкнең безгә: «Хәерле төн!» дигән
өнен иңдерүче кич бит ул!

## Көзге төндә

Дөм караңгы тышта. Суык.
Яңгыр ява, ява...
Китап укудан күзләр дә
ара таңга таба.
Килеп улымның юрганын
ипләбрәк ябам.
Аннан кысып кочаклыйм аны.
Ә ул — җылы, кайнар!
Кара төндә нур иңдергән
нинди бәхетем бар!
... Тышта серле яңгыр кызы
тора чәчен тарап.
Ә җил аның толымнарын
тәрәзләргә сара!
Ул чибәргә күз дә атмыйм —
торсын чәчен тарап!
Ятам уйлап — улым аша
киләчәккә карап.

## Июль. Таң. Идел. Икәү

Идел өсте... Юкә балы исе!

Сөттәй томан арасыннан
чак күренеп теплоход бара.
Дулкыннары безне иркәләп
көймәбезне рәхәт тибрәтә.

Ә бездән җавап шул мөсафирларга:
«Хәерле юл!
Тәмле төшләр — уянмаганнарга!..»
Ә, хәсрәте булып,
йоклый алмый барганнарга —
бар теләкләрнең дә иң олысы!

## Безнең Ниагара

Тау чишмәсе улагы астында
без-малайлар чупырдашабыз!
Дөнья гүләрендә ни гамь булсын —
өстебездә бер шау: су шавы!
Су толымына башларны тыккач,
чәчләребездән кояшлар чәчри!
Учларыбызда — салават күпере!
Күзләребездә — йолдызлар!
Тупырдашып баскан урын — Җир уртасы!
Әкиятләрне узар хыяллар — башта!
Беләкләрдә генә каз тәне бераз...
Тычкан утыдай сүрән генә кабынып алган бер уй:
«Соң кайттың дип әни кыйнамас микән?..»

... Байтак гомер кичкәч, хәзер генә,
исемен белдем
биек улаклы бу чишмәнең:
ул — малайлыкның безнең
Ниагарасы булган икән!

## Сездә рәхәт, сездә кыен...

Сездә рәхәт.
Сездә гөлләр бүтән.
Сездә Кояш үзгә карый кук.
Сезнең сәгатьләр дә гомерләрнең
тик бәхетле чагын саный кук.
Сездә ишетелгән һәр аваз да
кабатланмас гүзәл көй сыман.
Сездә бөтен тараф нурга тулган.
Сездә, ахры, һәр як кыйбла.
Сездә рәхәт!
Үзгә дөнья...

Сездә кыен.
Сездә читен миңа.
Сездә бар төшемне ут ала.
Сездә син кагылган бөтен нәрсә —
тәрәзәләр, диварлар яна,
кашагалар, китаплар яна...
Карашыңнан дөрләп мин янам!
Ике арада тагын кем яна?..
Я, алла!..

Сездә рәхәт, сездә кыен миңа...

●

Күзеңне йом да,
оныт бүгенгеңне!
Күм тирәнгә — күңел базына
ваклыкларны, мәшәкатьләрне...

Кит беразга әкиятләргә,
чык сабый чак сукмакларына,
йөгер каеннарга каршы болын буйлап...

Күзеңне йом да, үләннәргә күмел,
төклетураларны иркәлә,
дулкыннарда чалкан чайкалып тор,
ауна яңа яуган карда,
керфегеңә кунсын йолдызлар!

Күзеңне йом да,
шытсын кабат сабый хыяллар!
Чергән тамыр кебек калсын аста —
мәшәкатьләр, гайбәт, бурычлар,
җыелышлар, фани тетрәүләр...
Чыксын өскә үрләп —
онытылып бара торган хатирәләр,
оялчанлык, ялгыз айлы кичләр,
татлы өметләр, назга сусаулар,
гел яхшылык тулы китаплар...

Күзеңне йом да
кайт үзеңә,
асылыңа — ялгызлыгыңа.
Тагын якынай бер бала чагыңа!

●

Өскә авардай очлы кыялы
тарлавыклар буйлап үрмәлим.
Салкын. Юеш. Бер кат күлмәктән.
Тау очыннан — ни бау, ни җылы сүз...
Өстән ишелеп куя таш кантарлар
(кайберләре нәкъ миңа килә,
кемдер юри тәбәп ишә кук)...
Кул-аякка, башка тию бер хәл,
күз алмама тияр дип куркам!

Менә калсам әгәр —
барыбер
тирә-юньгә җете итеп карап,
каргыш, рәнҗеш, үпкә сүз түгел,
сокланулы сүзләр әйтәчәкмен
дөньяга...
кешеләргә...

## Йокысызлык

Эх, яшьлектәге бер генә сәгать йокы!

Тиздән — таң.
Саулар,
тазалар,
көчлеләр —
торырлар да
ташланырлар шау тормышка.
Гайрәтләнеп, яңа көч белән
яуларлар яшәүнең биегрәк үрләрен!

... Син дә торып чабарсың титаклап.
алар артыннан...
Сәдака өчен җеназага ияргән
гарип сыман.

## Кырымда

Диңгез шавы.
Яңгыр шыбырдавы.
Төнге чикерткәләр сайравы.
Тополь яфраклары лепердәве.
Күңелнең сагынып сулкылдавы...
Тагын диңгез шавы.
Яңгыр шыбырдавы...

Күктүбәдә минем өчен
симфония шулар инде.

## Кайчак уйлыйсыңдыр...

Эштән арып, кайчак уйлыйсыңдыр:
кешеләр таныймы хезмәтем?..
Маяклар да, һай, ишетә микән
адашкан җаннарның рәхмәтен?

## Туры килер...

Теләсәң күрсәтергә гел
алма күк кызыл ягың —
туры килер борылырга
кояш әйләнгән саен.

## Безнең гамь

Болытлардан да өстәрәк
чишмәләр бар.
Җир асларында шәһәрләр бар.
Һәркайсында безнең гамь бар.

## Кайтаваз

Кыш буена яуган ак карларның
ташыйсылары бар быел яз.
... Бик рәнҗеттең мине үткән елда,
шуңа хәзер сиңа сүзем аз.

## Теләк

Тагын чыкты тырнакларга
күгәрчен сөтләре.
Нәрсә телим?
Кайтсын иде бала чакның
хыял-өметләре!

1976

# Рәисә Ишморатова

# ЯЗМЫШЛАР

**«МИЛИЦИЯ ЛЕЙТЕНАНТЫ» ПОВЕСТЕНЫҢ ИКЕНЧЕ КИТАБЫ**

*Совет милициясенең 60 еллыгына багышлана*



Язучы Рәисә Ишморатованың пьесалары Казан, Уфа театрлары сәхнәләрендә, Әстерхан, Төмән, Оренбург, Чиләбе өлкәләре, Мари, Чуваш һәм башка республикаларда еллар буе куелып килә. Хикәяләре рус, башкорт, әзербәйҗан, кыргыз телләрендә басылды.

Ике пәрдәлек беренче комедиясе («Бай кияү») 1953 елда Әлмәт күчмә театрында куела. Яшьләрне гамьсез булмаска, намус һәм мәхәббәтләрендә турылыклы булырга өндәгән бу комедияне үзешчән драма коллективлары, халык театрлары хәзер дә уйныйлар.

1955 елда язылган «Тормыш юлында» исемле дүрт пәрдәлек драма Уфа академия театрында, Башкортстанның Салават, Баймак күчмә театрларында һәм Татар күчмә театрында уңыш белән барды һәм хәзер дә үзешчән коллективларда, халык театрларында өзлексез куелып килә. «Әйтер идем йөрәк серемне» лирик комедиясе 1965 елны Минзәлә театрында куелды. Ул әле дә театрлар репертуарында. «Яшьлек канат җәйгәндә» исемле пьеса исә Татар күчмә театрында зур уңыш белән барды. Ул бүген дә халык театрларында, мәктәп сәхнәләрендә уйнала. Рәисә Ишморатованың моннан кала да бер пәрдәлек пьесалары үзешчән драма коллективларында өзлексез куелалар. 1954 елны язылган «Куркыныч авыру» дигән бер пәрдәлек драма китап нәшриятында күп мәртәбә басылып чыкты һәм бүгенгесе көнне дә үзешчән драмтүгәрәкләрдә, агитбригадаларда уйналып килә.

«Милиция лейтенанты» повесте — милиция хезмәткәрләре тормышыннан алып язылган. Автор әсәрдә яшь буынны тәрбияләү, шул процесста гаиләнең, җәмәгать оешмалары һәм милиция органнарының роле, җаваплылыгы кебек актуаль мәсьәләне күтәрә.

Рәисә ханым халык белән еш очраша, аның төрле темаларга язылган очерк, мәкаләләре вакытлы матбугат битләрендә даими басыла.

Рәисә ханым Чистай шәһәрендә хезмәткәр семьясында туа. 1935 елны рафбак тәмамлый. 1942 елны Арча госпиталендә эшләгән чакта партия членлыгына кандидат итеп алына һәм 1945 елда Украинаның Винница шәһәрендә тугызынчы май көнне, Дәүләт Куркынычсызлыгын саклау комитетында эшләүче офицер Мәҗитова-Ишморатова партиягә кабул ителә.



Заһитка тормыш һәр вакыт ачык йөз күрсәтеп, елмаеп кына тормады. Егет булып җитәр-җитмәс үк аңа Ватан сугышында катнашырга, рядовой солдат булып, утлар-сулар кичәргә, ничәмә мәртәбә атакага барып, дошман белән күзгә-күз очрашырга туры килде. Яраланды. Бер кабыргасын фашист пулясы чәрдәкләп узды. Ярасы ике-өч ай буе сызлады. Җитмәсә, авырып госпитальдә яткан көннәрдә газиз анасының дөнья куюы, гомеренең соңгы сәгатьләрендә «Заһитым, Заһитым» дип ятулары турында хәбәр алу йөрәген өзгәләде. Күп, күп кичерде Заһит андый кайгыларны. Ләкин бүгенгесе барысыннан да авыррак. Аның мәрхүмә әнисе дә: «Дөньяда иң авыр хәсрәт — бала хәсрәте. Балаларыгыз сау-сәламәт булсын, тәүфыйклы булсыннар, тәүфыйк белән бәхет бергә йөри»,— дия иде. Ул Салих яткан диванга карап алды да, ачуын, рәнҗүен басарга тырышып, тәрәзә янына килде. «Мәгънәсез... Бер гамьсез йоклап ята. Әнисе белән төне буе борчылып чыктык. Керфек какмадык, ә ул типтереп йөри-йөри дә милициягә барып каба...»

Урамның каршы як тротуарыннан спорт киеме кигән Рәшитнең кызу-кызу атлап узып китүе аның уйлар агышын икенчегә борды. Рәшит Салих белән бер класста укый. Һәр иртәне я йөгерә-йөгерә каядыр бара, я кайта. Бәрәңге күтәргән булыр... Я бидон белән сөт... Димәк, өйдәгеләргә булыша. Ә бу... Ул артык түзә алмады, каты итеп:

— Тор, тор хәзер үк!..

Кухня ягыннан абына-сөртенә Мөршидә керде. Заһитның йөзенә бәреп чыккан усал карашын күреп, аның янына килде.

— Кычкырма инде, Заһит, бала төне буе йокламаган ич.

— Кем кушкан йокламаска. Әллә эшләп йөргәнме, ашарына ипи эзләп чыкканмы? Эшсезлектән, көчен кая куярга белмәгәннән урамда трай тибә. Кадерсез! Тор, дим...

Салих иренеп кенә башын күтәрде. Шешенеп киткән күзләре башта әтисенә, аннан әнисенә текәлделәр.

— Я, тор, улым, тор, — дип, Мөршидә Салихның өстендәге юрганын рәтләгәндәй итте. Аннары улының аяк очына диван кырыена утырды.

— Бар әле, Мөршидә, чәй әзерлә, башым сызлый, бар әле.

Салих әнисенең аркасына сул аягы белән төртте.

— Бар инде, әни, минем дә башым бик сызлый, чәй эчкәч узар, может.

Мөршидә, әкрен генә кузгалып, кухняга чыгып китте.

— Тор, дим!..

— Ял көне бит, йоклап калыйм, иртәгә мәктәпкә.

— Ике ай ярым йокладың, хәтта кирәгеннән артык. Йокы исерекләге белән саташып, хулиганнар арасына кереп киткәнеңне дә сизми калгансың түгелме?

— Хулиганнар?!. Минем бөтен дусларым да сезгә хулиган инде. Бәйләндегез бит... — Салих, юрганы астына капланып, әтисенә арты белән әйләнеп ятты.

Мондый әдәпсезлекне, мондый мәсхәрәләүне үз улыннан һич көтмәгән иде Заһит. Ул баскан урынында таптанып, ни әйтергә белми, Салихка карап торды. «Нишләтергә бу баланы? Сугарга ярамый, каты итеп кычкырсаң — анасы атылып килеп житә. Шау-шу, күз яшьләре башлана. Бу ни хәл бу?... Малай үсә, минем белән командовать итә башлады. Әле кайчан гына итәктән төшмәгән нарасый хәзер?..»

Ул юрган астында озын булып сузылып яткан Салихның гәүдәсенә карап торды. Аннары иртән милиция сержанты калдырып киткән повестканы, пижам кесәсеннән алып, тагын бер кат күз йөртеп чыкты.

«Барырга туры килә. Үз гомеремдә беренче мәртәбә милициягә барам. Нәрсә диярргә? «Ярдәм итегез, малайны жиңә алмыйм, мине тыңламый» дип акланыргамы? Тәрбия итә белмәгәнсез дип, Мөршидә белән мине ачуланырлар инде... Кеше көлкесе. Гомерем буе яхшы ата булып яшәргә тырыштым, бернинди начар үрнәк күрсәтмәдем кебек.. Укулар тәмамлангач та мәктәптә ремонт башлыйлар, мин дә булышачакмын, дигән иде. Бардымы, эшләдеме икән мәктәптә? Сорарга онытканмын».

Салих әтисенең бераз дулап алгач сүрелеп, яңадан йомшак сүзлегә әйләнәсен белеп, йокларанга салышкан хәлдә, күзләрен йомып ята бирде. Аның күңелендә күңелсез уйлар бере өстенә бере өелеп һаман чуалдылар.

«Хулиганнар, ди. Чыннан да, кемнәр соң алар? Әлегә кадәр Салихның Тәлгатьтән башка йөрешкән дусты, иптәше юк иде бит. Беренче мәртәбә ят малайлар белән дуслашты. Каян беләсең, хулиганмы, яхшымы алар? Уналты яшеңә житеп, бер-ике йотым кызыл вино эчү хулиганлык түгел әле ул... Иртәгә мәктәпкә баргач нишләргә? Милиция бәлки хәбәр дә иткәндер инде. Класс житәкчесе Хәлимә Бариевна, укучыларның күзләренә текәлеп, ике кулын пар канат итеп жәя дә: «Я, укучылар, нишлибез? Үзем генә бу мәсьәләне хәл итә алмыйм. Әнә бит Салих белән Тәлгать безнең класска нинди хурлык китергәннәр. Каникулда без мәктәп участогында эшләдек, экскурсияләргә бардык, ә алар? дисә... Хәлимә Бариевнаны да әйтер идем инде... Без Тәлгать белән: «Әти-әниләр белән жәйге каникулда Кырымга ялга китәбез», дигән сүзебезгә ышанды. Өйгә шылтыратып сорашмаган да...»

Салих өстеннән юрганын атып бәрде. Ванна бүлмәсенә трусиктан гына кереп, аны эчтән биклэп куйды.

Заһит кайнар чәй эчеп, яхшы костюмын киде. Янәшәсендә сүзсез генә басып торган Мөршидәнең беләгеннән тотып:

— Фәһимә егетен алып киләм дисә, пилмән пешер,— дип, авыр гына атлап чыгып китте.

Ислам Шәкүров өстәл янында утырып озак уйланды, төнлә аңа Салих сөйләгән сүзләрне язган кәгазьләрен тагын бер кат укып чыкты. Холкын, тормышын ныграк беләсе килде аның. Үзенең фикер юнәлеше дөрес булуына тагын да ныграк ышанды. Әйе, Салихның гөнаһлары усал нният белән эшләнгән түгел. Менә бит ул нәрсә ди:

Сорау: — Галим сезгә әлеге кызны мәсхәрәләргә теләгәнен белдергәч, нигә аңар каршы килмәдегез?..

Җавап: — Мәсхәрәләү? Мин аңламыйм... Нинди мәсхәрәләү? Без шаярдык кына. Көлә-уйный бардык та... Без бит картаны да шаярып уйнадык.

— Эчкән идегезме?

— Карта уйный-уйный гына кызып киткәнбез...

— Әлегә кадәр исерткеч эчкәнегез бар идеме?

— Юк, бөтенләй эчкәнем юк.

— Бәлки өегездә туган көн бәйрәме уздырганда эчкәнсездер?

— Юк, юк, туган көнемдә дә эчкәнем юк. Әнә шул көнне беренче тапкыр авыз иттем.
— Нишләтергә соң хәзер сине?
— Мин... Моннан соң андый эш эшләмәс идем. Бик үтенеп сорыйм, мәктәпкә хәбәр итмәсәгез икән, лейтенант абый? Үзем гаепле, ябып куйсагыз куегыз, әмма мәктәптәгеләр белмәсен иде.
«Кабат атлармы Салих бу юлдан, юкмы?» дигән сорауга Шәкүров туры гына җавап таба алмады. Шунысы ачык иде: «Бу беренче хәвеф-ле сигнал. Киләчәктә Салихны саклау өчен...»
Ишектән килеп кергән Заһитны Шәкүров аягүрә басып каршы алды.
— Гафу итегез, Заһит абый, сезне ял көнне борчырга туры килде. Рәхим итеп утырыгыз, — дип, аңа урын күрсәтте. Әңгәмәне рәсми төс-тә алып баруны уңайсыз күреп, өстәл янындагы урындыкка, Заһитның янәшәсенә килеп утырды.
Улы Салихның төнлә, иптәшләре белән бергәләп, унбиш яшьлек кызга бәйләнгәннәрен ишеткәч, Заһит тәмам коелып төште. Мәһабәт гәүдәсе кеп-кечкенә булып куырылып калды кебек. Тәненә салкын тир бәреп чыкты. Ул, сулышына буыла-буыла, «уф» дип, Шәкүровның күз-ләренә куркынып карады. Шәкүров аның нык борчылганын сизеп әй-тергә ашыкты:
— Бу эшне хәзергә туктатабыз. Салихның мәктәбенә дә хәбәр итү кирәкми. Сезнең белән даими элемтәдә булырмын. Шулай хәбәрләшеп торсак, минемчә, сезнең гаиләдә күңелсезлек булмас.
«Бу бит коточкыч, бу бит иң авыр газап, иң авыр хурлык»,— дип, аһ орды Заһит күңеленнән.
— Малай сезнең белән сөйләшкәнне сораса, ни дияргә икән миңа?..
— Бик гади итеп, тыныч кына... Бүтән беркайчан да мондый күңел-сезлекләр китермәвеңә ышандылар диярсез. Артыгы кирәкмәс. Үзенә уйланырга, үзенә хәл итәргә мөмкинлек бирегез.
Шәкүров белән саубуллашканда Заһитның кулы калтыранды. Яшь булса да, инде чәчләре агарып бетә язган, үткен кара күзле лейтенант алдында ул үзен бер сырхау кеше кебек хис итте.
— Үз каным үземне агулады, — диде үз-үзенә.

Алар шаяра-көлә Фәһимәләр урамына килеп чыктылар да, подъезд-лары янына җиткәч, туктап калдылар. Фәһимә стенага сөялде, Зөл-фәтнең күзенә карап нәрсәдер әйтергә теләде. Ләкин сүз тамак төбендә йотылып калды.
— Фәһимә! — диде Зөлфәт, аның кулыннан тотып.
— Әү, Зөлфәт?
— Нишләргә?..
Фәһимә тураебрак басты. Йөзе җитдиләнде. Йөрәге үрсәләнеп куй-ды. Нигә шулай икән? Нигә Зөлфәтнең сәеррәк һәрбер карашыннан югалып кала ул. Үзе Зөлфәтне эчкерсез ярата, ә үзе курка. Менә, менә Зөлфәт аны рәнҗетер, аның туктаусыз борчып торган нечкә бер хисен аңламас кебек тоела. Соң нишләсен Фәһимә?
— Фәһимә! — Зөлфәт кулындагы сәгатенә карап алды.— Сәгать ике туларга унбиш минут. Бүген ял көне. Гадәттәгечә, әни мине нәкъ икегә төшке ашка көтә. Нишлибез, ә?..
Фәһимә дә үзенең сәгатенә карап алды.
— Мөршидә апа да пилмән пешереп көтәм диде.— Алар, елмае-шып, бер-берсенә карашып куйдылар.
— Әйдә, алайса, бер ярты сәгатькә генә сезнекеләргә кереп чыгыйк та, аннан безгә йөгерербез, — диде Зөлфәт.

Фәһимә, яшь кызлардай йөгерә-атлый, өченче катка күтәрелде. Зөлфәт салмак адымнар белән аның артыннан атлады. Аларның кайтканын тәрәзәдән күргән Заһит ишекнең тышкы ягына ук чыгып баскан. Фәһимә, абыйсының агарып, ябыгып киткән йөзен күреп, борчылып куйды. Заһит ике кулын сузып Зөлфәт каршысына килде.

Өстенә килешле күлмәк кигән, чәчен кыска итеп кистергән, битен, кашын җиңелчә генә буяган Мөршидә дә Зөлфәтне, якын тугандай итеп, ачык йөз белән каршы алды. Салих өйдә юк иде. Зөлфәт аны сизмәмешкә салышты. Салих турында, гомумән, булып узган күңелсез вакыйгалар турында, бер генә сүз дә сөйләшмәскә дип юлда ук уйлап килгән иде ул. Салихның әтисе, зур заводның өлкән бухгалтеры Заһит абый — ачык күңелле, мөлаем, йомшак табигатьле кеше. Әдәбиятмы, сәнгатьме, гомумән, нинди генә темага булмасын, Зөлфәт белән ул җитди итеп, барысы турында да төпле фикер йөртеп сөйләшеп утырды. Соңгы көннәрне, участокта эшләр күп булу сәбәпле, үз эшеннән башка хәлләр турында иркенләп бирәү белән дә сөйләшеп утырырга туры килмәгән иде Зөлфәткә. Ул менә хәзер рәхәтләнеп гәпләшә. Шул ук вакытта Заһитның турыдан-туры аның эшенә кагылган мәсьәләләр хакында сөйләшмәвенә бүген бик канәгать ул. Фәһимә әледән-әле, Зөлфәткә сиздерми генә, сәгатькә карап ала. Башына ак яулык бәйләгән әнисенең, тәрәзә янына басып, Зөлфәтнең кайтканын зарыгып көтүен күз алдына китерә.

Зөлфәт, Фәһимәнең уйларын сизгәндәй:

— Рөхсәт итегез, Мөршидә ханым, Заһит абый, мин китим. Фәһимәне дә үзебезгә чакырам. Әгәр вакытыгыз булса, әйдәгез, бергәләшеп барыйк, — диде.

Мөршидәнең Зөлфәтләргә барасы, аның анасын, торган өен күрәсе бик килсә дә, беренче танышкан көнне үк бару килешеп бетмәс дип, чакыруны кире какты:

— Булыр әле, Зөлфәт энем, барган чаклар да булыр. Рәхмәт, менә килгәнсез, якын күргәнсез,— дип сөйли-сөйли, Зөлфәт белән Фәһимәне ишегалдына озата чыкты. Аннары урам чатына кадәр үк барды. Зөлфәт белән саубуллашырга кулын сузгач:

— Зөлфәт, ни дим... Салихларга алай-болай...

— Әй, Мөршидә апа, ул турыда сөйләшмә әле, көн әнә нинди матур, бар, абыйны урамга йөрергә чакыр, — дип, Фәһимә, апасының иңеннән кочып, аны өйләренә таба озатты.

Үз йортлары янында озын буйлы, чандыр гәүдәле, өстенә кызгылт-көрән плащ кигән ирне күргәч, Зөлфәт сул кулының йодрыгы белән маңгаен ничектер сәер төйгәләп, уйлап алды: ир кешенең фамилиясен исенә төшерергә тырышты. Ә ул исә, Зөлфәтне күргәч, әкрен генә атлап, алар каршысына килә башлады:

— Ә-ә, Васильев Вадим Николаевич... нче номерлы завод инженеры. Мине эзләп килдеме икән әллә? — дип, иңсәләрен сикертеп куйды Зөлфәт.

Вадим Николаевич Зөлфәткә кулын сузды:

— Исәнмесез, иптәш лейтенант! — Аннан мөлаем гына елмаеп баш иде дә Фәһимә белән исәнләште.

— Гафу итегез, зинһар, ял көне булса да, сезне юллап килергә батырчылык иттем, — дип, хәсрәтле күзләре белән Зөлфәткә карады.

Зөлфәт аңар ишек буендагы эскәмиягә утырып торырга кушты да Фәһимәне өйләренә алып кереп китте.

Фәһимә күз алдына китергәнчә, Камилә апай, чыннан да, бик сөйкемле, көләч йөзле апай икән. Ул, һич көтмәгәндә, улының кыз белән кайтып керүенә башта аптырап-югалып калса да, үзен, кем әйткәндәй, бик тиз кулга алды. Ишек төбендә тукталып калган Фәһимәне күтәреп алган төсле: «Хуш киләсең, кызым, әйдә, түрдән уз,— дип, ди-

ванда урын тәкъдим итте. Күңеленнән генә: яраббем, төкле тәпиләрең белән, бәхетең белән кил, күптән көткән киленем шулдыр инде, мөгаен», — дип уйлап куйды. Югыйсә, Зөлфәт моңарчы өйгә кыз-кыркын китермәде. «Мин, әни, өйгә бары өйләнергә дигән кызымны гына алып кайтырмын», дигән сүзе дә билгеле аның. Ана кеше куанычыннан кая басканын белмичә, өстәл өстенә ак эскәтер китереп япты.

Зөлфәт ишектән кызу гына чыкты да үзен көтеп торган Вадим Николаевич янына барып утырды.

Вадим Николаевич кесәсеннән кулъяулыгын алып битен, маңгаен сөртте, башын бер түбән иде, бер читкә борды. Аннан ничектер инәлеп Зөлфәткә карады.

— Сөйләшик әле, иптәш лейтенант, миңа киңәш бирегез, өйдә күңелсезлек... — Ул бик авыр сулап куйды, улы Николайның кичә милициягә эләгүен, нииндидер җинаять эшләвен әйтте.

Зөлфәт беразга аптырап калды.

— Гаҗәп!.. Нигә мин бу турыда бер нәрсә дә белмим?

— Миндә яшәми ул, әнисендә. Ленин районында тора. Беренче хатыннан.

— Фамилиясе Васильевмы?..

— Васильев Николай Вадимович.

Васильев Николай! Әйе, әйе... — Ул аны бик тиз хәтерләде. Теге көнне Маһруй әбиләр өеннән атылып-бәрелеп чыккан чандыр гәүдәле егет, иңенә телефон аппараты аскан «элемтәче». Маһруй әбинең илле сум акчасын чәлдергән егет. Зөлфәт дикъкать белән Вадим Николаевичка карады: — Әйе, әйе, ул егетнең борыны менә шушындый курносрак иде, маңгай да нәкъ шушындый чыгынкы. Менә сиңа мә...

Тик Зөлфәткә уйланып басып торыр чакмыни. Өйдә беренче мәртәбә килгән Фәһимә көтә. Вадим Николаевичны да хәсрәт капчыгы күтәртеп урамда бастырып тоту ярамый.

— Димәк, Коля сезнең улыгыз?

— Беренче хатыннан.

— Беләм мин ул егетне. Тик менә сезнең улыгыз икәнен...

— Минем белән яшәми. Кечкенәдән үк аерым.

Вадим Николаевич кулларын, кая куярга белмәгәндәй, әле тезләренә куйды, әле кесәсенә тыкты. Авыр сулавын Зөлфәткә сиздермәскә тырышты.

— Әлегә кадәр сезгә килгәне бар идеме?

— Бөтен бәла дә шунда шул. Килгәне юк. Әнисе аны сабый чагыннан ук миңа күрсәтмәде. Ничә мәртәбәләр теләсәм дә — рөхсәт итмәде. Хәлбуки, Коляның ятим калуында минем бернинди гаебем юк.

— Бүген бу турыда сөйләшеп торуның файдасы юк, Вадим Николаевич. Минемчә, Коляның сезгә килүе бик яхшы.

— Иртән иртүк килде. Кулында повестка. Әнисен милициягә чакырганнар. Ә ана кеше аны куып чыгарган. «Күземә күренмә, бар, әнә повестканы әтиеңә тапшыр, милициягә аның белән бергә барыгыз», дигән. Акча сорый, кемнекендер урлаган, түләргә кирәк... Мине бәладән коткар, ди... Нишләргә миңа? Киңәш бирегез. Минем тәрбиямдә үсмәгән бала ич...

— Улыгызның кайдадыр сукбай булып йөрүен теләмисездер бит?! Кичә сөйләшкәндә үзен яхшы тотты. Иптәш малайларына кереп илле сум акча урлавын яшерми әйтте.

— Койрыгына баскач...

— Койрыгына түгел, башына бассаң да сөйләми аның кайбере.

Вадим Николаевич Зөлфәткә күтәрелеп карады һәм: «Үзе милиционер, ә үзе җинаять юлында йөрүчеләрне аклап-яклап маташа. Әнә шу-

на күрә дә законны санламый башлады хәзер кайбер яшьләр», дип уйлап алды. Шулай да үз фикерендә нык торды. Хәзер лейтенантны алып барырга да Коляны өеннән куып чыгарырга уйлады. Адәм хуры бит, анасы гомере буенча баланы яшереп, әтисенә каршы котыртып яшәде. Әзме булды Вадим Николаевичның улын күрәсе килеп өзгәләнгән сәгатьләре. Икенче хатынга өйләнеп, малае Сергей тугач кына аңар бераз җиңел булып китте. Вадим Николаевич беренче хатыны Лида белән аерылышу сәбәпләрен асылда әле бүгенгә кадәр дә төшенә алганы юк. Ул Лидага яратып өйләнде. Лида да ярата кебек иде... Бала туып бер яшькә җиткәч исә: «Яратыша алмыйбыз... аерылышыйк. Мин синнән бала тәрбияләргә алимент та сорамаячакмын», — диде хатыны Лида. Аерылыштылар. Ике бүлмәле фатирны икегә бүлделәр. Лидага бала белән шәһәр уртасында әйбәт бүлмә, ә Вадим Николаевичка — шәһәр читендә, карават сыярлык бүлмә...

— Бик үтенеп сорыйм, иптәш лейтенант, барыйк безгә!!!

— Минем сезгә килеп керү Коляның ачуын чыгармасмы икән? «Милиция алып килдең», дип, улыгыз үпкәләмәсме?..

— Сез бигрәк инде, иптәш лейтенант, кемнең хәтерен саклыйсыз: юлдан язган бер малайныкынмы, әллә...

— Сез өлкән кеше, җирдә нык басып торасыз, ә ул әнә шулар кебек, — Зөлфәт, ияге белән ымлап, җилдә тирбәлгән агачларга күрсәтте. — Тирбәлә, бөгелә, сыгыла. Катырак җил иссә — сынып та куюы мөмкин. Нинди генә булмасын, кеше бит ул, кеше...

Зөлфәт белән Вадим Николаевич кайтып кергәндә, Коля стена буендагы диванда ята иде. Ботинкаларын да салмаган килеш. Бүлмәгә кеше кергәнен белсә дә, ул урыныннан кузгалмады.

— Торып утырырсың бәлки, кунак бар ич,— дигәч кенә муенын әтисенә таба каерып карады. Күзләре Зөлфәт күзләре белән очрашкач, урыныннан сикереп торды да идәндә яткан пинжәген алып иңсәсенә салды. Әллә басып торырга, әллә яңадан диванга утырырга теләпме, әйләнә-тирәгә карады.

— Исәнмесез, — диде аңа Зөлфәт коры гына. — Тагын очраштык?..

Коля диванга утырды. Ачу белән әтисенә карап торгач:

— Рәхмәт, эти, үзең озатып җибәрергә булдың, ә? Рәхмәт!

Аның битенә күкле-яшелле таплар бәреп чыкты. Кинәт ул өстендәге күлмәк изүен аерып җибәрде дә:

— Эх, сез!.. Сез дә бала тудырган, имеш. Берсе өеннән куа, икенчесе төрмәгә озатырга милиция алып килә. Мә, озат, озат төрмәгә! — дип ярсып ишеккә таба килде егет. Зөлфәт җәһәт кенә Коляның юлына аркылы төште:

— Тәртипле булыгыз, гражданин Васильев!

— Өйгә килеп мине куркытырга сезнең хакыгыз юк, — диде Коля.— Тәртип бозмадым, үз әтием янына килдем. Ул миңа ярдәм итәргә тиеш, ул минем өчен җаваплы. Бүген миңа акча кирәк... Сез бит, лейтенант, минем хәлне беләсез...

Аягында көчкә басып торган Вадим Николаевич икенче бүлмә ишеген аягы белән генә бәреп ачты да атылып бүлмәдән чыгып китте.

Зөлфәтнең җен ачулары кузгалды. Буйлары аталарыныкыннан да зур булган, типсә тимер өзәрлек егетләрнең: «Безнең өчен әти җаваплы, әти миңа ярдәм итәргә тиеш, ул бурычлы», дигән сүзләрен еш ишетә ул. Бу фикерен ул Коляның үзенә дә әйтмәкче иде. Шул чак, кулына кечкенә тартма тотып, Вадим Николаевич керде. Шул тартмадагы кәгазьләрне алып Коля басып торган якка ыргытты.

Лида алимент сорап судка бирмәсә дә, Вадим Николаевич ай саен улына тиешле акчаны почта аша җибәреп торды. Бу кәгазьләр шул акчаларны җибәргән квитанцияләр иде. Ничек инде Коля шуны белмә-

гән? Әллә белеп тә белмәмешкә салышамы, әтисенә бәйләнергә бер сәбәп эзлиме?..

Коля идәнгә, диван, тумбочка өсләренә төшкән квитанцияләрне җыйный башлады. Ул аларны шашып, ашыгып җыйнады. Әйтерсең лә ул кәгазьләр аның хәзерге авыр хәлен җиңеләйтә иде. Үз янында басып торган әтисен дә, Зөлфәтне дә онытты. Текәлеп-текәлеп әле бер квитанцияне, әле икенчесен укыды. Юк, юк, акчага комсызлыктан түгел иде аның бу хәле. Әтисе, димәк, аны онытмаган, әтисе аның янәшәсендә генә яши һәм Коляның тормышы белән кызыксынып яши. Колагында әнисенең: «Әтиең эчеп-исереп йөрде, сиңа акча да җибәрмәде», дигән сүзләре тагын яңгырады.

— Нигә ялганлаган ул? Нигә?... — Ул әтисенә сораулы итеп карады. Вадим Николаевич аңа җавап бирмәде, тәрәзәгә борылды. Коля Зөлфәт янына килеп басты.

— Әйдәгез, киттек. Сез мине алырга килдегезме? Мине бит расписка белән генә чыгардылар. Тикшерү беттемени?..

Икенче бүлмә ишегендә звонок чылтырады. Вадим Николаевич хатынының:

— Улым, кайттыңмы? Әнә абыең Коля. «Нигә ул безгә килми?» дип аптырата иден, әнә килде Коля абыең, — дип ашыга-ашыга сөйләгән сүзләре ишетелде. Бүлмәдәгеләр шул ишек ягына борылып карадылар.

Ишектән Вадим Николаевичка да, Коляга да нык охшаган, озын, чандыр буйлы, ак йөзле, чыгынкы маңгайлы яшүсмер керде. Ул, озын кулларын сузып, Коля каршына килде.

— Коля абый... Яхшы булган, килгәнсең...

Коля энесенә уң кулын сүзсез генә сузды, сул кулы белән квитанцияләрне пинҗәк кесәсенә тутыра башлады. Бүлмәгә кулына ап-ак итеп юылган күлмәк тотып, тәбәнәк буйлы, үзенең кечкенә икәнен яшерер өчен булса кирәк, аягына шактый ук биек үкчәле туфли кигән, чәчләрен баш түбәсенә өеп куйган, барлык йөзе белән елмаеп, гаҗәеп сөйкемле ханым — Вадим Николаевичның хатыны керде. Ул кыю гына атлап Коля янына килде дә:

— Әйдәгез әле, Коля, ваннага кереп юынып чыгыгыз да менә бу чиста күлмәкне киярсез, — дип сөйләнә-сөйләнә, Коляны култыклап алды. Коля әтисенә: «Нишлим?» дигән сораулы караш ташлады. Шуны аңлаган Вадим Николаевич:

— Бар, юынып чык, сүзләрне соңыннан сөйләшербез, — диде.

— Ярый, сау булып торыгыз. Иртәгәләргә тагын бер кереп чыгармын әле, — дип, Зөлфәт ишеккә юнәлде. Аның сүзләрен ишетеп алган Коля юыну бүлмәсенә кереп барган җиреннән тукталып калды:

— Кирәкми, кермәгез, лейтенант, минем өчен әтиләрне борчып йөрмәгез...

— Алайса, үзегез килерсез. Бүгеннән башлап минем участок кешесе булырсыз, дип уйлыйм әле мин,— дип куйды Зөлфәт, эчкерсез елмаеп.

Урамга чыккач, Зөлфәт бераз туңып киткәндәй булды. Бу туңу салкынлыктан түгел, кешеләрнең коточкыч язмышлары күңелен, йөрәген тетрәтүдән иде. Өч кеше. Үз язмышларын үзләре үк хәл итәрлек өч кеше. Өчесе дә һәлакәткә очраган тормышларын җайга сала алмаудан үзләре гаепле. Берсен дә акламады аларның Зөлфәт. Вадим Николаевич гаилә тормышы бозылуда бары хатынын гына гаепли. Ә бит яхшылабрак уйлап караса, үзендә дә гаеп булгандыр. Әйтик, гаиләдән киткәч ул балага алимент акчалары җибәрү белән генә тынычланган. Акча җан җылысы түгел бит. Нигә улының тормышы белән кызыксынмаган. «Сергей тугач, мин аны оныттым да инде», — ди. Ә бит ничек кенә булса да сезнең бала ул, хөрмәтле Вадим Николаевич. Хөкем кар-

шында булмаса, намусыгыз каршында гомер буена җаваплы сез аның өчен. Ә ана кеше нигә дип баланы үз атасына каршы котырткан? Баланың атасы бер генә бит. Бала читтә яшәсә дә, «Минем үз әтием бар» дип яшәргә тиеш. Сабый чакта әтисен эзләп таба алмаса да, үсеп акылга утыргач, балалар аталарын, аналарын барыбер табалар. Ләкин төрлесе төрлечә, төрле хәлләрдә таба. Нигә Коля әлегә кадәр әтисенә карата ачу саклап йөргән? Үсеп буйга җиткәч, атасы белән кара-каршы утырып, нигә сөйләшә-аңлаша алмаган? Вадим Николаевич та, аның аерылган хатыны Лида да югары белемле, җаваплы эштә эшләүчеләр. Димәк, кешеләргә белем генә җитми, әдәпле, тәүфыйклы, рухи культурага ия булу да кирәк. Зөлфәт өч кешенең фаҗигале язмышын күзәтүче гади шаһит кына түгел, ул аларны дөрес юлга, кеше исемен лаеклы йөртерлек юлга юнәлтү өчен дә ярдәм итәргә тиеш. Вадим Николаевич үзе дә аңардан киңәш сорады: «Ярдәм итегез?!» — диде. Ләкин ничек ярдәм итәргә? Ул иртәгә бүлекчәдә Коля турында сөйләячәк, әлбәттә. Иң әүвәл Коляны Маһруй әбиләрдән чәлдергән илле сум өчен гаеплиләр. Аның эше хәзер тикшерү органнарында. Милициядә берни дә яшерми дөресен сөйләп бирү Коляның эшен йомшартачак, билгеле. Әллә Тәлгатьнең әтисе Арслан абый белән сөйләшеп карарагамы? Әгәр ул Коляны гафу итсә? Коля илле сум акчаны аларга кайтарып бирәчәк... Ә киләчәге ничек Коляның? Кайда, кемдә яшәргә тиеш ул?..

Зөлфәтнең күз алдына Коляның акыллы, зәңгәр күзле энесе Сергей килеп басты. Әйе, туганлык хисе бар аңарда. Үги энисе дә Коляны читләтергә охшамый.

Зөлфәтнең күңеле тынычланып киткәндәй булды. «Иртәгә иртүк Вадим Николаевичның эшли торган җиренә барып, бераз сөйләшеп утырырмын». Тәлгатьнең дә әтисе курорттан кайткандыр, аларны да күрергә кирәк. Ул сәгатенә карады, вакыт соң иде инде. «Минем турымда хәзер Фәһимә нәрсә уйлый икән?.. Авыр булачак аңа минем белән яшәүләре», — дип көрсенеп куйды... «Кешеләр тормышын күреп, тикшереп, төрле нәтиҗәләр ясап йөрисең, ә үз башыңа төшсә шундый хәлләр?» Фәһимәң: «Җитәр, дускаем, эштән кайчан кайтканыңны көтеп гарык булдым инде, дип, баласын җитәкләп, ташлап чыгып китсә?..» Аның тәннәре чымырдап куйды. «Бәлки инде китеп тә баргандыр... Әни әйтмешли, аллам сакласын».

Ул адымнарын тагын да кызулатты, өенә ашыкты.

Камилә белән Фәһимә, бер-берсеннән азрак тартынып, оялыбрак булса да озак сөйләшеп утырдылар. Камилә апай Зөлфәтне мактаудан курыкты. Ә бит кайчакларда ана өчен мактаулы уллар да, өйләнешкәч, хатыннарына бик үк ярап бетмиләр. Әллә кайдан килеп чыга шунда килешмәгән яклары. Әле генә туйлары була, икенче очратканда аерылышканнар да инде. Әнә, күрше егете — үзе чибәр, холкы да әйбәттыныч, сабыр, сүгенми, кычкырмый, кулыннан теләсә нинди эш килә. Кирәгенчә, матур итеп, туйлап өйләнде. Киленне дүрт «Волга» машинасын чәчәккә күмеп алып кайттылар. Ярты ел да узмады, хатынын яңа гына биргән фатирда калдырып, егет әнисе янына әйләнеп кайтты. Әнисе: «Ник аерыласыз?» дип сорагач, «Аңа бер сүз әйтеп булмый, тота да, чалтыратып яңакка суга»,— дип әйткән ди. Нинди тамаша инде бу? Ир кадәр ирнең битенә кемдер суга... Ул, үзенә сиздерми генә, Фәһимәне бик сынап карарга тырышты. Болай сабыр, инсафлы күренә, сүзләрен дә җайлап кына сөйли кебек...

— Менә шулай инде, кызым, төн дими, көн дими, өйдә кадерле кунак бар дими, берәр кеше килеп, үзенең гозерен, бәхетсезлеген сөйләдеме, эчә торган чәен дә эчеп бетерми, фуражкасын кулына тота да изүен каптыра-каптыра чыгып чаба. Я, шулай килештеме инде? Беренче тапкыр сине алып килде, ә үзе... — Камилә апай, кирәксезрәкне ыч-

кындырам, ахры, дип, кинәт сүздән туктый, ә үзе, Фәһимә нәрсә әйтер икән дип, уйга кала.

Фәһимә чынын гына үзе дә аңламый иде: үпкәләргәме Зөлфәткә, кайтып китәргәме, көтәргәме? Беренче мәртәбә генә түгел инде — берәр төрле эше килеп чыкса да, ниндидер шиклерәк кеше очраса да, Фәһимәне ташлый да китә.

Фәһимә моңаеп кына уйланып утырган Камилә апайны кызганып куйды. Тизрәк аны борчулы уйларыннан арындырасы килде.

— Аның эше шул бит. Зөлфәт урынында, Камилә апай, мин дә шулай булыр идем. Кеше үзенең хәсрәте белән килгән, ә Зөлфәт, аны борып кайтарып җибәреп яки урам уртасында бастырып калдырып, безнең белән күңел ачып утыра бирсә, сез дә, мин дә аны яратмас идек.

Камилә апайның йөзе көләчләнде. Күңеленнән: «Әй, рәхмәт төшкере, балакаем, аңлый икән, мәнле икән», дип сөенеп куйды. Ул сугыш елларында госпитальдә санитарка булып эшләгән иде. Иртән һәр көнне радиодан: «Бүген син фронт өчен нинди файдалы эш эшләдең?» дигән сүзләр яңгырый. Кая узсаң, шунда стеналарга: «Тукта! Син бүген фронт өчен нәрсә эшләдең?» дип язылган плакатлар эленгән. Шушы сүзләр онытылмаслык булып күңелгә сеңеп калган, ахры. Кем дә булса берәр кешегә яхшылык эшләмәсә, көнен бушка узганга исәпли ул. Эшкә киткәндә Зөлфәткә дә: «Улым, һәр көнне һәркемгә кечкенә генә булса да яхшылык эшлә, рәхмәт сүзен күбрәк ишетергә тырыш, борынгылар «бер рәхмәт мең бәладән коткарыр» дигәннәр», дип сөйләнеп ала.

— Кызым, әллә диванга мендәр салыймы, бераз таянып тор. Хәзер, хәзер кайтып җитәр.

Фәһимә, китап шкафы янына килеп, Чеховның өченче томын алды да диванга утырды. Камилә апай, шкафның пыяласын, тузанлы булмаса да, ап-ак чүпрәк белән сыпырып алды. Аннары тәрәзәдән карап тора башлады. Аның Фәһимәгә әнә теге кечкенә сарай эчендә төрле эш кораллары барлыгын, әтисеннән калган мастерской хәзер инде Зөлфәтнеке икәнен, менә бу матур китап шкафын да Зөлфәт үзе ясавын сөйлисе килде. Ләкин берни әйтмәде. Фәһимә алдында мактану булыр дип уйлады. Шулай да:

— Китап шкафын да, кухня кирәк-яракларын да Зөлфәт үзе ясады. Аның бертуган абыйсы самолет заводында эшли. Анысын да алтын куллы егет дип бик мактыйлар. Әтиләренең дә белмәгән һөнәре юк иде, мәрхүмнең,— дип сөйләнә-сөйләнә, Фәһимә янына килеп утырды.

Фәһимә китапның беренче битендәге «Ауда булган вакыйга»ны укый башлаган иде. Күзләре укый, ә уйлары хәрефләр булып китап битләренә тезелә сыман.

«Үзең хәл ит инде, Фәһимә, яратасыңмы Зөлфәтне, юкмы? Менә аның тормышы, бөтен барлыгы шунда. Милициядә эшли, укый. Үз кулы белән тормыш өчен кирәк-яракны да ясый белә икән. Чибәр. Буйсыны мәһабәт. Тик ул синең өчен булырмы? Әллә сине, япа-ялгыз калдырып, төннәр буе көттерерме?... Көттерер, билгеле. Зарыктырыр... Төнен дә, көнен дә аның өчен борчылып яшәрсең».

Аннары узган көннәре күз алдына килде. Дамирга иргә чыкканда мондый сораулар биреп газапланмаган иде Фәһимә. Туй була, ир белән хатын бергәләп яши башлыйбыз, бала туар... Дамирның характеры, эшләгән эше, йөргән юллары бер дә кызыксындырмады. «Яратам» диде дә... Өйләнешеп бер мәртәбә хаталануны кичерергә була, ә менә икенче хаталансаң... Көтеп калдың. Кайда йөри ул, нәрсә эшләп йөри, кайчан кайта?.. Әзерлә җавабыңны, Фәһимә!..

Ишектә звонок чылтырады. Кулына фуражкасын тотып, йөзе бераз алсуланган Зөлфәт керде дә ишек янагына сөялде. Аның күзләре дә, иреннәре дә бәхетле елмая иде. Камилә апайның, Фәһимәнең дә күзлә-

рендәге шатлыклы очкын, мөлаем елмаюлары, анықына кушылып, өй эчен балкытып җибәрде.

— Гафу итегез, әни, Фәһимә! Бик тиз кайтырмын дигән идем дә соң... Рәнҗемәгез, ачуланмагыз инде,— дип, ботинкаларының шнурын чишә башлады Зөлфәт.

Камилә апай улының аягына йомшак туфлилар китерде. Фәһимә, аның фуражкасын алып, Зөлфәт каршында басып калды. Алар озак итеп чәй эчтеләр. Нинди тәмле чәй! Нинди ямьле, матур икән ич аларның бүлмәләре! Ә кайчакларда бу ике бүлмә Камилә апайга да, Зөлфәткә дә ошап бетми иде кебек бит — түшәмнәре тәбәнәк, кешеләр сөйләшкән тавыш стена аша ишетелә... Хәзер исә барысы да җитеш, барысы да яхшы. Фәһимәнең моңлы гына, сабыр гына сөйләшүе, тыйнак кына көлеп куюы өйгә нур, күңелләргә рәхәт бирә. Зөлфәт сиздерми генә әнисенең йөзенә, күзләренә карады. Ул да ничектер матурланып, яшәреп киткән кебек. Күлмәгенең дә иң матурын кигән.

«Яраткан Фәһимәне, ошаткан... Әллә әйтимме: «Әни, фатиха бир!» Әллә Фәһимәне бүген өенә дә җибәрмәскәме? Мин әни бүлмәсендә йоклармын, алар әни белән икәү бу бүлмәдә».

Ул Фәһимәнең:

— Зөлфәт, Камилә апай, миңа китәргә рөхсәт итегез! — дигән сүзләренә, йокыдан уянгандай, калкынып куйды.

— Китәргә дисең? Вакыт ничә соң әле? Ун тула икән...— Камилә апай үз бүлмәсенә кереп ишекне ябып ук куйды: яшьләр, үзләре генә калып, бераз сөйләшсеннәр, серләшсеннәр диюедер инде. Зөлфәт урыныннан кузгалмады. Ул Фәһимәгә беравык карап торгач:

— Китәсең дә мени инде? Ә кайчан бөтенләйгә киләсең, беркайчан да китмәскә?

Фәһимә башын түбән иде.

— Кызык бу тормыш, дөресрәге, кешенең характеры димме... Бая сине өйдә калдырып чыгып китү шундый авыр булды. Вадим Николаевич белән берничә минут сөйләшермен дә әйләнеп керермен дигән идем. Ләкин аларның өйләренә үк барып йөрергә туры килде. Мавыгып киткәнмен. Кинәт нидер эшлисе, кемнәргәдер ярдәм итәсе килде. Ни сәбәп дисәм, гаепле кеше син икән бит...

Фәһимә күзләрен тутырып Зөлфәткә карады.

— Әйе, син. Мине өйдә көтеп торасың. Син дөньяда бар! Бар гына түгел, минем өемдә син... — Зөлфәт Фәһимәне, ике кулыннан алып, үзенә тартты. Нык итеп күкрәгенә кысты. — Озак йөргәнгә ачуланмадыңмы?

— Мин бүген синнән башка яшь алмавыма тәмам ышандым, Зөлфәт.

Зөлфәтне әйтерсең кайнап торган суга ыргыттылар, юк, боз дингезенә салдылар. Ул янды, туңды. Күз алдына әллә нинди төсләр кушылып, өй эче танымаслык хәлгә килде. Йөрәге ярсып типте.

— Әни..., — диде ул дулкынланып.

Камилә апай ишекне сак кына ачып, яшьләр янына чыкты.

— Әни, мин... без... Фәһимә белән өйләнешергә булдык. Син ризамы?

Камилә апай Фәһимәнең аркасыннан нык итеп сөйде һәм аны йомшак кына итеп кочагына алды. Аның күз яшьләре Фәһимәнең муенына тамды. Ак батист яулыгы башыннан шуып төште. Шунда Зөлфәт әнисенең агарып беткән чәчләрен беренче мәртәбә күрде.

— Я, әни, нәрсә дисең?

Камилә апай күзләренең шатлык яшьләрен балаларыннан яшерергә дә теләмәде, алар аның бите буйлап ага бирде.

— Әй, улым, сорап тормасаң да, минем риза икәнемне беләсең бит инде.

Иртәнге җиде тулу белән, кулына портфель тотып, Салих урамга чыкты. Әтисенең: «Нигә иртә барасың?» — дип соравына «Мәктәпне сагындым» дип кенә елмаеп куйды. Аяк астындагы вак ташларны ботинка башы белән типкәли-типкәли, урам буйлап атлады. Күңелендә аның үзе дә һәм бүтән башка берәү дә аңламаслык бушлык иде. Каршысына бер кулына бидон белән сөт, икенче кулына ипи тотып кызу-кызу килүче Рәшитне күргәч, Салих, башын күтәреп, тукталып калды. Рәшитнең:

— Мәктәпкәме, нигә бик иртә? — дип соравына ул:

— Шулай... Барам әле...— дип кенә куйды.

— Мин менә әнигә боларны кайтарып куям әле. Көт мине...

— Тиз чыксаң гына...

— Хәзер!

Салих чат башындагы йорт кыриена килеп басты. Гаҗәеп җылы, кояшлы иртә. Ә көндез, әлбәттә, эссе булачак. Шундый матур көнне класста тынчып ничек итеп алты сәгать утырмак кирәк. Урамның әле теге, әле бу башыннан, бәйләм-бәйләм чәчәкләр тотып, әниләренең кулларына ябышып, беренче класста укыячак нәни балалар бара. «Кайсысы күңеллерәк? Унынчы класска барумы, әллә беренчегәме?» — дип, үзенә сорау куйды Салих. Һәм шунда ук үзе җавап бирде: «Әлбәттә, унынчыга. Тугыз ай укыйсы да, дүрт ягың кыйбла — теләсәң, укы, теләсәң эшлә».

Кулындагы өр-яңа портфелен уйната-уйната, Рәшит килеп җитте. Аның модный ботинкасы шундук Салихның күзенә бәрелде:

— Но, малай, бу күн товарың!.. Класстагы барлык кызлар тик синең артыңнан чабарлар инде. «Кайдан алдың, кайсы илнеке?» дип сорашып йөдәтерләр.

— Ленинградтан алып кайттым.

— Ничек инде алып кайттың? Әйтерсең лә Ленинградка барган...

— Син бит ел саен я Сочига, я Кырымга барасың. Мин менә быел Ленинградка бардым. Җәйге каникулда мәктәп үземә беркеткән эшне бетергәч, әниләр фабрикасына барып эшләп йөрдем.

— Нинди эш?..

— Төрлесен. Ни кушсалар — шуны.

Салих, мәктәпкә барып җиткәнче, Рәшиткә күтәрелеп карамый, сөйләшми генә уйланып барды. Яңа уку елына хәзерлек буенча аңа да байтак эш йөкләтелгән иде. Ул бер-ике көн барды да мәктәп тирәсеннән бөтенләй югалды...

Шау-гөр килгән класска барып кергәч, Салихның әлеге авыр уйлары онытылды. Классташлары кайсы кочаклаша, кайсы бүлмә буйлап зыр-зыр әйләнә, кычкырып-кычкырып кызык хәл турында сөйләшәләр иде. Ниһаять, звонок булды һәм класста тынлык урнашты. Салих аңарга да икенче рәттә урын алып куйган Тәлгатькә күзен тутырып карады да, нәрсәдер әйтергә теләп, бераз туктап торды. Аннан кызу гына артка, Рәшит янындагы буш урынга барып утырды. Тугыз ел бергә укыган дустының Рәшит янына киткәнен күргәч, Тәлгатьнең бите кызарып чыкты. Уңайсызланганын башкаларга сиздермәс өчен, ул башын түбән иде.

Беренче дәрес тәмам булып тәнәфескә чыккач, Салих янына Тәлгать килде дә үпкә белән:

— Рәшит белән янәшә утырырга булдыңмыни? — диде.

— Шуны аңладым мин уйланып йөри торгач: бергә утырырга ярамый икән безгә, Тәлгать, — диде Салих, бик тәвәккәл итеп. — Сиңа ияреп төрмәгә керә яздым.

— Үз башың кая иде? — дип, Тәлгать тә Салихка ачу белән карап куйды.

— Шул шул менә: үз башым белән уйлап түгел, кеше кыланганны кыланам шул мин. Раз шундый йомшак характерлы икәнмен икән, уй-

лабрак эш иткән кеше кыланганны кыланырга кирәк дип, Рәшит янына утырдым.

— Рәшит характерына калдыңмыни, мескен, — дип, Тәлгать аның яныннан китеп барды.

Салих, дәресләр беткәч тә, Рәшит белән бергә кайтып китте. Аның сүлпән генә атлавына Рәшитнең эче пошты, ахрысы, ул:

— Малай, әйдә әле кызулый төшик, минем өйдә вак-төяк эшләр бар,— дип ашыктыра башлады.

Алар адымнарын кызулата төштеләр. Салих, билгеле, болай ашыгып йөрергә өйрәнмәгән. Чөнки өйдә бернинди эш көтми. Ашарга ризык әзер, ипигә-сөткә барасы юк. Шулай да ул бүген Рәшит белән кызу-кызу атлады. Үз өйләре янына килеп җиткәч, Рәшиткә:

— Кичкә сезгә килимме? Дәресләрне бергә карар идек, — диде.

Рәшит, икеләнеп, бераз эндәшми торды. Аннары:

— Кил. Тик соңрак, яме, — дип китеп барды.

Кичен, әти-әнисе эштән кайтып ашап утырганда, Салих Рәшитләргә барасын әйткәч, Мөршидә урындыгыннан чак кына егылып төшмәде.

— Ни калган анда?.. Әтисе рәтле кеше түгел ди бит аның. Җибәрмим, бармыйсың. Өйдә утыр әнә... Сине хәзер ышанып урамга чыгарып булмый.

Салих әнисе белән сүз көрәштермәде. Шыпырт кына җыенды да чыгып китте. Заһит, тәрәзәгә килеп, улының урам аша кызу-кызу чыгып баруын карап калды.

Салихлар мәктәбендә Рәшит икенче генә ел укый. Яңа фатирга күчкәч, яңа мәктәпкә дә күчкән иде ул. Менә алар торган тугыз катлы йорт. Рәшитләр ишегенең звонок төймәсенә басты Салих. Сары бөдрә чәчләре тузгыган, күзләрендә яшь бөртекләре җемелдәп торган сигез яшьләр чамасындагы кыз ишекне аз гына ачып, зәгыйфь кенә тавыш белән:

— Керергә ярамый! — диде.

Эчке яктан кызу-кызу атлаган аяк тавышлары ишетелде.

— Килдеңме?.. Сеңелем, бар әле... — дип, Рәшит ишекне япты да Салих янына чыкты. Йөзе борчулы иде аның. Өйдә күңелсез хәл барлыгын сизеп, Салих сүз әйтә алмый катып калды.

— Ни, малай, бүген әле дәрес карап булмас, әйдә, булмаса, башка вакытта, — диде Рәшит, күзләрен Салих күзләре белән очраштырмаска теләп.

Салих аның сүзен бүлеп:

— Әйдә, алайса, безгә барыйк, — диде.

Өй эченнән нәрсәдер ауган, нәрсәләрдер дөбердәп ватылган тавышлар ишетелде. Рәшит бүлмә эченә ташланды.

— Әйт, кая әниегез? Кайчан кайтма — ул юк...

— Ят әле, әти, эчкәнсең икән — ят, йокла инде!

Салих бүлмә эченә узды. Анда изүләрен чишкән, бер аягы ботинкалы, икенчесе ялан аяк сәрхуш ир басып тора. Рәшит белән аннан кечерәгрәк бер малай аны ничек тә булса урынга яткырырга тырышалар. Куллары-аякларыннан өстериләр. Баягы кызчык, икенче бүлмә ишегеннән башын гына күрсәтеп, үксез-үксез елый. Салих, чыгып китәргә дә, малайларга ярдәм итәргә дә белмичә аптырап торгач, тәвәккәлләп тегеләргә булыша башлады.

— Яле, абзый кеше, ятыйк, — дип, көчле куллары белән тегенең беләгеннән тотты.

Ир кеше, ят кеше тавышын ишеткәч, күзләрен ялт-йолт иттереп як-якка каранды да бераз тынып калды.

— Һе, кем бу? Кит!

— Мин бу, абый, милициядән...

— Ә, милиция?.. Кем чакырды милицияне, ә? Мин нишләгән милиция чакырырлык? Мин тегеме әллә, түнеядисме?.. Эшләгән, арган мин, үз акчама эчкән мин... Имею право эчәргә... Акчам минем — хоть буа бу... Җиденче разряд мин...

Ул шулай үзен акларга тырышып сөйләнде-сөйләнде дә тынып калды, шап итеп идәнгә утырды.

Салих аның «милиция» сүзен ишетүгә тынып калганын күреп, әле үз аңында икәнен, милициядән курыкканын уйлап алды. Һәм тагын да кырысрак итеп әйтте:

— Я, абзый, нишлибез хәзер: ятып йоклыйсыңмы, әллә сине алып китимме?

— Бар, әнә урам хулиганнарын тот, яме? Мин өемдә, теләсә нишләргә хакым бар.

— Мин сезнең йорттагы бүлмәләрдә тәртип саклаучы дружинник булам, аңлашыламы? — дип тә куйды Салих, тавышын калынайтырга тырышып.

— Дружинник, милиция — икесе дә бер чурт... Милиция — алар үзләре эчә, ә мин... мин...— Ул, мүкәли-мүкәли барып, аягүрә басты да йомылып кына үз бүлмәсенә кереп китте.

— Вот шәп булды синең килү, — диде Рәшит куанып. — Һич тыңлатып булмый гына бит. Шулай кайта да әнигә бәйләнә... Әллә кайчан милициягә язып бирергә булган икән. Әти кеше бит, андыйга күнел бармый. Әни дә кызгана: «Әтиегез ләбаса, аны рәнҗетергә кирәкмәс, яябып куярлар», ди.

Кечкенә кызый Рәшитнең кулларына килеп асылынды:

— Бар, абый, әнигә әйт, керсен, әти тынычланды, диген.

Икенче бүлмәдән ата кешенең каты гырылдаган тавышы ишетелде. Кызый сикеренгәләде, ике кулын чәбәкләде:

— Йоклады, йоклады! Абый, бар инде, әнигә әйт. Аның ашыйсы киләдер, ул бит эштән кайткан.

Озак та үтмәде, ишектән ябык гәүдәле, күзләре яшь белән тулы әниләре килеп керде. Ул бичара ханым ире исереп кайткан саен өйдән чыгып китә икән. Югыйсә, этиләре, ни өчендер, аңа гел бәйләнә, сүгенү сүзләре әйтә икән.

Салих өенә кайтырга булгач, Рәшит тә аңа ияреп урамга чыкты. Алар сөйләшмичә әкрен генә атлыйлар. Рәшит өйдәге хәлләр өчен оялып бара. Ә Салих Рәшитнең тырышлыгы һәм түземлеге хакында уйлана. Уйланмаслык та түгел шул. Әгәр үз күзләре белән күрмәсә, Салих аның шулай борчулы яшәвен башына да китермәс иде. Чөнки бит Рәшитнең бу турыда беркайчан да сиздергәне юк. Иптәшләре арасында шат күңелле, шаян табигатьле булып йөри.

— Рәшит, нигә эчә икән ул синең атаң? — дип пышылдап кына сорап куйды Салих.

— Әни әйтә, егет чакта да аз-маз гына салгалый иде, ди. Ә өйләнешкәч бөтенләй үк эчми башлаган. Аларның миңа апа буласы балалары үлгән. Әни әйтә, этиең бик каты ярата иде шул кызны, ди. Шуның үлү кайгысыннан эчә башлады: «Йөрәгем яна, үземне кая куярга белмим», дип әйтә дә өйдән чыгып китә, ди әни. Ә хәзер нигә эчәдер — шайтан белсен. «Әти» дип эндәшәсе дә килми башлый кайчакта.

Рәшитнең бу сүзләрен тыңлап барганда, Салих этисе турында уйланды. Ул өйгә эчеп кайтмый. Әнисенең күз яшьләрен дә күргәне юк малайның. Бәлки әле аның этисе иң яхшы кешедер. Шул турыда моңарчы уйлап караганы бармы аның? Юк. Алай гына да түгел, ул этисенең хәтерен калдыруны моңарчы бернигә дә санамый иде бит. Ә бит Салих турында эти-әнисе, Фәһимә апасы һәр вакыт борчылалар, кайгыралар. Салих шуны бик табигый итеп саный.

Уйларыннан айнып, Салих Рәшиткә күтәрелеп карады. Тегесе һаман әле үз-үзен ике кулы белән кочаклап, гел шулай акрын гына атлап, уйланып бара иде. Ул тагын иптәше хакында борчыла: «Рәшит әчеп, сүгенеп йөргән әтисен дә милициягә җибәрергә кызгана, ә мин... әтине ял көнендә, кулына повестка тоттырып, милициягә җибәрәм. Уф!.. Җир ярылса — шунда сикереп төшеп югалыр идем».

Көчле җил исеп китте. Агачлардан тротуарга яфраклар коелды. Саргайган яфраклар. Көчсезләр шул алар. Җил кая иссә, шунда очалар. Салих үзе дә шундый түгелме соң? Кемнәргәдер ияреп, харап була язды. Ул да шул яфраклар шикелле үк көчсезмени? Нигә соң ул үзе артыннан берәүне дә ияртә алмый. Үз көче, ихтыяр көче бер дә юкмыни соң?

Өенә кайтып җиткәнче, Салих колагында аерылышкан чакта Рәшит әйткән: «Зинһар, зинһар, бездә күргән хәлләрне мәктәпкә барып сөйләмә», дигән сүзләр ишетелеп торды. Әйтерсең лә аның белән янәшә, авыр газаплы уйлары белән бергә, Рәшит үзе дә атлый иде.

Һашиянең көне буе эче пошты. Эшенең рәте-башы булмады. Бер сызмасын башлады, икенчесен ташлады. Хезмәттәшләре белән дә кырлы-мырлы гына сөйләште. Эш сәгатьләрен тизрәк тәмамлап өенә китәргә ашыкты. Өендә нииндидер бер күңелсез хәл көтәдер кебек тоела. Ничә көннәр инде Галим дә күренми, кайдадыр кунып, югалып йөри. Бәлки Рәуфтән хат бардыр. Анысы да каядыр китеп олакты. Бер ай ялы үтеп китүгә, «Тагын унбиш көнгә үз хисабыма озайтыгыз» дип, эшләгән җиренә телеграмма килгән ди...

Почта ящигыннан, газеталар арасыннан хат эзләде Һашия. Юк. Куе чәй эчсә йөрәге тынычлангандай, күңеле күтәрелеп киткәндәй була аның. Чәй кайнатып эчте, әмма тынычлык юк та юк. Ул белә: уң күз кабагы тарттымы, нииндидер күңелсез хәбәр килми калмый. Я раббем, нәрсә генә ишетер икән ул бу юлы? Бер-бер артлы бөтерелгән уйлар өермәсеннән котыла алмыйча, ары сугылып, бире сугылып, бер бүлмәдән икенчесенә кереп йөрде-йөрде дә, ниһаять, урын җәеп йокларга ятты. Ятар алдыннан телефонны тикшерде — эшлиме икән? Кемдер менә-менә шылтыратыр шикелле иде.

Телефон иртәнге алтыда шылтырады. Һашия атылып килеп, трубканы алды.

— Әйе, тыңлыйм.

— Милициядән... Галим Рахманов... сездә яшиме?.. Улыгызмы?..— Тагын нәрсәләрдер сораштылар. Һашия аңлар-аңламас: «Әйе, әйе, минем улым, өлкәне... улым-балам...» — дип җавап бирде.

Трубканы ул оясына куя алмыйча азапланды. «Галим, улым, син тагын...» Ул караватына йөзтүбән ятты да үкси башлады. Әмма күзеннән яше чыкмады. Елыйсы иде, күз яшьләре агызып, кычкырып елыйсы иде. Юк!.. Кинәт сикереп торды. «Юк, юк!.. Балавыз сыгарга ярамый, файда юк елаудан... Ярдәм!.. Галимгә ярдәм кирәк. Ул аның йөрәк парәсе, яшьлек хатирәсе. Юк, аны төрмәгә җибәрергә ярамый!»

Һашия йокы бүлмәсендә көзге шикелле ялтырап торган кием-салым шкафының ящикләре-киштәләрен актара башлады. Алардан зәбәрҗәт кашлы брошкалар, алтын йөзек-балдак, алкаларны, кыйммәтле тукымалардан теккән затлы киемнәрен алып, барысын бергә караватка ташлады. Әнә алар күз явын алып ничек ялтырый. Серванттагы хрусталь вазаларны да чыгарып өстәлгә куйды.

— Барысын да, барысын да бирәм, сатам. Күпме мең сум акча монда. Улымны сатып алам. Бирмим улымны, улымны бирмим!..— Аның күз алдында идән-түшәмнәр зыр-зыр әйләнде кебек. Ул, йөрәге-

нең авыртуына чыдый алмыйча, күзләрен йомды. Кулындагы хрусталь ваза, идәнгә төшеп, матур зыңгылдап, чәлпәрәмә килде. Ава-түнә атлап, көч-хәл белән, караваты янына барып җитте. Ә гәүдә караватка түгел, бизәкле линолеум җәелгән идәнгә ауды. Алтыннар, бриллиантлар, хрустальләр, нәфис мебельләр өстендә кояш нуры гына уйнады да уйнады.

Милиция идарәсендә төн кундыргач, соңгы мәртәбә кисәтү ясауларын, кечкенә генә җинаять эшләсә дә каты җавапка тартылачагын әйттеләр дә, сорау алган кәгазьгә кул куйдырып, Галимне өенә кайтарып җибәрделәр.

Фарук кебек усал, мәкерле дусларыннан тәмам бизгән, дөньяда башкалар шикелле үк намус белән яшәргә дигән фикергә килгән Галим сөенә-сөенә өенә йөгерде. «Кайтам да ваннада юынып өс-башымны алмаштыруга эшкә китәм. Әни белән яхшы итеп сөйләшермен, рөхсәт итсә — янында калам, булмаса — тулай торакка китәм». Шулай канатланган Галим өйләре ишеге төбендә, звонок төймәсенә басып, шактый озак көтеп торды. «Юри ачмый... Әле генә, милициядән шылтыраткач, җавап биргән иде ич. Бәлки базарга чыгып киткәндер?» Ул тагын төймәгә басты. Звонок шылтырады, өйдә аяк тавышы ишетелмәде. Галим кинәт куркынып куйды:

«Милициядән шылтыраткач, бәлки авырып киткәндер — йөрәгем сырхау ди иде бит...» Ул күршеләренең звонок төймәсенә тиз генә басты.

— Бүген иртән әнине күрмәдегезме?..

Күрше хатын куркынып та, гаҗәпләнеп тә Галимгә усал итеп карап куйды.

— Таң атмас борын кешеләр борчыйсың, катырак бас звонокны, йоклыйлардыр, — дип, ишеген шап итеп япты.

Галим икенче күршеләргә шылтыратты.

— Әнине күрмәдегезме?..

Күрше ир борчылган Галимнең күзләренә карап торды да:

— Иртүк кая китәр икән ул?.. Яхшылап бастыңмы звонокны? — диде.

— Ярты сәгать шылтыратам инде...

Күрше кеше өенә кереп китте дә, ике ачкыч тотып, кире чыкты.

— Син кайтырсың дип, әниең ачкычның берсен бездә калдырып йөри иде, мә ач...

Ишекнең ике биген дә ачып, Галим өйгә керде. Һәм «әни!» дип үзәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде. Ул, караваттагы ялтыравык һәм затлы әйберләрнең бөтенесен идәнгә сыпырып төшерде дә әнисен урын өстенә күтәреп салды.

— Үлгән, әни үлгән...

Күрше ир бер сүз дә әйтә алмый стенага сөялде.

— Әни, әни җаным, әнием-алтыным, ач күзеңне... Мин бит бу, Галимең, бөтенләйгә кайттым, әни... Мин бу, улың Галим, әни...

Улының тавышын ишеткәч, ана күзен ачты. Озын керфекләр арасыннан ике бөртек күз яше чыккан иде аның. Күршеләре аңа су салып бирде. Ниһаять, һашиянең иреннәре кыймылдады.

— Галим... улым... китмә!.. Мин сине җибәрмим... Бергә китәрбез, улым...

— Мин хәзер беркая да китмим, әни. Тик син генә тынычлан, тынычлан... Бүгеннән сиңа сүз бирәм: моннан соң чын кеше, әйбәт кеше булып яши башлармын. Тик син генә сәламәтлән, әни...

Смена тәмамланырга берничә минут кала, Галим янына цех башлыгы килеп:

— Инструментларыңны тапшыр да әнә коридорның аргы башындагы уникенче бүлмәгә кер, — диде.

Галим бүген башка көннәргә караганда күп мәртәбә тырышыбрак эшләде. Нормасын күпкә арттырып үтәде. Ләкин бүген берәү дә аның эшенә дә, үзенә дә игътибар итмәгән кебек иде. «Ачуланырга чакыралардыр,— дип фикер йөртте Галим.— Милициядән хәбәр килгәндер. Нәрсә диярга?» Әйтер сүзе дә юк аның. Бөтенесе берьюлы өелә дә тора. Әнисенең хәле ничек икән? Ансыз калса нишләр Галим? «Бер якын кешем дә юк бит бүтән...» Уникенче бүлмәгә барганда әнә шулай төрлечә уйланды егет. Бу аның аек баштан тәүге тапкыр ныклап уйлануы иде. Моңарчы болай булмады: чак кына берни ишетсә, берни килеп чыкса да, ачуланып, җенләнеп урамга чыгып китә дә шешәдәш дуслары аның күңелен бик тиз күтәрәләр иде.

Барып керсә, бүлмәдә унбишләп яшь егет һәм ике кыз утыра. Тәрәзә кырыенда ике өлкән кеше: берсе — цех башлыгы, икенчесен Галимнең моңарчы күргәне дә юк. «Гражданский кием кигән милиционердыр әле», дип уйлап алды ул. Өстәл янында утырган егет — цехның комсомол секретаре аягүрә басты да әйтте:

— Иптәшләр, безгә бүген чираттан тыш җыйналырга туры килде. Кайберләрегезнең әле эш сәгатьләре дә бетмәгәндер. Ләкин озак утырырбыз дип уйламыйм. Җыелышта бер генә мәсьәлә каралачак. Унҗиденче цех слесаре Рахманов Галим турында бу җыелыш. Әнә ул үзе, таныш булмаганнар танышыгыз. — Ишек янындагы урындыкта куырылып утырган Галимгә берьюлы әллә ничә күз текәлде. — Безнең заводка, ягъни цехка, моннан берничә сәгать кенә элек, бик күңелсез хәбәр килде, иптәшләр.— Ул өстәл өстендәге ак папка эченә салынган әллә ничә бит кәгазьне кулына алды.— Менә монда барысы да бик төгәл язылган. Укып чыгарга рөхсәт итегез.

Бүлмәдә чебен очса да ишетелерлек авыр тынлык. Бүлмәдәгеләр зур игътибар белән тыңлый. Һәр сүзне йотардай булып Галим дә тыңлый — исе китеп, аптырап тыңлый. Күз алдыннан аның берьюлы күпме ел гомере уза: анда сугылып, монда сугылып эшсез йөрде. Ярым исерек килеш олы бер апаның сумкасыннан акча урлавы... Төрмәдә утырды... Иреккә чыгуы... Аннары тагын ялгышу... Галимнең күзләре күрмәс диярлек хәлгә килеп сызлый башлады сыман. Их!.. Бөтенләй сукырайсын иде ул күзләр, күрмәсен иде ул бу минутта үзенә текәлеп утырган кызларны, егетләрне. Колаклары ишетмәс булсын иде хәзер. Нигә кеше булып туган ул бу якты дөньяга? Ник?.. Әле аңа беркайчан да болай авыр, болай хурлыклы булганы юк иде. Зур хәсрәт менә нинди була икән ул...

Секретарь укып бетерде дә, кесәсеннән кулъяулык алып, битен, маңгаен сөртте.

— Менә шул, иптәшләр... Галим Рахмановка кичә егерме яшь тулган һәм ул үзенең туган көненә менә шундый «бүләкләр» белән килә.

«Тизрәк куып чыгарсыннар иде мине моннан, — дип уйлап алды Галим. — Котыласы иде бу газаптан».

Ул арада кечкенә генә буйлы, битенә әллә ничә чуан чыккан егет сүз алды. Их, аның әйткән сүзләре!.. Пычак белән йөрәкне тураклый диярсең. Колониядә чакта көн саен бик акыллы, төпле сүзләр белән аларга лекция укыдылар. Аларны да күңел биреп тыңлый иде Галим. Тик ул лекцияләр болай ук тәэсир итмәде кебек. Ә монысы:

— Заводка, коллективка хурлык китердең, намусыбызга тап төшердең, Рахманов. Ачудан өзгәләп ташлыйсы килә, әмма син — егет кеше, ир кеше — яшәргә тиешсең... Чын кеше булып, чын ир булып...

Син берүзең, ә без күбәү. Завод исемен, эшче исемен яман атлы итәргә без сиңа юл куймабыз...

Аннары сүз завком члены Мөслимә Рәсүловага бирелде. Кыз аккошныкына охшаган озын ак муенын бераз алгарак сузды, иңсәләренә таралган кара чәчләрен ике кулы белән йомарлап артка җыйнады, зур кара күзләрен тагын да зуррак ачып Галимгә карады.

— Ошамый башлады әле миңа бу «үз тәрбиябезгә алу» дигән нәмәрсә. Моннан өч ай элек берсен, нәкъ Галим шикеллесен, тәрбия итеп карадык бит инде. Нәрсә күрсәтте ул безгә? Акладымы безнең ышанычыбызны. Артыннан чаптык, үгетләдек, киңәшләр бирдек. Үзебезчә барын да эшләдек. Ә ул нәрсә күрсәтте?.. Төзәлдеме егет? Төзәлмәде. Эчеп-сугышып, айныткычларда йөрде-йөрде дә заводтан чыгып ук китте. Ә безгә «завод яшьләре тәрбия эше белән шөгыльләнми» дигән ярлык тактылар. Әгәр кешенең үз акылы булмаса, йөрәген ярып биш акыл салсаң да, бер нишләтеп булмый андыйларны.

— Пессимист булма әле, яме, иптәш Рәсүлова, — дип әйтеп салды комбинезонлы яшь кенә егет.

— Пессимист түгел мин, турысын яратам — шул гына. — Ул уң кул бармагы белән Галимгә янады. — Аңла, Галим, егетләр барысы да: «Тәрбия итәбез, аякка бастырабыз» дигән сүз әйттеләр. Син бишек бәбие түгел, үскән инде. Ак белән караны аера белергә тиешсең. Үзеңне-үзең кулда тота белсәң генә кеше булырсың. Ә без сиңа кирәк чакта ярдәм итәрбез — дус та, иптәш тә булырбыз. Менә шул!..

Цех башлыгы, карлыккан тамагын кыра-кыра:

— Рәнҗеттең син безне, энем Галим... Табигать сиңа барысын да биргән: буй-сын дисеңме, сөйкемле чырай дисеңме... Ә менә иң кирәклесе — акыл җитенкерәми. Балалыгың белән ундүрт яшеңдә ялгыш юлга тайпылгансың икән, ул ялгышыңны төзәт хәзер, төзәт!.. Инде бит егет булган син. Егермедә чак — яшьлекнең иң күркәм, иң җаваплы чоры. Әнә иптәшләрең ярдәм итәрбез дип тора. Әгәр инде үзеңне чын егет итеп күрсәтең килми икән — ул чакта, энекәем, иптәшләрең сиңа берничек тә ярдәм итә алмас. Син сабый түгел, артыңнан каравыллап йөреп булмый. Аларның үз мәшәкатьләре дә аз түгел — эшлиләр, укыйлар, кайберләренең инде үз гаиләләре бар. Безнең белән калырга теләсәң — иртәгәдән җиң сызганып эшкә тотын. Әнә комсомол секретаре сөйләштем диде, техникумга кичен укырга керерсен. Вот шул, энем. — Ул стена буендагы урта яшьләрдәге иргә, партоешма секретарена карап алды. — Кулыбыздан килгән яхшылыкның барысын да эшләрбез, бездә үгиләр юк. Коллектив нык безнең, бердәм коллектив.

Комсомол секретаре сәгатенә карап куйды.

— Җыелышны тиз генә үткәрербез дигән идем, нәкъ өч сәгать вакыт үтте. Өч сәгать! Унҗиде кешенең өчәр сәгать вакытын алдың, Галим. Шуның хакын син ничек түләрсең?

Соңгы сүз Галимгә бирелде. Ул каты арыган, талчыккан кыяфәттә салмак кына аягүрә басты.

— Мин сезнең кебек акыллы итеп сөйли белмим, туры килмәде сөйләргә... — Ул бераз тын торды. «Нәрсә дияргә, ни сөйләргә?» — Кылт итеп әнисе исенә төште: «Нишли икән, хәле ничек икән?» — дип уйлап, йөрәге «жу» итеп китте. — Ышанычыгыз миңа, иптәшләр, ышаныгыз... Мин тырышып эшләр идем. Бүген әнигә дә сүз бирдем... Мин...

Була бит шундый минутлар. Синнән бәхетлерәк кеше дөньяда юктыр кебек тоела. Бар да тәртиптә, күңелдә бернинди борчу юк. Зөлфәтнең хәле нәкъ шундый иде хәзер. Ишек төбендә кайгы-хәсрәтләре белән килгән кеше дә көтеп тормый. Шәһәрдә дә бүген төнлә

яман хәлләр булмаган иде. Аңа аз гына үзе турында да уйланып алырга ярый иде бу минутта. Һәм ул Фәһимәсен күз алдына китерде, әкрен генә телефон номеры җыйды:

— Хәерле көн, Фәһимә!

— Хәерле көн, Зөлфәт!..

— Фәһимә, беләсеңме, минемчә, житте, дускай, булды!..

— Нәрсә житте, нәрсә булды?..

— Тартып-сузып йөрүләребез дигәнем. Кисәтеп куям. Бүген кичен, сигезенче яртыда, бер дусым белән сезгә барабыз. Сине сорап, яучылап дигәнем. Ишетәсеңме? — Трубка дәшми иде. — Фәһимә дим!..

— Я, я, тыңлыйм, — диде бик ерактан тонык тавыш.

— Кара әле, дустым, нигә шул кадәр ерактан сөйлисең?

— Я, дидем бит инде, я... Ишетмәсәң, үзең якынрак кил!..

— Килəм, килəм... Сигезенче яртыда... Ә иртәгә загска гариза бирербез. Без инде, башкалар кебек, ай буе срок көтеп йөрмәбез, минем анда таныш-белешләр бар... — Трубка тагын эндәшмәде. — Яме, дим?.. Кара, югала гына бит, иң кирәк чакта... — Зөлфәт трубкага өрә башлады.

— Өрмә инде, ишетәм бит.

— Ишеткәч, җавап бир соң, я, диген...

— Я, дим бит инде, я, я... үзе ишетми дә...

— Хәзер ишетәм. Менә рәхмәт, ичмасам. Гөлкәем минем, күгәрченем, көт, яме! Төшке ашка кайткач әнигә дә әйтәм... Сау бул!..

Трубканы куйгач, Зөлфәт «уф!» дип тирән сулап куйды, гимнастерка якасын ычкындырды. Күпме айлар буе үзен борчыган өйләнү мәсьәләсен шулай кыю, кызу тотуына үзенең дә исе китте. Ул яңадан телефон номеры җыйды:

— Ислам! Сәлам, дускай!

— Сәлам. Ай-һай, бүген синең тавыш көр чыга.

— Күп сөйләшмибез, дускай, әйдә әле бүген кичкә икәү Заһит абыйларга барып, Фәһимәне яучылап кайтыйк.

— Өйләреннән куып чыгармаслармы соң?

— Чыгарсалар, кайтып китәрбез.

— Шаярам... Барабыз!.. Ничәдә?..

— Нәкъ сигезенче яртыга аларның өе янына кил. Сөйләштек... Син инде, Ислам, ни... өстеңә дим...

— Борчылма, кичә генә бик шәп костюм алдык, хатын белән икәүләшеп...— Ул бераз тамак кыргандай итте дә:— Син үзеңне абайлый төш, Зөлфәт. Һәр ягың килгән булсын. Аннан шул, алтын таулар вәгъдә итештән булмасын. Болай ышанулары кирәк.

— Юк ла, Фәһимә үтәдән-үтә күреп белә мине. Ярый, хәзергә.

Аннары Зөлфәт, буш вакыттан, кәефнең яхшылыгыннан файдаланып калырга кирәк дип, шкафта өелеп торган китаплар арасыннан дәреслек китабын алды.

— «Совет законнары сагында». Шулай... Мин дә бит совет законнары сакчысы...— дип сөйләнә-сөйләнә, карандаш белән кирәк урыннарны сызгалап дәрес әзерли башлады. Башкача булалмый. Юридик факультетның икенче курсында укый бит ул хәзер. Армиядән кайткач та көндезге факультетка кергән булса, быел университетны тәмамлый иде инде. Ләкин башта милиция мәктәбендә уку да начар булмады. Эшләп укуы авыррак, билгеле. Аеруча «ЧП» күп булган көннәрдә. Шулай да түзәрлек. Милиция идарәсендә эшләп укуның үзенә бер яхшы ягы бар. Аның көндәлек эше ахыр чиктә университетта үтелә торган проблемаларга килеп бәйләнә.

— Әйе!.. — дип куйды Зөлфәт үз-үзенә. «Революциягә кадәр юридик законнарны белү никадәр кирәк булса, революциядән соң социалистик җәмгыять төзү өчен дә аларны белү һәм аларны дөрес куллану

шул кадәрле үк кирәк һәм әһәмиятле булган...» Мавыгып, кызыксынып укыды, үзенә күп сораулар биреп уйланып утырды ул... Кинәт өстәлдәге блокнотка язылган «Тәлгатьләргә шылтыратырга» дигән сүзләргә күзе төште. «Арслан абыйны ялдан кайтып керү белән борчымыйм, хатыны да һаман больницадан чыкмаган» дип, Тәлгатьнең хәлен әтисенә сөйли алмый йөргән иде. Хәзер кыю гына алар телефонының номерын җыйды.

Тәлгатьләр квартирасында телефон шылтырады.

— Әйе, тыңлыйм сезне,— диде өй хуҗасы.

— Арслан Галимовичмы бу? Сезне милиция лейтенанты Мәрдәнов борчый.

— Ә?.. — Арслан Галимович тынып калды. Көр тавышы юкка чыкты. Трубканы әле бер кулына, әле икенчесенә күчерде ул.

— Тыңлыйм, иптәш лейтенант.

— Кайчан кайттыгыз? Ял яхшы уздымы?

— Ә, әйе, яхшы, бик яхшы булды.

— Безгә кереп чыгарга вакыт таба алмассызмы икән?

— Вакыт... Вакыт табылыр анысы. Тик нәрсә бар?..— Арслан янәшәдә торган урындыкка таянды.— Мин хәзер үк тә бара алам.

Бәла беркайчан да ялгыз йөрми, диюләре хак та сүз инде. Арслан әле генә больницадан врачның: «Хатыныгыз әле тагын бер айлап ятар», дигән сүзләренә хафаланып кайткан иде. Инде милициягә чакыралар. Ул кухняда нәрсәдер эшләп йөргән әнисе янына ашыгып килде.

— Әни, Тәлгать ничек мин юкта?

Маһруй әби билен турайтып улына карады. Улының борчулы йөзен күреп, ана үзе дә хәвефләнеп куйды.

— Тәлгатьме? Тәлгать әйбәт инде ул, аллага шөкер, әйбәт.

— Өйгә малай-шалай ияртеп килмәдеме?..

— Мин өйдә юкта гына булмаса, күрмәдем, улым, күрмәдем. Һаман ялгыз. Кайчакларда Салих кына килгәләде.

— Ярый, әни, ашыңны әзерли тор, мин хәзер кайтам, — диде Арслан чыгып киткәндә.

Зөлфәт өстәле каршына барып утыргач кына ул үзенең пижам өстеннән плащ киеп килгәнен абайлап алды. Аягында да өйдә киеп йөри торган киез туфлилар иде. Ул сискәнеп куйды. Аяк өсте басып, Зөлфәттән гафу үтенде.

— Нәрсә бар, сөйләгез зинһар, миемә ут капты,— диде ул, Зөлфәткә инәлеп карап.

Зөлфәт аңа Тәлгать белән Салихның җәйге каникул вакытындагы мәҗараларын сөйләп биргәч, Арслан урындыгында өнсез калып торды. Аннары көчле кулы белән тезенә сугып:

— Аңлашылмый, иптәш лейтенант... аңлашылмый, — диде. Кечкенәдән ятим булып, ачлы-туклы үскән, рәтле кием күрмәгән көннәре күз алдына килде аның. Сигезенче классны тәмамлагач һөнәр училищесына укырга кергән иде. Аннары монтажчы булып заводка эшкә урнашты. Кичке техникумда укыды. Өйләнде. Кеше өендә фатирда яшәделәр. Тәлгать тугач, хуҗаларга комачау итмик дип, баланы елатмаска тырышып, төннәр буе йокламый чыктылар. Читтән торып институтны тәмамлады Арслан. Хатыны техникумда укыды. Хәзер алар берсе заводта җитәкче, икенчесе — югары квалификацияле эшче. Әйбәт яшиләр, өч бүлмәле квартиралары, дачалары бар. Өйдә һәр яктан тәртип. Үзе эчү, тәмәке тарту ишене белми. Тәлгатькә дә бөтен шартлар тудырылган. «Укы! Үзең кем буласың килсә, шул профессияне сайла. Безнең теләк шул гына: саф күңелле кеше бул, кешеләргә ярдәмчел, олы җанлы бул, тормыш юлында берәүне дә рәнҗетмә!» дия килде аңа Арслан. Әнисе дә гел яхшылыкка гына өйрәтте.

— Юк, юк, юк, аңлашылмый, иптәш лейтенант... ышанмыйм да... Монда ниндидер ялгышлык бар. Башкалар өчен җавап бирмим. Ләкин минем улым караңгы төндә кыз баланы хурларга баруына мин ышанмыйм.

Зөлфәт, өстәл тартмасыннан папка алып, Тәлгатьтән сорау алганда язган сүзләрне укып күрсәтте.

— Я ходай!..— Арслан аягүрә басты, бүлмә буйлап озын аяклары белән арлы-бирле йөреп алды. Минут эчендә йөзе агарып, күзләре төссезләнеп калды. «Бала хәсрәте Арсландай кешене дә аяктан ега бит. Бөтен тәне калтырана» дип борчылып уйлап куйды Зөлфәт.

— Тынычланыгыз әле, Арслан абый.

Арслан Зөлфәт каршысына килде дә, усал караш ташлап:

— Дөрес булгач, нигә дип сез, милиция, аны ябып куймадыгыз? Нигә дип әле ул мәктәпкә тып-тыныч укырга китеп барган? Эх, селәгәй, ә... чукындырам мин аны, яндырам. — Арсланның куллары тагын сизелебрәк калтырана башлады. Зөлфәт чәчләрен ике куллап сыпырып алды да, коридорда кемнәр бар икән дип, ишекне ачып карады. Берәү дә юклыгын күргәч, ишекне эчтән бикләп куйды. Арсланның әрнүе, ярсуы шул кадәр көчле, аңа үгет-нәсихәт сөйләү бу минутта урынсыз иде. Зөлфәт яңадан өстәл артына утырды. Арслан кызганнан-кыза бара. — Әнисе белән икәүләп тырыштык-тырмаштык, картаеп килгән көнебездә әйбәт тормышка ирештек. Җаныбыздан артык күреп, шул малайны яраттык. Ышандык без аңа. Төкергән икән ул әнә безнең яхшылыкларга. Хәзер мәктәбенә барам, парта артыннан өстерәп чыгарам да... Бу хурлыкны күтәреп йөри алмыйм.

— Бу инде көчсезлек һәм бик ансат юл, Арслан абый.

— Сез ул көчсезлек күрсәткәнсез. Берсен заводка, эшчеләр арасында тәрбияләргә, икенчеләрен, башларыннан сыйпап — укырга... Ул минем уналты ел иткән яхшылыгыма төкергән икән, сезнең кешелеклек күрсәтүегездән бот чабып көлә генә инде. Монысын гафу иттеләр, икенчесен дә гафу итәчәкләр дип тагын да яманрагын эшләрләр әле. Ул ике кулы белән дә битен томалап бераз тын торды, аннары үксп башлады.

— Арслан абый!..

— Гафу итегез, күңелем елый... Мәрхүм әти искә төште. Миңа сигез яшь иде. Күршебез Сөнгатулла абзыйның Донбасста эшли торган улы, ялга кайткан саен, әллә нинди инструментлар күрсәтә безгә. Бервакыт аларның ишегалларында бик матур итеп эшләнгән кечкенә генә чүкечкә төште күзем. Аларның чүкечләре дә, башка тимер-томырлары да күп, барысы да җирдә аунап ята дип, шуны үзебезгә алып кайттым. Әти миннән сорый: «Каян алдың, сорапмы?» Мин әйтәм, йортта ята, аларга кирәкмидер ул дим... «Бүген син кеше онытып калдырган әйберне алырсың, иртәгә җыйнап куйганын» дип, шундый яңаклады әти, гомерем буена кеше әйберенә кагылмадым.

— Тәлгатькә сукканыгыз булдымы?

— Бер тапкыр да юк.

— Мин ышанам, Арслан абый, моннан соң да Тәлгатькә кул күтәреп, аны үзегезгә карата нәфрәтләндермәссез. Сезнең гаиләдә улыгызга карата дуслык, ышаныч, хөрмәт бар. Бу инде әдәп, культура билгесе. Үзегез беләсез, әдәп булган җирдә физик җәзага урын калмый. Киңәштек тә, хәзергә малайларның мәктәбенә хәбәр итмәскә булдык. Үзләре уйлансыннар. «Без бик начар эш эшләдек» дигән фикергә килсәләр, шул була инде алар өчен җәза.

— Әйтүе ансат, билгеле. Ә мин аның күзләренә хәзер ничек карыйм да ничек аңа «улым» дип эндәшим.

— Ата-ана күп нәрсәне гафу итә ала, Арслан абый...— Зөлфәт тәрә-

зә янына килеп шактый уйланды. Уйларын Арсланга әйтергә дип тел тибрәтмәктә генә, аның сулып калган йөзенә карап:

— Кайтырга машина чакырыйммы? — диде...

— Үзем дә «такси чакырыгыз әле» димәкче идем. Бу кыяфәт белән шәһәр буйлап ничек узмак кирәк, тиләләр йортыннан качкан диярләр.

Зөлфәт Коля турында да Арслан белән сөйләшергә уйлаган иде дә: «Юк, кирәкми», — дигән нәтиҗәгә килде. Арсланның җинаятьчеләргә, бозык юлда йөрүчеләргә карата фикере ачык иде Зөлфәткә: аяусыз бу-лырга, барысын да пешекләргә, кыздырырга... Ләкин Совет законнары каты, таләпчән булу белән бергә асылда кешелеклеккә нигезләнгән бит.

Тәрәзә төбенә генә такси килеп туктагач, Арслан үзенең өс-башын тагын бер карап алды һәм кычкырып көлеп җибәрде:

— Янгыннан качкан кешенеке шикелле булган минем хәл. Милициядән шылтыраталар дигәч, аптырап калдым...— Аннары ул каты итеп Зөлфәтнең кулын кысты да: — Рәхмәт, иптәш лейтенант. Ярый әле, эзләренә төшкәнсез... Бу инде сезнең өлкәдә эшләүчеләрнең үз бурычларын төгәл үтәүләре — профилактика, дисезме әле. Тагын бер кат рәхмәт! — дип ишеккә юнәлде.

Зөлфәт аңа: «Сау булыгыз, Арслан абый, мин үзем дә кереп чыгармын әле сезгә», — дип калды.

Ислам Шәкүров урам чатына килеп басты. Өстенә күксел-зәңгәр костюм, ап-ак тукымага зәңгәр ефәк буйлар төшкән күлмәк, ачык зәңгәр галстук... Яхшы драптан тегелгән көзге пальто кигән. Бу киемнәр аны гаҗәп сөйкемле күрсәтә. Очраткан таныш-белешләр аңа гаҗәпләнебрәк карап узалар. Чөнки ул, дөресен әйткәндә, үзенең милиция формасын бик яратып кия һәм аны беркайчан да, хәтта бәйрәмнәрдә дә салмый. Ә бүген аның өчен тарихи вакыйга: гомерендә беренче мәртәбә димче булып бара. Күз алдына Зөлфәтне китереп ул: «Но, киенгәндер-ясангандыр инде егет», дип елмаеп та куйды. Бераз арлы-бирле йөренде дә урамның аргы ягында ундүрт катлы йорт салырга куелган күтәрү кранының эшләгәнен карап тора башлады. Яшь кенә егет күренә кранчы. Әнә ул, әле бер рычагка, әле икенчесенә басып, кранны нинди иптә эшләтә. Ыргагына җирдә эләктереп җибәргән һәр нәрсәне минут эчендә теләсә нинди катка күтәреп куя. Йөкне озатучылар да, кабул итүчеләр дә — шундый ук тиз-төгәл. Алар, үзара уенкөлке һәм шаян сүзләр әйтешеп, шундый күңелле эшлиләр, әйтерсең йорт салу бөтенләй җиңел, әйтерсең ул ниндидер тылсымлы бер кодрәт белән шулай үсә.

Шуны мавыгып күзәтә торгач, янына Зөлфәт килеп басканын да сизми калды Ислам. Ә инде аның милиция киеменнән икәнен һәм бик арыган кыяфәттә булуын күргәч, бөтенләй исләре китте.

— Киттекме, Ислам дус, сигезенче ярты. Чак-чак кына соңга калмадым,— диде Зөлфәт.

— Тукта әле, кая барабыз? Кыз сораргамы, әллә оперативкагамы?

— Әй, әйтмә дә инде, дускай. Үч иткәндәй, шундый тынгысыз көн булды бүген... Иртән матур гына башланып киткән иде, ә кичке якта...

— Килешми бит, әйдә, тиз генә өеңә кайт та алыштыр өс-башыңны. Зөлфәт Исламның култыгыннан алды.

— Киттек. Тик өйгә түгел, анда. Фәһимә дә, туганнары да белеп торсыннар — минем гомерем күп вакыт менә шулай милиция формасын киеп үтәчәк.

— Хәер, сиңа форма бик әйбәт килешә дә! — дип, Ислам Зөлфәтнең аркасына сугып куйды.

Җәйге күңелсез хәлне Салих та, Тәлгать тә онытa башладылар. Мәктәпкә милиционер да килмәде, директор да кабинетына чакырып ачуланмады. Бүген соңгы дәрес бетәр алдыннан Салих Тәлгатьне бер читкә чакырып алды да, бик зур сер итеп, Рәшитнең әтисе һәр кичне эшеп кайтканын, әнисен өйдән куып чыгарганын, балалар алдында әшәке сүзләр белән сүгенүен сөйләде. Аннары:

— Әйдә, малай, бер файдалы эш эшлибез. Рәшитнең әтисе эшеннән чыкканны көтеп торабыз да аны өйләренә үзебез алып кайтабыз.

— Кит әле, исерек артыннан йөрергә... Я тагын берәр бәлагә тап булырсың,— диде Тәлгать. Аннары сорап куйды:— Син миңа шуны әйт: үз өегездә нихәлләр?

Салих кичә кичен Арслан абыйсы әтисе белән телефоннан сөйләшүен әйтте:

— Минем әтигә әйткән әтиең: «Авырыйм, малайларның ямьсезләнеп йөрүе башыма сукты»,— дигән. Син, малай, гафу үтен әтиеңнән.

Бик каты үтенде гафуны Тәлгать — бер генә түгел, ике-өч кат үтенде. Тик ул белми, гафу иттеме әтисе, юкмы. Рәнҗетте шул әтисен, нык рәнҗетте. Һәр вакыт көләч йөзе кара көйде, хәрәкәтләре авырайды әтисенең. Ярый әле, әнисе белән әбисе белми бу хәлләрне, алар исә бөтенләй тилерерләр күк иде... Тәлгать Салихның иңсәсенә җиңелчә генә сукты да:

— Киттем... Дус булып калыйк, малай, тик бер-беребезне башка бәла китерә торган җирләргә чакырмыйк, яме? Эти әйтмешли: үз сукмагыбыздан гына йөрик әле,— дип китеп барды.

«Алып барып күрсәтәсе иде Рәшитнең тормышын Тәлгатькә. Нинди газап чигә бит ул. Ничек кенә ярдәм итәргә соң аңарга?» дип, дәрес вакытында да баш ватып утырды Салих. Ә тәнәфескә чыккач Рәшитне бер читкә дәшеп алды да үзенең аңа ничек кенә булса да ярдәм итәргә теләвен, ләкин ничек ярдәм итәргә белмәвен әйтте.

Әле смена тәмамланырга унбиш минуттан артык вакыт бар. Рәшит белән Салих завод каршындагы электр баганасы артына, кешеләр күзенә бик чалынмый торган җиргә, бастылар да заводтан чыкканнарны күзәтә башладылар.

— Эти күренгәч тә без аның янына барыйк. «Практикадан кайтып килә идек» диярбез.

— Бәлки бөтенләй аңа күренмәскәдер... Карыйк, күрик, кемнәр белән кайта ул, кемнәр белән эчә? — диде Салих.

— Чекистлар мәктәбенә китәргә кирәк сиңа,— дигән җавап ишетте ул.

— Чекистлар мәктәбе белән генә чикләнеп булмас. Университетның юрфагына кереп, тикшерүче булырга минем исәп.

Төркем-төркемләп эшчеләр заводтан чыга башлады. Алар, кызукызу атлап, завод янына ук килеп туктый торган трамвай, троллейбус яки автобусларга барып утыралар да китеп баралар.

Рәшитнең әтисе дә килеп чыкты. Өстенә гади генә кара пальто, башына кепка кигән. Әнә ул, бер читкәрәк китеп, тирә-ягына карана-карана, кемнедер көтә башлады. Аның куе кара кашлары, кысыграк күзләре бик тә акыллы, бик тә мөлаем булып күренде Салихка. Теге кичне идәндә үрмәләп йөргән, авызлары күбеп чыккан кеше түгел иде бу.

Әнә заводтан чыгучыларның икесе, төркемнән аерылып, Рәшитнең әтисе Мөбарәк янына килделәр. Алар, өчесе бер булып, кесәләрендәге акчаларын барладылар. Аннары, көлешә-шаярыша каршыдагы бакчага юл тоттылар.

— Әнә бакча капкасын кергәч тә сул якта сыра сата торган «Кафе»-

дан башлана инде аларның «күңелле» яшәешләре,— диде Рәшит.— Әтине минем беренче каршылавым түгел.

— Их, эшчеләр өйләренә таралышкан вакытта гына булса да, аракы кибетләрен ябып торсалар икән, — дип әрнеп куйды Салих.

— Алай гына котылып булмас кебек. Эчә торган кеше җир тишеге ннән алып булса да эчә инде ул, малай. Минем әни шулай ди.

Көзге җил егетләрнең юка пальтолары эченә үтеп керә. Салкыннан аларның борыннары кызарды, битләре күгәрде. Яфраклары коелып, шәрәләнеп калган агачлар арасында шыкланырлык урын юк.

Бераздан теге өч дус, «Кафе»дан чыгып, алга атладылар.

— Болай булгач әле эшләр бик үк начардан түгел: күр, төз атлыйлар, бер дә исерек түгелләр әле, — дип сөйләнә-сөйләнә Салих белән Рәшит янәшә атлады.

Эчемлек сатыла торган кечкенә кибет янына барып җиткәч, «өч дус» яңадан кесәләрен актарды. Яннарына тагын ике ир килеп кушылды. Араларыннан берәве кибеткә кереп китте. Калганнары кибет буендагы капка артына барып постылар. Озак та үтмәде, ничәдер шешә күтәреп, теге ир әйләнеп тә чыкты. Берсе кесәсеннән стакан чыгарды. Һәм минут арасында шешәләрнең башына да җиттеләр.

— Әнә теге килбәтсезен күрәсеңме, әтине шул кабахәт аздырды инде, — диде Рәшит.

— Әйдә яннарына барабыз да әтине... — Шул чак Мөбәрәк, дусларыннан аерылып, айкала-чайкала кибеткә кереп китте. Рәшит белән Салих та аның артыннан керделәр. Мөбәрәк учына йомарлаган акчаларны сатучыга сузды. Сатучы ханым исә шактый исерек иргә күтәрелеп тә карамады. Акчаны алып санады да ике шешә кызылны сузды. — Сатмагыз!.. Ул минем әти, бирмәгез аңа аракы! — дип үзәк өзгеч тавыш белән кычкырып, Рәшит сатучы янына йөгереп килде. Кибетче хатын аптырап калды. Кулындагы шешәләрне күкрәгенә кысты. Мөбәрәк мәгънәсез, төссез булып калган күзләрен башта сатучыга, аннары Рәшиткә текәде. Бернәрсә дә әйтә алмыйча иреннәрен кыймылдатты, кулларын төрлечә болгады. Ул арада ишектән Мөбәрәкнең «дуслары» килеп керде һәм:

— Син, Мөбәрәк, аракыны Мәскәүнең үзеннән барып алырга булгансың, ахры. Давай, тизрәк, өйләргә кайтасы бар, — дип ашыктыра башладылар.

Сатучы акчаларын кире бирде. Тегеләр, бер-берсен этешә-төртешә, сатучыга, синең безгә аракы сатмаска хакың юк, без арып-талып эштән кайтып килүче эшче халык, эшче ул — дөньяның тоткасы, илнең хуҗасы, аңа бернинди каршылыклар булырга тиеш түгел дип, никадәр генә тавышлансалар да, сатучыны җиңә алмагач:

— Әйдәгез, бүтәненә киттек,— дип кибеттән чыктылар.

Шулчак Салих инде шактый сыекланган, озын буйлы исерекне кисәк кенә читкә этәрде дә Мөбәрәкнең кулыннан нык итеп тотты. Аны күрә Рәшит тә әтисенең икенче ягыннан култыклап алды. Мөбәрәк үзе әйтерсең ава-түнә йөрүдән туйдым, дигәндәй, егетләрнең көчле кулларына бөтен гәүдәсе белән салынып, алга атлады.

... Салих белән Рәшит иртәгә дә Мөбәрәкне каршыларга барырга, тик инде аны иптәшләре белән очрашканчы алып китәргә сүз куештылар. Һәм икенче көнне Салих йөгерә-атлый кайтып барган Рәшитне куып җитте.

— Нишлибез, барабызмы?..

Рәшит башын аска иеп атлавын дәвам итте. Барыргамы, юкмы икәнен үзе дә белми иде. Әтисе иртән эшкә киткәндә аңа: «Әгәр тагын каршыма дружинник килсә, миңа үпкәләмә!» диде. Чыгып киткәч тә ишекне ачып: «Мин сиңа ата кеше, син мине дусларым алдында хурлыкка калдырасың, абруемны төшерәсең», диде. Иртән йокысыннан

уянгач хатыныннан гафу үтенгән: «Моннан соң эчмим инде, заводта да соңгы мәртәбә кисәтәбез, диделәр. Үзем дә сизәм: хәлем шәптән түгел, ашказаным да авырта, йөрәгем дә... Син миңа бүгеннән башлап көндезге ашка акча бирмә, ни дә булса әзерләп кесәгә генә сал», — дигән. Бәлки сүзендә торыр...

Шулай да, уйлаша торгач, егетләр завод янына барырга һәм Мөбәракне күзәтеп торырга булдылар.

Завод янына алар нәкъ вакытында килде. Проходнойдан халык чыгып бетте инде. Ләкин алар арасында Мөбәрәк күренмәде.

— Күрми калганбыздыр, ахрысы, — дип, егетләр кайту якка юл алды. Эти кешенең кичәге маршруты белән кайтырга карар кылынды. Башта бакчадагы «Кафе»га килделәр. Нишләптер аның ишегенә зур йозак элгәннәр, эчке яктан тәрәзәләре дә томаланган иде. «Кафе» тирәсендә байтак ир-ат җыйналган, ишеккә моңаеп карап торалар. Берсе йозакны хәтта кулы белән суккалап карады да:

— Бөтенләйгә япканнар, ахры, моны... Менә йөре инде хәзер әллә кайлардан зәмзәм эзләп, — дип сөйләнә-сөйләнә китеп барды. Аннары башкалары да таралышты.

Безнең егетләр аракы кибете янына бардылар. Кибет эчендә ак халат кигән сатучылар арлы-бирле йөреп нәрсәдер эшлиләр иде. Ябык ишекнең ачылуына өметләнеп монда да байтак кына ирләр җыйналган. Бер түземсезе ишеккә аягы белән тибә һәм туктаусыз мыгырдана иде...

— Бу нинди тәртипсезлек инде, понимаешь!.. Бусы инде өченче кибетем. Берсен завод якын дип, икенчесен балалар бакчасы якын дип япканнар. Ә монда нәрсә якын? Көтеп торучыларның һич тә китәр чамасы күренмәгәч, пыяла ишекнең эчке ягына зур хәрефләр белән: «Кибеттә исерткеч эчемлекләр сатылмый», дип язылган белдерү элеп куйдылар. Шул белдерүне берсе кычкырып укыды да:

— Менә сиңа мә! Үз акчаңа да эчеп булмый... Тьфу!.. Эт оргыры, — дип сүгенеп китеп барды.

Рәшит белән Салих Мөбәрәкне таба алмадылар.

Рәшит кайтып кергәндә алар өендә олы яшьтәге чит бер хатын белән чит бер ир утыра иде. Рәшитнең әнисе яулык чите белән күзләрендәге яшьләрен сөртеп алды да:

— Әтиеңнең эшеннән килгәннәр, тикшерергә. Әллә син, улым, заводка барган идеңме? — диде.

— Берәүнең дә заводка килгәне юк, — диде ир. — Әллә кайчан килеп өегездәге хәлләрне безгә сөйләргә иде. Мөбәрәк Илаловичның элек эшкә эчеп килгәне булмады, ә менә соңгы вакытта кинәт үзгәрде. Берничә мәртәбә эшкә соңга калды. Ә бүген, «хатыным авырый» дип, сменасын да тәмамламый китеп барды. Бәлки аны больницага салып дәваларга кирәктер?..

— Юк, юк, андый дәрәҗәдә түгел әле ул, — дип, Мәрьям ирен якларга тотынды.

Бу минутларда Мөбәрәк коеп яуган яңгыр астында, манма су булып, үзләреннән бөтенләй кире якта яшәүче «дусты» яныннан ава-түнә өенә кайтып килә иде. Ул аягында нык басарга, гәүдәсен төз тотарга тырыша. Ләкин барыбер булдыра алмый. Берничә адым атлый да абына, берничә атлый да авып китә. Әнә тагын аяклары таеп асфальтка башы белән барып төште. Мүкәли-мүкәли торырга тели. Тора алмады. Кемдер аны аягына бастырды. Кемнәрдер аның яныннан читләтеп, җирәнеп, төкеренеп үттеләр.

Кайберләре:

— Әнә шунда бастырып куйыйк та милициягә шылтыратыйк, — диделәр.

Кемнәрдер:

— Тимәгез, үзе кайтып барган кешене милициягә озаталармыни. Исереккә берни дә булмый, кайтып җитәр әле, — диделәр.

Һәм ул, чыннан да, бик авырлык белән булса да өенә кайтып җитте. Баскычта пычрак эзләр калдырып өенә керде.

Хатыны, Рәшите, Рөстәме, Ләйләсе, котлары очып, аның каршысына килеп бастылар.

— Мөбәрәк, нишләвең бу?..

Ул, кулларын болгап, нәрсәдер әйтергә теләде, теле әйләнмәде. Күзләрен тутырып балаларына карады. Ул шап итеп идәнгә ауды. Ләйлә, бүреген салдырып, әтисенең пычрак суга манчылган чәчләрен сыйпый, үзе куркынып үксеп-үксеп елый. Рәшит әтисенең пальтосын, пычранган юеш ботинкаларын салдырды. Ана кеше тиз-тиз генә урынҗир рәтләде. Тик Рөстәм генә, йөзенә ачу чыгарып, әтисенә ачу белән карап тора бирде. Урамдагы салкынны, шомлы җилләрне, тынга каба торган сасы исне ата кеше үзенә ияртеп өйгә алып керде. Рөстәм туңды, калтыранды. Аның гәүдәсе куырылып, хәлсезләнеп калды. Шундый ямьсез хәл килеп чыккан саен үндүрт яшьлек Рөстәм дөньяда үзен иң бәхетсез кеше итеп саный. Урамга чыгып, бөтен дөньяга кычкырып, кемнәрнедер ярдәмгә чакырасы килә. Ләкин кемне, кемнәрне? Ата кеше үзе тудырган балаларын үзе бәхетсезлеккә, хурлыкка төшергән, кем соң аларга ярдәмгә килер? Өйдән чыгып качарга, үзләрен кимсетә торган бу бәхетсезлектән гомергә котылырга иде. Кая качарга, газиз әнисен, туганнарын калдырып кая качарга?..

Рәшит белән әнисе атаны, як-ягыннан җитәкләп барып, урынга яткырдылар. Өстенә юрган яптылар. Шуннан соң гына, бераз тынычлангандай булып, ашап-эчеп, утларны сүндереп йокларга яттылар. Рөстәм, баш авыртуы басылмасмы дип, тәрәзәдән урамга карап тора бирде. Шыбыр-шыбыр көзге яңгыр ява. Урамдагы электр лампаларын җил чайкый. «Берәүнең дә өендә бездәге көбек авыр хәсрәт юктыр»,— дип уйлана Рөстәм.

Маңгаен салкын тәрәзә төбенә куеп, Рөстәм йокымсырый башлады. Каты итеп шапылдап идәнгә нәрсәдер төште. Бүлмәдә ут кабынды. Әнисе:

— Балалар! Әтиегез... — дип үзәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде. Ул ялан аяк, эчке күлмәктән үзенә таба килгән әнисен кочаклап алды. Рөстәм йөгереп әтисе янына кергәндә әтиләре соңгы сулышларын ала иде инде.

Ата үлде. Нәкъ әтисенеке шикелле киң маңгайлы, кысыграк зәңгәр күзле, әтисе шикелле тырыш, эшчән улы Рәшит калды. Әтисе айнык чакта да, исерек чакта да аның дулкынланып торган кара чәчләрен сыйпап, «әти», «әтием»! дип эндәшүче Ләйлә калды. Әтисе шикелле үк иңбашларын сикерткәләп, бераз чайкалыбрак йөрүче, әтисенеке шикелле тоныграк тавышлы Рөстәм калды.

Ир үлде. Уңсыгез яшеннән сөеп, аңа кияүгә чыккан һәм гомер буе аны яратып яшәгән хатыны Мәрьям калды.

Галимнең көннәре кызыклы гына үтә сыман. Әнисе аңа балкон тәрәзәсе кояшка караган иркен бүлмәне бирде. Ана улын эштән кайтканда тәмле ризыклар пешереп, куанып каршы ала. Заводта да аңа кырын карамыйлар, ышаналар. Эшче яшьләр белән бергәләшеп ул еш кына кинотеатрларга бара. Завком члены, аппаратчы кыз, җыелышта Галимне ачуланган Мөслимә, янына еш кына килеп, аның ничек эшләгәнен карап тора. Кинотеатрларга барганда билетны да иң элек аңа бирә. Кинога бер барганда Мөслимә белән урыннары янәшә туры килгән иде. Шулай да Галимнең кайчакларда эче поша, күңеле үрсәләнеп

куя. Янында иңбашына кулын салып, серен сөйләшеп утырырлык дусты юк аның. Урамга чыкса да берүзе. Өйләрендә телефон шылтыраган саен Галим ашкынып трубканы ала, кемдер аны үз янына чакырыр, кемдер аның янына килердер кебек, ләкин... Шылтыраткан кеше дәшми, трубканы элеп куя. Ә Галим үзенә дус булырлык кешене — Айсылуны күңелендә йөртә. Ул Айсылулар урамыннан берничә тапкыр әйләнгәләп тә кайтты. Аларның йортлары яныннан да узып киткәләде. Тик Айсылу күренми иде. Ә менә кичә Галимнең бәхет йолдызы кабынды. Кичә ул аны очратты. Кыз өстенә кызыл плащ кигән, башына ак капрон яулык бөркәнгән иде. Йөгерә-йөгерә килеп автобуска утырды. Галим дә аның артыннан сикереп менде. Халык арасыннан үтеп, Айсылу янына килеп басты.

— Айсылу!..

Айсылу сискәнеп китте. Галимне күргәч, күзләре очкынланып, иреннәре калтыранып куйды.

— Исәнмесез, Айсылу!..

— Исәнмесез!.. — Айсылу нәфис кулын Галимгә сузды. Алар җитәкләшеп автобустан төштеләр.

— Айсылу, өегезгә кадәр озата барыйммы?..

— Ярый... Галим, син ник югалдың? Үзең иртәгә киләм дип киткән идең.

Галим бер сүз әйтә алмыйча Айсылу белән янәшә бара бирде. Үзе Айсылуның йөзенә сынай карап куйгалады.

Айсылуның алсу чәчкәдәй йөзе тагын да алсуланып, күзләре тагын да очкынлана төште. Иреннәре елмайды да елмайды. Димәк, ул да сагынган, көткән Галимне.

— Мин эштән кайтам бит әле, өйгә кереп кенә чыгам да, техникумга китәм, — диде Айсылу үзләренең подъездлары янына килеп җиткәч.

— Көтеп торыйммы синең чыкканыңны, Айсылу? Мин сине озата барырмын. Аннан үзем дә укырга китәрмен. Мин дә кичен укыйм бит, Айсылу.

— Көт, алайса, мин хәзер...— дип өйләренә кереп китте Айсылу.

Бу инде Галим өчен дөньяда иң зур бәхет иде. Галим кинәт үсеп киткәндәй булды. Бу минутларда тауларны урыныннан күчерә алырлык көч сизде ул үзендә. И дөнья, нинди матур икән ул! Ничек соң әле Галим шуны әлегә кадәр сизми яшәде.

Мехчылар техникумы бинасының эченә үк озатып куйды Галим Айсылуны. Иртәгә алар тагын очрашырга сүз куештылар.

Галим Айсылу белән очрашу сәгатьләрен зарыгып көтте. Һәр җирдә ул Айсылуны күз алдына китереп, аның турында уйланып йөрде. Аңа сөйлисе сүзләрен тәкрарлады, үз-үзе белән гәпләште.

«Барысын да сөйлим Айсылуга. Дөресен сөйлим. Әгәр ул акыллы кыз булса, аңлар минем хәлне. Аңлар, бәлки гафу итәр. Мин бит хәзер бөтенләй башка кеше. Әни белән дә сөйләшермен...

Әнигә әйтергә кирәк әле, Рәүф абыйны чакырсын да торсыннар бергә... Мөслимә дөрес әйтә, әти-әнинең тормышына тыгылырга безнең хакыбыз юк, аларның да тормышта төрле чаклары була, ди. Без әниләрне тудырмаганбыз, әниләр безне тудырган. Шуңа безгә аларның ялгышларын гафу итә белергә кирәк, ди. Дөресе дә шулай бит. Ә мин, юләр, әни этине ташлап китте дип, эчеп, исереп, урлашып йөрдем, төрмәгә эләктем. Шул вакытта миңа этигә булышырга, әни белән яхшы итеп сөйләшергә, семьяда зур кеше булып калырга кирәк булгандыр да бит... Кечкенә булганмын шул, нибары ундүрт яшь, хәзерге шикелле дусларым булмаган. Фаруклар... Ә бит, бер карасаң, алар да шәп малайлар кебек иде. Мине алар үз иттеләр, кызгандылар. Аларның сүзләре дә төпле, мәгънәле иде кебек:

— Әниең синең әшәке хатын, әтиең бозау, төкер башларына, ташла син аларны, рәнҗеттеләр алар сине, әйдә безнең белән, без беркайчан ташламыйбыз сине, башыңа бәла килсә, ялгыз калдырмабыз, диделәр. Ну бу Фарук, юха елан шикелле, юата, үгетли, ашата, эчертә, «һөнәргә» өйрәтә. Мөслимә дөрес әйтә:

— Галим, син үзең гаепле, безнең цехта әтисе ташлаган да, әнисе ташлаган егетләр дә бар, тик алар синең шикелле эчеп-исереп йөрмәгәннәр, төрмәгә дә эләкмәгәннәр, яхшы эшчеләр алар, яхшы кешеләр. Тырышалар, үз көчләре белән аякка басалар. Ә син җил кая иссә шунда авасың, характерың юк синең, Галим, ди. Ихтыяр көчең юк, ди...

Икенче көнне очрашкач, Айсылу белән Галим, кулга-кул тотышып, урам буйлап йөрделәр. Айсылу Галимгә һаман бер сорауны бирде:

— Әйт инде, Галим, ник шулай бик озак килми тордың?..— Алар кечкенә бакча кырыендагы эскәмиягә утырдылар. Галим өстендәге плащын салып Айсылуның иңенә япты. Галим башыннан үткәннәрне дөп-дөрес итеп, барысын да сөйләргә тотынды. Ачынып-әрнеп сөйләде ул. Айсылуның күзләренә карамады, башын түбән иде, еш-еш сулады егет. Галим сөйләгән саен кыз аннан читкәрәк тайпыла барды, иңеннән Галимнең плащы сыдырылып җиргә төште. Ахыры түзмәде, кинәт йөзен ике кулы белән томалады да әчке әрнү белән, рәнҗеп кычкырып җибәрде.

— Оятсыз!

— Айсылу!..

— Оятсыз!.. — Айсылу урыныннан сикереп торды. — Син, син, ничек оялмыйча... Мин гомерем буена кешеләрнең әйберләренә рөхсәтсез кагылу түгел, күңелләрен рәнҗетерлек авыр сүз әйтергә дә куркып яшим. Син үзеңнең урлашып йөрүләреңне, исереп йөрүләреңне оялмыйча миңа сөйлисең. Сагындым, имеш, мәхәббәт, имеш!.. Сиңамы соң ул мәхәббәтне аңларга!.. Синең намусың да, изге хисләрең дә тапталган, пычранган. Син аларны үзең, үзең таптагансың. Кит, күземә дә күренмә!.. Әгәр бу урамга кабат килсәң, абыйларымны чакырып, милициягә озаттырам...

Айсылу үксеп елый-елый өйләренә таба йөгерде.

Галим, өнсезләнеп, урыныннан кузгала алмый озак утырды. Кап-караңгы төн... Ярый әле, күктә ай юк, йолдызлар да җемелдәми. Галимнең кара пәрдә ябылган хәсрәтле йөзен берәү дә күрми. И, тормыш! Бер минут эчендә кешене тагын упкынга атып бәрдең. Бөркеттәй егет сыгылып төште.

Галим ике кулының учы белән битенә бәреп чыккан тир бөртекләрен сыпырып алды. Аннары әкрен генә урыныннан кузгалды. Тик берничә адым атлау белән кемдер авыр кулын аның иңенә салды. Галим, сискәнеп китеп, шул кешегә карады: аның янында түм-түгәрәк йөзле, таза гәүдәле бер егет тора, аннан читтәрәк тагын берсе — ябыграгы басып тора иде.

— Сәлам, браток! — диде Галимнең иңенә кулын салганы.

— Нәрсә кирәк сезгә?..

— Берни дә кирәкми. Просто сагындык. Ничә көн, ничә төн үзеңне күрәсе килеп йөрибез, җай чыкмый.— Ул кесәсеннән сигарет алып кабызды. Галимгә дә тәкъдим итте.— Мә, тарт, нәрсә бөрешеп калдың, мә!.. Кара, кара,бөтенләй өнсезләнгән... Әйдә, утырыйк. Ну кызык итте үзеңне чеплән аяк: ничек чаба, артыннан умарта кортлары куа диярсең!.. Ә телисеңме, иртәгә шушы вакытка чәченнән сөйрәп китерәм мин аны, китерәм дә алдыңа тезләндереп гафу үтендерәм. Калганын үзең карарсың, практикаң бар.

Галим, куркудан нишләргә дә белмичә, шап итеп эскәмиягә утырды. Тегеләр аның як-ягына утырдылар.

— Я, я, алай ук аһ орма, кызлар өчен авыз корытыр заман түгел. Теләсәң, унны, йөзне табабыз... Фаруктан сәлам!
— Нинди Фарук?..
— Оныттың дамыни, хәтерлә, хәтерлә... Андый шәп дусны тиз генә онытырга ярамый. Үзеңнең төрмәдәшең бит.
— Мин колониядә идем, ул төрмәдә...
— Аерма юк. Ул да кеше талаган, син дә кесә карагы.
— Кесә карагы булганым юк. Ялгыш кына булган хәл ул.
— Фарук та кайчандыр шулай ялгышлык белән генә кеше кесәләренә кереп йөргән, ә аннан өйрәнеп киткән...
Галим авызыннан сарымсак, суган, тагын әллә нинди тынчу ислэр килгән бу кешегә ачу һәм нәфрәт белән карап алды:
— Нәрсә кирәк сезгә дим бит.
— Ашыкма, төн безнеке,— диде егет сабыр гына.— Шул. Фарук синең аркада тагын төрмәгә эләкте. Шуны беләсеңдер дип уйлыйм.
— Ничек минем аркада?..
— Ничек булсын, син сатлык җан булган өчен! Туган көн үткәрәм дип җыйналгансыз да син алдан милициягә хәбәр итеп куйгансың...
— Юләрмени мин алай итәргә? Туган көнне мин үткәрмәдем, Фарук үзе чакырды. «Яшь малайлар белән танышасым килә, алып кил үзләрен», диде.
— Ул малайларың кая хәзер?
— Белмим.
— Белергә туры килер. Ничә ел Фарук канаты астында җылынып яткансың, ул тапкан акчага тыгынгансың, аракы, сыра чөмергәнсең. Алай сатлык җан булырга ярамый!
Галим хәлсезләнә барды. Тыны кысылды. Башы әйләнә, косасы килә башлады.
— Барысы да бетте, — дип уйлады ул. — Кара төндә харап итәчәк болар мине... Тукта әле!.. Нигә син шул кадәр куркынып калдың, Галим? Караңгылыктанмы? Ә үзең ничә ел караңгылыкта яшәдең. Якты көнне, кояшлы иртәне син яратмадың. Кичне, төнне сагынып көтә идең бит. Нигә хәзер җебеп төштең? Теге кызның авызын томалап читкә өстерәгән чагында караңгы төн иде бит, хатынның сумкасыннан акча алганда да кич иде, караңгы иде. Ул чакта син бер дә курыкмадың, батырның батыры идең. Алар да синнән котлары очып кемнәрдәндер ярдәм көттеләр. Аларга ярдәм итүчеләр табылды. Менә сиңа хәзер кем ярдәм итәр икән? Алар икәү, син бер ялгызың...
— Я, я, калтыранма, куркак җан, — дип, Галимнең иңсәсеннән селеккәләп алды зур гәүдәлесе. — Күтәр башыңны, кара әле менә бу матур егетне. — Ул, иягеннән тотып, Галимнең башын сул якта утырган егеткә таба борды.
— Яхшылап кара, икенче күргәндә танырлык булсын. — Ул сул кулы белән Галимнең аркасына сугып куйды. — Фарук сиңа сәлам әйтергә кушкан дидемме әле? Беләсеңме кайда ул хәзер?..
— Белмим...
— Зөя төрмәсендә, хохма, валлаһи. Нинди статья бит әле — 210 нчы. Яшүсмерләрне бозык юлга тарткан өчен, ике ел... Котырттымы сине?.. Тарттымы ул сине бозык юлга, ә?.. — Галим дәшмәде. — Дәшмичә дөрес эшлисең. «Фарук мине котыртты», дип авызыңны ачып кара... — Ул чалт итеп җиргә төкереп куйды. —Син Коля Васильевны беләсеңме? Адресын әйт әле... Башка квартирага күчкән ди...
— Белмим.
Якыннан гына, зәңгәр утларын җемелдәтә-җемелдәтә, милиция машинасы узып китте.
— Әнә узып баралар синең дусларың. Дураклар, утларын яндырып килаләр, безнең шикелләләргә хәбәр генә бирәләр ич: «Качыгыз, ми-

лиция кылә!» — Ул, кулы белән авызын каплап, пырхылдап көлеп алды. — Коляның адресын дим...

— Белмим...

— Белмим дә белмим. Әйтерсең лә суд залында... Менә нәрсә, дускай, Фарук синең изменне изәргә, аннан соң үзенең үтенечен әйтергә кушкан, белдеңме... Но мин андый ерткыч түгел, урамда кешеләр кыйнап йөрмим мин, бармак белән дә чиртмим сиңа.— Сул якта утырган яхшы ук салмыш егет, башын эскәмия артына куеп, гырылдап йокыга китте. — Йоклавы хәерле... Яхшы гына эшләп йөрисең икән, эшлә, тырыш, тик Фарукны онытма. Акча алгач, аңа да өлеш чыгарырсың дип ышанам. Менә шушы егет аша миңа акча җибәрерсең, ә мин — Фарукка. Безнең очрашу турында милициягә хәбәр итсәң... — Ул уң кесәсенә кулын тыкты. — Хәбәр итсәң, башың баскан җирендә аунап ятыр. Аңлашыламы?. — Ул урыныннан торды да йоклаган егетнең кулыннан тартып аягына бастырды.

— Ужым бозавы, тор, киттек! Башыңны тактага куеп йоклаганчы берәр чибәрнең күкрәгенә салып йокларсың ичмасам. — Ул кулын Галимгә сузды. — Сау бул, тагын очрашканга чаклы.

Галим болай җиңел генә котылуына иркен сулап куйды.

— Кайчан очрашабыз соң? — диде ул, кулын сузып.

— Кирәк чакта үзем сине табармын.

Ул шулай диде дә, иптәшен җитәкләп, салмак кына атлап китеп тә барды.

Ишекне Һашия ачты. Галимнең агарган йөзен күргәч, коты алынып, ул стенага сөялде.

— Әни, су бирче, — диде Галим, өстендәге плащын сала-сала.

Кайнар чәй эчкәч Галимнең йөзенә төс керде. Һашия сораулар биреп улын борчырга кыймады, үз бүлмәсенә кереп, стаканга дару тамызып эчте дә, йокыга ятты. Галим түр бүлмәдә, креслога утырган килеш, озак уйланды. «Тагын тыныч, рәхәт көннәрә бетте. Беренче саф мәхәббәте юкка чыкты. Җаны пычак астына куелды. «Ужым бозавы». Фарук ачуы чыккан саен Галимгә дә «син бит ужым бозавы» дип кычкырына иде. Гомер буена беркемгә дә кирәксез җан, «ужым бозавы» булып тормышны дәвам итәрме ул, әллә Мөслимә әйткән егет була алырмы? «Рухың көчле булсын, синнән теләсә кем бау ишмәсен» ди бит аңа Мөслимә.

Галим ана бүлмәсе янына килде.

— Әни, йоклыйсыңмы?..

— Юк, улым, кер...

Галим аның караваты янына урындык куеп утырды. Һәм гомерендә беренче мәртәбә серен ачып, барын-барын да яшермичә сөйләп китте.

Һашиянең йөзе кызарды, арка сөякләре сызлап куйды. Улын дикъкать белән тыңлады, ә күз алдыннан үз тормышы һәм ирләре үтә торды. Әллә шулар аркасында килеп чыктымы мондый аяныч хәлләр? Кайсысында ялгышты ул? Ә бит ирләренең икесен дә яраткан иде. Икесе дә Һашиягә күңелле, матур минутлар, сәгатьләр, көннәр бүләк иттеләр. Әйе, бик бәхетле булган көннәре бар иде аның. Камиле, Галиме газап чигеп яшәгән көннәрдә Һашия үзе бик бәхетле иде... Галим ялгыш юлда, җинаять сукмагында йөргән чакларда ул кайларда иде?.. Рәүф белән Сочида, диңгез буенда типтерде.

Ана бар көче белән Галимне күкрәгенә кысты. Яшь аралаш тавыш белән:

— Улым, җаным, гафу ит! Вакытында әйбәт ана була алмадым шул, гаеп миндә. Гафу ит, улым, — диде.

Галим әнисеннән читкә тартылды да, аягүрә басып, озак кына ана

карап торды. Үзгәндәгы газаплы кѳннәре тагын бер кат аның күз алдыннан узды. Беренче мәртәбә бик нык рәнҗеп әйтте:

— Безне озакка калдырып киткәндә шундый күңелсезлекләр килер дип бер дә уйламадыңмыни соң, әни, ә?.. Син кайтмагач, Камил елады да елады, әти эчте дә эчте. Их, әти, әти!.. Ул бит миңа «елама, кайгыңны бас» дип, үзе салып аракы эчерде.

— Әтиеңә сүз әйтмә, улым, минем аркада, хәсрәттән аптырагач шуңа баргандыр инде ул.

— Хәсрәт белән көрәшерлек көч тапмаган өчен үпкәлим мин аңа. Ул биргән аракы мине төрмәгә, үзен каберга кертте.

Һашия бизгәк тоткандай калтыранды. Тәрәзәгә бәреп, тышта каты яңгыр ява һәм ана белән улының болай да шомлы күңелләрен тагын да ныграк шомландыра иде. Һашиянең колагына кемдер: «Син, үз хисләреңә хуҗа була алмыйча, ике нәни балаңны җиде юл чатында ташлап калдырдың. Мәхәббәт хакына дидең. Сөясем-сөеләсем килә дидең дә, балаларың ятим итеп, икенче бер ирнең иңенә сарылдың... Балалар бәхете исәбенә үзең бәхетле булырга теләдең. Мәхәббәт ул яшьлекнең чәчкә аткан чагында гына көчле, саф була. Балалар анасы булгач, азгын хисләр китергән мәхәббәт көчсез дә, гомерсез дә. Ә газабы гомер буена китә аның» дип пышылдый сыман иде.

Зөлфәт, кабул итү сәгатьләрен тәмамлап, иртәгә эшлисе эшләрне язган кәгазьгә тагын бер кат күз салып алды да, гимнастеркасының күкрәк кесәсеннән пөхтәләп икегә бөкләнгән кәгазь чыгарды. Туйга кирәк булачак әйберләр исемлеге иде бу. Иртән эшкә киткәндә Зөлфәткә әнисе үзе әйтеп яздырды һәм: «Вакытың булган арада гел кибетләргә керә йөр», — дип калган иде. Әмма Зөлфәткә кибеткә керү түгел, әлеге исемлекне укып карарга да вакыты тимәде. Ниһаять, менә хәзер, эштән соң, ул туй хәстәренә керешергә уйлап, кесәсендәге акчаларын барлап, өстенә плащын кия башлады.

Шул чакны ишектән, рөхсәт тә сорап тормыйча, ашыгып-кабаланып ябык ак чырайлы, күз кабаклары шешенгән бер егет килеп керде. Керде дә хәле беткән, еш-еш сулу алган хәлдә ишек янагына сөялде. Аннан соң гына:

— Ярыймы икән, иптәш лейтенант, — дип әкрен генә әйтеп куйды.

Зөлфәт кулындагы фуражкасын кире чөйгә элде, плащының төймәләрен чишеп җибәрде. Егеткә текәлеп карап торды да:

— Ни йомыш? Нигә шул кадәр ашыктың? — диде Зөлфәт, егетнең йончыган киеменә, шешенгән күзләренә тагын бер кат игътибар итеп.

— Мин ни, тегеннән кайткан идем дә... — Егет өстендәге балонья курткасының җиңен, итәген тартып куйгалады. Кат-кат борынын тартып алды. Аннан кулындагы конвертны Зөлфәткә сузды.

— Утырыгыз!..

Егет күзләрен челт-челт йомгалады. Кибеп ярылган иреннәрен ялап куйды.

«Ник бик кыюсыз тота бу үзен. Гадәттә төрмәдән кайтып участокка килгәндә кешеләр пөхтә киемнән, кырынып, чистарынып киләләр, үзләрен тотышлары да мондый булмый, ә бу?..» дип уйлап куйды Зөлфәт һәм егетнең документларын кат-кат укыды да:

— Төрмәдән кайтканыңа биш көн, ник кайтуга ук килмәдең?..

Егет эндәшмәде, утырган урындыгына елыша барды, ике кулы белән дә шуның артына тотынды.

«Һе!..— дип уйланды Зөлфәт,— әйтерсең урындыгыннан кубарып алып, аны төрмәгә кире озаталар. Ник болай?..» Аның эш тәҗрибәсендә, тоткынлыктан кайтып та өлгерми, янадан җинаять юлына басучылар очраганы бар бит...

— Әтиең, әниең шатлангандыр инде сине күреп? — дип сорады Зөлфәт, егеткә сыный карап.
Егет ялт итеп Зөлфәткә күтәрелеп карады һәм шунда ук башын түбән иде. Аннары әкрен генә:
— Шатланмыйча... Ике ел утырдым бит...
— Мин менә, Кадыйр иптәш, сине күреп, бер дә шатланмадым, — диде Зөлфәт. Кайтып керергә өлгермәгәнсең, бүртенгәнче эчкәнсең. Бар, өеңә кайт, иртәгә үзеңне тәртипкә китереп, мунча кереп, тәмам айнып килерсең...— Үзе шулай диде диюен Зөлфәт, әмма күңеленнән: «Шунда төн кунсам кунам, егетнең бу иләмсез кыяфәтенең сәбәпләренә төшенәм», дип уйланды.
— Миңа тизрәк эшкә урнашырга кирәк, — диде егет кыю гына.
— Сөйләштек... Бәлки иртәгә иртүк, сәгать сигезләрдә үзем сезгә барып чыгармын...
Егет нык каушап калды.
— Безгә?.. Кирәкми, бармагыз, үзем килдем бит...
— Бару-бармау минем эш... Күлмәк якаңны, чалбарыңны кара. Әй, син... кем әйтер егерме бер яшьлек егет дип...
Егет урыныннан торды, ишеккә атлар-атламас килде, кабат курткасының җиңеп, итәген тарткалап алды, кулындагы кепкасын күзләренә кадәр төшереп башына киде.
Зөлфәт тә өстәл артына торып басты, егетнең күзләренә карарга тырышты ул. Ләкин егет башын түбән иеп басып тора бирде.
— Утыр урыныңа, Кадыйр, кайтып җитмәс борын кемнәр белән эчеп йөрдең, сөйлә, барыбер беләм...— Зөлфәт каты-каты басып идән буйлап йөренеп алды... — Сөйлә, төрмәгә нәрсә өчен кердең?
Егет күзләрен йодрыгы белән угалап алды да:
— Иптәш лейтенант, ышаныгыз, усал ният белән түгел минем эләгүем... Ул чакны сез монда эшләми идегез әле, икенче лейтенант иде монда,— диде.— Усал ниятем юк иде, юләр булдым... Шул аракы бәласе инде. Иптәшләр белән бераз салган килеш инде... Бер ирнең бүреген салдырганны карап кына тордым. Ә ул явызлар, минем белән эчкән малайлар инде, мине, карап кына тормады, бүрекне салдырышты дип әйтәләр, судта инде...
— Утыр, утыр әле, — дип, Зөлфәт уң кулы белән егетнең аркасына йомшак кына кагылды...
— Инде нишләргә уйлыйсың?..
— Токарь мин. Училище тәмамладым. Яхшы гына эшли дә идем, разрядым да бишенче. Алсалар, үзебезнең заводка керергә иде исәп.
Зөлфәт уң кулының бармаклары белән өстәлгә каккалап уйланып утырды. Аннары:
— Иртәгә үк заводның кадрлар бүлеге белән сөйләшермен, әгәр... Ул тагын текәләп егеткә карады...
Егетнең күзләре яктырып китте, ул нәрсәдер әйтергә теләде, аннан «уф» дип тирән сулады да:
— Ышаныгыз, иптәш лейтенант, мин усал ният белән түгел, тагын шул аракы бәласе инде, — диде. Зөлфәт бер сүз дә дәшми аңа карап торуын дәвам итте. Егет бөтенләй ачылып, эчкерсез сөйли башлады.
Кадыйр төрмәдән чыгарга бер атна кала алар барагына Фарукны китергәннәр. Шунда танышканнар. Кадыйр кайтып киткәндә Фарук аңа үзенең бер танышына хат биреп җибәргән һәм поездан төшкәч тә илтеп тапшыруны үтенгән. Бу егет шулай эшләгән дә: Казан вокзалына кайтып төшү белән хатның иясенә туп-туры киткән. Хуҗа аны бик хуплап каршы алган, алар аның исән-имин өенә кайтып җитүен аракы эчеп нык кына юганнар. Һәм хуҗа биш көн буена егетне айнырга ирек бирми сыйлаган да сыйлаган... Тегенең янына Фарукның башка әшнәләре дә килеп торган. Һәр кичне Фарукны сагынып сөйләп утырганнар.

Аның төрмәгә нахактан, начар, ышанычсыз иптәшләре аркасында гына эләгүен әйтеп зарланганнар... Хуҗаның Госман исемле булуы, зур гәүдәле икәнен әйтте Кадыйр һәм:

— Кичә ул мине шул Фарукны утырткан «Сатлык җан» белән танышырга алып барды. «Очрашкаларбыз әле», диде. Бик арган идем, нык кына салдырды да. Алар сөйләшкәндә йокыга киткәнмен. Сөйләгән барлык сүзләре дә хәтердә калмаган, — диде. Аннан куркынган кыяфәттә Зөлфәткә туры карап:

— Мин бу турыда сөйләшмәскә аңарга ант иттем... «Әгәр лыгырдый калсаң, үзеңә үпкәлә», — диде. Бүген иртән, ул кибеткә аракыга чыгып киткәч, мин аның өеннән чыгып киттем. Чөнки айнып беткән идем инде... Иптәш лейтенант, ышаныгыз, усал ниятем юк иде. Характерым юк минем, характерым... Ул башын ике кулына салды...

— Бар синең характерың, Кадыйр, бар,— диде Зөлфәт елмаеп...— Башыңа килгән бәладән котылырга теләү, үз ялгышыңны аңлау — бу инде характер, Кадыйр, ирләр характеры бу... Рәхмәт, рәхмәт сиңа... Үзеңне дә, тагын кемнәрне дә зур бәладән коткардың, рәхмәт! — Аннары ул егетнең аркасыннан дусларча кагып алды:

— Иртәгә иртән заводның кадрлар бүлегенә бар. Мин сөйләшермен. Прописка мәсьәләңне хәл ит.

Егет, «Сау булыгыз, рәхмәт» диде дә, бәреләсугыла чыгып китте. Зөлфәт тәрәзә янына килеп басты. Кадыйр ашыга-ашыга автобус тукталышына китте. Аның адымнары тигез һәм нык иде... Зөлфәт егетнең документларын кабат карап алды да дәфтәр битенә: «Алиев Кадыйр 1956 елда туган... Эшкә урнаштырырга», дип язып куйды. Аннан телефон номеры җыйды. Трубкада: «Милиция лейтенанты Симагин тыңлый» дигән мәһабәт тавыш яңгырады.

— Сәлам, Симагин! Мәрдәнов!..

— Сәлам, дускай!.. Нинди уңай белән исеңә төшердең без фәкыйрегезне?..

— Фарукның тагын кулы уйный башлаган. Яныннан берәү кайткан, минем участок кешесе.

— Беләм, дускай, рәхмәт!..

— Кай арада? — дип, гаҗәпсенеп сорап куйды Зөлфәт.

— Галим Рахманов үзе килеп барысын да сөйләп китте. Аны нык кына куркытырга теләгәннәр. Рахманов молодец, югалып калмаган...— Аннары Симагин тирән сулап алды да:— Ну рәхәт тә булып китте әле, дускай, Галимнең шакшы тормыштан арынырга омтылуы. Әйтерсең йөрәккә май салдылар...

— Тәбрик итәм, дускай, димәк, тырышып йөрүләрең бушка китмәде.

— Шулай гына булсын инде, — диде Симагин.

Алар трубкаларын элделәр... Бүлмәдә тынлык. Идән уртасына баскан килеш Зөлфәт үзалдына елмаеп бераз торды. Бу елмаю аның күңеленә куаныч, канәгатьлек бирә торган халәт иде.

Тынлыкны бозып телефон шалтырады.

Полковник Борһанов икән.

— Хәерле көн, иптәш Мәрдәнов.

— Хәерле көн, иптәш полковник!..

— Сезне чын күңелдән тәбрик итәм, иптәш лейтенант... СССР Эчке эшләр Министрлыгыннан приказ алынды — Сезгә өлкән лейтенант званиесе бирелгән. Тагын бер кат чын күңелдән котлыйм, эшегездә зур уңышлар телим, сәламәтлек телим, иптәш өлкән лейтенант...

«Рәхмәт. Рәхмәт, иптәш полковник!» Зөлфәт тагын нәрсәдер, ниндидер кирәкле сүзләр әйтмәкче иде... Ә полковник трубканы куйган булып чыкты.

Коля бер атна инде этисе өендә яшн. Беренче көннәрне ул үзен тыныч тотты. Өйдәгеләр аның белән яхшы мөгамәләдә булдылар. Бигрәк тә энесе Сергей. Мәктәбеннән атылып дигәндәй кайтып керә. Коляга классларындагы хәлләрне сөйли, китапханәдән китаплар алып кайта. Этисе дә кичләрен Коля белән шахмат уйнап утыра.

Ләкин бу тынычлык озакка бармады. Өйдәгеләргә карата көнләшү хисе туды аңарда. Барысы да иртән өсләренә матур киемнәр кияләр, ашыйлар, эчәләр дә эшкә, укырга чыгып китәләр. Коляга күпме теләсә шул хәтле йокларга кушалар. Өстәл тулы ризык, теләгәнчә аша да, тагын йокла, радиоладан матур музыка тыңла, телевизор кара... Аның йоклыйсы да, ашыйсы да килмәде. Тәрәзәдән урамга озаклап карап торулар да әллә ни юаныч бирә алмады аңа. Менә ул, энесенең дәрес әзерли торган өстәле янына килеп, аның матур почерк белән язылган дәфтәр битләрен актара башлады. Күзе күргән тырышлыктан ачуы чыгып, дәфтәрне читкә этәрде. Ул үзе дә җиденче, сигезенче классларда яхшы укый иде. Теләсә, математиканы гел бишлегә белде. Ләкин ул тырышмады. Мәктәпкә бармый калган чаклары да күп була иде. Шулай да ун классны тәмамлады. Армиягә китәсе килгән иде аның — алмадылар, йөрәгең авыру диделәр. Алынган булса, бәлки башкача яшәп киткән булыр иде. Хәзер кулында ни һөнәр юк, ни рәтләп эш белми... Аның урамга чыгасы, кешеләргә кушылып, эшлекле кыяфәттә берәр учреждениегә эшкә барасы килде. «Бетмәде инде бу тикшеренүләре дә», — дип уйлады ул. Тизрәк хәл итсеннәр иде инде. Туйдырды. Чакыралар да сорау бирәләр: «Ник укымыйсың? Нигә төпләнеп эшләгән урының юк? Ник эчәсең? Кайчаннан бирле эчәсең?».

Башка сорауларына җавап бирә алмаса да, үзенең кайчаннан бирле эчә башлаганын белә Коля. Тик тикшерүчеләргә дөресен әйтә алмый. Ул чакта тикшерүче аның әнисен гаепләячәк. Ә әнисен гаепләтәсе килми аның, чөнки бары үзе гаепле. Суд булса анда да әйтәчәк ул: «Әтиәнинең гаебе юк», диячәк. Коля сигезенче класста укыганда, Сигезенче март бәйрәменә әнисе кунаклар чакырды. Җырлап, биеп озак кына вакыт уздырдылар да барысы бергә чыгып киттеләр. Әнисе кунакларны озата китте. Коля өйдә берүзе, өстәл тулы ашамлык, эчемлек... Әнисе берсен дә җыештырып куймаган, хәзер әйләнеп кайтырмын дип уйлагандыр. Коля ашап-эчеп утырды, аннары, юри генә авыз итеп карыйм әле дип, кечкенә рюмка белән, әнисе бик мактап эчә торган виноны йотып куйды. Чыннан да бик тәмле икән. Әйтәм аны табында утыручылар да мактап-мактап эчкәннәр иде. Әнисе аны «Ленинградтан алып кайттылар» дип тә сөйләнде бит. Ул тагын бер рюмка эчте. Аңарга бик тә рәхәт, бик тә күңелле булып китте. Аннары, әни белмәс әле, дип, бер шешә виноны яшереп тә куйды. Әнисе иртән ах-ух килеп кайтып кергәндә Коля рәхәтләнеп йоклап ята иде. Әнисе аны, көчкә генә уятып, мәктәпкә җибәрде. Мәктәптә исә ул башы авыртуга йөдәп утырды да, түзә алмагач, өченче дәрестән китеп барды. Юлда очраган күрше малаена, көлә-шаяра: «Баш авырта, кичә күбрәк эчеп ташланган», диде.

— Исең киткән икән, тагын берәр стакан тондыр да баш авыртуың шунда ук бетәр, — диде аңа малай. Күрше киңәшен тотып, Коля кичә яшереп куйган виноны өеннән тиз генә алып чыкты да шуны икесе бергә эчтеләр. «Рәхмәт, мин дә сине сыйлармын», диде күрше малае һәм сүзендә торды. Икенче көнне үк Коляның мәктәптән кайтканын көтеп алып: «Кичкә безгә кер, өйдә үзем генә, баш төзәтәбез», диде.

Менә шуннан әкренләп китте дә инде... «Иптәшләре» дә арта барды. Ул буйга озаеп китте, үзен өлгереп җиткән егет дип хис итә башлады. Туган көннәргә йөрде, армиягә иптәшләрен озатты, алар исәнлегенә эчелде. Кемнәрнеңдер иптәш малае армиядән кайтты, шатлыктан күбрәк эчеп ташлангач, эшкә бара алмый калды. Беренче мәртәбә гафу

иттеләр. Танышы, көнкүреш комбинатында эшләүче, үзеннән күпкә олы Фарук аңа:

— Борчылма, эшеңнән кусалар да зарар юк. Син яшь әле, эштә ватылырга өлгерерсең. Иптәшләрең күп синең, ярты ел, бер ел эшләмәсәң дә сиңа ярдәм кулы сузачаклар, — диде. Ашарга-эчәргә аптырау булмады. Кайчан кайтма, өстәл тулы ризык. Исерек булмаса, әнисе аның өчен җанын да кызганмады. Тик сәрхушләнеп кайткан чакларында гына усал сүзләр белән тиргәде. Чалтыратып яңагына суккалап та алгалый иде. Ә инде Коля һәр көн шулай кайта башлагач:

— Кайда эчтең, шунда кун! Моннан соң мин сиңа ишек ачмыйм, — диде.

Коля кайда эчте, шунда йоклап калды. Вокзал тирәләрендә дә кунгалады, яңа танышлар да тапты. Бер төнне алар озак кына итеп карта суктылар. Коля ун сум оттырды... Акчаны шунда ук түләргә куштылар. Коля иптәшләренең күзләренә аптырап карады.

— Мин бит юри генә уйныйбыз дип торам. Эшләмим бит, миңа акча кайдан килсен, — дип карады. Ә иптәшләре аның аркасыннан сөйделәр, чәчләреннән сыйпадылар:

— Юри-мари гына уйнарга син әллә сабыймы? Егет кеше син, әйткән сүз — аткан ук. Бүген булмаса, иртәгә түләрсең. Подумаешь, акчага аптырап торырга... Өйдә әнисенең кирәкмәгән чүп-чары бардыр әле, алып кил, бергәләшеп шудырырбыз, — диделәр.

Икенче көнне Коля тегеләргә әллә кайчаннан бирле матур тартма эчендә сакланган, алтын йөгертелгән ике чәй кашыгын алып килде. Иптәшләре аны мактадылар. Кашыклар чыннан да бик тиз шудырылды.

Көннәр уза торды. Коля, әнисе өйдән чыгып киткән саен, сервантагы, кием шкафындагы «чүп-чар»ны кыстырып үзе дә чыгып китәргә гадәтләнде. Өйдән әйберләр югалганын белгәч, әнисе зур тавыш чыгарды, кулына нәрсә туры килсә, Коляга шуны ыргытты. «Милициягә хәбәр итәм, барыгызны бергә җыйнап төрмәгә яптырам, җир бит, оятсызлар», — диде.

Коля да, иптәшләре дә бер мәлгә тынып калды: «Чыннан да, хәбәр итсә, беттек бит», диештеләр. Ләкин... Әниләр гафу итмәгән гаеп буламыни? Ничек инде ул үз улын үзе милициягә илтеп бирсен. Шуннан соң Коля өйдән әйбер урламады. Иптәшләре аны төнлә үзләре белән бергә анда сугылып, монда сугылып йөрергә өйрәттеләр. Шул чакта ул Тәлгать белән дуслашып китте... Галим белән алар кәрзин-кәрзин алма саттылар. Акчаны Тәлгать белән урталай бүлештеләр... Бусы инде урлау түгел иде, эшләп алган, көне буе базарда басып торган өчен килгән акча иде... Әнә шулай «урламый» гына яшәгән чакта менә сиңа мә: милициягә эләктеләр.

Аның уйларын бүлеп ишек звоногы чылтырады. Хат ташучы икән. Конверт эчендәге ак кәгазьгә: «Васильев Николай Вадимович, 1976 елның 22 октябрендә Вахитов районы халык судына чакырыласыз», дип язылган иде.

Коля, кәгазьне учында йомарлап, беравык басып торды да креслога барып утырды. Башын артка ташлап, тирән сулады. Йөрәге кысып-кысып авыртып куйды. Икенче бүлмәдә телефон шылтырады.

— Әйе, тыңлыйм...

Вадим Николаевич шылтырата икән.

— Коля, улым!..

Әтисе аның хәлен сорашты:

— Ашадыңмы, эчтеңме, берәр яңалык юкмы өйдә? — диде. Коля үзенең судка повестка алганын әйткәч, Вадим Николаевич бер мәл дәшми торды. Аннары: — Килергә тиеш тә иде, нишләмәк кирәк. Шу-

лай да бик борчылмыйк әле, — дип Коляны юаткандай итеп трубканы куйды.

Коля телефонга карап уйга калды... Аңа унбер яшь тулган көн иде. Өйдә телефон шылтырады. Әнисе икенче бүлмәдә кемнәр беләндер чәй эчеп утыра. Трубканы Коля алды.

— Коля, улым, — диде дулкынланган тавыш белән Вадим Николаевич.— Туган көнең белән котлыйм, Коленька!..

— Әти, әтием!..

Шул чак Коляның әнисе Лида, ефәк халат итәкләрен җилфердәтеп килде дә трубканы Коля кулыннан йолкып алды.

— Вадим Николаевич, сезгә ничә мәртәбә әйттек бит, шылтыратмагыз, баланың йөрәген бозмагыз! — диде. Трубканы элеп куйгач, Коляны җилтерәтеп диванга илтеп утыртты. — «Нинди әти ул сиңа, аның улы бар. Соңгысы булсын, «әтием» дип төчеләнәсе түгел».

Коля диванга йөзтүбән ятты да кайнар күз яшен түкте. Шулчак аның йөрәге беренче мәртәбә кысып-кысып авыртты. Шуннан соң аның йөрәге гел шулай бимазалана торган булып калды. Менә хәзер дә каты итеп чәнчеп куйды. Коля дивандагы кечкенә мендәргә башын салды.

Туй көне бишенче ноябрьга билгеләнгән иде. Бүген бере. Биш көн вакыт бик аз да, бер карасаң — озак та. Күңелләрдәге ярсуны ничек басарга да белми аптырап калды бу көннәрне Фәһимә. Я ул бишенче ноябрь көнен зарыгып, сагынып, шатланып көтте. Я коты очып, куркынып калды. Нишләргә? Беренче иренә чыкканда мондый каршылыклы хисләр кичермәгән иде бит ул. Туй күлмәген кию, бармагына беренче алтын балдак кидерү — ул чакта барысы да гади, табигый иде. Ә менә хәзер, икенче каты, уйландыра икән шул һәм өркетә дә.

Фәһимә кибеттә туй күлмәкләре сайлый. Матур эчке күлмәкләр, чигеп эшләнгән мендәр тышлары, ак һәм төрле төстәге бизәкле җәймәләр, юрган япмалары... Кулына барысын да тотып карады, тик берсен дә алмады. Ул аларны барысын да бер алган иде бит... — Юк, юк, туй күлмәкләре киеп тормаска кирәк. Алтын балдак та кирәкми. Хәтта туе да кирәкми. Кешеләр күрмәгәндә язылышып кайтырга да, туганнары белән бергәләп чәй эчәргә. Кияүдән аерылып кайткан егерме биш яшьлек тол хатынга шунысы да бик җиткән.

Ул Дамир белән никахлашкан көннәрен исенә төшерде. Алар Загска чәчәкләр белән бизәлгән дүрт «Волга» белән барганнар иде. Анналары Аккош күле буена да барып, «ура» кычкырып, шампанский бөкеләрен шартлаттылар... Парк каршындагы һәйкәл янындагы мәңгелек ут каршына басып, иң изге уйларга чумып тордылар. Ә ахыры нәрсә белән бетте? Бер уйласаң нинди кешелексезлек, ике йөзлелек. Сугышта билгесез югалган каһарманнарны хөрмәтләп искә ал да, сөйгәненне өеңә алып кайткач, исергәнче аракы эч. Ә иртәгесен «син минем белән йокладыңмы?» дип сора...

Фәһимәнең күз аллары караңгыланып китте. Каядыр тирән упкынга төшеп киткәндәй булды ул. Як-ягына каранып алды. «Раббем, танышбелешләр очрамасын тагын» диде дә кибеттән тиз генә чыгып китте. Урамда йөреп бераз тынычлангач кына өйләренә кайтты. Өстенә җиңел күлмәк кигәч, салкын су белән битен дә югач аңа хәл керде.

Аның бүлмәсенә Мөршидә керде дә, каршысына ук басып, кулындагы зур төргәкне сузды.

— Җиңги, нәрсә бу?..

— Сүт тә кара! — Үзе, Фәһимәне көтеп тә тормыйча, төргәкне чишә һәм елкылдап торган ак ефәк тукыманы Фәһимәнең иңенә салды. — Сиңа абыең белән миннән — туй күлмәге. Үз тегүчем белән сөйләштем, бүген үк килсен, бик тиз өлгертермен, диде.

Фәһимә бүләкне ике кулына алып күкрәгенә кысты.

— Нинди кешелекле син, җиңги! Җиңги җаным,— дип, Мөршидәнең ике битеннән үбеп алды. Аннары тукыманы урындык башына куеп, сокланып карап тора башлады. Кинәт аның йөзе моңсуланып китте. Боегып кына Мөршидәгә күз салып алды... Ул Мөршидәнең Зөлфәткә кияүгә чыгуына баштан бик нык каршы булып та хәзер кинәт риза булуына бераз гаҗәпләнә. Үзеннән сораргамы-юкмы дип бераз икеләнеп торды да:

— Җиңги, син минем никахка чын күңелеңнән ризамы?..

— Үзең соң, үзең чын күңелдән яратасыңмы Зөлфәтеңне? — диде Мөршидә, Фәһимәнең күзләренә туп-туры карап.

Фәһимә Мөршидәнең иңенә башын куйды.

— Бик, бик яратам җиңги, үлеп, газапланып яратам. Яхшы кеше бит, сынадым инде...

— Яхшы да булгач, яраткач та, мин каршы килә алмыйм инде, балакаем, — диде Мөршидә.

Фәһимәнең күңеле күтәрелде, кибеттә йөргәндәге икеләнүле уйлары барысы да юкка чыкты.

Ишек звоногы чылтырады. Зөлфәт килгән иде. Мөршидә аны хөрмәтләп каршы алды һәм үзе, кибеткә барып килим әле дип, чыгып китте.

Чәчләрен аркасына туздырып салган, битенә җиңел генә кершән сөрткән Фәһимә бүлмәсеннән чыкты.

— Ярый әле, килдең, үләм дип торам... — Ул шушы ике-өч сәгать эчендәниләр кичергәнен Зөлфәткә сөйләп бирде дә:

— Бәлки чыннан да икенче иргә чыкканда туй күлмәге тектереп, балдаклар сатып алуның да кирәге юктыр, — диде.

— Мин бит, Фәһимә, беренче мәртәбә өйләнәм. Һәм син дә миңа беренче тапкыр чыгасың. Мин синең элеккеңне белмим һәм аның кирәге дә юк. Син минем өчен иң саф, иң намуслы кыз. — Ул костюм кесәсеннән кечкенә генә тартма чыгарды да аннан алтын балдак алып Фәһимәнең учына салды.

Чәчәкләр белән бизәлгән ике «Волга» машинасы мәрмәр баскычлар янына килеп туктады. Ишекләр ачылды. Фәһимә ап-ак туфлилары белән яңа яуган ак карга басты. Ул, Зөлфәтнең беләгенә кулын салып, нык адымнар белән мәңгелек ут янына атлады. Машинадан төшкән милиция лейтенантлары Шәкүров, Симагин һәм тагын ике кыз алар артыннан киттеләр. Обелиск алдында кара шинельләре эченнән ап-ак кофта якалары күренеп торган, беләкләренә кызыл тасмалар бәйләгән ике кыз, ике егет басып тора иде. Фәһимә, мәңгелек ут янында уйланып басып торганнан соң, озын күлмәгенең бер читен сул кулы белән җиңелчә генә күтәрде дә кулындагы роза чәчәкләрен мәрмәр таш өстенә куйды. Сакта торган кызлар, яшьлек нуры белән тулы күзләрен аңа текәп, керфек сирпеп куйдылар. Фәһимә әйләнә-тирәгә җыйналып өлгергән кешеләргә карап алды. Барысының да күз карашлары эчкерсез, алар да Фәһимә белән Зөлфәткә бәхет телиләр иде сыман. Рәхмәт инде барыгызга да, без бәхетле булырбыз, бәлки әле без бик бәхетле булырбыз, дип елмайды Фәһимә бу минутта.

1975—1976.

Нури Арсланов

# АЛТЫН КОЯШ

## Җаекта

Җиктереп пар ат Казанга
Моннан киткән Тукай.
Ерак инде ул заманга.
Менә Җаек, тугай...

Тугайда яфрак-агачлар
Калтыраган җилгә.
Бәхилләшкән шагыйрь, яшьләр
Тамган торган җиргә...

Бу туфракта изге эзләр —
Кая гына басма.
Монда туган шигъри сүзләр
Уелганнар ташка!

Әнә, еракларда чыңлый
Кыңгыраулар тавышы:
Йөрәк дулкынланып тыңлый —
Анда шагыйрь сагышы...

Кайта канатлы яңа чор
Казанына карап:
Чаптыра атларны кучер,
Очып бара пар ат.

Каршыларга көрәш язын
Аңа яшьтән язган.
Иң мөкатдәс моңлы сазын
Көткән нурлы Казан.

Колагымда тарантас та
Тояк тавышлары —
Тирән уйлар килә башка,
Шагыйрь язмышлары:

Кавышкандай Идел, Җаек
Коеп киң диңгезгә,
Тукай рухы, колач җәеп,
Диңгез булды безгә.

Ак Җаек гел аккан кебек,
Йөзгән кебек тын Ай,
Шагыйрь җаны да мәңгелек —
Һаман юлда Тукай!

## Карт ветеран сүзләре

Кургаш булып сагыш басты җанны, —
Сыгылмадым, түздем, күтәрдем,
Күтәргәндәй Атлант бар җиһанны.
Бүлешкәнгә сагышын күпләрнең

Шатлыкларым минем күккә ашты! —
Үзем җирдә калдым... Аннары,
Хатом-Тай[1] бит күңел, гел өләште, —
Бәхет милкем була алмады.

Төрлесеннән, шөкер, күңелләр тук...
Менә утырам Идел ярында:
Шатлык та юк инде, кайгы да юк,
Хатирәләр генә янымда.

Алышынып торды манзаралар, —
Нинди генә көннәр булмады...
Без мөкиббән идек — ватандарлар,
Яңа Республика уллары.

Һәр көн туган төсле иде хикмәт:
Йөрәк дәртле булды, баш комар!
Җитмәгәндәй эчке борчу, михнәт,
Тыштан килеп сугыш ачтылар.

Ил кайгысын бөек кайгы итеп
Башын салган ата-бабамнар!
Дөрес иттем шул юл белән китеп
Мин — сагышлы, көләч ватандар.

Йөзләремне чытык итмәк булды
Язмыш, курчак ясап кулында:
Тик битләрем чокыры тулып торды
Көләчлекнең балкып нурында.

Үксүме бу — куям тирән сулап,
Нинди яшьләр икән күземдә?!.
Шатлыкларым булса булсын уртак,
Сагышларым калсын үземдә.

---

[1] Хатом-Тай — Таиландтагы Тай кабиләсеннән чыккан легендар юмарт.

Кайгыларны бүлешү нигә кирәк?
Җитәрлек бит алар кемдә дә...
Чыгалмасын, әйдә сыкрап, көйрәп
Калсын алар бу тән-төрмәдә!

Калсын алар... Мин яшәдем горур,
Чыгармадым тышка үзләрен. —
Булыйм дидем халкым шикелле зур!
Шуннан булды барлык түзгәнем.

Аттай чыдам, эттәй тугры бер зат,
Ил-оямда сакта мин торам:
Утлар-сулар кичкән чыдам солдат, —
Яшь күңелле карт бер ветеран.

## Чапай җыры

Чапай баткан җирдән туфрак алсам,
Җиңеләер микән туфрагы?
Урал суларында Чапай янган, —
Кызганмаган дошман уклары...
— Э-һе-һе-һәй!
Түзәлмыйча әрнеп бер кычкырам,
Яңгырый тын елга буйлары:
Елга өсләренә яткан томан
Уята ла хәсрәт-уйларны.

Урал суларына баткан тәне,
Бирелмәгән дошман кулына:
Яманнардан хурлатмаска аны
Дулкын алган диләр куйнына.
— Э-һе-һе-һәй!
Ераклардан кемдер оран сала,
Яңгырый киң елга буйлары.
Елга өсләрендә кояш яна,
Суларында дулкын уйнавы.

Менеп баскан Чапай биек ярга,
Каршы ала Урал таңнарын.
Хәтерлидер даулы далаларда
Туздырганын дошман яуларын.
— Э-һе-һе-һәй!
Чапай өнди әнә бәйгеләргә, —
Кылыч айкап чыга атлылар:
Шул атлылар эзе күңелләргә
Тирән эзләр булып яттылар!

## Булмаса халык

Ахак, зәмруд, алмаз, якут...
Бар да асыл таш.
Тик аларның кыйммәте юк
Булмаса кояш:

Алар караңгыда калса
Күренми күзгә,
Яктылыкта гына чагыла
Нурланып безгә.

Шагыйрьләр дә — нәкъ асыл таш.
Тик шунысы анык:
Балкымас, янмас, яктырмас —
Булмаса халык!

## Үзгәреш

Кай диңгезгә шәлен манган бу күк,
Бертуктамый сыга суларын:
Күргәнем бар иде элек тә күп
Табигатьнең болай сулавын.

Яшен дә юк, җил дә, өстән коя. —
Ак явымга баткан әйләнәм.
Тән оеган, калгый, җан — йокыда,
Аяк-кулны миңгерәү бәйләгән...

Чыдап булмас кебек бу халәткә!
Менә кинәт һава кузгалды, —
Чапты җилләр менеп зәңгәр атка:
Карап тордым болыт тузганны.

Менә дөнья гөмбәзендә янып
Озак көткән кояш күренде:
Үзгәрде рух, китте җан уянып,
Өмет, шатлык алды күңелне!

## Кояш бата да, калка да

Әллә төтен, әллә томан,
Еракта яңа офык.
Нигә бер янам, бер туңам,
Ник тетрим җаным өшеп?!.

Әллә таң, әллә кич җиткән...
Кояшның баюымы?
Сулавы ник авыр икән —
Тынның тараюымы?

Эх, бер бутап вакытларны,
Сызгырып җибәрергә!
Таралсын төнгә моңнары,
Яки таң җилләренә.

Кояш бата да калка гел,
Аның юк сызланасы.
Нигә шулай гамьсез түгел
Икән адәм баласы?!

## Безнең музыка

*Кантата*

Тыйсалар да җырлау, уйнаулардан,
Яшәдең син аулак өйләрдә,
Басуларда, тирән забойларда
Халык сагышын,
Халык моңын салып көйләргә.

Мең ел буе язык саналсаң да,
Чигенмәдең, тына белмәдең.
Юлдаш иттең авыр сынауларда,
Сердәш иттең
Тальянканың көмеш телләрен.

Инде оркестрлар тавышы чыңлый
Күкрәгендә безнең ватанның.
Тибрәлә җыр, бөтен дөнья тыңлый
Милли моңын, —
Музыкасын тыңлый татарның.

Музыканың сулышы — серле диңгез,
Йөрәкләрдән чыга ул аваз,
Музыкасыз булса тормыш көйсез,
Җырла, күңел,
Яңгыра, җыр, уйна, дәртле саз!

## Минем Кемдерем

Тыңлыйм, кемдер нидер сөйли миңа,
Аңлашылып җитми сүзләре.
Шулай да бит серле... Ахры, шуңа
Йөрәккә бик якын үзләре.

Радиоларны шунда кирегә борам,
Гәзитләрне куям бер якка:
Бушыйм дөнья ыгы-зыгысыннан,
Тик теге өн кала колакта.

Ул чакыра төсле еракларга,
Космонавтлар гизгән илләргә,
Ак болыттай ап-ак пыракларга,
Мен! дигәндәй, алтын ияргә.

Күз алдыма килә Җир-Йортымдай
Галәмдәге гаҗәп җиһаннар,
Аһ, бу хисләр, тырыш бал кортыдай,
Ни кадәрле нектар җыйганнар!

Әлеге Кемдер миңа кабатлый гел,
Тел төбендә гади фәлсәфә:
«Берәү дә бит мәңге бакый түгел,
Мәңгелеге Җирнең нәрсәгә?!».

Бер сый миңа — хәят кунагына
Гомердән бу матур көн бүген:
Пышылдыйлар өннәр колагыма,
Күңелем тыңлый үзенең Кемдерен.

## Ал син шәфәкъ болытларын

Кашың — амур җәяседәй каш икән бер,
Каушавымны сиздереп ник фаш итәмдер?
Тылсымыңнан исердем шул... әйләнде баш,
Гомерлеккә тынгы белмәс баш икән бер.

Я, акыллым, шул кадәрле әйбәт тә син!
Муеныңдагы энҗе, мәрҗән, мәрвәт тә син.
Бер карауда шулай һуштан яздырырлык
Куәт булса җирдә — ул да, әлбәттә, син.

Күз карашың серле — гүя тирән диңгез.
Керфекләрең — әйтерсең лә тылсымлы без:
Шундый рәхәт чәнчә җанны сөеп, назлап,
И бу татлы газап! — бәхет икән тиңсез.

Гел әйтәләр: «Ачның күзе — икмәктә»не,
Кабатлыйлар: «Тукның күзе — хикмәттә»не,
Тук булсам да, ач булсам да, син барында
Искә керми хикмәт сере, икмәк тәме.

Синең алда онытам бөтен барлыгымны,
Кая шуклык! Бу чакта мин зарлы-моңлы...
Фирдәүсиләр, Ширазилар үрнәгендә
Язам менә бу мәхәббәт ярлыгымны.

Бөек сәнгать — матурлыкны белү танып,
Яшәү әйбәт матурлыктан ләззәт алып.
Гаепләмә алҗыган дип мин сантыйны,
Гаҗәпләнмә торсам сиңа хәйран калып.

Өметләнеп тә кызыгып яши кеше.
Табигатьтә һәр нәрсәнең үз өлеше:
Матурлыкның — сокландыру, күзнең — карау...
Шулай булгач, я кемнең кемдә бар эше?!

Күзең — диңгез, керфегең — без, кашың — кыйгач!
Матурлыгың белән күңел күгемне ач,
Күзләремнән ал син шәфәкъ болытларын,
Ялтыра гел сокландырып, алтын кояш!

## Казагым - ай

Туфрагында бала чагым таңнары атты:
Казакъ иле үз улыдай үстерде-бакты,
Акын бала дип атады, думбра бирде...
Шуңа артык якын күрәмдер шул казакъны.

Ул иярләп бирде миңа беренче атны, —
Шул казакы[1] атта күңелем урләргә чапты,
Күтәрелде далалардан Ала-тауларга!
Шуңа хөрмәт итәмдер шул дустым казакъны.

Алматаның алмасыдай алсу яңаклы,
Көләч йөзле сылу кызлар мактала хаклы:
Татар-казакъ кушылганнан туган күбесе,
Шулай булгач ничек туган итмим казакъны?!

Казагым-ай, сиңа охшап, мин дә беркатлы.
Ашың тәмле, суың тәмле, сүзләрең татлы,
Киң даладай киң күңелле, калҗыңлы, тапкыр,
Акын җанлы... Шуңадыр үз итәм казакъны.

## Ир булсаң

Үләр чакта һәркем чынын әйтә,
Исән чакта әйт син ир булсаң,
Ишарәләр белән аңлат, әйдә,
Тавышың бетеп әгәр буылсаң.

Юкса, калыр бар да үкенечкә, —
Өлгермәссең соңгы сулышта!..
Күпме мәкер һәм сер ята эчтә, —
Гомер үтә салкын сугышта...

## Парадокс

Туган көннән алып бергә бара
Хәят белән үлем катыңда:
Хәят ишек ача киң дөньяга,
Үлем поса ишек артына...

## Белим дисәң

Дуслар хәтер саклый — яшерә синнән,
Дошман карап әйтә күзеңә:
Үз хәлеңне чынлап белим дисәң,
Колак сал син дошман сүзенә.

## Казан, Казан!

Казан, Казан! Горур манараңнан
Зур дауларга дәшкән башкалам,
Бу туфракта нигез ташын салган,
Язмышны син шуннан башлаган.

---

[1] Казакы — казакъ нәселле ат.

Казан суы ярларына яткан,
Иделләрдә үскән, тирбәлгән:
Татар синдә яңа мәкан тапкан,—
Елъязмалар ачып җибәргән.

Казан, Казан! Сагыш-моңнарыбыз,
Шатлыгыбыз сиңа бәйләнгән.
Җәйрәп ята болын-кырларыбыз...
Бабайлар йорт корган җәйләүдән
Килә җырлар, телдән-телгә күчеп,
Кайтаваздай яңгырап күңелдә,
Җырлый халкың, дәверләрне кичеп,
Үз моңында, туган телендә.

Дәүран сөргән синдә патша, ханнар,
Канлы яшькә тулган җирләрең,
Кылыч айкап йөргән күпме яулар...
Беркайчан да тик баш имәдең!
Чорлар аша безне алып чыктың,
Көрәшләргә өндәү ташладың,
Бөек Октябрьда мәйдан тоттың, —
Иркен-азат хәят башладың!

Күкрәп чәчәк атсын изге җирең,
Бәрәкәтле булсын бусагаң.
Гел яшәрә торган калам минем,
Син тылсымлы илгә охшаган!
Казан, Казан! Киләчәккә атла,
Биек тотып Ленин байрагын!
Син һәр вакыт заман белән сафта, —
Котлы булсын бөек бәйрәмең!

1976

## Фатих Хөсни

# ҖҮЛЯ-КАЙГЫЛЫ ЭТ

хикәя

I



Акмы ул, сарымы? Кәефеңнең нинди чагы туры килүгә карап, аны ак дип тә, сары дип тә кабул итәргә мөмкин. Әгәр берәр җирдә урынсыз рәнҗетеп, хаксыз сүз әйтеп кайтарсалар яки бик тә кирәк нәрсәне, дөнья бетереп эзләп тә, тапмый кайтсаң һәм шунда ул мәхлук искәртмәстән генә синең аяк арaңа килеп сарылса, ул сары, хәтта коры сары гына да түгел, пәри алыштырган шәмәхә-сары булып күренә, эченә тибеп җибәрәсе килә. Әгәр инде юлың уңай яки акча алганнан соң кәефеңне күтәреп кайткан чакка туры килсә, ул инде ак — сөттән дә аграк дип әйтмик, этне ризыктан өстен куйсак гөнаһысы булыр, һәрхәлдә, су коеныргa дип барып та, хәтта чишенеп тә: «Әттә генәсе лә! Суы бик салкын, бәладән башаяк!» дип, коенмыйча кире киенгән кешедән аграк. Аңарга җылы сүз ташлыйсың, кулың буш булса, хәтта аркасыннан бер сыпырып алуны да җәлләмисең. Ах алла, барыбыз да кешеләр лә без, төрле чагыбыз була, эткә шул бер сыпыру җитмәгәнмени!

Берәр асыл затлы, күргәзмәләрдә һөнәр күрсәтеп, күкрәгенә медаль таккан нәселле эт булса икән әле. Бернинди хуҗасы юк аның, шул ук вакытта биш катлы зур йортның ишегалдындагы барлык малайлар аңа хуҗа. Тегесе теге нәрсә алып чыгып сыйлый Җүлкәне, бусы бу нәрсә. Атланып та йөриләр, иркәлиләр дә, типкәлиләр дә. Ә ул бөтенесенә риза. Хәер, соңга таба бөтенесенә риза булмый башлады, мәсәлән, кара ипине ашамый, ак ипине дә иснәп кенә карый. Шушы хәтле зур йортка бер эт, ашатырсың ипи. Син аңа печенье бир дә шикәр шакмагы ташла. Шикәр дигәне дә рафинад булсын — авызга йомшак. Кыскасы, тәмам аристократка әйләнде эт. Дәрәҗәле

олы кешеләр аңа игътибар итми, ул дәрәҗәле кешеләргә игътибар итми. Көләбез дә, иркәлибез дә, атланып та йөрибез, тик төнне кайда үткәргәнен генә белгән кеше юк. Гомумән, йоклыймы ул, юкмы? Нинди дә булса кайгысы бармы аның, юкмы? Шушы турыда гына башыбызга килми.

Ә мин шуны беләм һәм, еллар буена күзәтә йөреп, шундый карашка килдем: Җүлянең, безнең ишегалдындагы гап-гади этнең, зур кайгысы бар. Ник дисәң, аңарга нәселен калдырырга, балаларын үстерергә, үсеп җиткән балаларын күреп сөенергә ирек бирмиләр. Әлеге шул эт белән этләшеп беткән ишегалды малайлары. Югыйсә, бичаракаем, ничәмә-ничә тапкыр йөккә калып, юанаеп һәм, уйларга кирәк, шул юаная баруы өчен эченнән куанып, балалары буласына менә-менә өметләнеп йөрде. Өметләнеп кенәме әле!

Юк, моннан соң язылачак хәл-әхвәлләргә тамчы гына да фантазия кыстырырга ярамый. Көлке кыстыру шулай ук гөнаһы булыр иде.

Кайларга гына качып балаламады бичара Җүлкә. Бер шулай кочегаркага төшү юлында караңгы баскыч астына качып балалады һәм берничә көн күзгә дә күренмәде, тамагына ризык та алмады. Малайлар, үзләре дә аптырашып, этне исеме белән чакырып, колбаса, тәлинкә белән ит шулпасы, печенье, шикәр шакмаклары тотып, эзләп йөрделәр. Эт күренмәде, ашауга караганда, аңа яңа туган, әле күзләре дә ачылыр-ачылмас балалары газизрәк иде. Ул шуларны ялап ятты, күзләре ачылганны көтәргә, ялап шомартырга, матурларга, тик шуннан соң гына тезеп алып чыгып, ишегалдын шаккатырырга уйлаган иде булса кирәк.

Тик шаккатырырсың хәзерге заман ташбашларын. Кесә фонаре яндырып, кайда тишек бар — шунда керә-керә эзләнә торгач, тәки тапканнар малайлар. Монда аларга ишек төбендәге эскәмиядә көн вә кич җыелып, узганны-барганны тикшереп, кеше гайбәте чәйнәп утыручы эшсез хатыннар да булышкан булса кирәк, Җүлянең балаларына күзләрен ачып дөньяны күрергә форсат бирмәделәр, баскыч астыннан берәм-берәм алып юкка чыгардылар. Үзләренең башы җитмәгәнне олылары өстәде: янәсе, нигә кирәк нәселсез этләр белән ишегалдын тутыру!

Шуннан соң ул хәтсез вакыт барыбызга да, шул җөмләдән ни эт җанлы кеше — миңа да үпкәләгәндәй, кыргыйланып йөрде. Малайлар биргән ризыкка якын да килми, малайларның үзләрен дә якын җибәрми, элеккечә берәрсе иркәләргә-сыпыргаларга маташса — бармагын һап! Дөрес, безнең ишегалды малайларыннан берсе дә бармаксыз калды дип әйтмәс идем мин, булмаганны булды дип әйтә торган ялганчы түгел. Мәгәр Җүлянең ишегалды малайларына җене чыгуы — факт. Ул гынамы әле! Гомумән, җене чыкты этнең — барыбызга да. Беркем кулыннан бер ризык алмый, берни ашамый — бу чаклысына үзем шаһит дип үк әйтә алмыйм, әлеге шул ишек төбе эскәмиядә кеше гайбәте чәйнәп утыручы хатыннар «информбюро»сыннан алып әйтүем. Ә ябыгуы, дүрт аякта килеш корыша баруы — анысы барыбызның да күз алдында. Тагы бер сәер гадәте өстәлде: бернинди сәбәп юкта, тора торгач үтә дә тырышып өрә-өрә чабып китеп, ишегалдын шулай бер урап уза. Бу чаклысын — ни белдекле халык! — хәтта ишек төбен саклаучы хатыннар да аңлый һәм аңлата алмыйча тәкатьсез калдылар.

Ләкин шунда да Җүля безнең ишегалдын ташламады. Балаларын югалту кайгысын әкренләп-әкренләп эченә йота барды бугай —

тамак тәмугка кертә диләр. Әтне дә кертә икән! Әкренләп-әкренләп биргән ризыкны да ашый башлады — әлбәттә, кем бирсә — шуның кулыннан алып түгел. Кайдан сизә диген, бигрәк тә көчекләренә куллары тигән малайларны якын җибәрми — ник шунда шикәр шакмагына май сылап бирмәсеннәр!

Ә гомер эт кайгысы белән түгел, кеше кайгысы белән дә исәпләшеп тормый, уза бирә, уза бирә. Көз узды, салкын кыш узды — Җүля бичаракаем ничек җан саклап калгандыр ул салкын кышны — икенче язны, бөтен табигать яңадан терелгәндә, безнең Җүлябездә үрчергә теләү инстинкты яңадан терелмәсенме. Кайда, ничек һәм кай ягы белән кызыктыргандыр, белгән кеше юк, ләкин фактны әлеге шул ташбаш малайлар күреп калган, бу юлы безнең Җүлябез «кияү»не ни җиттене түгел, асыл затлылардан берсен — шатландски овчарка дип йөртелә торганны тапкан. Әтлеккә эт тә, башы эшли, күрәсең. Теге юлы сез минем көчекләремнең башына нәселсез булганлыклары өчен җиттегез, алайса, бу юлы менә асыл затлыларны китерим әле, диде бугай. Әлбәттә, тагы юаная башлады, кыргый гадәтләрен ташлады, бер кирәксезгә ишегалды бетереп һауһаулап чапмый, булган энергиясен туачак асыл затлы көчекләре өчен саклый. Һаман да шул хәзерге заманның туганда ук җиде класс бетереп туган белдекле малайларыннан сора инде, белмәгәннәре юк, Җүлянең кайчан йөгеннән котылачагын календарьдай алдан белеп торалар, имеш. Ләкин бу юлы Җүля үзе дә ачык авыз булып калмады. Җүләрмени ул җәен-кышын асфальты өшетеп тора торган шәпшәрә баскыч астында кабат балалап торырга. Караңгылыкка караңгы да ул, теге күп белүче тиктормас малайлар караңгы дип тормадылар, җаен таптылар, бер баласыз калдырдылар бит мәхлукны. Шундый хәтәр барлыгын алдан сизенгән кебек, бу юлы эт үзе вакытында чарасын күрергә тотынды. Безнең ишегалдында ян-яннары һәм өсте каплаулы, идәнле эстрада сыман бер алачык бар. Болай үзе, әлбәттә, яхшы ният белән — яңгырда-мазарда бала-чага ышыклансынга ясалган, ләкин анда вакытсыз исереп кайтып хатыны өйгә кертмәгән исерекбашлар да, үбешергә бүтән җайлырак урын тапмаган бәхетле гашыйклар да ышыклангалыйлар. Барыбыз да күреп тордык, безнең Җүлябез бер дә бер көнне арткы яктан шул изге почмакның идән астын казырга тотынмасынмы! Әлеге шул күпне белүче аяклы «календарь»лар шундук бар тавышка ярып салдылар: бер дә тикмәгә түгел, Җүля балалау өчен үзенә урын әзерли. И тырышты да соң мәхлук җан! Ун көн буена казыды, аста җыелып калган чүп-чарны тырнаклары, борыны белән этеп тышка чыгарды, кеше-кара күзенә чалынмаска тырышып кына чүпрәк ташыды, уйлады бугай мескенкәй: дворец корыйм әле туачак балакайларыма! Бала-чага буе җитмәс җиргә.

Һәм шулай булып чыкты да. Шунда балалады. Шуннан беркая чыкмыйча атна буена балаларын саклап ятты. Бик ачыккач бугай, бик азга гына чыкты, ябыккан, кабыргалары чекерәеп калган, ә күзләре бәхет очкыннары белән тулы иде. Гүяки әйтә иде күзләре: «Минем балаларым бар. Юк инде, бу юлы сезнең буй җитә торган җирдә түгел!» Малайлар китергән ризыкларны хап-хоп ялмый торды. Ачыгуы көчле иде булса кирәк, бу юлы инде күп сайланмый, нәрсә китерсәләр — шуны уба, артканын өненә тарттыра бирде.

Малайлар төрле тәмле ризыклар белән өзлексез сыйлый торгач, гөнаһсыз мәхлук, ахрысы, артык нык ышанды бугай. Кем белгән, бәлки балалары белән мактанасы килгәндер, бер көнне ул аларны үзе белән ияртеп ишегалдына — кояш яктысына да алып чыкты. Хатыннар «информбюро»сыннан аерылып (менә, ичмасам, егетлек!),

кош тоткандай, минем хатын йөгереп менеп, бу зур вакыйганы миңа җиткерү белән, эшли торган эшемне бер якка куеп, мин дә чабып төштем. Дүртәү иде Җуляның баласы, күзләре инде ачылган, әйтеп бетергесез җете, ләкин бер нәрсәгә дә исләре китми, әниләре янында тере йон гөнҗәләләредәй тәгәрәшеп йөриләр иде.

Ләкин әниләреннән башка чыгып йөргәннәрен күрүче булмаган, моны миңа соңыннан җиткерделәр. Гөнаһсыз ана, күрәсең балаларын тумыштан ук тәүфыйклы булырга, сүз тыңларга, вакытлы-вакытсыз чыгып йөрмәскә өйрәткән. Ә аныңча, аларның идән астындагы ул нык «крепость»ларына берәүнең дә сузылып кулы җитмәячәк.

Хәлбуки, безнең ишегалдының ташбаш малайлары сузылып-нитеп тормаганнар. Җуляның «Эрмитаж» бакчасына чыгып киткәнен (гел генә идән астында ята алмас, эткә дә прогулка кирәк ич!) сагалап торганнар да, эстраданың идән тактасын каерып ачып, көчекләрне камап алганнар. Күрәсең, алдан ук сөйләшеп, нәселле көчекләргә күзләре януңы «нәни разбойниклар»ны әзерләп куйган булганнардыр. Әлеге хатыннар «информбюросы»ннан ишетеп, хатынымның миңа җиткерүенә караганда, көчекләрнең берсен-берсен бишәр сумнан сатканнар, имеш.

Җуля йөгереп кайтса — балалары юк. Бичаракаемның шуннан соңгы үрсәләнүен күрсәгез икән! Айга сикерер иде, әгәр кайсы да булса бер рәхимсезе, эт телен белеп, «балаларыңны айга алып менеп киттеләр» дип, бәхетсез мәхлукны ирештерергә җөрьәт итсә...

Эт шуннан соң бөтенләй кыргыйланды. Ишегалды малайлары кулыннан бернинди ризыкны алмый — ник шунда кекс өстенә май ягып бирмиләр. Кайдадыр чит ишегалларында, чүп әрҗәләре тирәсендә ни тапса шуны каба, тапмаса, ач йөри, ә үзебезнекеләргә җаны каткан. Арадан кем дә булса, юмаларга маташып, элеккечә сыртыннан сыпыргалый башласа, тешләрен ыржайтып ырылдарга тотына. Тешләвен тешләми, ә күзләре әйтә: юхаланмагыз минем тирәмдә, минем балаларымның башына җитүче сез бит.

Шулай да безнең ишегалдын, безнең малайларны бөтенләйгә ташлап китмәде ул. Ияләшкән җиренә этләрчә бирелгән иде булса кирәк. Шулай ук кешеләргә булган нәфрәтен дә озак саклап йөртмәде. Хәтта, киресенчә, кешеләргә тагын да ныграк иялэште — безнең йорт кешеләренә түгел, «Эрмитаж» бакчасындагы чит-ят кешеләргә. Аларның да теләсә кайсына түгел, коляскага баласын утыртып күләгәле аллеяларда тартып яки этеп йөрүче яшь аналарга иялэште. Югыйсә, чакырып та алмыйлар андыйлар, якты чырай күрсәтеп эткә бер эндәшеп куюны да кирәк санамыйлар, шулай да Җуля аларга тагылган. Башын игән, көчекләре суырудан кинәт туктагач сөт белән тулып шешенкерәгән имчәкләрен салындырган, коляска йөртүче яшь ана артыннан, ул йөргән ходка, әкрен генә йөри дә йөри... Төрлечә юрый безнең ишегалды халкы моны. Балаларын сагынудан башын кая куярга белми диләр берәүләр. Ичмасам, бер генә баласын булса да кире кайтарып, үзенә бирегез, дип малайларны битәрли икенчеләре. Кайтарырсың, көчек сатып алган акчаларын морожныйга, киного әллә кайчан очырып бетергәннәр. «Исегез китмәсен, күп тә үтмәс, тагы җыяр, тагы күбенеп йөри башлар әле менә» дип кенә җибәрәләр оятлары качкан азгын малайлар. Тагын Җуля артыннан мыштым гына күзәтү алып бара башлыйлар. Ә балаларыннан язгак ятим эт моны сизми, алай нечкәләп торырга аның вакыты юк, шулай

ук яңадан «җыярга» да вакыты юк, ул коляскадагы балаларны — кеше балаларын саклап йөреп бушый алмый.

Бала үстерү куанычыннан вак-төякне күрмәскә өйрәнгән яшь аналар да бөтенләй үк сукыраерга өлгермәгәннәр. Кәефләре күтәренке чакта, бигрәк тә бала чүпрәкләрен кайнаналары яки үз аналары юып-киптереп куярга сүз биреп, боларны тынычландырып чыгарган көннәрдә дә гел коляска артыннан, чак-чак кына ара калдырып, тагылып йөрүче сары этка күзләре төшә. Буялып-керләнеп беткән, имчәкләре капчыкланып салынган иясез сары этнең болай тагылып йөрүе, әлбәттә, искитмәле «декорация» түгел, киресенчә, күңелгә чак кына шом да сала түгел микән әле! Туктап, куып карыйлар хатыннар этне. Беравык утырып калып та тора Җүля, ләкин озак та үтми, әйләнеп карыйсың, ул тагы ияргән. Бу юлы шактый ара калдырып, ләкин ияргән, килә, башын салган, килә...

Яшь ана да, гәрчә үтә туклыктан һәм баласын яратудан дөньяның гамь-хәсрәтенә колак салмас дәрәҗәгә җиткән булса да, бөтенләй үк таш күңелгә әверелмәгән икән, борылып карап, сары этнең тагын алар артыннан ияреп килгәнлеген күрә дә, туктап, аны көтеп ала. Эт якыная төшкәч, алар бер мизгел бер-берсенә карашып торалар.

— Син, шомлык, нәрсә табарсың икән безгә шулай тагылып йөреп? — ди коляскалы яшь ана, әллә көлеп, әллә ачуланып.

Җүля аңарга бер күтәрелеп карый да күзләрен шундук аска күчерә. Шул бер карашы белән гүяки әйтә ул әлеге мәгърур анага: «Урлатмыйк балаңны, йөрсәм, мин шуны саклап йөрим. Минем дә бар иде балаларым, таш бәгырьле кешеләр урлап киттеләр әнә!»

1976

Василий Багряшевский

# ЧУАЛ

хикәя



Тегермән тирәсендә ыгы-зыгы купты.

— Буа китә! Буа китә!— дип сөрән сала, йөгерешә башладылар. Янгын каланчасында чаң суктылар.

Тыны-сөре бетеп, бүрегенең алдын артка кигән Кадыйр бабай килеп җиткәндә эшләр харап иде. Кинәт кузгалган ташу ничә еллар буе мыек очын да селкетми утырган тегермән буасы белән бөтенләй сөйләшеп тә тормаган: буаның үзәген җимереп, ялап кына алган. Кавыз дигәннәренең, ичмаса, сынык субае да калмаган.

Кадыйр бабай, халык төркемен ера-ера, яр буенарак үтте һәм, түбәнәя барган кояштан күзләрен каплый төшеп, дулап аккан инешкә карап тора башлады.

Бер агай, ярый әле, килеп җиттең, ату күрми кала идең бит, дип, картның бүреген төзәтеп киертте.

Сүзгә-сүз ялганып китте.

— Менә сиңа Чуал! Утар айгыры сыман сиздермичә ярсып кына яткан икән!

— Чиста эшли, чиста! Әнә тагы умырып алды. И... и... и... Кар шәп иде. Яңгырлатып та җибәрде. Язгы ташулар әнә шулай булсын ул. Игенкәйләр уңар...

— И Чуалкай, Чуалкай! Болай шаяра торган булсаң, бәкәлләреңә бетон богау киертергә туры килер, ахры, синең.

Бер агайның мөшкәгә салынган арышы тартылмыйча калган икән. Ул шуңа кайгыра, бүреген маңгаена ук төшереп кигән.

Кадыйр бабай карап-карап торды да агайның аркасыннан кагып куйды.

— Бәрәч, чәпер булгыры! Фәләхетдин кода, син икәнсең ләбаса... И... күзләр!.. Танымый да торам. Кил әле, кил, егетләр кулын тотып җибәр, җылынып китәрсең. Нигә шул кадәр канат-каурыйларыңны салындырдың әле? Пычагым да кайгырма, калхузыбыз исән булсын, диген. Буа китми тора димени? Яңасы булыр. Үзең дә, челем кабып, бакча киртәңә таянып кына тормассың әле. Түзә алмассың дип әйтүем. Буаны чуеннан буарбыз. Үз чуеныбыз җитмәсә, КамАЗдан сорап торырбыз. Аның кишәрлегенә кертелгән без, үзең дә беләсең анысын... Кәрепчәтке ясый торган тегермәнебез Агыйдел аръ-

ягында түгел. Бодаең бер келәт, маладис, кода! Бурсык күпере дә китеп бармасын тагы, чәпер булгыры. Тояп кит тә тарттырып та кайт. Ак калач кына ашап ятарсың, арышың җәренгә калыр дип, — кәлә-кәлә, кодасының бүреген кыйшайтып куйды. Кодасының да йөзе ачылып китте. Ул, авызын ерып:

— И Кадыйр кода, Кадыйр кода! Җен кебек икәнсең әле син!..— дип, кыз ярәшергә барасы егеттәй хәтәр итеп, бүреген кыңгыр салды.

Язгы ташу эшләре бераз җиңеләю белән махсус бригада төзеделәр. Боегып калган буа тирәсендә бульдозер, балта, пычкы тавышлары яңгырый башлады. Баганасы, тактасы, цементы, гудроны — барысы да кайтарылган. Ком, балчык, чакма ташы кебек «җәүһәрләр»нең чуты-кыры юк. Мохтаҗлыгы чыккан кеше була калса, пажалысты, рәхим итсен.

Көн кояшлы, тымызык. Тегермән өе янындагы шомыртлар туй күлмәге кигән. Ә ул һавасын әйтерең бармы.. Бер ара табып, шешәләргә тутырып каласы иде.

Яр астындагы чишмә буена казан асканнар, учак ягып җибәргәннәр. Аксыл төтен үзән буйлап ерак-еракларга сузыла.

Субай сугарга әзерлек бара. Субайлары субай гынамы — уникешәр метрлы. Чокырын бораулап, субаен сугып куя торган «махина» кайтмаса да, көймәләре комга терәлеп калачак түгел. «Әбекә»ләренә күз салсагыз, үзегез барын да аңларсыз. «Әбекә»не, мичкә юанлыгы имән түмәреннән ясап, тимер кыршау белән буып алганнар. «Әбекә» дисәң дә «әбекә»! Дүрт егет көчкә күтәрә. Шулай итмичә ни... машина кадәр машинаны алмаштырасы бит ул.

«Әбекә» субай башына ничә ат көче белән китереп сугасыдыр, әлегә анысын белүче юк. Акчасы күчерелгән булса да, электронисәпләү машиналары кайтып җитмәгән. Шуңа күрә бу четерекле эшкә егетләр үзләре ясканып тора. Исәп-хисапта ялгышмаячакларына иманнары камил. Барысы да диярлек читтән торып укый. Кайсылары йөз илле, кайсылары өч йөз илле чакрымнан. Җитмәсә, барысы да байлар: кесә саен икешәр, өчәр автокаләм. Яза торганнары да булмый калмас. Берәр вакыт, тәмәке намазы укып алган арада, үлән өстенә авып, исәп-хисапны «ишекле-түрле йөртеп» алырлар әле.

Чү, дилбегәне тарта төшик булмаса... Сүз бозау имезә, артка таяк тигезә, дигән әйтем дә бар бит әле. Сүзгә мавыгып, иң кызыгын күрми калмыйк тагы.

Әнә, шау-гөр килә торгач, беренче субайны тиешле ноктасына кадап та куйдылар. Тәрәү, трослар белән ныгытып, күперчегән менгерделәр, басма салдылар. «Әбекә»ләре, акыл утырткан «карчык» булса да, тач тискәре икән, карышып маташты. Буа алдында муен тиңентен су ера-ера ярсып-кызышып беткән егетләр, дәррәү тотынгач, «әбекә» субай башына, иң югарыга менеп кунаклаганын сизми дә калды.

Күрәсезме әнә, кулына балтасын тотып, яр өстендә бер абзыкай елмаеп тора. Изүе ачык, җиңнәре сызганулы, башында СМУ прораблары гына кия торган шакмаклы картуз. Буа киткән көнне мөшкәдәге арышы тартылмыйча калган Фәләхетдин кодабыз түгелме соң бу?

Фәләхетдин абзый әнә шул хәлдән соң уйга тарып, Чуал инешенә үпкә тотып йөрде. Үзебездә тартылган оннан пешерелгән икмәк бик тә тәмле, бик тә туклыклы була, дип башка тегермәнгә бармады. Һәм, быел пенсиягә чыккан булуына да карамастан, тәпиләрем талмас, кулларым калмас, дип, тегермәнне аякка бастырырга карар итте. Идарә агайлары, аның бу изге теләген белеп алгач, болдыр баскычына чыгып, «ура»! кычкырдылар. Кычкырырсың да шул... Фәләхетдин абзый кебек осталар Чуал урамында да, Ашыт тыкрыгында

да аунап ятмый. Өч көн дә үтмәгәндер, абзыйны, кем әйтмешли, тегермән һәм су хуҗалыгы буенча шеф-мастер итеп билгеләп тә куйдылар.

Планнар чия суы белән генә түгел, алтын суы белән язылган, әкияттәге кебек бик тә мавыктырырлык, бик тә кызыктырырлык итеп төзелгән иде. Буа бөтенләй бетон белән йөзләнәчәк, тимер-бетоннан коелачак, арык капкачлары электр чыгырлары ярдәмендә ачылачак-ябылачак икән. Кыска гына итеп әйткәндә, тегерменгә Чуал инеше, Чуал авылы тарихында күрелмәгән автоматика керәчәк; тегерменче агай, кырын ятып, концерт баянындагы кебек якут төймәләргә баскалап кына куячак, имеш. Әнә шул хакта ишетеп алгач, абзый егерме яшькә яшәреп китте: сызлап торган аркасы сихәтләнеп, егетләрчә атлап йөри башлады.

Әллә ничә кавыз тактасын, әллә ничә алтагачны яндырып, чайкый-чайкый көлен эчкән кеше, үз бакчасы артында гына шундый әкәмәт корылма корылганда, комнан бау ишеп ята аламы соң?

Бераз «төшереп» алган чакларында да, ул: «Мин — борыс остазы, мин — тегермән остазы»,— дип, күкрәк кагып йөрми. «Үрнәк» колхозының үрнәкле кешесе. Балта тотса — балта, тимер тотса — тимер, электр тотса — электр эшен белә. Иллә мәгәр, автоматлаштыру хакында сүз кузгалган чакта ул телсез кала. Калыр да шул. Әле аның ул әкәмәт приборларны яндырып, көлен эчеп караганы юк, телевизор көзгесендә генә күргәләп тора. Тормыш югары таләпләр куя икән, куя бирсен. Кеше канатлы булырга, һаман югарыга омтылырга тиеш лабаса. Генерал булырга теләмәгән солдат — солдатмыни ул. Теләк кенә булсын, барысына да өйрәнер. Өйрәнеп җитә алмаса да, аптырап калырга уйламый. Чуалда торса да китап, ятса да китап кимерә-кимерә җенләнеп беткән егет-җилән — карават саен. Попларныкыдай озын чәчне, көнҗәлә итеп кабага бәйләрлек сакалмыекны бер дә юкка гына йөртми торганнардыр. Берәр хикмәте бардыр. Бөтен сүзләре кибернетика, электроника, автоматика, космонавтика, астронавтика, галактика. Тирә-ягыңны шундый укымышлы акыл таулары урап алгач, булдыра алмам дип шикләнергә, иске чикмән бөркәнергә урын каламыни?

Булгач булсын, абзыйның йорт-җиренә дә күз төшереп узыйк. Иренмәсә дә иренми икән кеше! Пычкы, уймыр белән чигү чигә икән. Әнә капка түбәсендә калай әтәч канат кага. Капкасында, тәрәзә нәришникләрендә күперенке итеп эшләнгән җем-җем арыш башаклары, имән яфраклары, аю башлары, кар бөртекләре... Үткән-сүткәндә бу бизәкләр: «Хуҗабыз — матурлык алласы»,— дип кычкырып тора.

Өй эче — оҗмах эче. Пыяла ишекләр, зур тәрәзәләр. Ак стеналарда — миләш яфраклары. Җайдаклы көзге, күкеле сәгать...

Бер көнне Фәләхетдин абзый кичегебрәк тә кайтты. Көн буе имән каезлап талчыкса да, күңеле күтәренке, кәефе шәп иде. Табын янына утыргач ул:

— Дүрт класс та бер коридор... Ул багаж белән айга сикерә алмам. Их, карчык, егет чакларым хәзерге заманга туры килгән булса... Фән-техника заманына, дип әйтүем. Любой комнан — тимер, тимердән — бакыр, бакырдан — көмеш, көмештән — алтын коеп утыра торган тегермән ясаган булыр идем. Бер хикмәти хода чыгарыр ием тульке. Кояштыр менә,— дип шаяртып алды.

Карчыгы көлә-көлә авызын каплап:

— Болай да сине «прафисер» иттеләр түгелме соң инде? Шунысына шөкер әйт. Әнә, суына күрмәсен, яраткан ашыңны — борчак эштие пешердем, телеңне йота күрмә,— дип, коштабакны картының алдынарак этә төште.

Абзый күзен кыскалап:

— Ә беләсеңме, ул вакытта абзаң — академик, герой труда... Ә син академик җәмәгате булсаң да ни туда, ни сюда,— дип келә-келә, кашыгын кулына алды.

...Фәләхетдин абзый, балтасын сул кулына күчереп, уң кулын югары күтәрде дә кинәт төшерде. Күперчек өстендә шуны гына көтеп торган егетләр:

— Раз, два — взяли, еще раз взяли! — дип кычкыра-кычкыра «әбекә»ләрен бер күтәрә, бер төшерә субай сугарга тотындылар. Субай ташлыкка туры килгән иде. Ташлык үз позициясен тиз генә бирергә теләмәде. Әмма егетләр беләкле, «әбекә»ләре саллы иде. Ничә тапкыр сукканнардыр, санап тормадылар, субай тиздән үз гәүдәсен үзе тотарлык хәлгә килде.

Җир үкертеп «Беларусь» килеп туктады. Бигрәк тә тернәкле алаша инде. Тауны — тау дип, чокырны — чокыр дип, сазны — саз дип тә белми. Барасы базарына бара, кайтасы кайтармасыннан кайта. Кирәк-яракны ташып кына тора.

Фәләхетдин абзый балтасын бүрәнәгә чабып куйды да, югарыга карап, картузын болгап алды.

— Маладис, егетләр! Эчкә җылы керде болай булгач. Башланган эш — беткән эш. Төшегез, перекур ясыйк!

Фәләхетдин абзабызның речь тотасы бар икән. Ул такта өеме өстенә менеп басты. Картузын кулына тотты. Такыр башын сыйпаштырып алды да, кулларын болгый-болгый, сөйләп тә китте.

— Иптәшләр! Митинговать итеп алабыз. Беренче субайны аякка бастыру шатлыгы белән барыгызны да котлыйм һәм тәбрик итәм! Безнең кебек ике аяклы, ике куллы кешеләр КамАЗ төзи, БАМ төзи. Шулай түгелме, оланнар? Безнең буабыз, ул гигантлар белән тиңләшә алмаса да, чарауна, коммунизм корылмасы. Ул безнең көннәрдә генә түгел, ике меңенче ел ызанын үтеп, яңа гасырда да гөрләп утырасы корылма. Агай-эне егерме беренче гасырда да кәнфит кенә суырып йөрмәс, ипиен-коймагын пешерер, бәлешен салыр. Партоешмабыз, калхузыбыз менә шушы бик тә җаваплы эшне безгә ышанып тапшырды. Белеп торасыз, яңа бишьеллык — сыйфат бишьеллыгы. Димәк ки, Әхмәтҗаннан киткәнче, Мөхәммәтҗанга җиткәнче дип эшләү ярамый. Димәк ки, тегермән буабыз Зәйнски платинәсеннән ким булмаска, наять булырга тиеш. Оланнар, әйтәсе килгәнем шул: авыр хезмәтен кеше элек тә җыр белән җиңеләйткән. Хезмәт җыр тудырган, җыр хезмәтнең канатына әйләнгән. Хәзер дә шулай. Җыр — беләктән көчлерәк. Түгәнәйне җырлап савалар. Агачны, тимерне җыр төйи. Космоста да җырлап очалар.

Һәм ул башын сыпыра-сыпыра көйләп үк җибәрде:

— Илкәй белә, илкәй ишетеп тора...

Аннары, тәмәке янчыгы белән авызын сөртеп алды да:

— Оланнар, без дә җырлап кына эшлик! Эшебез тәгәрәп кенә барыр, алла боерса. Вче... Калганын яшьләр әйтер,— дип сүзен бетерде.

«Ура!» кычкырмасалар да кулларын җәлләп чапмадылар.

— Я, тагы кайсыгыз?

Барысы да аңлашылган иде: «сайрарга» теләүче башка кеше табылмады. Шуның белән митингка нокта куйдылар. Шулай да егетләрнең кайберләре тәэсирләрен уртаклашмыйча түзә алмады.

— Әйттеме кирәген?!

— Өздереп кенә салды!

— Политрук булып служить иткәндер бу...

— Комиссар бу, чын комиссар!
— Шулай булмаса «профессор» итеп куяр идекмени?
Абзабыз елмая-көлә урынына төшеп утырды, челемен кагарга кереште.
Салкын әйрән күтәреп, тегермәнче агай килеп җитте. Чиләген такта башына утыртып куйды.
— Братва, «кымыз» белән сыйлыйм әле үзегезне!
Кояш күтәрелгән, көн җылы, тамаклар янган иде. Бакрач кулдан кулга күчеп йөрде. «Кымыз»ны рәхмәтләр әйтә-әйтә яратып эчтеләр. Су буенда кибегеп утырып булмый бит инде. Бер чиләкне ялтыратуга, икенчесе килеп утырды.
Тегермәнче кыстый торды.
— Эчегез, эч! Алла боерса, кичкә кырын теге нәмәстәкәй дә булыр.
Өлкәнрәк бер агай аңа бармак янап куйды.
— Син теге... Әллә безне кода булып килгәннәр дип беләсеңме? Ул нәмәстәгә каршы рукапашный барганны күреп торасың. Ходайга шөкер, әртилебез ышанычлы...— Агай, кулларын угалый-угалый, сүзен икенчегә борды.— Мин, мукамол иптәш, арт капкаңны кагарга чамалыйм. Әвәлге картлар кымыз артыннан табынга симез җылкы ите куя торганнарые. Күңелләрне шулай күрсәгез, синең субайларың белән озак чикитсы итеп тормас идек,— дип шаяртып алды.
— Ник, кордаш, анысы да бар, ник булмасын,— диде тегермәнче.— Дәүләтебез иркен, бәрәкәтебез киң. Әллә син безне... Теге түбән карап, мырык-мырык килеп йөри торган карт «алаша»бызны суйдык. Тач май. Ризыкка язсын. Казанда мыркылдый да башлагандыр инде,— дип, ялкынланып янган учакка таба күрсәтте.
Анысын аның бульдозерчы ударникка дип кенә салганнардыр. Ул да җирне борыны белән казый ич.
— Мин казымыйм, тавариш, сөзәм. Минем өчен булса, тәкә башы кайнатырлар иде.
— Фәләхетдин абзый, ишетәсеңме?
— Колагыма чүбек тутырмаган ла... Ничава. Терпим. Солдат кеше. Бер татаринга рус-керәшен оҗмахында да урын табылыр әле. Челем тарта-тарта почмакта булса да торырмын... Сул як кабыргасын миңа таба шудырып җибәрерсез...
Су буйларын яңгыратып көлешә-көлешә, үз урыннарына таралдылар.
Фәләхетдин абзыйларын әйтәм, аңласа да аңлар икән җыр кодрәтен! Колхоз хорында катнашучы ир-атның яртысын үз бригадасына җыйган. Опера артистлары диярсең. Җырлап сөйләшәләр. Җырлап эшлиләр. Хәтта балта, пычкыны да җыр белән генә сорап алалар.
Аларның дәртле җырлары әллә кайларга яңгырап тора.
...Булачак икән быел каз өмәләре! Йөрергә генә ирекмә. Әнә тыкрык тулып казлар көтүе төшеп килә. Бәбкәләре каз кадәр була язган. Казлар артыннан Кадыйр бабай тыраклый. Озынча битле, ап-ак сакаллы, өрлектәй таза карт. Аякларында койган кәлүш, башында салам эшләпә. Кулында озын саплы пумала.
Ул, пумаласын болгый-болгый:
— Көш, көш көшкәйләр!— дип куа-куа инешкә казлар төшерә.
Бәбкәләр үзара сөйләшәләр дә сөйләшәләр:
— Пи... пи... Ипи... ипи... пи... пи...— диләр.
Бабай:
— Бирмәм ипи, бирмәм ипи!— дип тамак кыра. Бирмәс тә шул. Тегермән эшләми. Тарткан оны бетеп килә.

Бабай, казларын инешкә куып төшерде дә, үзе яр башына, бәбкә үләне өстенә утырып калды.

Бу — бәбкә саклап утыру түгел. Бәбкәләре, үзе әйтмешли, инде кеше булган. Бу — яшел үләннәргә, челтерәп аккан суларга карый-карый, татлы хыялларга чумган хәлдә, изрәп, оеп алу.

Җылы, рәхәт. Черкиләр тешләми.

Утыра торгач, бабайның колагына җыр тавышы ишетелеп киткәндәй булды. Ул торып басты, эшләпәсен салып кулына тотты. Башын әле бер, әле икенче якка бора-бора, тыңларга тотынды. Җыр тавышы бабайны әйтерсең лә яшьлегенә кайтарды. Бөтен фронтка даны таралган атаклы снайпер иде ул. Фашист башындагы «битюкне» чакрым ярымнан әйләндереп кенә сала торган чаклары бар иде аның. Энә шул арслан йөрәкле, бөркет күзле вакытлары исенә төшеп, Кадыйр бабай тирән уйга чумды.

— Әйттерәләрме? — диде ул аннары үз-үзенә. — Сабан туена баралар дисәң, сабан туе ясарга иртәрәк әле. Хы... Кода озаталар дияр идең, чәчү бетмәс борын кем туй үткәреп ятсын. Хы... Менә сиңа табышмак! Кайсылары шулай эш вакытында көпә-көндез авыз җәеп җырлап йөрер икән?! — Ләкин ул ни тырышса да су буендагы талтирәкләрдән башка бернәрсә дә күрә алмады. Ни әйтсәң дә уен эш түгел: сиксәнгә якынлашып килә бит.

Кадыйр бабай чигәсен кашып торды. Баскан җирендә беравык таптангалап алды, һәм кинәт, эчен тотып, көлеп җибәрде:

— Ә... ә... ә... Алай икән, болай икән, самавыры калай икән, — дип, сөйләнә-сөйләнә, эшләпәсен пумала башына элеп куйды һәм кинәт кабынып киткән татлы тойгылар дулкынында тирбәлгән хәлдә, көр тавыш белән сүзен дәвам итте. И... чәпер булгыры... Тавык мие эчкән нәмәстә! Ике сугыш кичердем. Ике тапкыр яраландым, Ике «Знамя», ике «Звезда», унике медаль алдым. Чут-чут кенә «Герой Советского Союза» булмадым. Чуал буена дан-дәрәҗә знакларым тагылган гимначтюркамны киеп төшәсем калган икән. Хәзер казлар куып йөргәч тә... Командущийлар белән кул кысышып йөргән чакларым бар ие. Вәт син! Вәт син! Снайпер башым белән исәп ала алмыйча торам икән ләбаса... Эт өрдерер, кеше көлдерер өчен җырлап йөргәннәр ие ди. Кабан ягыннан никрутлар китә торгандыр, никрутлар! И гомерләр! Үткәнен күрми дә каласың икән. Безнең дә шулай, чыбык арбаларга утырып, картузларны кыңгыр салып, тальян көйләренә җырлый-җырлый киткән чакларыбыз бар ые. Җанашларыбыз ауный-тәгәри җылап кала торганнар ые. Энә бүген — алар никрут. Хушыгыз, балакайларым, хушыгыз! Дөньялар имин булсын! Туган илебезгә безнең кебек әтличник хезмәт итеп, исән-сау әйләнеп кайтыгыз! Сезне табыннарга ипекай-тоз, каклаган казлар куеп каршы алырбыз!

Ләкин бабай ялгышты. Армиягә китүчеләр җыры түгел иде ул.

Тал-тирәкләр артыннан субай сугучыларның дәртле җырлары яңгырап тора, алар җырлап эшли иде.

------------

## Кронид Обойщиков,

Кубань шагыйре

### Татарстанга хат

Мин белмим ул төнне әнием төшенә
Нәрсәләр кергәнен һәм ничек кергәнен.
Бәлки ул күргәндер аяз таң яктысын,
Киң күктә күңелле яктылык балкышын,
Ә җирдә сукмаклар сузылып ятканын,
Башкае яуларда исән һәм сау калган
Улының куанып өенә кайтканын.

Ышанам, куаныч күргәндер әнием —
Тик шуны төшенә һәм аңлый алдым мин:
Үлемнән ычкындым — бер җитез самолет
Коткарды һавада! һәм исән калдым мин.

Мин инде бишенче һөҗүмгә ташлангач,
Соңгы сүз әйтәсе соңгы җыр башлангач
Яклады ул мине дәһшәтле ут белән —
«Мессер»ны [1] һавада юк итте, үтерде,
һәм шулай ул мине үлемнән аралап
Җиңүгә юл ярды, җиңүгә китерде.

Соңыннан белдем мин ул кыю пилотның
Казаннан бер татар егете икәнен,
Хәсәнме, Мәхмүтме — исемен белмәдем,
Тик күрдем «Мессер»ны аның көл иткәнен.

Күпме ел эзләдем — адресын табалмыйм,
һәм менә хат язам хөрмәтле Казанга —
Билгесез якыным — җан дустым исменә.
Бәлки ул татарча басылыр... Укыр да,
Бәлки шул җан дустым төшерер исенә:

... Юлларда дөберди танклар. Клейст һөҗүме.
Бу — Хорол тирәсе, бу — Киев янында.
Кырларда игеннәр таптала, җан яна, йөрәкләр...
Ә безнең полклар тәнен дә, җанын да

Кызганмый сугыша. Чөнки без камалган,
Коткарса бары тик батырлык коткара,

[1] Мессершмитт — гитлерчыларның иң көчле һәм җитез самолеты.

Я яшәү, я үлем — икенең тик берсе.
Йөрәктә үч дөрли, күкрәкләр ут яра.

Яралы сентябрь. Числоның унөче.
Таң алды. Без исә өч очкыч «җиктек тә»
Киң күккә атылдык — һөҗүмгә ташландык.
Карасак, ис китте танклар күплеккә.

Һәммәсе ут сибә — хәтта күз ачкысыз.
Безнең дә бомбалар түбәнгә очалар,
Пулялар яңгыры кабына биектә.
Кысыла кулларда гашетка тимере,
Дошманны тиргибез «анаңны!..» диеп тә.

Зенитка төтене күзләрне әчетә,
Һәм дәшми микрофон — ишетер-тоярга
Чара юк. Ә җирдән күзәткән комиссар
Бу эшкә иң биек бәяне куярга

Тырышкан, әлбәттә... Әмма эш бозылды...
Мәтәлде түбәнгә Реваз дус очкычы.
Караңгы ут сарды әйләнә-тирәсен —
Тик күрдек Көнбатыш тарафка очканын.
(Танклар шартлатмак булгандыр, күрәсең.)

Кычкырды тик бер сүз: «Хушыгыз, егетләр...
Әйтегез!..» диде ул. Ә нәрсә әйтергә?
Әлбәттә, теләгән Горида әнкәсе,
Биредә Нинасы янына кайтырга.

Без тагын танклар ягына борылдык,
Эшебез — күк утын җиргә мул сибәргә!
Кирәк бит Реваз дус үчен дә алырга,
Ярату белдереп ул сөйгән чибәргә.

Туктаусыз тәкелди ике зур утатар,
Көпшәләр кызалар үч-нәфрәт яудырып,
Һәм тагын бер бәла: мәтәлде икенче
Самолет... Һөҗүмдә тик безне калдырып.

... Бары тик таранга ташланыр чара бар —
Елмаеп өзәргә яшәүдән өметне...
Шул чакны «Тилгәнен» [1] ярсулы чыжлатып
Күренде һавада ул — татар егете.

Һөҗүмгә ташланды яшендәй атылып,
«Мессер»лар юк булды — эзләре суынды.
... Горурлан син, Идел, шул улың белән дә,
Табарга булыш син, Казан, шул улыңны!

Тоташтыр — кайчандыр бик кайнар күкләрдә
Өзелгән җепләрне ялга син:
Һәм күрсәт, һәм укыт, һәм аңлат күпләргә,
И Казан, бу хатны кулыңа алгач син!

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе

---

[1] Дошман самолетларына һөҗүм итүче самолет-истребитель

**Рәшит Мусин,**
КПССның Казан шәһәр комитеты
беренче секретаре

# КИЛӘЧӘККӘ АТЛЫЙ КАЗАН



Казанның күп гасырлык тарихы халкыбыз башыннан узган революцион, сугышчан һәм мәдәни вакыйгаларга, халкыбыз кодрәте белән тудырылган матди һәм рухи казанышларга бик бай.

Җиде гасырлык гомерендә нинди генә көрәшләрдә чыныкмаган Казанда XIX йөзнең 80 нче елларында социал-демократик хәрәкәт үсә башлый һәм беренче марксистик түгәрәкләр һәм төркемнәр барлыкка килә. Аларны оештыруда беренче рус марксистларыннан берсе Н. Е. Федосеев турында В. И. Ленин: «...шул заман публикасы, марксизмга таба борылыш ясаганда, гадәттән тыш талантлы һәм үз эшенә гадәттән тыш бирелгән бу революционерның йогынтысын үзендә, һичшиксез, бик һәм бик күп сынады» (В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә, 33 том, 438 бит.)

Н. Е. Федосеев кулыннан революцион көрәш байрагын Казанның икенче мәңгелек гражданины даһи Ленин алып калды. Бөтен дөнья хезмәт иясе халкының остазы һәм юлбашчысы Владимир Ильич Ленинның титаник эшчәнлеге тулы көченә безнең шәһәрдә башлануы белән Идел буеның бар халыклары, казанлылар исә аеруча, горурланалар.

Казанда Ильичның көрәштәшләре — Я. М. Свердлов, С. М. Киров һәм башкалар революцион эш алып бардылар. Казан партия комитетын төрле вакытларда Н. Э. Бауман, Н. А. Семашко, П. А. Саммер, А. М. Стопани, В. А. Тихомирнов, В. В. Адоратский, Н. Е. Вилонов кебек күренекле революционерлар җитәкләде. Биредә татар халкының Хөсәен Ямашев, Камил Якубов, Мулланур Вахитов кебек атаклы уллары революцион массаларның талантлы җитәкчеләре булып җитлектеләр һәм эш күрсәттеләр.

Казан хезмәт ияләре 1905 елгы революциядә зур оешканлык белән каһарманнарча катнаштылар. Ике көн дәвамында — 19 һәм 20 октябрьда — шәһәргә большевиклар тарафыннан оештырылган, асылда революцион власть вәкаләтләрен үтәгән Шәһәр коммунасы җитәкчелегендәге баш күтәргән халык идарә итте.

1917 елда, Петроградтагы революция эзенә басып ук, шәһәрдә коралды восстание җиңде. Һәм 8 ноябрьда Казан Кремле өстендә Кызыл байрак җилфердәде. Җиде гасыр ярым тарихы булган чал шәһәргә беренче мәртәбә большевиклар җитәкчелегендәге хезмәт иясе халык хуҗа булды. Бөтен губернаның барлык шәһәрләрендә һәм өязләрендә совет властен урнаштыру Казан большевиклары, эшчеләре ярдәмендә барды.

Гражданнар сугышы елларында Казан — кулдан-кулга күчкән шәһәр. Аның өчен сугышларда ил язмышы, революция казанышлары язмышы хәл ителгән көннәрдә фронтка ут эченә Казан партия оешмасы үзенең һәр йөз кешесенең җитмешен җибәрде. Шушы изге көрәшләрдә һәлак булган каһарман уллары: Мулланур Вахитов, Яков Шейнкман, Ян Юдин, Камил Якубов, Мартын Межлаук, Абрам Комлев һәм башка бик күпләрнең истәлеген Татарстан халкы, аеруча казанлылар, йөрәкләре түрендә саклыйлар.

1920 елның маеннан бирле Казан — В. И. Ленин тырышлыгы белән төзелгән Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы башкаласы.

Совет власте елларында партиянең ленинчыл милли политиканы тормышка ашыруы, совет халыкларының туганнарча хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә өч орденлы Татарстанның башкаласы Казан илебезнең иң эре экономик, мәдәни һәм гыйльми үзәкләренең берсенә әверелде. Шул арада шәһәрнең халык саны алты мәртәбә диярлек артты һәм миллионга тула язды. Хәзерге Казанда дистәләрчә милләт вәкилләре яши. Әгәр төп халык — татарлар революциягә кадәр нибары 13 процент тәшкил итсә, хәзер аларның өлеше 36 процентка җитте. Социалистик Ватан хакына уртак хезмәттә үз тормышларын марксизм-ленинизм тәгълиматы нигезендә коручы барлык милләтләрнең дуслыгы ныгый бара. Алар барысы да — бөтен матди һәм рухи байлыкларны тудыручылар — шәһәрнең иң зур байлыгы, даны һәм горурлыгы.

Хәзер Казан хезмәт коллективлары, партия оешмалары җитәкчелегендә, КПССның тарихи XXV съезды карарларын тормышка ашыру өчен тырышып эшлиләр. Тугызынчы бишьеллыкта шәһәрдә промышленностьның җитештерү күләме бер ярым мәртәбә артык булды. Планнан тыш чыгарылган продукция 300 миллион сумнан күбрәк тәшкил итте. Предприятиеләрдә продукциянең 2380 яңа төре үзләштерелде

Партия съезды карарларын үтәү өчен социалистик ярышта алдынгылар сафында С. П. Горбунов исемендәге авиация заводы бара. Бу предприятие — казанлыларның горурлыгы. Самолетлар җитештерү буенча хөкүмәт йөкләмәләрен җиренә җиткереп үтәп килгәне өчен ул ике тапкыр Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

Сугыш елларында завод фронтны сугышчан машиналар белән тәэмин итте, бүгенге көндә ул реактив самолетлар, шул исәптән бөтен дөньяга билгеле ИЛ-62 лайнерлары чыгара.

Яки, мәсәлән, «Теплоконтроль» заводын алыйк. 1952 елда сафка басканнан бирле продукция чыгару бирелдә 45 мәртәбә күбәйде. Соңгы елларда гына предприятиенең 64 типтагы әйберенә дәүләт Сыйфат билгесе бирелде. Бу коллектив 1965 елдан бирле үз тармагы предприятиеләренең бөтенсоюз социалистик ярышында җиңүче булып килә. Завод үзе Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы, тугызынчы бишьеллыкта прибор төзүчеләрдән 150 кеше хөкүмәт бүләкләренә, ә слесарь-лекальщик Наил Гыйләҗев Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды.

«Органик синтез» берләшмәсенең дә даны Казаннан еракларга билгеле. Җитештерү күләме узган бишьеллыкта гына 75 процентка артты һәм 1975 елда 166 миллион сум тәшкил итте. Заводның 120 мең тонна куәтле өченче чираты сафка басты һәм ул бар көченә җигелгәч бездә 1975 елда бөтен илдә җитештерелгән кадәр полиэтилен алып булачак. Завод байрагында илебезнең Октябрь Революциясе ордены балкый.

Резина-техник җиһазлар заводы беренче продукциясен 1942 елда фронт өчен җитештергән иде. Ә менә соңгы биш елда ул чыгарган резин җиңсәләр белән Җир шарын ике-өч мәртәбә урап булыр иде! Бу коллективның хезмәт җимешләре СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәләреннән төшеп тормый, ә 28 төр җиһазы 35 илдә күрсәтелә. Бөтенсоюз социалистик ярышында завод 19 квартал рәттән җиңүчеләр сафында булды.

Казан предприятиеләреннән С. М. Киров исемендәге синтетик каучук, В. В. Куйбышев исемендәге химия, «Урак һәм чүкеч» заводлары, В. И. Ленин исемендәге җитен, М. Вахитов исемендәге химия комбинатлары һәм башкаларның хезмәте мактаулы, даны шаулы.

Ә эшләре җырларга күчкән мехчыларыбыз? Хөсәен Ямашев исемендәге мех җитештерү берләшмәсе — беренче бишьеллыклар баласы. Аның биналары иске Казанның кырыенда, борын-борыннан килгән пычрак, саз һәм тузан эчендә калыкты. Хәтерлисезме, шул урыннар хакында Максим Горький: «Яңгырлы көннәрдә шәһәр үзенең бөтен пычрагын бирегә агыза», дип язган иде. Хәзер монда шәһәребезнең эре һәм төзек районнарыннан берсе калкып чыкты.

Мех берләшмәсенең илебездә үз ишләре арасында беренчеләр рәтеннән төшкәне юк. Аның продукциясе Париж, Брюссель, Лейпциг, Монреаль һәм дөньяның башка шәһәрләре күргәзмәләрендә һәм ярминкәләрендә мактала. Чехословакия, Венгрия һәм ГДР мехчылары безнекеләрдән өйрәнәләр. Ә монгол дуслар, бирәдә практика үтеп кайтып, үз илләрендә беренче мех фабрикасы ачтылар.

Бар тавыштан әйтергә мөмкин: шәһәребездә хуҗалык төзелешенең эре һәм катлаулы бурычларын хәл итәргә мөмкинлек бирүче промышленность куәте булдырылды. Өстәвенә, аларга ярдәмгә килерлек фәнни-тикшеренү институтының саны илледән артык, проект һәм конструкторлык оешмалары күпме! Аларның промышленностьтагы новаторлар белән иҗади хезмәттәшлеге соңгы бишьеллыкта гына 660 миллион файда китерде.

Предприятиеләрдә продукциянең сыйфатын яхшырту буенча күп эшләнә. Хәзер 470 әйбер дәүләт Сыйфат билгесе белән чыгарыла. Бу исә 1970 елдагыдан ун мәртәбә күбрәк. Дөнья базарында дәрәҗәле продукция төрләре арта бара. Казан җитештергән товарның 82 илгә озатылуы шул хакта сөйли түгелме? Соңгы елларда гына безнең 36 предприятие халыкара ярминкәләрдә һәм күргәзмәләрдә катнашып, 380 төрле әйберен күрсәтте, дипломнар һәм призлар алып кайтты.

Шәһәрдә хезмәткә коммунистик караш өчен хәрәкәт киңрәк җәелә бара. Казандагы биш предприятие «Коммунистик хезмәт коллективы» исеменә лаек булды. Предприятиеләрдә 160 мең коммунистик хезмәт ударнигы эшли.

Уңышларыбыз күз алдында. Казан хезмәт ияләре бишьеллыкны тиешлесеннән алда, 1975 елның ноябрь уртасында үтәп чыкты. Меңләгән алдынгылар партия съездына Хезмәт рапортына кул куйды. Социалистик Хезмәт Геройлары Г. Ә. Әсхәдуллин, М. В Карпов, Р. Г. Заһидуллин, Г. З. Сәлимҗанов, Ленин ордены кавалерлары Ю. А. Шишкин, Г. Р. Бәйрәмова, В. Н. Кузьмина, М. Г. Юзеева һәм башка бик күпләр шундыйлар арасында.

1975 елгы бөтенсоюз социалистик ярышы алдынгыларыннан 5 мең 600 кеше орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде. «Органик синтез» берләшмәсе аппаратчысы Г. Х. Җантимерова белән тимер юлчы А. А. Павловка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде.

Ә Казан шәһәре үзе җиңүче дип табылды, РСФСР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл байрагына лаек булды.

Шәһәребез хезмәтчәннәре бу бишьеллыкта да сынатмыйлар, үзләренә тагын да зуррак үрләр билгеләп, аларны яулау өчен зур тырышлык белән эшлиләр. Ә үрләр чыннан да биек. Бу бишьеллыкта промышленность продукциясе күләме бер ярым мәртәбә ортачак, шуның 90 проценты җитештерүчәнлекне күтәрү исәбенә ирешелергә тиеш. Машина һәм приборлар төзелеше, энергетика, химия индустриясе бу елларда кызу темплар белән үсәчәк, шулай ук җиңел һәм азык промышленносте предприятиеләрен, транспорт һәм элемтәне тагын да үстерү карала.

Моторлар төзелеше заводында яңа двигательләр чыгару, В. В. Куйбышев исемендәге заводта яңа производстволар, шул исәптән магнитлы тасма җитештерүнең икенче чиратын сафка кертү каралды. Киң куллану товарлары эшләп чыгару артачак. Радио-телевизион аппаратура һәм катлаулы көнкүреш техникасын ремонтлау, химик чистарту һәм кием буяу, мебель ясау һәм төзәтү буенча эре ательелар, модельле аяк киеме йорты һәм башкаларны салу күздә тотыла. Яңа микрорайоннарда йөздән артык заманча мастерскойлар һәм кабул итү салоннары ачылырга тиеш.

Аэропортны гына алыйк. 1975 елда гына һава юлларында миллион ярымнан артык пассажир йөрде, 16 мең тоннадан артык йөк ташылды, ярты миллионнан артык гектар кыр һавадан торып эшкәртелде.

Хәзерге Казан һава юллары аша илебезнең 55 шәһәре һәм Татарстанның 35 ноктасы белән бәйләнгән. Җирле һава линияләренең озынлыгы гына — дүрт мең километр. Казан авиапредприятиесе Идел буе гражданлык авиациясендә беренче урынны тота. «Казан-2» аэропорты төзелгәч, шәһәребезнең әһәмияте тагын да артачак.

Елга транспорты, тимер юл транспорты шулай ук шәһәребез өчен елдан-ел зур роль уйный, аларны да үстерә бару карала.

Казан гасырлар буена төзелеп килгән. Биредә үзенең архитектура йөзендә талантлы осталарның иҗади даһилыгы эзен саклаган йортлар аз түгел. Алар шәһәребезгә кабатланмас төс биреп торалар. Ләкин революциягә кадәрге Казан, билгеле булганча, үзенең пычрак, тар урамнар пәрәвезе, искергән агач өйләре белән типик купецлар шәһәре булып килде. Шәһәр думасы гласныйларыннан берәүнең әйтүенчә, революциягә кадәр алар «мифик рәхәтлекләр һәм канализация, елның теләсә кайсы вакытында йөрергә җайлы таш юл һәм тротуарлар, саф һава һәм шәһәр кырыйларын төзекләндерү турында» хыяллана гына ала иделәр.

Бу хыяллар Совет власте елларында чынга ашты. Шәһәрнең барлык районнарында заманча төзек поселоклар, яңа кварталлар калыкты. Хәзер капитал салуларның күбрәк өлеше торак йортлар, балалар учреждениеләре, мәктәпләр, больницалар, сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре төзүгә тотыла.

Менә чагыштыру өчен кайбер исәпләүләр: соңгы унбиш елда файдалы торак йорт мәйданы ике ярым мәртәбә артты һәм 12 миллион квадрат метрга җитте. Тугызынчы бишьеллыкта гына ике миллион квадрат метр мәйданлы 50 мең фатир төзелде, ягъни 200 мең казанлы өй туйлары уздырды.

Торак төзелешендә сыйфат үзгәрешләре бара. Хәзер нигездә тугыз катлы йортлар салына. Аларда бүлмәләрнең урнашуы, кухня һәм ярдәмчел мәйданның иркен булуы җайлы.

Тугызынчы бишьеллыкта 17 мең балага бакча һәм ясле корылды. Шәһәрдә ел саен өч зур мәктәп төзеп тапшырыла. Шундый темплар белән эшләгәндә унынчы бишьелык ахырында мәктәпләрдә балаларның бары тик бер сменада гына укуларына ирешеләчәк.

Югары һәм урта махсус белем йортларының да яңа бикалары күтәрелә тора.

Шәһәребез яңара, матурлана бара. Монда төзүчеләребезнең өлеше зур. Алар арасында Социалистик Хезмәт Геройлары бригадирлар А. А. Хабаров, К. Х. Ибәтуллин, С. Г. Гыйльманов, И. Г. Шәйхетдинов, орденлы эшчеләр Р. К. Йосыпов, З. С. Сафин, Н. Д. Жесткова, Н. З. Җәләлиев, З. Ш. Хәмидуллина һәм башка бик күпләр — барыбызның да горурлыгы.

Казан 2000 елгача исәпләнгән генераль план нигезендә яңартыла. Татарстан, Жданов, Вишневский, Фрунзе, Декабристлар урамнары, Х. Ямашев һәм Г. Ибраһимов проспектлары кебек төп магистральләрдә эш кайнап торганын күрәсез булыр. «Татаргражданпроект», университетның икенче биек бинасы, Татар академия театры, вузара ашханә, элемтә йорты, Пионерлар сарае, «Казан» кунакханәсе кебек үзенчәлекле корылмалар башкалабызның архитектура йөзен бизиячәк.

Казанның үзеген заманча нәфис һәм тәэсирле, мәгънәле итеп үзгәртеп кору эшләре җәелдерелде. Үзәк Татарстанның башкаласы дәрәҗәсенә җавап бирерлек архитектур яңгырашлы булсын — архитекторлар һәм проект оешмалары алдына шундый бурыч куелды. Кабан күле һәм Болакны төзекләндерү буенча зур эшләр билгеләнде. Казан елгасы яр буен шәһәребезнең иң матур урыннарыннан берсенә әверелдерү юнәлешендә кызыклы һәм үзенчәлекле планнар тормышка ашырыла башлады.

2000 елга Казанда халык саны бер миллион ике йөз меңгә җитәчәк. Шәһәр һәр яклап үсә, матурая, яшәрә. Партия һәм совет органнары аны тагын да матурлау, яшәр өчен тагын да уңайлыландыру турында даими кайгырталар. Чөнки, Л. И. Брежнев әйткәнчә, сүз «хезмәт кешесенә эшләр, укыр, ял итәр, үзенең барлык сәләтләрен үстерер һәм аларга иң яхшы кулланыш табар өчен иң уңай шартларны тудыру»[1] турында бара.

Казанлыларны җылы, су, транспорт, элемтә белән тәэмин итү яхшыра. Киләсе еллар планнарында шушы җәһәттән зур эшләр билгеләнгән. Мәсәлән, хәзер шәһәрдә телефон станцияләренең сыешлыгы кырык мең номер тәшкил итә. Бу бишьеллыкта тагын 28 мең номерга исәпләнгән өч станция салына.

Сәүдә челтәре үсә. Хәзерге кибетләрне «Хатын-кызлар өчен», «Ирләр өчен», «Балалар өчен», «Көнкүреш товарлары» кебек бер керүдә бөтен ихтыяҗыңны канәгатьләндереп була торган махсус кибетләр алыштырачак. Әйтик, бездә илебездә иң эреләрдән саналган сәүдә үзәге салынып бетте. Анда бер түбә астында күп төрле товар белән сату итәргә, хезмәт күрсәтү культурасын күтәрергә зур мөмкинлекләр тудырылган.

Шәһәрдә медицина хезмәте күрсәтү, халыкның сәламәтлеге турында кайгырту игътибар үзәгендә тора. Унынчы бишьеллыкта республика клиник больницасының яңа дәвалау, лаборатория һәм поликлиникасы корпуслары, органик синтез заводының дәвалау комплек-



---

[1] Л. И. Брежнев. Ленинским курсом. Речи и статьи. Т. 2, 574 бит, М., Политиздат, 1970 ел.

сы, Горкида шәһәрдәге иң зур поликлиника бинасы һәм башкалар салына. Киров районында бала тудыру йортлары, дәвалау корпусы төзү, ашыгыч ярдәм күрсәтү станциясе, Мәскәү районында балалар больницасы кору, ике балалар санаторие һәм предприятиеләрдә санчастьлар ачу планлаштырылды.

Хәзер өлкәннәрнең 45 проценты даими диспансер күзәтчелегенә тартылган. Ел саен 40 мең хезмәт иясе үзенең гаиләсе белән санаторийларда, ял йортларында сәламәтлеген ныгыта. Спорт секцияләрендә генә 120 меңнән артык кеше шөгыльләнә. Казан совет спортына бик күп күренекле осталар үстерде. Олимпия уеннары һәм дөнья чемпионнары В. Никонова, Н. Гыйлаҗева, О. Князева һ. б. шундыйлардан.

Шәһәрдә 185 спорт залы, Спорт сарае, тугыз стадион, шул исәптән В. И. Ленин исемендәге комплекслы стадион бар.

Хезмәт ияләренең тормышы яхшыруының нәтиҗәләре күз алдында: әгәр 1900—1913 елларда Казанда мең кешегә үлүчеләр саны — 30, туучылар — 29 кеше булган булса һәм, революциягә хәтле кайбер экономистлар фараз кылганча, 1960 елларга Казан халкы үлеп бетәргә тиеш булса, бүгенге Казанда туучылар өлеше вафат булучыларга караганда икеләтә артык.

Татарстан башкаласы — белем, фән, культура үзәге, КПССның XXV съезды тарафыннан куелган мөһим бурыч — гомуми урта белем бирүгә күчү шәһәребездә тормышка ашырылды.

14 югары һәм 20 махсус урта белем бирүче уку йортларында 85 меңнән күбрәк студент укый. Бу — шәһәрнең һәр унбер кешесеннән берсе дигән сүз. Казан вузларында студентлар саны Австрия белән Швейцариянең икесендәгедән күбрәк.

Ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру нәтиҗәсендә Казан халык интеллигенциясенең дистәләрчә мең талантлы вәкилләрен үстерде. Хәзерге вакытта шәһәребез вузларындагы студентларның 42 проценты — татарлар.

Казанда «пешеп» чыккан белгечләр илебез халык хуҗалыгының барлык тармакларында, фән, культура, мәгариф, халык сәламәтлеге, партия һәм совет органнарында менә дигән итеп эшлиләр. Алар авиацияне, машина һәм прибор төзелешен, радиоэлектроника, химия һәм нефтехимияне, төзелеш индустриясен, физика һәм математиканы, педагогика һәм медицинаны, әдәбият-сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертеп, Ватаныбызның данын һәм куәтен арттыралар.

Гыйльми фикер үсеше Н. И. Лобачевский, А. М. Бутлеров, Н. Н. Зинин, А. Е. Арбузов, Г. Х. Камай, П. В. Лесгафт, Н. А. Миславский, А. В. Вишневский һәм башкалар башлаган фәнни мәктәпләр нигезендә бара. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы уңышлы эшли. Аның органик һәм физик химия, физик-техник, биология, тарих, тел һәм әдәбият институтларында хәзерге фәннең иң мөһим юнәлешләрендә тикшеренүләр алып барыла. Филиалның гыйльми көчләре арасында Социалистик Хезмәт Герое академик Б. А. Арбузов, член-корреспондентлар Б. М. Козырев һәм А. Н. Пудовик, профессорлар М. М. Зарипов, Х. М. Мөштәри, Ю. П. Китаев, М. К. Мөхәррәмов, И. А. Тарчевский һәм фәннең нигез проблемаларын уңышлы хәл итәрлек тагын бик күп галимнәр бар. Алар тырышлыгы белән органик һәм нефтехимик синтез, парамагнитик резонанс, магнитлы радиоспектроскопия, тышчалар һәм сүрүләр теориясе, микробиология, үсемлекләр һәм туфрак физиологиясе, Татарстан АССР тарихы һәм башка бик күп тармакларда Ватаныбыз фәнен һәм дөньякүләм фәнне үстерүгә зур өлеш кертелде.

Казанның фәнни-тикшеренү институтлары һәм уку йртлары промышленностька һәм авыл хуҗалыгына эшлекле ярдәм итәләр.

Авыл хуҗалыгының фәнни, техник, социаль-экономик проблемаларын ачыклау, шулай ук алдынгы тәҗрибәне гомумиләштерү белән 15 фәнни-тикшеренү, проект-конструкторлык һәм тәҗрибә учреждениеләре, вузлар шөгыльләнә. Казан авыл хуҗалыгы һәм Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты, фәннәр академиясенең биология институты уңыш алуны һәм игенчелек культурасын күтәрү буенча тикшеренүләр алып баралар. Ветеринария институты галимнәре союзкүләм әһәмиятле проблема — терлекләрне йогышлы авырулардан саклау проблемасын өйрәнәләр. Университет галимнәре республика җирләренең агрофизик картасын төзеделәр, көзге бодай һәм арышны ашлау системасын, тары һәм күп еллык үләннәр агротехникасын эшләделәр, культуралы кәтүлекләр өчен ясалма буалар итеп файдалану максатларында ташландык ярлар, чокыр-чакырларның инженер-геологик үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен өйрәнделәр. Галимнәрнең эшчеләр, колхозчылар белән дуслыгы ныгый һәм үз җимешләрен бирә.

Татарстан АССРның һәм аның башкаласының экономик үсеше милли культураның чәчәк атуында чагылыш тапты.

Казанның культура мирасының иң яхшы казанышларына нигезләнеп үсүче рухи тормышы күп кырлы һәм бай. Әдәбият һәм сәнгатьнең бик күп күренекле вәкилләренең язмышы Казан белән бәйләнгән. Монда Г. Р. Державин, С. Т. Аксаков, Л. Н. Толстой, П. П. Мельников-Печерский, М. Горький, Ф. И. Шаляпин, В. И. Качалов, Н. И. Фешин, татарлардан Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Һ. Такташ, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, К. Нәҗми, Ф. Кәрим һәм башка бик күпләрнең иҗаты чәчәк атты, күп милләтле совет халкының рухи байлыгына әверелде. Биредә Советлар Союзы Герое Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең канатлары ныгыды, биредән ул гражданин һәм шагыйрь буларак үлемсезлеккә юл алды.

Иҗади союзларга берләшеп, язучылар, композиторлар, рәссамнар рухланып иҗат итәләр. Алар заманыбыз рухына җавап бирерлек әсәрләрендә совет кешесен хезмәттә, коммунизм идеаллары хакына көрәштә чагылдыралар. Халкыбыз Г. Бәширов, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Ш Маннур, Х. Туфан, С. Хәким, З. Нури, Т. Миңнуллин, Д. Вәлиев һәм башкаларның әсәрләрен яхшы белә.

Совет чорында милли профессиональ музыка сәнгате зур үсеш алды. Талантлы татар композиторлары С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, А. Ключарев, Р. Яхин, З. Хәбибуллин, Ә. Бакиров, Ф. Әхмәтов, М. Яруллин һәм башкаларның иҗат бишеге Казан булды. СССРның халык артисты, Дәүләт премияләре лауреаты Нәҗип Җиһановның опералары һәм симфонияләре Татарстанда гына түгел, илебезнең һәм дөньяның бик күп сәхнәләрендә, концерт залларында яңгырый.

Биредә Татар дәүләт филармониясе, М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры, СССР халык артисты, Дәүләт премиясе лауреаты Н. Рахлин җитәкчелегендәге симфоник оркестр, күп санлы эстрада оркестрлары, шулай ук сәнгать осталары: З. Хисмәтуллина, Ф. Насретдинов, А. Аббасов, В. Шәрипова, И. Шакиров, Ә. Афзалова, Р. Ибраһимов, И. Хәкимова, С. Хантимерова, М. Әхмәтов, Р. Абдуллин һәм халыкта исеме киң билгеле башка бик күп артистлар үсеп җитте, яши һәм иҗат итә.

Г. Камал исемендәге татар академия театры 70 нче сезонын тәмамлады. Илебез тамашачыларының мәхәббәтен казанган бу коллективта талантлы иҗат көчләре күп. Актер Фуат Халитовка СССРның халык артисты исеме бирелде.

Казан рәссамнарының да иҗади уңышлары зур. СССР Художество академиясе член-корреспонденты Х. Якупов, Б. Урманче, Л. Фәттахов, К. Максимов, В. Куделькин, С. Лывин, В. Маликов, С. Прокопьев, И. Зарипов һәм башкаларның әсәрләре бөтенроссия, бөтенсоюз һәм халыкара күргәзмәләрдә уңыш казана.

Иҗади интеллигенция алдында мактаулы бурыч — заманыбызның бөеклеген җырлау бурычы тора. Совет власте елларында Татарстан ирешкән казанышлар моның өчен рухландыргыч материал булып тора. Язучылар, композиторлар һәм рәссамнар казанлылар, нефтьчеләр һәм химиклар, КамАЗны һәм Түбән Каманы төзүчеләр, тавыштан тизрәк очучы самолетлар һәм электрон хисаплау машиналарын иҗат итүчеләр, авыл хезмәтчәннәре — коммунизм төзүче барлык замандашларыбыз алдында зур бурычлы.

Казан хезмәт ияләренең хезмәт һәм иҗат казанышлары үзенең сафларына 70 меңгә якын коммунистны берләштергән шәһәр партия оешмасының нәтиҗәле политик һәм оештыру эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән. КПССның XXIV һәм XXV съезды карарларын тормышка ашыру өчен көрәштә ул хуҗалык һәм культура төзелеше белән партия җитәкчелеге ысулларын һәм формаларын баета бара, идея һәм оешканлык ягыннан ныгый.

Шәһәр партия оешмасы Социалистик Хезмәт Геройлары В. П. Лушников, В. В. Копылов, Л. В. Гыйззатдинов, П. А. Витер һәм башка бик күпләр кебек сәләтле белгечләр һәм хуҗалык җитәкчеләре тәрбияләде. Югары уку йортларында М. Т. Нужин, Р. Ш. Нигъмәтуллин, П. А. Кирпичников, Х. С. Хәмитов, М. З. Зәкиев кебек галимнәр, оештыручылар күп.

А. А. Шуртыгин, М. К. Рәмиев, А. В. Сафьянов, З. Х. Зарипова кебек партия район комитеты секретарьлары экономика, культура үсеше мәсьәләләрен эшлекле хәл итәләр, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбия итү юнәлешендә нәтиҗәле эш оештыралар.

Хәзерге көндә шәһәр һәм район советлары эшчәнлегендә 2200 депутат актив катнаша. Депутатлар — эшчеләр сыйныфы һәм хезмәтчел интеллигенциянең иң яхшы вәкилләре — В. И. Ленин әйткәнчә, «...дәүләтне демократик идарә итүгә һәр вакыт, әлбәттә, шуның белән бергә, хәлиткеч катнаштырылалар» (В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә, 28 нче том, 478 бит).

Шәһәребезнең революцион, сугышчан, хезмәт даны традицияләрен ишәйтүдә профсоюз һәм комсомол — партия һәм совет органнарының иң якын ярдәмчеләре. Комсомолларның 80 меңе җитештерүчән хезмәттә эшли. Аларның һәр өченчесе — коммунистик хезмәт ударнигы.

Бу көннәрдә Казан партия оешмасы КПСС Үзәк Комитетының «Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгы турында» карары нигезендә зур эш алып бара. Казан хезмәт ияләре партиянең XXV съезды карарларын тормышка ашыра барып, унынчы бишьеллыкның икенче елында да иҗтимагый-экономик һәм культура тормышының барлык тармакларында яңа казанышлар яулыйлар. Марксизм-ленинизм идеяләренә, данлы революцион, хезмәт һәм сугышчан традицияләргә тугрылык, эшчеләр сыйныфы һәм интеллигенциянең фидакарь хезмәте, кадрларыбызның өлгерлеге, партия оешмаларының сугышчанлыгы билгеләнгән үрләребезгә күтәрелүебезнең ышанычлы гарантиясе булып тора.

**Мидхәт Миншин**

# ТАШКЫН

ОЧЕРК



Зур эшләр башкару өчен талант кына җитми, көрәшче дә булырга кирәк.

Нефть машиналары төзелеше буенча Татарстан фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык институты директоры Бувайло кулындагы кәгазь кисәген селки-селки тагын шуны кабатлады: «Талант кына җитми, көрәшче дә булырга кирәк».

Бүлек начальнигы Рәфгать Гайнетдинов аның нигә ярсуын аңламыйча гаҗәпләнеп карап торды, сорау бирергә дә кыймады. Күңелен нинди-дер шом биләп алды, Илья Александрович тикмәгә генә кызмыйдыр, хикмәте бардыр моның.

— Мә, укы,— диде директор, бераз тынычлана төшеп.

СССР Химия машиналары промышленносте министрлыгыннан килгән рәсми күрсәтмә иде бу.

«Эшегезне туктатыгыз, бу проблема белән Подольск институты шөгыльләнәчәк»,— дип әмер биргәннәр.

Рәфгать үз күзләренә үзе ышанмады. Тагын укып чыкты. Акка кара белән язылган: «Эшегезне туктатыгыз»,— дип кистереп әйткәннәр.

— Бу нинди дә булса хатадыр, Илья Александрович! Башына тай типмәгән кеше мондый кәгазь җибәрмәс,— диде ул.

— Җибәргәннәр ич.

— Җибәрсәләр соң?! Сез моны әллә җитди нәрсәгә саныйсызмы? Дәүләтнең шул кадәр акчасы тотылган, күпме көч, күпме вакыт сарыф ителгән. Ничек инде эшне ярты юлда калдырырга мөмкин. Министрлыктагы иптәшләр әллә саный белмиләрме?

— Хәзер һәркем санарга ярата. Әмма «ике дә икең дүрт» дигән хакыйкатьне раслар өчен дә якалашкан чаклар була. Син моны «хата» гына дип үзең ялгыша күрмә. Бу урындашлык, ведомствочылык чире. Шушы кәгазьгә кул куючыларга «сез хаклы түгел» дип әйтеп кара, сине алар әллә нәрсәләрдә гаепләп бетерәчәкләр,— диде Бувайло.

— Алардан куркып шул кадәр эшне җилгә очырып та булмый бит инде.

— Мин дә шул ук фикердә. Тик ничек кенә җиңеп чыгарбыз икән?! Көчебез җитәрме соң?! Мин шул турыда баш ватам, кадерләм.

Бүлмә буйлап арлы-бирле йөргән директор үз урынына утырды,

ике кулы белән ике як чигәсен тотты. Хәлнең кискенлеге Рәфгатькә дә барып җитте. Икесенең дә йөзе җитди. Маңгайларында буразналар тирәнәеп, калынаеп китте кебек. Бер-берсенә туры карарга да уңайсызланалар төсле — гүяки һәркем үзен нәрсәгәдер гаепле саный. Һәркайсы үз алдына уйлана. Әгәр берәр могҗизалы аппарат икесенең кичерешләрен кәгазь битенә күчерә алса, анда күп кенә охшашлык табылыр иде, икесе дә бер үк эш өчен яна, омтылышлар, теләкләр уртак икән, язмышлар да якыная.

Беренче тапкыр алар моннан егерме еллар элек очрашты. Казан химия-технология институтын тәмамлап, Рәфгать Гайнетдинов махсус конструкторлык бюросында эшли иде. «Татнефть» берләшмәсе нефть һәм газны үзәктән кудыручы компрессорлар төзергә заказ бирде. Һава белән эшләүчеләренә караганда ул куәтлерәк тә, техника куркынычсызлыгы ягыннан да камилрәк булырга тиеш. Мәсьәләне хәл итү артык озакка да сузылмасын. Татарстан республикасында нефть һәм газ чыгаруның югары темплар алуы таләп итә моны. Берләшмәнең баш механигы Илья Александрович Бувайло һәммәсен бик җентекләп аңлатты.

Рәфгать Сәләхович Гайнетдинов, Владимир Борисович Шнеп, Николай Яковлевич Салопов өчәүләп эшкә керештеләр. Кайсы юлны сайларга? Әллә булган компрессорларны гына үзгәртергәме, яисә бөтенләй яңаларын төзергәме? Беренче карашка сораулар катлаулы да түгел кебек. Әмма һәммәсен исәпләргә, санарга кирәк. Кайсы юл файдалырак?

Эшне нольдән башласаң, ягъни яңа компрессорлар төзүгә тотынсаң, биш еллап вакыт узачак. Моның белән нефтьчеләр һич килешмәячәк. Бу вариантны үзләре үк кире кактылар.

Ә гамәлдәге компрессорларны үзгәртү үзен аклармы? Монысы да билгесез.

Конструкторлар саныйлар, сызалар, бозалар, тикшерәләр. Берсе биргән идеяне икенчесе я куәтли, я яраксызга чыгара. Бәхәсләшәләр. Тагын саныйлар, сызалар, тикшерәләр. Тармактагы фән-техника яңалыклары белән танышалар. Проблема өчесен дә бөтереп алды, эш сәгатьләре белән дә исәпләшми башладылар. Һәм эзләгәннәрен таптылар да. Элеккеге компрессорларны үзгәртүнең иң кулай, иң файдалы мөмкинлекләрен ачтылар. «Татнефть» берләшмәсенең заказы бер ел эчендә үтәлде. Яңа компрессорлар югары бәя алды. Серияләп җитештерелә башлады һәм бөтен Советлар Союзына таралды.

Беренче иҗади уңыш Рәфгать Гайнетдиновның киләчәк язмышын да билгеләде. Нефтьчеләр аның сәләтен дә, тырышлыгын да сизенделәр булса кирәк, бөтенләйгә үзләренә тартырга карар бирделәр.

Татарстан нефть пионерларының берсе Илья Александрович Бувайло конкрет тәкъдим ясады.

— Көчсәң, һич тә үкенмәссең,— диде ул.— Син яшь кеше, белемең бар, иҗади эшкә һәвәслегең дә көчле, безгә шундый белгечләр бик кирәк хәзер, елына йөзәр миллион тонна нефть чыгару, дөрес, бүген хыял гына, ә иртәгә — чынбарлык булачак. Татарстандагы нефть ташкыны дөньяны хәйранга калдырыр. Шундый зур эшләргә чакырып торганда каршы төшмә. Зур кораблар зур диңгездә генә йөзә.

Рәфгать ризалык бирде, «Татнефтегазразведка» трестында өлкән инженер булып эшли башлады, баш механикка кадәр күтәрелде. Хикмәт күтәрелүдә генә түгел иде. Ул биредә зур тәҗрибә туплады.. Нефть чыгаручы машиналар белән җентекләп танышты. Буровойларны сүтмичә ерак араларга күчерү Татарстан нефте тарихында яңа сәхифәләр ачты. Бу яңалыкны көндәлек практикага кертүдә Рәфгать Гайнетдинов юл ярып баручыларның берсе иде.

Промыселларны комплекслап автоматлаштыру проблемасы көн тәртибенә менде. Советлар Союзында иң беренче булып Татарстан нефтьчеләре шушы катлаулы эшкә керештеләр. Фән-техника революциясен ясардай кадрлар кирәк иде. Аларны кайдан аласың. Беренче чиратта производствода чыныккан белгечләргә таянасың. Институт директоры итеп билгеләнгән Илья Александрович Бувайло инде эш күрсәткән, киләчәктә дә эш күрсәтердәй «башлы» кешеләрне җыйды, аларның берсе Рәфгать Гайнетдинов иде.

Галимнәр, конструкторлар, нефтьчеләр моңарчы беркайчан да булмаганча берләште. Фән һәм тормыш аерылгысыз дәрәҗәдә якынайды. Төрле министрлыклар бәйләнешкә керде. Бердәм планнар төзелде.

Халыкта «илдә булмаганны сөйләмә» дигән сүз бар. Илдә булмаганны сөйләргә генә түгел, эшләргә, нефть һәм газны чыгару, эшкәртү, озату процессларын бергә кушардай автоматлар тудырырга кирәк иде. Бу — кара алтын ятмаларын үзләштерүне тизләтә, промыселларны зур-зур өстәмә төзелешләрдән арындыра, җир-суны пычрату бәласеннән коткара. Бөтенесен бергә җыеп санаганда нәтиҗәлелек миллиардлар белән исәпләнәчәк.

Конструктор Рәфгать Гайнетдинов бүлеккә талантлы яшьләр туплады. Тынгысызлыгы гына түгел, ә үз-үзен тотышы, пөхтәлеге, хәтта җәяү йөрергә яратуы да хезмәттәшләре алдында начальникның абруен күтәрде. Улы укыган мәктәптә ата-аналар комитетында тырышып эшләп йөрүен дә ишеткәннәр, белгәннәр. «Балам йомшак укый», «улым тәртип боза, нишлим икән?» дип киңәшкә-табышка килергә тайчанмыйлар. Аның холкы-фигылендә кешеләрне читкә этәрүче нәрсә юк. Мондый «бәхет» аңа каян килгән диген. Мәрхүм эти-әнисе дә гадиләрнең гадие иде. Әтисе — Сәләх — тимер юлчы, әнисе — Мөхипкамал — йорт хуҗасы. Әллә ни белем дә алмаганнар, ә тормыш философиясен, балалар үстерү фәнен ничек шул кадәрле нечкә үзләштергәннәр диген. Тугыз баланың тугызын да аякка бастырганнар. Арадан берәү дә күз күеге булып йөрми: уллары да, кызлары да. Кияүләр, киленнәр дә аларга пар килгән. Рәфгатьнең хатыны Татьяна Германовнаны хөкүмәтебез «Почет билгесе» ордены белән бүләкләде, сеңелесе Нәзирәгә «Министрлыкның иң яхшы монтажчысы» дигән исем бирелде. Рәфгать шуны беркайчан да онытмый: бүлектәге конструкторлар да кемнеңдер баласы, кемнеңдер әтисе, әнисе, кемнеңдер ире яки хатыны бит — беркемнең язмышы белән дә уйнарга ярамый. Үзеңә әнә тугыз туганның берсе дә артык түгел. Син — начальник кеше — хезмәттәшләреңә яхшылык эшли алсаң, күпме кешене сөендерәсең, канатландырасың, бәхетле итәсең.

«Коллективта микроклимат тудыру» дип авыз тутырып сөйләү модага керде. Бик тә фәнни бу терминны гади генә аңлатырга мөмкин. Үзара эшлекле мөнәсәбәт, бер-береңне хөрмәт итү, көтелмәгән хәлләр туганда да бер-береңне аңларга тырышу ул.

Иҗади коллективта көтелмәгән хәлләр — «әрсез кунак» — көттереп, ялындырып тормый. Алабугадан килгән хәбәр әнә аяз көнне яшен суккандай итте.

«Сез иҗат иткән установка эшләми» дигәннәр. Рәфгать яңа машинаның сызымнарын ялгызы гына тикшерде, юк, болай «яраксызга» чыгарырдай кимчелеген таба алмады. Бүлектәге конструкторларны, инженерларны эшкә җикте. Күпме генә анализламасыннар, актарынмасыннар — җавап бер иде: машина эшләргә тиеш, эшләргә тиеш.

— Без монда вакыт әрәм итмик әле,— диде яшь кенә инженер Фәрит Борһанов.— Урынга барып ачыкларга кирәк. Җибәрегез мине, Рәфгать Сәләхович. Бүген үк чыгып китәм.

— Дөрес сөйлисең,— диде начальник.— Икәү барырбыз.— Үзләре тудырган установканы барып күргәч исә телсез калдылар.

— Ишкәннәр ишәк чумарын,— диде Фәрит.— Соң инде шуны да аңламаска. Хәзер яңадан сүтәргә, башка урынга күчерергә кирәкме?

— Установка үзе — илле мең сум, төзү-монтаж эшләренең бәясе — егерме мең сум. Димәк, бу егерме мең җилгә очкан. Җиһазларны сүтү дә күпмегә төшәчәк,— диде Рәфгать ачынып.— Нәтиҗәлелек, экономия, фәнни-техник революция дибез, үзебез меңнәр белән дә санашып тормыйбыз.

Ул «үзебез» диде. Бөтен гаепне нефтьчеләргә атмады. Зыян бик зур булмасын, дисәң, әмәлен тап, син — конструктор. Һаман да шул искечә эшләүнең, инерциянең чабудан тартуы иде бу «ЧП». Моңарчы нефтьне, газны чыгару, кара алтынны судан арындыру аерым-аерым процесслар иде. Аларның һәркайсы өчен күпме җиһазлар куела — җир өстендәге төзелеш объектлары санап бетергесез була.

Яңа установка бу процессларның барысын берьюлы башкарырга тиеш, җир куенындагы хәзинәне чыгару һәм эшкәртүне автоматлаштыруның хикмәте дә шунда.

Ә монда нишләгәннәр?! Яңа җиһазларны газсыз мәйданга көйләгәннәр. Газ булмагач, нефть ташкынын тудырырдай басым юк, установкага җан кермәячәк. Менә сиңа яңалык, менә сиңа техник прогресс. Яман телләргә шәп азык, кичәге көн белән яшәүчеләргә әйбәт терәк.

Конструктор «минем гаебем юк» дип Казанга кайтып китсә дә, кайберәүләргә каршы «кәгазь давылы» куптарса да, үзенчә хаклы булыр иде. Рәфгать Гайнетдинов мондый юлны сайламады. Ул бит үзенең хаклылыгын расларга килмәде, яңа техниканы үзләштерү беркайчан да җырлап кына бармый, нефтьчеләргә ул булышмыйкем булышсын.

Хатаны бергәләп төзәтергә булдылар. Установканы сүтеп, башка урынга күчерү, яңадан монтажлау бик кыйммәткә төшәчәк, аннан файдалану юлын менә шушында, куелган урында табарга кирәк иде. Ун көн буена вакытында ашамадылар, туйганчы бер йокламадылар. Установканы мәйданга яраклаштырып үзгәртү өчен унбиш вариантны сынап карадылар, өстәмә насослар куйдылар. Ниһаять, җиһазларга «җан иңде», җир куеныннан куәтле нефть ташкыны бәрде.

«Алабуга» вакыйгасы юлдагы сикәлтәләрнең беренчесе дә, соңгысы да түгел иде.

Конструктор айлар буена промыселда «казына». Үзләре төзегән машиналарның үрнәкләрен производство шартларында тикшерә. «Лениногорскнефть» идарәсендә нефтьне судан арындыручы яңа җиһазларны сынаганда СССР нефть промышленносте министры Валентин Дмитриевич Шашин килгән иде.

Машиналарны ошатты ул. Шунда ук: «Производствога кертү өчен күпме вакыт кирәк?» — дип сорап куйды.

«Татнефть» берләшмәсенең ул вакыттагы баш инженеры Валерий Исакович Грайфер, конструктор Рәфгать Гайнетдинов үзләренең исәп-хисаплары белән таныштырдылар.

— Алайса,— диде министр,— бүгеннән үк машинаның куәтен арттыру хакында кайгыртырга кирәк. Бу бит тәүлегенә 400 тонна гына сыек ягулык эшкәртә. Мең тонна, өч мең тоннага йөз тотыйк. Югыйсә, алар мораль яктан бик тиз искерәчәк, нинди кыенлык туса да, минем белән бәйләнешкә керегез, булышырга һәрвакыт әзермен.

Министрның хуплавы һәркайсына канат куйгандай итте, яңадан эзләнүләр башланды.

Кара, алма бирергә торган агачны төптән кисәргә кушучылар да

табыла икән. «Эшегезне туктатыгыз» дигән приказ шул бит ул. Иртәгеге көненә ышанып яшәмәгән кеше балалар да, бакча да үстерә алмый, андыйлардан рәтле галимнәр, конструкторлар да чыкмый.

Рәфгать ул да, бакча да үстерде, конструктор икәнен дә расламый калмас. Расламый калмас!

...Ул гайрәтләнеп директор бүлмәсеннән чыгып китте. Бер-ике минуттан сызымнар күтәреп тагын йөгереп керде.

— Менә бит никадәрле эш, Илья Александрович, аларны кем юкка чыгара алыр икән,— диде төргәкләрен өстәл өстенә тарата-тарата.

— Мин белмимме инде, мине үгетләп мәшәкатьләнмә. Әйт, нишлибез!? — диде директор кырыс кына.

— Мәскәүгә барырга кирәк.

— Мин дә шулай уйлыйм.

Дөньяны күбрәк күргән, «булган кеше» — Бувайло мәгънәле генә өстәп куйды:

— Баргач, эш чыгарырлык булсын. Һәммәсен янә бер кат ачыклыйк. Көчле якларга да, йомшак якларга да тиешле бәясен бирик. Нинди сорау туса да, җавап эзләп кесәгә керерлек булмасын. Анда утыручылар да юләр түгел, бүрек белән бәреп кенә ега алмассың. Үзләре белән телефоннан хәбәрләшеп тә куярга кирәк. Сөйләшмичә генә барсаң, секретарь кыз ук юлыңа киртә булып төшә.

— Карталарны хәзер үк ачып күрсәткәч, уен бетә бит,— диде Рәфгать борчылып.

— Ә мин карталарны ачарга җыенмыйм әле. Уен — алда.— Директор телефон трубкасын күтәрде, Мәскәү телефонының номерын атады.— «Без баш күтәрәбез» дип әйтеп тормыйм ич мин. Барлык исәп-хисаплар белән конструктор Гайнетдинов барачак, дим. Кабул итү көнен, сәгатьләрен сорыйм.

Рәфгатьнең йөзендә елмаю билгеләре уйнаклады. Директор белән бүлек начальнигы булачак сөйләшүләрнең тактикасын билгеләгән арада Мәскәүне дә тоташтырдылар.

— Сезнең приказны алдык,— диде Илья Александрович.— Без инде аның буенча конкрет эшкә керештек.

— Яхшы, яхшы,— дип хуплау ишетелде.

— Кирәкле документларны Гайнетдинов илтәчәк. Кайчан кабул итәсез?

— Вакыт бик тар инде, бу үзгәртүләр белән тәмам башыбыз әйләнде,— диде Мәскәүдән сөйләшүче.— Шулай да бер ярты сәгать тапмый калмабыз. Сишәмбе көнне сәгать биштә керсен.

— Рәхмәт.

Телефон трубкасын урынына куйгач, Бувайло балаларча кычкырып көлеп җибәрде.

— Башыбыз әйләнде, диме. Без аны әйләнүдән туктатырбыз, Рәфгать, шулаймы?

— Ярый ла, эш барып чыкса уңайга,— диде тегесе елмаеп.

— Кешеләрнең башын үз урынына утырту җиңел түгел, нишлисең, башыңа төшкәч, башмакчы буласың. Нефть, газ чыгару технологиясен үзгәрткәндә кайберәүләрнең фикерен, дөньяга карашын да үзгәртергә кирәк.

Директорның уены-чыны катыш әйткән сүзләре Рәфгатьнең кәефен күтәреп җибәрдеме, йөзе ачылып китте.

— Бу «күрсәтмәне» синнән башка әле беркемгә дә күрсәтмәдем, хәтта урынбасарларыма да,— диде Илья Александрович.— Син дә «кап та йот». Әле ачыкланып бетмәгән килеш кешеләрнең башын катырмыйк. Мондый хәбәр таралса, эшлекле атмосфера калыр димә, юк-бар сүз агачны эчтән ашап баручы корт кебек ул.

— Кешеләрнең кәефен төшерергә ярамый,— дип җөпләде Рәфгать тә.

— Килештек, мин хәзер приказ бирәм. Иртәгә Мәскәүгә китәсең. Бәхәсләр купса да, бер үк кыза күрмә, ашыгып әйткән сүз түгел, уйлап әйткән сүз кадерле. Хәер, моңа сине өйрәтәсе юк инде, үзең дә беләсең, эшләр бик катлауланып китсә, шунда ук хәбәр ит, үзем дә барырмын. Безнең чигенергә дә, бирешергә дә хакыбыз юк. Бу — безнең «мин-минлек»тән генә килми, нефть һәм газ промышленностеның киләчәге таләп итә моны.

— Мин дә үзебезнең хаклы булуыбызга җаным-тәнем белән ышанам, кечкенә генә икеләнсәм дә, Мәскәүгә барып йөрмәс идем.

— Хәерле юл сиңа, кадерлем!

Конструктор Гайнетдинов поездда барганда да уйларыннан арына алмады. Ул үзе әйтергә тиешле иң тәэсирле сүзләрне табарга тырышты. Бу бит ялгызың гына шахмат уйнау шикеллерәк. Көндәшең каршына утыргач, үзеңне ничегрәк тотарсың, хикмәт шунда. Әмма киеренкелек барыбер үзенекен итә, әзләнергә, акылыңны бөтен көченә эшләтергә мәҗбүрли. Рәфгать төрле «акыллы машиналар» — роботлар һәм кешеләр арасындагы бәйләнешләргә багышланган бәхәсле мәкаләләрне аз укымады. Машиналар акыллыланган саен кешенең роле кимер дип куркуга төшүчеләр дә булмады түгел. Моның кысыр хәсрәт икәнен аңларга бик зур галимлек тә кирәкмидер. Фән-техника революциясе барганда кешенең акылына ихтыяҗ аеруча үсте — бусы минә бәхәссез. Теләсә нинди акыллы машина да үзеннән акыллырак машина тудыра алмаячак, моңа бары тик кеше генә сәләтле. Кеше хайваннар дөньясыннан да шулай аерылган, техника могҗизасы да кеше кулына, кеше акылына буйсына. Хикмәт бөтенләй икенче нәрсәдә: акылга, белемгә таянып эшләмәүчеләрнең кадере кими бара — монысы хак. Эшчеләр арасында югары белемле белгечләр көннән-көн күбәя икән, бу табигый күренеш. «Акыл һәм физик хезмәтнең якынаюы» философик төшенчә генәмени?!

Кешегә машиналарга караганда катлаулырак вазифалар йөкләнә. Әнә Бувайло да нәрсә ди: «Зур эшләр башкарырга талант кына җитми, көрәшче дә булырга кирәк»,— диме. Көрәшсез беркайчан да дөнья бармас, тик аның формасы, эчтәлеге үзгәрер, көндәлек эшләрне, меңнәрчә, миллионнарча тапкыр кабатланган мәшәкатьләрне дә сәнгать, шигърият дәрәҗәсенә кемнәр күтәрә? Көрәшчеләр! Дөньяның санап бетергесез төсләрен кемнәр саклый? Көрәшчеләр! Нигә без ир-егетләр хакында иң олы сүзне әйтергә теләгәндә «корыч ихтыярлы» дибез, ә түбәннәрнең-түбәннәренә «чүпрәк» дип кул селтибез!

Менә бит әле нефть һәм газ чыгаручы автоматлар язмышын хәл итү өчен дә бәхәсләшергә, бәрелешергә кирәк. Ярый ла, үземдә җиңәрлек көч тапсам, ә җиңелсәм?.. Җиңелсәм? Промыселларны комплекслап автоматлаштыру биш-алты елга соңгарачак, килер бер көн, безгә дә «чүпрәк» диярләр, «Без гаепле түгел, безнең кулыбызга суктылар», дип акланудан файда булырмы?.. Юк, җиңелергә хакым юк. Мин бит коммунист, кирәк икән, партия Үзәк Комитетына барып җитәрмен, хакыйкатьләрне ачмый калмам...

Министрлыкның бүлек начальнигы Рәфгать Гайнетдиновны җылы каршылады, өстәл артыннан чыгып кул бирде, урын күрсәтте. Берничә сүз белән генә булса да, саулык-сәламәтлекне сорашты. «Эшкә» тотындылар.

— Сез бик тиз кузгалдыгыз әле, каршы төшеп тә йөдәтмәдегез, хәлгә аек бәя бирә белдегез,— дип мактады аны бүлек началь-

нигы.— Шундый белгечләрне, хезмәткәрләрне хөрмәтлим. Югыйсә, кайберәүләр «без дә юкәдән урелмәгән» дип күкрәк кагарга яраталар.

— Гафу итегез,— диде Рәфгать.— Сезнең күрсәтмәне кире тапшырырга килдем мин.

Бүлек начальнигы әллә ишетмәгәнгә салышты, әллә аңлап бетермәде.

— Дәвам итегез,— диде.

Рәфгать, папкасын ачып, министрлык җибәргән кәгазьне алды.

— Без моны сезгә кире кайтарырга кирәк таптык.

Бүлмә хуҗасы да «теше чыккан абзыйлардан» булса кирәк, кабынып китмәде, тавышын күтәрмәде, елмая-елмая кәгазьне алды, укып та чыккандай итте. Ул моңа хәзерләнмәгән иде, вакытны сузды, «нокаутка» эләгүен дә сиздермәскә чамалады.

— «Бувайло — булган кеше» дигән сүзне ишеткәнем бар иде, болай уктыр дип уйламаган идем. Бу кинофильм аның сценариесе буенча төшерелдеме?

— Бергәләп хәл иттек.

— Сезнең нинди контрдәлилләрегез бар инде?

— Алар бик күп. Блоклы автомат-җиһазлар төзүнең системасы нигездә ачыкланды. Без якын араларда «Лениногорскнефть» идарәсенең Куакбаш мәйданын комплекслап автоматлаштырырга исәплибез.

— Яхшы, яхшы,— диде бүлек начальнигы аны хуплагандай.— Кара, сез инде мәсьәләне тәмам хәл иткәнсез ич. Алай икән, нигә Алабуга ягында установкагыз эштән баш тартты, аны яңадан көйләргә мәҗбүр булдыгыз?

Ул астыртын гына, зәһәр генә елмаеп куйды.

— Аның тарихы гади,— диде Рәфгать.— Җиһазларны газсыз мәйданга урнаштырганнар, технология бозылган, моңа бит инде конструкторлар гаепле түгел.

— Гаепле булмагач, нигә үзегез яңадан көйләдегез?

— Дәүләт акчасын кызгандым. Җиһазларны яңа урынга күчерү яңа мәшәкатьләр тудырачак иде, илгә файдалырак юлны сайларга тырыштык.

— Бик акыллы да булгач, ил исеменнән сөйләргә дә яраткач, мондый ялгышны булдырмаска кирәк иде.

— Гаеп бездә,— диде Рәфгать,— кешеләр шулай такыр җирдә абынып дип уйламадык шул.

— Без дә тиктомалга гына шундый карарга килмәдек,— диде бүлек начальнигы, үзенең дәрәҗәсен сиздерергә тырышкандай. «Лениногорскнефть» идарәсендә сынаган җиһазларыгызны да производствога кертмәдегез, яңаларын, куәтлерәкләрен эшләргә тотындыгыз. Болай булса, сез беркайчан да максатка ирешә алмаячаксыз. Чөнки дәрманыгыз җитми, шуңа күрә дәүләт акчасын төрле җиргә таратмаска, ә бер урынга тупларга, институтны көчәйтергә уйлыйбыз, аңлашылдымы?

— Беренче карашка логикагыз бар да шикелле. Әмма сез берике агач артына басып, урманны күрмисез, безнең еллар буена туплаган тәҗрибәбезне, табышларыбызны танымыйсыз. Бу проблеманы подольскилыларга тапшыру нефть һәм газ чыгару тармакларын яңадан коралландыруны киләндә бер бишьеллыкка тоткарлаячак. Бер бишьеллыкның ил өчен ни икәнен аңлатып тормыйм.

— Сез күтәрә алмаслык йөк салмыйсызмы үзегезнең өскә? Бик югарыдан торып сөйлисез.

— Әлбәттә, сез хаклы. Бу — күп коллективлар эше. Монда ялгы-

зың гына ерак бара алмыйсың. Шуңа күрә төрле министрлыклар бердәм план төзеде, бергәләп эшлибез. Озын чылбырның бер буыны — без, аннан безне алып ташлап булмый, чөнки илебездә иң күп нефтьне Татарстан бирә, нефтьчеләребез университетларда дәрес бирерлек. Без аларга таянабыз да, булышабыз да. Кыенлыкны бергәләп җиңәчәкбез.

— Күрер күзгә тыйнак кына, ә нефть ташкыныннан бер дә ким түгел икәнсез. Сыңар кул белән генә каплап, туктатып булмый.

Ул ачыла төште.

— Әйтегез әле, мин борып чыгарсам, «боерыкны үтәгез» дип озатсам, нишләрсез? — дип сорады.

— Министрның үзенә керәм.

— Ул да минем сүзне кабатласа?

— Ул да борып чыгарсамы? Барыбер тукталып калмыйм.

— Нишләрсез? Үзегез уйлаганча әйтегез.

— Кешеләрне өркетергә яратмыйм. Шулай да үзегез сорагач, әйтим инде. Партия Үзәк Комитетына барам.

— Анда яклау табарга ышанасызмы?

— Ышанам. Ышанмасам, сезнең вакытны да әрәм итеп йөрмәс идем.

Бүлек начальнигы Рәфгатьне тагын баштанаяк күзәтте. Спортчыларга хас килешле буй-сын. Шушы киеренке минутларда да карашыннан җылылык бөркелә. Ул син әйткәнне дә, үзе әйткәнне дә аңлый. Ул үзен дә алдамый, сине дә алдамый.

— Рәфгать Сәләхович,— диде ул,— нишләрбез икән? — Моңа бит әле мин генә кул куймаган.

Кинәт селектор төймәсенә басты.

— Безнең күрсәтмәне Казаннан кире китергәннәр,— диде.

— Сез аларга аңлатыгыз,— диделәр икенче бүлмәдән.

— Юк, ул миңа үзе аңлатты. Аңларлык итеп аңлатты. Син дә белеп тор, дим, давыл куптарудан мәгънә күренми.

Сөйләшүен тәмамлап, ул яңадан Рәфгать ягына борылды.

— Мин җиңдем, дип масаеп китсәгез, җиңелерсез. Сөйләгән сүзләрегезне хәтеремә язып куям. Без әле очрашырбыз. Бүгенге сүзләрегезне аяк астында таптасагыз, кабергә кергәнче онытмаслык итәрмен...

«Без әле очрашырбыз»... Бүлек начальнигының бу сүзләре Рәфгатьне озак-озак эзәрлекләп йөрде.

Институт директоры Илья Александрович Бувайло белән киңәшәме, бүлек конструкторлары белән башкарылган эшләрне анализлыймы, яңа җиһазларны производство шартларында сыныймы — һаман да шул «без әле очрашырбыз» колакка ишетелә сыман. Бүлек эшләгән машиналар СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә күрсәтелә башлады, алтын медальләр белән дә бәяләнде. «Лениногорскнефть» идарәсенең Куакбаш мәйданын комплекслап автоматлаштырырга керештеләр.

«Пат-Нефтяник» телемеханик системасы нефтьчеләр өчен яңа дөнья ачты. Мәйданны үзләштерү вакыты ике тапкыр кимеде, яңалык — бер миллион 400 мең сум экономия бирде. Илебездә нефть чыгару производствосын фәнни-техник ачышлар нигезендә өр-яңадан коралландыру өчен үрнәк булды ул.

Партиянең XXIV съездында аны тормышка ашыруның конкрет программасы билгеләнде. 120 промыселны комплекслап автоматлаштыру каралган иде. Ул уңышлы тормышка ашырылды, тугызынчы бишьеллыкта 137 промысел автоматлаштырылды. Алардан елына 347 миллион тонна нефть алына. Адреслары: Татарстан, Башкортстан, Әзербәйҗан, Көнбатыш Себер.

«...Нефть чыгару производствосын фән-техника казанышлары нигезендә яңадан коралландыруның гомуми экономик нәтиҗәсе — бер миллиард 300 миллион сум» дип яздылар «Правда» газетасында Ленин премиясе лауреатлары, академиклар Крылов һәм Патон.

Эшләгән кешенең эше бетми. Конструктор Гайнетдинов: «Эзләгәнемне таптым, министрлыкның бүлек начальнигы белән генә түгел, министрның үзе белән очрашсам да, курыкмыйм хәзер», дип тукталып калмады. Унынчы бишьеллыкның колачы да бүтән, таләбе дә бүтән. Машиналарны тагын да куәтлерәк, «акыллырак» итәргә кирәк, алар теләсә нинди очракта да үзләре «карар чыгарып», үзләре үк хәрәкәт программасын билгеләсеннәр. Әйе, әйе, җиһазлар сыйфат ягыннан бөтенләй яңа баскычка күтәрелсен.

Рәфгать дөньясын онытып ватманга сызымнар төшерә иде.

— Директор чакыра! — диделәр.

Бүлек начальнигының керүен Илья Александрович көтеп тә тормаган, каршыга чыккан.

— Әле генә Мәскәүдән сөенечле хәбәр әйттеләр,— диде ул, коридор буйлап килә-килә.— 1976 елгы Ленин премиясе лауреатлары арасында син дә бар, кадерлем. Котлыйм үзеңне, барыбыз өчен дә мәртәбә бу. Улым кебек иттереп кысып кочаклыйм әле үзеңне.

— Барысы өчен дә мең-мең рәхмәт, Илья Александрович, кечкенә инешләрдә йөзгән көймәне зур диңгезгә чыгардыгыз, давыл вакытларында да курыкмыйча йөзәргә өйрәттегез.

— Сәләтеңне беренче эшеңдә үк күрсәткән идең, чын көрәшче булуыңны да расладың. Бераз сәеррәк тә шикелле: күрер күзгә тыныч, мөлаем, ә үзең, теге Мәскәүле иптәш әйтмешли, нефть ташкыныннан һич кенә дә ким түгел.

**Клара Таҗиева,**
музыка белгече

# ТАТАР МУЗЫКАСЫ КЛАССИГЫ

*Иҗат портретына эскизлар*

Профессиональ композиторларыбызның беренче буыны өлешенә гаять җаваплы бурыч — татар совет музыка сәнгатенең нигез ташларын салу бурычы төште. Алар халыкның музыка традицияләрен җирлек итеп алып, музыка сәнгатен бик кыска тарихи вакыт эчендә моңарчы күрелмәгән биеклекләргә күтәрергә, халык җыручылыгының милли стихиясен классик музыка сәнгате жанрлары һәм формалары белән синтезлаштырырга, идея эчтәлеге һәм сәнгатьчә кыйммәте, халыкчанлыгы ягыннан киләчәк буын иҗатчы-музыкантлары өчен таяныч һәм этәргеч бирерлек әсәрләр язарга, формасы, стиле һәм музыкаль теле белән яңа заманга аһәңдәш, яшь совет сәнгате алдына куелган максатларга лаек рухи хәзинәләр тудырырга тиешле булдылар.

Композитор Мансур Мозаффаров өнә шул өлкән буын музыка эшлеклеләребезнең иң күренеклеләреннән берсе иде. Музыка иҗатының алда әйтелгән һәр яссылыгында ул тирән эз салып калдырды, халык көйләрен эшкәртүдән башлап, җырлар һәм романслар кебек кече формаларда да, опера, симфоник поэма һәм инструменталь концерт кебек катлаулы, эре жанрларда да зур талант нуры белән балкыган әсәрләр иҗат итте. Кайсы жанрдагы әсәрләрен алма, М. Мозаффаров милли художник буларак кабул ителә, иҗатының тамырлары халыкка барып тоташа. Аның музыкаль теленең халыкчанлыгы халык җырын кабатлауда, аңа сукырларча иярүдә түгел, ә халык җыр сәнгате, җыручылыгының эчке хасиятләрен тирәнтен үзләштерүдән килә.

Үсмер чагыннан алып, М. Мозаффаров бөтен гомерен татар музыкасына багышлый. Төрле инструменталь ансамбльләрдә уйнаучы гади музыкантмы, театр оркестрларында дирижер яисә радионың музыкаль тапшырулар редакторымы, музыка теориясе буенча укытучымы — һәр җирдә ул ихлас күңелдән бирелеп эшли, ихтирам һәм хөрмәт казана. Ә композитор буларак исә ул татар совет профессиональ музыка сәнгатенең нигезләрен салышты, музыка образлары аша чынбарлыкны күзаллавыбызны алга этәрде һәм тирәнәйтте.

Мансур Мозаффаров иҗат иткән әсәрләрнең үзенчәлеге, барыннан да элек, үз халкының сәнгатьчә фикерләвендәге лирик җылылыкны, самими, тирән хиссиятне ачуда чагыла. Бу, әлбәттә, композиторның эмоциональ-психологик характер сыйфатларыннан, шәхес буларак искиткеч дәрәҗәдә тыйнак һәм кешелеклелегеннән, илен һәм халкын тирәнтен яратуыннан, гаҗәеп бай мелодик талантыннан килә.

Мансур Мозаффаров 1902 елда Казанда туган. Әтисе бик иртә вафат була. Малай — әнисе, танылган шагыйрә, кызлар мәктәбендә укытучы Мәһруй Мозаффария тәрбиясендә үсә. Мансур бик кечкенәдән китап кибетендә йомышчы малай булып эшли башлый. Композиторның үз сүзләре буенча, ул елларда Казанда Габдулла Тукайны, Салих Сәйдәшевне очратулары аның бала чагының иң шатлыклы тирән хатирәләре булып күңелендә сеңеп калган.

Башлангыч белемне ул мәдрәсәдә ала. 1916 елда учительская школага укырга керә. Мәктәпне тәмамларга өлгерми, 1919 елда үз теләге белән Кызыл Армия сафына баса. Шул ук елларда ул Казан музыка училищесының кларнет классында да белем ала. 1923 елда Мансур Мозаффаров Мәскәүгә консерваториягә укырга китә. Авыруы сәбәпле укуын берничә тапкыр бүләргә мәҗбүр була. Консерваториянең композиторлык факультетында этнография бүлеген тәмамлагач, 1931 елда ул Татарстан радиокомитетына эшкә җибәрелә.

Иҗат эшчәнлеген яшь композитор халык җырларын эшкәртүдән башлый. Утызынчы еллар башында инде симфоник оркестр өчен беренче оригиналь әсәрләрен — Увертюра һәм Сюитасын, беренче җырларын һәм романсларын яза. 1933 елда М. Мозаффаровны Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт студиясенә музыка теориясе буенча укытучы итеп чакыралар. Бер үк вакытта ул Татар опера студиясендә дирижерлык эшен алып бара, үзе дә яңадан-яңа әсәрләр иҗат итә. 1939 елда композитор, опера студиясен тәмамлаучылар белән бергә, Казанга кайта һәм Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли башлый. Бөек Ватан сугышы елларында Мансур Мозаффаров — Культура министрлыгы каршындагы фольклор кабинеты, Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясе хезмәткәре. Казанда консерватория ачылганнан соң ул анда эшкә күчә, башта укытучы, аннары доцент, музыка теориясе һәм композиция кафедрасы мөдире булып эшли.

Илленче еллар — композитор иҗатының чәчәк аткан чоры. Бу елларда ул иң яхшы симфоник әсәрләрен — халкыбызның атаклы уллары Г. Тукай һәм М. Вахитов истәлегенә багышланган поэмаларын, скрипка һәм оркестр өчен концертларын, Ленин, Ватан, замандашларыбыз турында күп санлы җырларын яза. Композиторның эшчәнлеге партия һәм хөкүмәтебез тарафыннан югары бәя ала: ул Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнә, аңа Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты, Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә. 1952—1958 елларда ул Казан хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы депутаты итеп сайланды.

Тирән шигърияткә ия булган иң талантлы композиторларыбыздан берсе, татар совет музыкасы классигы Мансур Әхмәт улы Мозаффаровны бары алтмыш дүрт яшендә үлем бездән алып китте.

Мансур Мозаффаровның иҗаты совет строе, яңа чынбарлык белән бергә үсте һәм җитлекте. Бу иҗат үзе яңа эпоха кешесенең рухи дөньясындагы тамырдан үзгәрешне чагылдыра. Ул бер тавышлы халык җырыннан югары профессиональ сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелде, милли музыка сәнгате төрләрен үстерүдәге уңышларын симфония жанрында гомумиләштерүгә иреште.

М. Ә. Мозаффаровның тормыш һәм иҗат юлын күздән кичергәндә, композиторның һәр чорда даими рәвештә халык җырына мөрәҗәгать итүен күрербез. Халык җыры һәм көйләренә ул композитор өчен иҗат азыгы бирүче чыганак дип карый. Халкыбыз җырлары хакында бөек татар шагыйре Г. Тукай фикерләрен иҗатында даими юнәлеш итеп ала. Музыка аңлаешлы булсын өчен халык иҗатын җентекләп

өйрәнергә кирәк, дип саный ул. М. Мозаффаров үзе барлыгы йөздән артык халык көен нотага теркәп калдыра, шуларның сиксән икесе «Татар халык җырлары» исеме белән 1964 елда Мәскәүдә басылып чыккан җыентыкка кертелгән [1].

Мансур Мозаффаров халык көенең нечкәлекләрен гаҗәеп үткен тоя, аның орнаментлары байлыгын, катлаулы һәм нәфис борылыш-бизәкләрен оста тотып ала белә, шуңа күрә ул язып калдырган көйләр иң тулы һәм төгәл башкарылган язмалардан санала. Фольклор материалын нотага язу-теркәүдән тыш композитор халык җырларын сәнгатьчә эшкәртүгә дә гаять зур көч куя. Аның мондый хезмәте дә йөздән артык исәпләнә. Әгәр композиторның күп көйләрне берничә тапкыр һәм кайта-кайта эшкәртүен, һәр юлы көйнең рухына һәм характерына якынрак килергә, аны тулырак ачарга, баетырга ярдәм итә торган яңа нюансларны табуын искә алсак, бу өлкәдә аның нинди зур көч сарыф итүен аңларбыз. Мисалга, М. Мозаффаров эшкәртүендә популярлашып, халыкның гаять зур мәхәббәтен казанган «Сибелә чәчәк», «Галиябану», «Зиләйлүк» һ. б. көйләрне алу да җитә. Халык җырларын композитор фортепианога кушылып җырлау өчен дә, аккомпанемент белән хор, яисә хор өчен генә, шулай ук кыллы квартет белән башкару өчен дә эшкәртә. Мәсәлән, хор өчен ул «Тәфтиләү», «Сибелә чәчәк», «Казан сөлгесе» һ. б. көйләрне эшкәртә, ике скрипка, альт һәм виолончельдән торган кыллы квартет өчен татар халык җырлары темаларына ун пьесадан торган цикл төзи. Бу әсәрләрдә композиторның халык көйләре белән гаять сак эш итүе, фольклорны профессиональ иҗат алымнары белән гаҗәеп нечкә яраштыра белүе таң калдыра. Халык көйләре өстендә шулай тирән һәм җентекле эшләве композиторның үз стиле һәм музыкаль теле формалашуында бик зур роль уйный. Аның үз җырлары һәм романсларының да байтагы халык көйләре белән тыгыз бәйләнештә тора, халык көйләре җирлегенә барып тоташа. Мисал рәвешендә композиторның әле яшьлек чорында ук А. С. Пушкин шигыренә язган «Җырлама син, иркәм» (Ә. Ерикәй тәрҗемәсе) романсын алырга мөмкин.

Кече жанрдагы вокаль музыка төре — романска М. Мозаффаров әле утызынчы елларда ук мөрәҗәгать итә. Мәскәү консерваториясендә укыган чорда А. С. Пушкин шигырьләренә язылган иң яхшы җырга конкурс игълан ителә. Яшь татар композиторлары да конкурста яңа әсәрләре белән катнашалар. М. Мозаффаровның «Җырлама син, иркәм» романсы арада иң яхшыларыннан берсе дип таныла. Бу әсәр Пушкин лирикасына тирән үтеп керүе һәм аны милли музыка стихиясендә гәүдәләндерүе белән аерылып тора, эмоциональ эзлеклелеге, тонус бөтенлеге, көйнең табигый агышы, интонацияләрнең нечкәлеге белән сокландыра. М. Мозаффаровның ул романсын Балакирев, Римский-Корсаков кебек рус композиторларының Пушкин шигърияте белән рухланып язган әсәрләре янәшәсенә куюда да тыйнаксызлык булмас иде. Пушкин шигырьләренә романслар язуын композитор кырыгынчы елларның ахырында да дәвам иттерә. Ул чорда классик поэзия әсәрләренә мөрәҗәгать итү профессиональ музыкабызның сурәтләү чараларын баету, речитатив стиленең мөмкинлекләрен киңәйтү ягыннан да әһәмиятле булды.

М. Мозаффаровның әле утызынчы елларда ук язылган җырларының да байтагы менә инде дүрт дистә ел буе яши бирәләр. «Җиләк җыйганда» (М. Җәлил сүзләре), «Сайра, сандугач» (М. Садри сүзләре), «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Туган ил» (Ә. Ерикәй сүзләре) һ. б. җырлар интонация төзелешендәге яңалык, якты һәм дәртле аһәңнәре белән халкыбыз күңеленә хуш килделәр. Композиторның илленчеалтмышынчы елларда иҗат иткән вокаль әсәрләре татар музыкасы үсешендә үзенә бер сәхифә тәшкил итә. Бу чорда ул утыздан артык җыр яза, аларның иң уңышлылары оркестр белән башкару өчен эшкәртелгән. Җырларда композиторга хас иҗат стиленең иң яхшы сыйфатлары бергә җыелган: тирән эчтәлек тә, ачык аңлаешлы аһәң дә, кеше күңеленә үтеп керә торган ихласлык һәм инсафлык та бар аларда. Бу елларны М. Мозаффаровның җыр иҗатында иң бәхетле чор дип атарга мөмкин. Композиторның җыр өлкәсендә озак еллар туктаусыз эшләве гүзәл нәтиҗәләргә китерә: җыр иҗатында үзенә аерым яңа бер төр — уйланулар дип атарга мөмкин

---

[1] М. Мозаффаров, Ю. Виноградов, З. Хәйруллина. «Татар халык җырлары». Музгиз, Мәскәү, 1964 ел.

булган жанр туа. Татар музыкасында яңа вокаль стиль барлыкка килү дигән сүз иде бу. Яңалык композиторның җыр текстларын сайлавында ук күренде: ул югары гражданлык рухы бөркелеп торган, туган ил, аның гүзәл табигате, яшәешнең мәгънәсе хакында тирән уйлануларга корылган шигырьләргә мөрәҗәгать итә. С. Хәкимнең «Кайда да йөрәктә», «Башка берни дә кирәкми», М. Мазуновның «Туган як», Г. Зәйнашеваның «Мин тормышка гашыйк», «Менәргә иде Урал тауларына» әсәрләренә язылган җырлары әнә шундыйлардан. Аларга тирән гражданлык хисе, лирик-философик яңгыраш, киң һәм салмак хикәяләү интонациясе, акыртын темп, кырыс, сабыр һәм тыенкы ритмнар хас. Инструменталь партиянең роле ул җырларда сизелерлек рәвештә көчәя, әсәрнең эчтәлеген баетуга ярдәм итә. М. Мозаффаров лирикасының фәлсәфи тирәнлек юнәлешендә үсә баруы, бер яктан, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган композиторның иҗади җитлегү чорына керүен, аның үз иҗат юлына билгеле бер йомгак ясауга омтылуын күрсәтсә, икенче яктан, совет кешесенең рухи дөньясын, бүгенге замандашыбыз күңелендә тупланган рухи хәзинәнең колачын һәм гүзәллеген чагылдырырлык көй-яңгырашларны эзләве, шушы юлдагы иҗади табышлары хакында сөйли. Һәм ул җырлар халык хиссиятенә гаҗәеп рәвештә тәңгәл килә. Гражданлылык темасы аларда иң алгы планга калкып чыга, шул ук вакытта алар кешеләрнең табигый күңел тибрәнешләре булып яңгырыйлар, йөрәккә бик тиз барып җитәләр, гүзәллеккә омтылыш хисе тәрбиялиләр. Мисалга композиторның Г. Тукай истәлегенә багышланган җырларын китерергә мөмкин. Г. Зәйнашева сүзләренә язылган «Тукай истәлегенә», «Тукайны сагыну» кебек җырлар халкыбызның үз шагыйренә булган тирән хөрмәтен, шагыйрь исеме һәм ул калдырган рухи мирас белән горурлануын чагылдыралар. «Кайда да йөрәктә» (С. Хәким сүзләре), «Юлым илтә гел яктыга» (И. Фазлуллин сүзләре), «Тибрәнә җыр дулкыннары», «Замандашыма» (Г. Зәйнашева сүзләре), «Бәйрәмнәр» (М. Мазунов сүзләре) һ. б. җырларда да тормышка мәхәббәт, туган җирне сөю хисләре саф һәм якты моң булып агыла. Композиторның заманга, тормышка мөнәсәбәте, оптимизмы ачыктан-ачык гәүдәләнә. М. Мозаффаров үзенең җырларында тынычлык һәм халыклар дуслыгы хакында, яшьлек һәм хезмәт турында, тыныч төзелештә ирешкән җиңүләр шатлыгы, космосны үзләштерү дәвере өчен характерлы булган яңа хис-омтылышлар турында сөйли (мәсәлән, «Айга менәсем килә» җыры). Иҗатының һәр чорындагы кебек, бу елларда да ул туган илебез темасына берничә җыр багышлый. Алар арасында иң уңышлысы — М. Мазунов сүзләренә язылып, гаять киң таралыш алган һәм композиторның җыр иҗаты өлкәсендәге иң гүзәл казанышы булып исәпләнергә лаек «Туган як» исемле җыр-поэма. Халык җыры җирлегеннән, музыкага тереклек бирүче чишмәләреннән аерылмастан, композитор монда киң гомумиләштерүләр югарылыгына күтәрелә, җырның лирик герое гаять киң колачлы шәхес булып гәүдәләнә — фәлән авыл, төгән төбәк кешесе генә түгел ул, ә ил хуҗасы, гражданин.

Бу яңа форма җыр жанрының табигый үсеше нәтиҗәсе буларак барлыкка килә. Чыннан да, мондый киңлекне бары тик хискә бай, тирән эчтәлеккә ия булган көй генә бирә ала иде. Һәм композитор аны гомере буе эзли, озын лирик көйләргә, кыска шәһәр көйләренә, романсларга, элегия, гимн кебек жанрларга мөрәҗәгать итеп, аларның эмоциональ һәм мәгънәви мөмкинлекләрен сыный. Ниһаять, иҗат гомеренең соңгы чорында уйланулар жанрындагы җырларын тудыруга килә. Гомуми сыйфатлары белән бергә, бу жанрга караган һәр җырның, әлбәттә, үз төсмерләре, үзенчәлекле, яңгыраш-аһәңнәре бар.

М. Мозаффаровның җыр иҗаты турындагы сүзне тәмамлап, шуны әйтәсе килә: аларда үзенә бертөрле иркенлек, үтә күренеп торган нәфислек, җиңеллек сизелеп тора. Алар хисләрнең ихлас бәлдерелүе, ачык эмоциональлеге белән күңелне җәлеп итәләр. Композиторның иң яхшы җырларындагы һәр фраза һәм интонация йөрәк серен, тирәндә яткан хис-тойгыны самими төстә турыдан-туры әйтеп бирү рәвешендә кабул ителә. Шуңа күрә ул көйләр кабатланмас аһәң белән, саф һәм эчкерсез яңгырыйлар.

Мансур Мозаффаров — татар музыка сәнгатенең яңа төре — опера сәнгате өлкәсендә дә сизелерлек эз калдырган композитор. Мәгълүм булганча, Г. Әлмөхәммәтов, В. Виноградов, С. Габәшинең иҗади хезмәттәшлеге нәтиҗәсе буларак, 1925 һәм 1930 нчы елларда «Сания» һәм «Эшче» опералары туа. Шул ук чорда А. Эйхен-

вальдның «Дала» операсы да сәхнәгә куела. Татар совет операсын тудыру юлындагы бу беренче тәҗрибәләрдә әле «максатка ярашлы музыкаль-драматургик үсеш һәм ачык гәүдәләнгән образ-характерлар» җитенкерәми [1].

Милли музыка театры оештырылгач, татар опера сәнгатендә яңа чор башланып китә. Татар дәүләт опера һәм балет театры 1939 елда Н. Җиһановның «Качкын» операсы белән ачыла. Операдагы тарихи-героик тема Н. Җиһановның 1940 елда сәхнәгә куелган икенче әсәре — «Ирек»тә дәвам иттерелә. М. Мозаффаровның «Галиябану» операсы исә опера һәм балет театрыбызда куелган өченче милли әсәр була. Бу әсәр белән музыка сәнгатебездә лирик-көнкүреш, лирик-психологик опера юнәлеше башлана. Әсәрнең язылу тарихы шактый кызыклы. Утызынчы елларның икенче яртысында татар композиторларының байтагы опералар язу өстендә эшли. М. Фәйзинең мәшһүр «Галиябану» пьесасын опера либреттосы итеп эшләү уе 1935 елда туа. Озаклап тикшерелгән һәм эшкәртелгәннән соң, Ә. Ерикәйнең либреттосы 1937 елның августында композиторга тапшырыла. Әйтергә кирәк ки, либреттоны эшкәртүдә Мәскәүдә Татар студиясенең әдәби бүлекчәсендә эшләгән М. Җәлил дә катнашкан. Бу хакта без студиянең әдәби эшчәнлеге турында 1937 елның 1 сентябрендә М. Җәлил тарафыннан язылган отчеттан да белә алабыз [2].

«Галиябану» операсы Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә 1940 елның 23 июнендә куела. Әмма әсәрнең язылу тарихы беренче тапкыр башкарылуы белән тәмамланмый. Автор аңа әледән-әле әйләнеп кайта. Композиторның архивында әсәр клавирының һәм партитурасының яңа варианты табылуы да шул хакта сөйли.

Мансур Мозаффаровның бу әсәре М. Фәйзинең татар тормышына тирән үтеп кергән сәхнә әсәренә нигезләнә. Ул — татар театрына музыкаль драмалар жанрын алып килгән әсәр. Шундый пьеса материалы нигезендә опера иҗат итү — гаять четерекле һәм җаваплы бурыч. Операның премьерасыннан соң «Кызыл Татарстан» газетасында чыккан рецензиясендә Г. Кашшаф: «Үлми торган әсәрнең операсы да үлми торган, классик опера булырга тиеш. Бу табигый таләп»,— дип язуы белән бик хаклы иде [3].

Опера сәнгатендә беренче адымнарын гына атлаучы башка республикаларда да опера жанрын үзләштерү сүзле музыкаль әсәрләр аша барганлыгы мәгълүм. «Галиябану» операсы да татар театрындагы шул катлаулы күчеш процессының бер мисалы була. Монда музыкаль драманың эчтәлеге, Асафьев сүзләрен кулланып әйтсәк, «интонация драматургиясе» чаралары белән ачыла.

Опера өч пәрдәдән, биш күренештән тора. Әсәрнең драматургиясе ачык һәм гади, ул Хәлил-Галиябану белән Исмәгыйль-Бәдри линияләренең бер-берсенә капма-каршы куелуына корылган. Әсәрнең төп драматик үсеш моментлары, конфликты операда шактый тулы гәүдәләнә. Интонацияләр ягыннан бу конфликт Галиябану белән Хәлилнең халык җырларына якын торган эчкерсез лирик көйләренең декламацион һәм речитатив характердагы, кискен, кырыс яңгырашлы Исмәгыйль арияләре һәм инструменталь темаларына капма-каршы куелуында гәүдәләнә. Спектакль барышында һәр ике тема үсә, катлаулана. Галиябануның әти-әнисе образлары кыска җыр элементларын куллану аша чишелә, конфликт үсә барган саен ул көйләрнең интонация төзелешенә Исмәгыйль темасына хас борылышлар үтеп керә башлый.

Опера тамашачыга яхшы таныш булган «Галиябану» җыры белән башланып китә. Алга таба ул уен кораллары башкаруында героиняның лейтмотивы булып әверелә. Ике яшь йөрәкнең бер-берсенә мәхәббәте темасы да шушы көй аша гәүдәләнә. Галиябануның эчке дөньясы, эчкерсез, тирән хисләре беренче тапкыр «Уйламаган җирдән» дип башланган ариясендә ачыла. Талгын агышлы, ягым-

---

[1] Совет Татарстанының музыка культурасы. Проф. Г. И. Литинский редакциясендә мәкаләләр җыентыгы. Рус телендә, Мәскәү, 1959 ел, 80 бит.
[2] СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты архивы, 10 фонд, 2 тасвирлама, саклау берәмлеге 20.
[3] «Кызыл Татарстан», 1940 ел, 22 август саны.

лы көй интонация ягыннан күпмедер дәрәҗәдә халык җырын хәтерләтә, шул ук вакытта ул оригиналь сыйфатларга бай булган уйлану характерындагы романска якын тора.

Операның финалында без кабат халык көен ишетәбез. М. Фәйзи әсәрендәгечә, сөйгән егетенең тынсыз гәүдәсе өстендә Галиябану әлеге таныш җырны җырлый. Көткән бәхетле тормышның күз алдында җимерелүе көйне дә үзгәртергә, сындырырга тиеш иде кебек. Ләкин мәхәббәтне юк итеп булмый, ул үлемсез, һәм җыр да, шуны раслагандай, якты һәм саф яңгырый. Чынлыкта, җырның бөтен колоритын саклап җырлау монда тирән тәэсир итүче драматургик алым булып әверелеп китә, зур психологик киеренкелек тудыра.

«Галиябану» операсы чын-чыннан милли әсәр булды. Музыкаль драматургиясендәге аерым кимчелекләренә карамастан, автор калку образлары, конфликтлы ситуацияләре, үз йөзе һәм аһәңе булган, бөтенлекле, төгәлләнгән әсәр тудыра алган. Композитор үз халкының музыкаль табигатен нечкә тоя һәм иҗатында аңа кыю рәвештә таяна. Халык җырларының сюжетларын яхшы белгән хәлдә, ул халык сәнгате хәзинәсеннән оста файдалана.

1943 елда Мансур Мозаффаров үзенең икенче операсын — «Зөлхәбирә»не тәмамлый. Бу әсәрен дә ул халык моңнары чыганакларына таянып иҗат итә. Әмма «Галиябану»да халык көйләре әсәрнең тукымасына кертелеп, турыдан-туры файдаланылган булса, икенче операда без принципиаль яңалык белән очрашабыз. Монда бер генә халык көе дә юк диярлек. Һәм шул ук вакытта ул — чын милли формага төрелгән әсәр, музыкаль сурәтләүнең классик чаралары монда халык моңнары рухы белән сугарылган. Операның драматургиясендә симфонияләштерү методларына зур урын бирелә. Бу исә композиторның опера жанрында яңа зур адым атлавын күрсәтә. Әсәрнең драматик сюжет нигезен, эчтәлектәге драматизмны яңа музыкаль чаралар, гомумиләштерелгән, симфоник югарылыкка күтәрелә барган аһәңнәр аша ачуга омтылыш нык сизелә.

Мансур Мозаффаров симфоник музыка өлкәсендәге беренче тәҗрибәләрен әле утызынчы елларда ук ясый. Аның бу эше дә халык җырын тирәнтен өйрәнүдән башлана. Ул чорда ук инде композиторның симфоник стиленә хас сыйфат — инструменталь музыканың халык көйләре белән тыгыз бәйләнгән булуы төсмерләнә. Тик шулай да бу өлкәдә зур уңыш аңа озак еллардан соң гына килә. Аерым көйләрне, мотив һәм борылышларны әсәрдә турыдан-туры файдалану этабы аша үтеп, ул интонация закончалыклары, эчке табигате белән халык көйләренә аваздаш, әмма тулысынча оригиналь булган темалар тудыра. Илленче елларда композитор халкыбызның сөекле уллары Габдулла Тукай һәм Мулланур Вахитов истәлегенә багышланган симфоник поэмаларын яза. Бу әсәрләрендә ул якты киләчәк идеаллары өчен көрәштә гомерләрен корбан иткән каһарман шәхесләрнең көчле эмоциональ һәм эпик яңгырашлы музыкаль образларын тудыра. Һәр ике поэманың эчке драматургиясе гаҗәеп киеренке, һәр икесе мелодик материалга бай. Автор халык көйләре интонацияләреннән кыю файдалана. Мәсәлән, Г. Тукайга багышланган поэмада без шагыйрьнең яраткан җырларыннан берсе «Әнкәм кабере янында» дигән җырның көен, икенче әсәрдә һәркемгә таныш рус революцион җыры «Смело, товарищи, в ногу» мотивларын ишетәбез. Алар әсәр тукымасына бик табигый килеп керәләр, авторның симфоник фикер сөрешен көчәйтүгә хезмәт итәләр. Бу поэмалары белән М. Мозаффаров профессиональ иҗатның иң югары баскычларына күтәрелүен раслый, һәм ул әсәрләр хаклы рәвештә татар совет музыкасы классикасы хәзинәсендә үз урыннарын алдылар.

Болардан тыш, М. Мозаффаров илленче-алтмышынчы елларда «Туган ягым» исемле симфоник поэма, симфониэтта, скрипка һәм оркестр өчен ике концерт иҗат итә. Югары художестволы сыйфатлары, идея-эстетик кыйммәте, халыкчан көйләргә байлыгы, нәфислеге белән скрипка һәм оркестр өчен язылган концертлары аеруча тиз популярлык казанды. Борынгы һәм хәзерге заман татар, башкорт халык җырларын бөтен нечкәлекләре белән белүе композиторга, фольклор материалының аерым фрагментларын гына файдаланып, шул нигездә тирән эчтәлекле симфоник темаларны үстерергә мөмкинлек бирә. Киң таралган рус һәм татар совет җырлары

белән уртак интонация һәм аһәңнәр концертларны һәркем күңеленә якын, аңлаешлы итә. Аларда күтәрелгән музыкаль темаларның байтагы эпик яңгыраш ала, кайбер кисәкләре (мәсәлән, беренче концертның кереш темасы, икенче концертның икенче өлеше) сурәтле образларны күз алдына бастыра. Инструменталь музыкада хәтергә сеңеп кала торган калку образлар тудыру осталыгы композиторның шактый еллар буе опера жанры өлкәсендә эшләвеннән дә килә.

Шулай итеп, инструменталь музыка иҗатын даими төстә җыр белән бергә бәйләп алып баруы, классик сәнгать тәҗрибәсен милли музыка белән органик рәвештә куша белүе композиторны югары иҗади казанышларга алып килә.

Композитор Мансур Мозаффаров яңа тарихи чор тарафыннан үзалдына куелган бурычны намус белән үтәде. Аның иҗат мирасы — совет власте елларында формалашып, профессиональ сәнгатьтә гүзәл казанышларга ирешкән татар музыкасы классик хәзинәсенең аерылгысыз өлеше. Татар композиторлары арасында беренчеләрдән булып, ул халык музыка культурасының иң кыйммәтле элементларын гомумиләштерү, аны рус һәм көнбатыш классик сәнгатенең күп төрле форма һәм жанрлары белән бергә бәйләү нигезендә үз иҗат стилен тудырды.

М. Мозаффаровның иҗат мирасы гаять бай һәм күп төрле. Музыканың һәр жанрында ул бары тик үзенә генә хас сурәтләү чараларын эзли, яңа буяулар, образлар таба, яңа сукмаклар сала. Яшь буын композиторларының күбесе бу эзләнүләрне дәвам иттерәләр, табышларны иҗади төстә үстерәләр. Мәсәлән, скрипка өчен лирик рухтагы концерт жанрын М. Яруллин һәм Р. Билялов күтәреп алдылар. Р. Еникеев М. Мозаффаровның тирән фәлсәфи лирик җыр иҗаты юнәлешен үстерә. А. Монасыйповның кайбер җырлары хакында да шуны әйтергә мөмкин. Сәнгатьтә үз эзләрен салганда, алар өлкән остазларының ачышларыннан да иҗади файдаланалар. Мансур Мозаффаровның үз әсәрләре генә түгел, нигезен ул салган күркәм традицияләр дә яши дигән сүз бу.

------------

I

# ИВАН ФРАНКО ӘСӘРЛӘРЕ ТАТАРСТАНДА

Украин һәм татар әдәбиятларын вакыт сынауларын үтеп килгән дуслык, тугандашлык җепләре бәйли. Ләкин бу ике әдәбият арасындагы күп кырлы элемтәләр әле бүгенгәчә җитәрлек өйрәнелмәгән.

Украин һәм татар халыкларының әдәби-мәдәни багланышлары Октябрь революциясенә кадәрге чорда ук башлана. Патша самодержавиесенең төрле милләтләр арасында дуслык элемтәләре урнашуга ачыктан-ачык каршы юнәлтелгән политика алып баруына да карамастан, татар һәм украин әдәбиятларының халык мәнфәгатьләре өчен көрәшкә күтәрелгән алдынгы вәкилләре үзара аралашуга омтылалар. Аларны уртак язмыш, азатлык һәм тигезлеккә ашкыну, милли кимсетелүләргә каршы протест хисе берләштергән.

Шул уңайдан украин халкының бөек улы Тарас Шевченконың 1854 елның октябрендә сөргеннән кайтышлый Казанда тукталуы әһәмиятле факт булып тора. Көндәлегендә язып калдырган истәлекләренә караганда, шагыйрь ике көн дәвамында шәһәр белән танышып йөри, аның хәтеренә аеруча җирле халыкның авыр язмышы уелып кала. Шевченконың, Иван Посяда һәм Георгий Андрузскийлар язмышы белән кызыксынып, Казан университетына баруы да мәгълүм. Бу ике студент, украин яшьләре арасында алдынгы идеяләр пропагандалауда актив катнашулары өчен, Киев университетыннан Казанга сөрелгән була.

Үз чиратында, безгә татар әдәбияты классигы Г. Ибраһимовның да 1913 елда Киевта тукталып, анда студентларның яшерен оешмаларында катнашуы мәгълүм. Г. Ибраһимовка политик эшчәнлектә гаепләнеп, берничә ай Киев төрмәсендә утырып чыгарга да туры килә. Шул арада татар язучысы малорус халкының авыр язмышы, кайгы һәм сагышлары җырчысы, мәшһүр шагыйрь Шевченко иҗаты белән якыннан таныша.

Киевта булган очрашулар һәм бигрәк тә Шевченко иҗаты белән танышу Г. Ибраһимовка зур тәэсир ясый, аның революцион активлыгын үстереп җибәрә. Шуңа күрәдер, Шевченконың 100 еллык бәйрәме көннәрендә, юбилейны билгеләп үтү патша цензурасы тарафыннан тыелуга да карамастан, Г. Ибраһимов украин халкының мәшһүр шагыйре турында язып чыгуны үзенең гражданлык бурычы итеп саный. «Йолдыз» газетасының 1914 елгы 25 февраль санында басылган мәкаләсендә, автор татар җәмәгатьчелегенең игътибарын, барыннан да элек, Шевченконың хөррият каһарманы, патша самодержавиесе тарафыннан изелгән һәм кимсетелгән халыкның иҗтимагый-политик омтылышлары җырчысы булуына юнәлтә. Бу бер дә очраклы хәл түгел. Г. Ибраһимов каһарман шагыйрьнең һәм барлык украинлыларның язмышында, милли кайгыларында татар халкының тормыш шартларына зур якынлык күрә. «Ятимнәр бер-берен тиз аңлыйлар,— дип яза ул.— Шевченконың халкы белән безнең татарның язмышында күп уртак нәрсә бар. Шевченконың йөрәгендә кайнаган, әле бу көндәге малорус мөтәфәккирләренең җанын әрнеткән күп дәрт һәм хәсрәтләр бездә, безнең татарда да бар...» Шул рәвешчә, татар язучысы Шевченко әсәрләрендә чагылган иҗтимагый көрәш мотивларының татар халкы өчен дә уртак булуын күрсә-

теп, аның иҗатын өйрәнүнең үз халкы өчен нинди зур әһәмияткә ия булуын нигезләп чыга. Г. Ибраһимовның Шевченко әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү эшен оештыруда да зур активлык күрсәтүе мәгълүм.

Украин әдәбиятыннан татарчага тәрҗемә ителгән беренче әсәр — И. Франконың «Урман һәм утлавык» хикәясе. Ул украин әдәбияты классигының рус телендә чыккан беренче җыентыгыннан алынган. Хикәяне рус-татар мәктәбе укытучысы, 1905—1908 елларда социал-демократик брошюралар тәрҗемә итүдә дә актив катнашкан Борһанетдин Юскаев тәрҗемә иткән.

Аерым китап булып чыккан революцион эчтәлекле бу әсәрнең Беренче рус революциясе елларында ук (1906) дөнья күрүе аеруча әһәмиятле факт була. Хикәя татар әдәбияты һәм халык иҗаты үрнәкләре белән беррәттән дөнья һәм бигрәк тә рус әдәбияты классиклары әсәрләрен киң пропагандалаган бертуган Шәрәфләр матбагасы «Мәгариф»тә чыгарыла. Аның татарлар арасында революцион идеяләр таратуда зур роль уйнаган Ермолова типографиясендә басылуы да очраклы хәл түгел. И. Франко хикәясе басылып чыккан көннәрдә ук И. В. Ермолова, тикшерми-хөкем итми, Казаннан куыла. Архив документлары күрсәткәнчә, ул үз типографиясендә революция рухы белән сугарылган әдәбият бастыруда гаепләнгән.

Беренче рус революциясе чорында болай да көчсезләнгән патша самодержавиесе халык массаларының басымы астында кайбер чигенүләр ясарга мәҗбүр була. Даһи Ленин Бөек Октябрьның «генераль репетициясе» дип атаган бу революциянең иң зур казанышларыннан берсе, мәгълүм булганча, төрле милләт вәкилләре арасында үзара дуслык һәм тугандашлык хисләре урнашу. Ә бу хисләр исә, милли әдәбият һәм культураларның тар рамкалардан чыгуына китереп, үзара аралашуга булган омтылышларын бермә-бер үстереп җибәрә. Әдәбиятка шушы революция белән килеп кергән Г. Тукай бер дә юкка гына «Иң бөек максат безем: һәр мәмләкәт — һәр Россия!» дип язмаган, әлбәттә.

Шунысы кызык, татар халкының сөекле шагыйре әйткән бу сүзләр И. Франконың 1882 елда язылган тәнкыйть мәкаләләреннән берсен хәтергә төшерә. «Украинлылар тәрәзәсендә ирек һәм азатлык кояшы үзеннән-үзе генә елмаймас. Моның өчен барлык славян халыкларының, Европаның һәм бөтен кешелекнең ихтыяры берләшү шарт», кебек юллар бар ул мәкаләдә.

Украин һәм татар әдәбияты классикларының, төрле чорларда яшәүләренә дә карамастан, югарыда искә алган сүзләрендә чынлап та зур уртаклык бар, ул — һәр ике авторның да төрле милләтләр арасындагы дуслыкның, бердәмлекнең ирек һәм азатлык өчен көрәштә иң олы көч булуына ышаныч.

Беренче рус революциясе елларында Казан эшчеләре һәм студентлары арасында И. Франконың рус телендә чыккан әсәрләре дә зур популярлык казана. Бу елларда полиция Казанда әледән-әле үткәргән тентүләр вакытында, легаль булмаган әдәбият белән бергә, И. Франко әсәрләре дә табыла тора. Мәсәлән, шундый китапларның берсе университетның Лобачевский исемендәге китапханәсендә, сирәк очрый торган китаплар бүлегендә саклана. И. Франко әсәрләреннән тупланган әлеге җыентыкка Казан жандарм идарәсенең тамгасы сугылган.

И. Франконың хикәя һәм очерклары яңа революцион күтәрелеш елларында да Казан эшчеләре арасында легаль булмаган әсәрләр белән беррәттән кулдан-кулга йөреп укыла. Р. И. Нәфиков күрсәткәнчә, И. Франко әсәрләре Казан большевиклар оешмасының эшче М. Жаков фатирында урнашкан яшерен китапханәсендә дә булган. Бу китапханә кара реакция елларында эшчеләр арасында марксистик идеяләр пропагандалау нияте белән оештырыла. Ләкин ул озак эшли алмый — 1912 елда жандарм идарәсе кулына эләгә. Яшерен китапханәдә В. И. Ленин, К. Маркс, Ф. Энгельс хезмәтләре, күпләгән брошюралар, И. Франко, Золя, Гюго, Горький, Короленко, Серафимович, Вересаев, Сергеев-Ценский кебек язучыларның әсәрләре тупланган була.

1911 елда Казан университеты студентлары кулына И. Франко чыгарган «Життє і слово» журналының тулы комплекты килеп керә. 1894—1896 елларда Львовта чыгып, аннан полиция тарафыннан ябылган бу әдәби, фәнни һәм политик журнал прогрессив карашлы студентларда зур кызыксыну уята. Чөнки арада, И. Франконың социализм

идеяләрен пропагандалаган күп кенә әдәби һәм публицистик әсәрләре белән бергә, украинлыларның Л. Украинка, М. Коцюбинский, В. Шашкевич, П. Грабовский, М. Павлык кебек алдынгы фикер ияләре, шагыйрь һәм язучыларның бай мирасы тупланган була. Шулай итеп, әлеге журнал университет студентларына Украина әдәбиятының күп кенә күренекле вәкилләре һәм аларның әсәрләрендә чагылган прогрессив идеяләр белән танышу мөмкинлеге тудыра. Бу авторларның әсәрләре, нигездә, тыелган әдәбият исемлегенә кертелүен дә искә алсак, И. Франко журналының студентлар арасында алдынгы фикерләр пропагандалауда нинди әһәмиятле роль уйнавын аңлавы кыен түгел.

Журнал университет студентлары кулына ничек килеп кергән соң?... Бу турысынча Казан университетының славян филологиясе кафедрасы мөдире, профессор Н. М. Петровскийның шәхси инициативасына бәйләнгән. Н. Петровскийның берничә еллар буе И. Франко белән хат алышып торуы да мәгълүм. Казан университеты профессорының украин әдәбияты классигына язган хатлары хәзер Украина Фәннәр академиясенең Шевченко исемендәге институтында И. Франконың шәхси архивында сакланалар. Ә менә 1921 елда Казанда вафат булган Н. Петровский архивының кайда икәнлеге бүгенгәчә билгесез, анда бит И. Франконың үз кулы белән язган дистәләрчә хаты сакланырга мөмкин.

И. Франко әдәбият һәм сәнгатьнең халыклар арасында дуслык хисләрен ныгытуда көчле чара булуын тирәнтен аңлап иҗат иткән. Публицистик мәкаләләренең берсендә «әдәбият, — дип яза ул, — төрле милләт вәкилләренең бер-беренә кырын каравын юк итүдә, алар арасында үзара дуслык, тугандашлык хисләрен ныгытуда, массаларны интернационалистик рухта тәрбияләүдә иң көчле чараларның берсе». Менә шуңа күрә дә ул милли әдәбиятларның тар рамкаларда гына бикләнеп ятуларына каршы чыгып, тәрҗемә эшен активлаштырырга чакыра, тәрҗемәнең милли әдәбият һәм милли аң үсешендә никадәрле зур әһәмияткә ия булуын күрсәтеп чыга. «Тәрҗемәләр, — дип яза ул, — халыклар арасындагы үзара мөгамәләләрне яхшырта, аларны бер-беренә якынайта». И. Франко үзе дә дөнья әдәбияты классикларыннан украин теленә дистәләрчә әсәр тәрҗемә итеп калдыра.

Ләкин украин әдәбияты классигының тәрҗемә өлкәсендәге бөтен омтылышлары да тормышка ашмый, моңа төп тоткарлык, әлбәттә, патша цензурасы була. Тәрҗемә эшенең ул хыялланганча, гомуми төс алып, киң җәелеп китүе өчен кирәкле шартлар Бөек Октябрь революциясе җиңүе нәтиҗәсендә генә туды. Совет власте елларында украин язучыларының татар телендә чыккан җыентыклары саны алты дистәдән артып китте. Татар укучысы, илебезнең башка халыклары кебек үк, бүген үзенең ана телендә И. Франко һәм Т. Шевченко, М. Коцюбинский һәм Л. Украинка, О. Гончар һәм А. Довженко, П. Тычина һәм М. Рыльский, Н. Рыбак һәм Ю. Яновский, А. Малышко һәм А. Корнейчук кебек украин язучыларының әсәрләрен укый.

И. Франко әсәрләре генә дә Октябрьдан соң татар телендә берничә тапкыр аерым китап булып басылып чыкты. Мәсәлән, 1948 елда дөнья күргән җыентыкка авторның 11 автобиографик хикәясе тупланган, аларның күбесе борислав циклыннан. Әлеге җыентыкка «Яктылыкка», «Урман һәм утлавык», «Ташчы», «Көтүче» кебек идея эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан да зур әһәмияткә ия булган хикәяләрнең кертелүе аеруча куанычлы күренеш. Г. Бәширов тәрҗемә иткән әлеге җыентыкка шул ук елны «Совет әдәбияты»ның 6 нчы санында Г. Камилов рецензия язып чыга. Рецензент җыентыкка кергән хикәяләргә һәм аларның тәрҗемәләре сыйфатына югары бәя бирә һәм украин әдәбияты классигының татар укучылары арасында да зур популярлык казануына алдан ук ышаныч белдерә. Әлеге ышаныч турысында аклана — 1955 елда И. Франконың татар телендә тагы да күләмлерәк җыентыгы чыгу шул хакта сөйли. Игътибар итик, 14 әсәр кергән бу җыентыкның тиражы инде 10 меңгә җиткән.

Татарстан китап нәшриятында 1951 елда И. Франконың тагы бер әсәре — «Урланган бәхет» пьесасы басылды. Драматург Р. Ишморат тәрҗемә иткән әлеге пьесаның Әлмәт драма театрында берничә ел сәхнәдән төшмичә уйналуы, шунда ук украин әдәбияты классигының республикабызда никадәр популяр булуын күрсәтүче факт булып тора.

И. Франко әсәрләре Татарстан вакытлы матбугаты битләрендә дә әледән-әле күренеп килә. Мәсәлән, 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында аның Кави Нәҗми тәрҗемәсендә «Пан икмәге» хикәясе басылуын күрсәтеп узарга мөмкин. 1956 елда журнал сәхифәләрендә украин әдәбияты классигының шигырьләре һәм «Төрмәләрдән курыкмагыз» сонетына урын бирелә. Ә. Исхак тәрҗемә иткән ул шигырьләр И. Франконың «Калкулыклар, үзәнлекләр» һәм «Минем Измарагд» циклларыннан алынган.

Татар вакытлы матбугаты И. Франко иҗатына караган әдәби тәнкыйть һәм библиографик мәкаләләргә дә зур урын биреп килә. Югарыда искә алынган рецензияләрдән тыш, 1941 елда «Совет әдәбияты» һәм «Кызыл Татарстан» да, 1956 елда «Совет Татарстаны» газетасында чыккан күләмле тәнкыйть мәкаләләре дә татар укучыларына И. Франко иҗатының күп кенә үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итте. Ул мәкаләләр һәркайсы украин әдәбиятының күренекле белгечләре тарафыннан язылган.

Соңгы елларда татар әдәбиятының күп милләтле тугандаш әдәбиятлар белән элемтәсе тагы да үсә һәм ныгый бара. Мәсәлән, 1972 елда басылып чыккан «Украин шагыйрьләре» җыентыгы шуның бер ачык мисалы булып тора. Бу җыентыкка кергән 43 авторның шигырьләрен украин әдәбиятының күптәнге дусты шагыйрь Зәки Нури сайлаган һәм тәрҗемә иткән. Китапны, икеләнүсез, украин әдәбиятының шигъри мозаикасына тиңләргә була. Җыентык украин әдәбияты турында тәрҗемәче тарафыннан язылган җылы сүз белән ачылып китә. Аерым шагыйрьләр һәм шул исәптән И. Франко турында да кыскача биографик белешмәләр дә язылу «Украин шагыйрьләре»нә үзенчәлекле төс биргән.

1976 елның 20 нче ноябрендә илебез халыклары Украинаның күренекле улы, шагыйрь, язучы, драматург һәм ялкынлы публицист И. Франконың 120 еллык бәйрәмен билгеләп уздылар. Бу көнне Татарстан җәмәгатьчелеге Казан композиторы Леонид Любовскийның И. Франко сүзләренә язылган симфония-ораториясен тыңлады. Берничә еллар дәвамында иҗат ителгән бу музыкаль әсәрдә украин шагыйреннең үткән гасырның 80 нче елларда иҗат ителгән революцион рухтагы шигырьләре яңа яңгыраш тапкан — музыка белгечләренең уртак фикере шундый.

И. Франко шигырьләренә язылган күләмле музыкаль әсәр симфония-ораториянең Казан композиторы тарафыннан язылуы, әлбәттә, куанычлы күренеш һәм уйлавыбызча бу очраклы хәл түгел. И. Франко иҗаты Татарстан җирендә элек-электән популяр була. Киләчәктә дә аның әсәрләре, украин һәм татар халыклары арасындагы дуслык, тугандашлык символыдай, Татарстан китап нәшриятында басыла торыр, И. Франко — татар укучыларының яратып укый торган авторларыннан берсе булып калыр.

**И. И. АНДРЕЕВА,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# ИЛЕБЕЗ – КАДЕРЛЕ ҖИРЕБЕЗ...

Революциягә кадәр һәм егерменче елларда чыккан газета-журналларны актарганда, әледән-әле Фазыл Туйкин (Туйкә) имзасы белән басылган материалларга юлыгасың. Характерлары һәм жанрлары ягыннан алар төрле-төрле. Күп кенә мәкаләләрдә ул милли мәктәпләрдәге уку-укыту эшләренең торышы белән кызыксына, аны әдәби тел мәсьәләләре, халык иҗатына кагылышлы проблемалар борчый. Ф. Туйкин әдәбият тарихына караган материаллар җыю белән шөгыльләнә. Ул, мәсәлән, Мәулә Колый иҗатын ачыклау эшенә зур өлеш керткән кеше.

Татар мәдәниятенең төрле тармакларына караган мәкаләләрдән тыш, ул «Шура», «Безнең юл», «Мәгариф» кебек журналларда, шулай ук вакытлы башкорт матбугатында халык иҗаты әсәрләренә нигезләнеп язылган легендалар һәм поэмалар, бик күп шигырьләр һәм җырлар, хикәяләр бастыра. Заманында аның әдәби иҗат эшчәнлегенә Галимҗан Ибраһимов игътибар иткән. Үзе төзегән «Яңа әдәбият» (1914) исемле альманахка, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Дәрдмәндләр белән бергә, Ф. Туйкинның да «Агыйдел буйларында» исемле шигырен керткән.

Төрле китапханәләрдә һәм архивларда Ф. Туйкинның алты китабы, ул төзегән бер дәреслек сакланып калган. Шуларның һәммәсе белән танышканнан соң, ул күз алдына үткен каләмле әдәбиятчы, күп кырлы иҗат эшчәнлеге алып барган тынгысыз җанлы мәгърифәтче булып килеп баса.

*
* *

Фазыл Туйкинның тулы биографиясе язылмаган. Шулай да тормыш иптәше Хөршидә Туйкинаның (ул хәзерге көндә Уфа шәһәрендә яши — Э. Ш.), туганнары һәм замандашларының ярдәме белән кайбер нәрсәләрне ачыклап булды.

Фазыл Кәрим улы Туйкин 1887 елның 22 июнендә хәзерге Лениногорск районының Зәй-Каратай авылында мәзин гаиләсендә туа. Җитмеш җиде яшьлек әтисе Әхмәткәрим дөнья куйганда Фазыл нибары җиде яшендә була.

Ул башта авыл мәдрәсәсендә, аннан — Уфада «Хәкимия» мәдрәсәсендә, күпмедер вакыттан соң, Казанга күчеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Биредә ул Ф. Әмирхан белән бер үк чорда укый дияргә була. Ф. Туйкинның язучы буларак формалашуында мәшһүр сабакташының йогынтысы булмыйча калмагандыр, билгеле. Чөнки Фатих Әмирхан инде шул чакта ук әдәби әсәрләре, публицистик мәкаләләре белән алдынгы, хөр фикерле яшьләр арасында зур ихтирам казанган бер кеше була. Фазылның сабакташларыннан Кашшаф Патиев, Гарифҗан Мостафин, Вафа Бәхтияров, Нургали Мамин,



Ибраһим Бикколов, Хәлил Әбүлханов, Ризван Ибраһимов (Алушев)лар да — татар әдәбияты һәм журналистикасы тарихында мәгълүм бер эз калдырган шәхесләр.

1904 елда Мөхәммәдия мәдрәсәсенең урта сыйныфын тәмамлагач, Ф. Туйкин туган авылы Зәй-Каратайга кайта һәм 1909 елга кадәр үз авылында мөгаллимлек итә. Шул елларда ул, журналист язучы Афзал Таһиров белән бергәләп, Габдрахман авылында... «Тирмән» исемле журнал да чыгарып йөри [1]. 1909—1911 елларда Ф. Туйкин Бөгелмә өязенең Ташлы авылында, 1911—1912 елларда Уфа шәһәрендә, аннан Бөгелмә өязенең Кара Елга авылында балалар укыта. Февраль революциясеннән соң ул укытучылык эшен Бөгелмә шәһәрендә дәвам итә.

Туйкинның беренче шигырьләре 1906—1907 елларда Уральск шәһәрендә чыккан «Фикер» газетасында басыла. 1912 елдан башлап аның иҗат эшчәнлеге аеруча актив төс ала. Шул бер ел эчендә ул Казанда «Сугышчы Сатыш әфәнде» дигән хикәя, «Ватан каһарманнары» исемле драма, «Җырлар әхтәрисе» дигән җыентыклар һәм Уфада «Тормыш корбаннары» дигән тагын бер сәхнә әсәре бастырып чыгара. Бу китаплар арасында татар һәм башкорт халык җырларыннан төзелгән «Җырлар әхтәрисе» аеруча зур игътибарга лаек. Аны халык җырларын җыю һәм билгеле бер тәртипкә салу өлкәсендәге иң уңышлы тәҗрибәләрнең берсе дип санарга була.

Музыкаль яңгырашлары, аһәңле булулары ягыннан Ф. Туйкинның үз шигырьләре дә халык җырларына якын тора. Бу яктан авторның 1915 елда чыккан «Нардуган» җыентыгы бигрәк тә характерлы. Анда халык җырларына хас якты сагыш, туган илнең матурлыгына соклану хисләре белән сугарылган шигырьләр күп кенә. Язучы драма әсәрләрендә, хикәяләрендә дә халык җырларын, үз шигырьләренең халык җырларына тартым вариантларын оста куллана. Ихтимал, монда шагыйрьнең җыр яратуы, музыкаль кеше булуы да мәгълүм бер роль уйнамый калмагандыр. Замандашларының истәлекләренә караганда, Ф. Туйкин моңлы тавышлы җырчы, оста скрипкачы була. Әдәби эшчәнлегеннән тыш, Ф. Туйкин фәнни хезмәтләр, дәреслекләр язу белән шөгыльләнә. Аның туганы К. Туйкә белән язган «Төрек тарихы» дәреслеге үз чорының шактый популяр китапларыннан саналган. «Озак вакытлардан бирле эшләнеп килгән «Төрек тарихы» өч бүлем буларак хәзерләнде, — диләр авторлар. — Алдыгыздагы беренче бүлем тарих башыннан алып Чыңгыз хан дәверенә кадәр булган әхвәлдән бәян итеп, тиздән куелачак икенче бүлем Чыңгыз хан дәвереннән алып Казан ханлыгы ясалганга кадәр, вә өченче бүлем исә Казан ханлыгы ясалганнан алып хәзерге көнгә кадәр булган әхвәлдән бәян итә» [2].

Кызганычка каршы, Казан китапханәләрендә зур күләмле, бай эчтәлекле бу тарихның беренче кисәге генә сакланган. Замандашлары һәм якыннарының әйтүенә караганда, аның беркайда басылмаган кульязма әсәрләре дә байтак булырга тиеш. Иҗаты җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгәнгә күрә, матбугатта төрле хаталар да китә. Ф. Туйкин әсәрләрен башка авторларныкы белән ялгыштыралар, аерым шигырьләрен чит җыентыкларга кертәләр. Мәсәлән, Ф. Туйкинның 1912 елда «Нардуган» җыентыгына кергән «Сабанчы карт» шигыре ялгыш 1959 елда Фоат Садыйков тарафыннан төзелгән Давыт Гобәйди җыентыгына кертелгән [3]. Аның Ф. Туйкин әсәре булуы бернинди шик уятмый. «Нардуган» җыентыгына хәтле ул башта Ф. Туйкин имзасы белән «Шура» журналында басыла. Шигырь кульязма хәлендә шагыйрьнең тормыш иптәше Х. Туйкинада да саклана.

Ә «Туган ил» шигыренең язмышы тагын да гыйбрәтлерәк. Ул И. Надиров төзегән

---

[1] Башкорт халык антологиясе. Уфа, 1972 ел, 193 бит.
[2] К. Туйкә, Ф. Туйкә. Төрек тарихы. Оренбург, 1919 ел.
[3] Д. Гобәйди. Шигырьләр. Казан, 1959 ел.

«Җырлар китабы»на (1972) татар халык җыры дип кертелгән. Берьяктан, бу — бик күңелле күренеш. Әсәре теллөрдән-телләргә күчеп җырлана, халык аны үзенеке дип кабул иткән икән, шагыйрь өчен моннан да зуррак бәхет булырга мөмкинмени?!. Әмма шулай да «Туган ил» халык җыры түгел, ә бәлки Фазыл Туйкин шигыре. Аның өч варианты бар. Беренче тапкыр бу шигырь белән без авторның «Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясендә очрашабыз. Шуннан автор аны 1915 елда чыккан «Нардуган» җыентыгында бастыра. Ниһаять, «Шура» журналының 1919 елгы саннарында «Туган ил»нең өченче варианты басыла. Елдан-елга, варианттан-вариантка шигырьнең эчтәлеге яхшыра, сәнгатьчә эшләнеше камилләшә барган. Кыскасы, җырның Ф. Туйкин әсәре булуына шик була алмый.

Фазыл Туйкинның әдәби әсәрләре турында сөйләгәндә, «Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясе белән «Ватан каһарманнары» исемле пьесасына да тукталып үтми булмый. Аларның һәр икесе тарихи пландагы әсәрләр. «Сугышчы Сатыш әфәнде»дә Болгар дәүләте чорындагы вакыйгалар сурәтләнсә, «Ватан каһарманнары» исә 1812 елгы Ватан сугышына багышланган.

«Ватан каһарманнары» — эпик характердагы, киң колачлы әсәр. Анда вакыйгалар бер татар һәм башкорт халыкларының тормышы белән генә чикләнми. Ә бәлки ил язмышы, аның иминлеге, киләчәге турында кайгырту пьесаның төп пафосын билгели. Ил өстенә кара яу килгәндә төрле милләт халыклары дошманга каршы бердәм күтәрелә, халык күңелендә интернационализм хисләре уяна. Автор шул нәрсәләрне алгы планга куя, «Ватан каһарманнары» әнә шул сыйфаты белән кадерле. Ул хисләрне, билгеле, Ф. Туйкин уйлап чыгармаган, аларны ул тормыштан алган. «Илнең язмышын хәл иткән бөек тарихи вакыйгада актив катнашу — татар халкын, татар солдатларын... рухи яктан үстергән, утны кичеп, дошманнарны җимергәндә аларда яңа сыйфатлар туган, Россия һәм аның батыр халкы өчен горурлык хисе уянган. Халык күңелендәге мондый яңа халәт, әлбәттә, аның сәнгатенә, поэзиясенә эз салмый калмаган»[1]. Пьесаның эчтәлеге буенча фикер йөрткәндә, ватандарлык, патриотизм хисе сугыш кырындагы солдатлар күңелендә генә түгел, ә бәлки караңгы бер авылдагы гади крестьяннар күңелендә дә туа.

«Ватан каһарманнары» гади татар авылындагы вакыйгаларны сурәтләүдән башлана. Әсәрнең төп герое — егерме ике яшьләрендәге, карап торуга юаш сыман гына күренгән Солтанкай исемле егет.

Ул Кармыш бабайның Бибикамал исемле кызына өйләнергә йөри. Бабай үзе дә, карчыгы да кызларын Солтанкайга бирергә ризалар. Тик Бибикамалның абыйсы Ногман гына, Солтанкайга ышанмыйча, бу эшкә каршы төшеп маташа. Бераздан егет күңелендә бернинди дә мәкер юклыгы, бәлки кызны чынлап яратуы билгеле була һәм туй турында сөйләшүләр башлана. Шул чак көтмәгәндә сугыш башлануын хәбәр итәләр. Бу коточкыч хәбәр егет белән кызны гына түгел, авылның барлык кешеләрен тетрәтеп ала. Ләкин халык куркуга бирелеп, югалып калмый. Явыз илбасарларга карата һәркемдә нәфрәт, ачу тойгысы уяна. Үзара ярсып сөйләшә-киңәшәләр дә авылның ир-атлары берләшеп яуга чыгып китәләр.

Әсәр ахырында ике зур бәйрәм бергә туры килә. Авыл кешеләре, французларны җиңеп, туган җирләренә исән-сау әйләнеп кайталар. Ул да түгел, Солтанкай белән Бибикамалның туе башлана...

«Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясе Болгар дәүләтенең тәмам бөлгенлеккә төшеп, нигездән үк туздырылып, җимерелгән чорына карый. Әсәрнең сюжеты шактый мавыктыргыч һәм кызыклы итеп корылган.

Төп вакыйга Болгар шәһәреннән шактый еракта урнашкан Дәүләт исемле зур бер авылда бара. Дәүләт авылы халкы иген игә, мал асрый. Ләкин халыкның тынычлыгы югалган. Нindидер хәвеф көтелә. Менә-менә дошман яулары килеп чыгарлар да, аларның бөтен җир-суларын тартып алырлар сыман. Шулай да авылның аксакалы Кармыш агай тыныч күренергә тырыша, халыкны да тынычландыра. Болгарларның батыр халык икәнен искәртеп: «Сугыш булса да борчылырга кирәк түгел, без инде дошман җиңә алудан үткән. Менә фәлән сугыш ничек куркыныч иде, анда да ирек бирмәдек, аның өстенә никадәр малларын алдык»,— ди. Кармыш бабайның бу сүзләре ае-

[1] Х. Госман. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе, Казан, 1960 ел, 5 бит.

руча улы Сатышка нык тәэсир итә. Ул көннәр буе «йөгерек кара атына» атланып болыннарда сугыш уены уйный, үзен алдагы көрәшләргә хәзерли.

Көннәрдән бер көнне Болгар иленә дошман килгән дигән хәбәр ишетелә. Болгар шәһәреннән батыр ирләрне яуга чакырып чапкыннар килә. Сатыш, бу хәбәрне ишетү белән, коралларын алып, атына атланып, Болгар шәһәренә чыгып китә. Ләкин юлда адаша, ялгыш дошман яулары өстенә килеп чыгып, әсир төшә. Ун ел гомерен әсирлектә үткәрә. Шуннан качып туган җиренә әйләнеп кайтканда, Болгар шәһәре дә, Дәүләт авылы да җимерелгән була... Хикәядә әнә шул вакыйгалар тасвирлана.

Әсәр тыныч тонда, өченче заттан язылган. Җөмләләр озын. Хикәянең стиле беркадәр борынгы Шәрык әдәбиятын, «Мең дә бер кичә» әкиятләрен һәм легендаларны хәтерләтә. Әсәрдә диалоглар аз. Ләкин булган кадәресе үзенчәлекле. Автор аларда «диде» «дип», «ди» шикелле ярдәмче фигыльләрне бик сирәк куллана. Бу яктан карағанда, аның хикәясендәге диалоглар сәхнә геройларының сөйләшүләрен хәтерләтә. Автор халык иҗатына тартым бик матур алымнар, чагыштырулар куллана. Ул шәһәрдә кешеләр — бичара, мескен. Шәһәр текә таулар белән уратылып алынган. Автор «...йөзе җимерелеп, канга батып үлгән кеше...», «Залим аю урталай бөкләнеп җиргә егылды» кебек чагыштырулар куллана. Сатыш әфәнденең аты «ярсып-ярсып кешни»», «яшен кебек оча»...

Ниһаять, хикәянең тарихилык дәрәҗәсе никадәр соң? Автор үзе бернинди чыганакларны күрсәтми. Вакыйганың елы анык мәгълүм түгел. Әсәрдә очраган Так шәһәре дә, Дәүләт авылы да шартлы исемнәр. Болгар шәһәренең урнашкан җире дөрес күрсәтелсә дә, хикәядә бернинди тарихи документлар, архив материаллары файдаланылмаган булса кирәк. Автор күбрәк үз фантазиясе тудырган образларга, вакыйгаларга мөрәҗәгать итә.

Шулай да сугышчының сөнгеләр, кылычлар белән кораллануы, сунарчыларның тире киемнәр киеп йөрүе, яшүсмер Сатышның, чын Болгар сугышчылары кебек, ак чикмән киеп билен бәйләве, башына холи эчле тирән бүрек, аягына күн итек киюе, кечкенә гәүдәле йөгерек атка атлануы һәм тагын башка бик күп детальләр Ф. Туйкинның Болгар тарихыннан шактый мәгълүматлы кеше булуы турында сөйлиләр.

«Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясе туган илгә мәхәббәт, патриотизм идеясе белән сугарылган. Кайдадыр туган иле барлыгын тоеп яшәү кешеләргә караңгы әсирлектә нинди генә авыр-газаплы хезмәтләргә дә түзә алырлык куәт, яшәү көче бирә. Сатыш бөтен җаны-тәне белән туган иленә омтыла. Аның уйлары да, хисләре дә — еракларда калган Ватан турында. Бу яктан хикәя «Ватан каһарманнары» пьесасы белән аваздаш яңгырый. Әлеге әсәрләрнең икесендә дә беренче чиратта ил кайгысы, ил хәсрәте турында сөйләнә. Туган җирен илбасарлардан азат итүгә бөтен көчләрен биргән кешеләр бәхетле булып калалар («Ватан каһарманнары»), ә инде баскыннар кысрыклавына каршы тора алмаганнары коллыкка дучар ителәләр («Сугышчы Сатыш әфәнде»).

Моннан тыш, Ф. Туйкинның «Тормыш корбаннары», «Салих бабай» (балалар өчен) исемле пьесалары бар. Җыйнап әйткәндә, ул төрле әдәби жанрларда каләм көчен сынап караган шактый киң диапазонлы язучы.

Әмма шулай да Ф. Туйкин әдәбият тарихына күбрәк халык иҗатын җыючы, башкача әйткәндә, фольклор галиме булып кереп калган. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге — зур да, мактаулы да. Халык иҗатына багышланган мәкаләләре белән танышканда, галимнең фольклор белән бик яратып һәм мавыгып шөгыльләнгәнен тоясың. Әйтик, ул җырларны изге бер максат — халык күңелен нурландыру максаты белән җыйган, шул максаттан чыгып аларны билгеле бер системага салган, тәртипкә китергән. Ф. Туйкинның «Җырлар әхтәрисе» (1912 ел) әнә шулай барлыкка килгән.

Язучы Шәйхи Маннур үзенең «Агымсуларга карап» дигән әсәрендә болай дип яза: «Ул миңа, төрле догалыклар белән бергә, «Җырлар әхтәрисе», «Менә шәп җырлар», «Сугыш бәете», «Канау буе», «Суга баткан кыз» дигән китаплар күрсәтте»[1]. Димәк, «Җырлар әхтәрисе» заманында гади халыкның иң яраткан китаплары белән бергә йөргән, бергә сакланган. Аннан соң ул кыска гына вакыт эчендә (1912—18) дүрт тапкыр басылып чыккан икән, бу шулай ук күп нәрсә турында сөйли.

---

[1] «Казан утлары» журналы, 1973 ел, 9 сан, 60 бит.

«Җырлар әхтәрисе»нең байтак өлешен дүрт юллык кыска җырлар тәшкил итә. Тагын шунысы кызыклы, ул җырларның яртысына якыны «ак» тамырына башланган җырлардан тора. Бу, әлбәттә, һич очраклы хәл түгел. «Ак» сүзе җырларда гына түгел, әкиятләрдә, бәетләрдә, мәкаль-әйтемнәрдә һәм табышмакларда еш очрый. Халкыбызның үз җырларына «ак» сүзен кушып җырлавы аның яктылыкка, матур тормышка омтылуыннан килә торгандыр. Чөнки «ак» сүзе борын-борыннан халык күңелендә матурлык, зирәклек, яхшылык, кыюлык символы булып килгән. Агыйдел, ак егет, ак әби, акбүз ат, аккош, ак келәт, ак өй. Ф. Туйкин халык иҗатының бу үзенчәлегенә беренчеләрдән булып игътибар иткән.

**Ап-ак бадьян чәчкәсен**
**Нигә таптап үтәсең!**
**Яшьдин сөйгән яшь матурым,**
**Нигә ташлап китәсең!**

**Ак келәтнең алдында**
**Туңам җаный, туның бир.**
**Ай да бата, чулпан калка,**
**Китәм, җанкай, кулың бир.**

**Ак Иделнең яланы,**
**Пешә ачы баланы.**
**Ата-ана ник үстерә**
**Хәсрәт өчен баланы.**

Тематик яктан «Җырлар әхтәрисе» нигездә ике зур төркемгә бүленгән. Беренче төркемгә — мәхәббәт, дуслык җырлары, икенчесенә иҗтимагый җырлар (монда туган җирен ташлап бәхет эзләргә киткән кешеләрнең хәсрәтле, сагышлы җырлары аерым урын алып тора) керә. Җыентык, болардан тыш, шаян җырлар, солдат һәм рекрут җырлары, тормыш-көнкүрештәге теге яки бу вакыйгага багышланган, халык бүген дә яратып җырлый торган җырларның шул еллардагы вариантлары белән таныштыра. Хәзер «Кама буе...» дип җырлана торган җыр Ф. Туйкин китабында «Ока буе...» дип бирелгән. Ихтимал, бу җырның беренче тапкыр Кама буенда түгел, Ока суы буенда тууы турында сөйлидер.

**Ока буе бик ямьле,**
**Ока суы бик тәмле.**
**Ока суын эчкән кызлар**
**Ак беләкле, ак тәнле.**

Югарыдагы мисалдан күренгәнчә, Ф. Туйкин заманындагы җырларның кайберләре хәзер, заман шартларына туры китереп, азмы-күпме үзгәртелеп җырлана икән.

**Оканың ак суында**
**Вак балыклар — уенда.**
**Балык кебек матур кызлар**
**Үсә Ока буенда...**

**(Ф. Туйкин җыентыгы.)**

**Каманың ак суында**
**Вак балыклар — уенда.**
**Балык кебек чая кызлар**
**Үсә Кама буенда.**

**(Хәзерге халык җыры.)**

«Әхтәрие» җырларының күбесе бүгенге фольклор китапларында сирәк очрый. Менә шуларның кайберләре:

**Алты ат җиктем, подряд киттем**
**Казански кантунга.**
**Малым түгел, җаным фида**
**Сезнең кебек матурга.**

**Алтын булып агармын,**
**Көмеш булып тамармын.**
**Сез дусларым каршысында**
**Шәмнәр булып янармын.**

**Алдыр Казан каласы,**
**Гөлдер Казан каласы.**
**Эчең тулы кайгы булгач,**
**Уттыр Казан каласы...**

Г. Тукайның «Халык моңнары» дигән китабында басылган кайбер җырларның үзгә вариантлары Ф. Туйкин җыентыгына да кергән:

**Агыйделгә төшә яздым**
**Вак-вак кына таш өчен.**
**Хәйран башлар вәйран була**
**Кызның кыйгач кашы өчен.**

**[Г. Тукайда.]**

**Ак Иделгә төшә яздым**
**Кул кисәге таш өчен.**
**Хәйран башым вәйран булды**
**Сез дусларым хакы өчен.**

**[Ф. Туйкинда.]**

«Җырлар әхтәрисе»ндә шулай ук Г. Тукай игътибар иткән, заманында ул җыйган җырлар да очрый. Димәк, халык җырларын туплау мәсьәләләрендә аларның карашлары бер төрлерәк булган дип уйлый алабыз.

Ф. Туйкин җыентыгының бер өлешен көйле җырлар тәшкил итә. Ләкин бу җырлар тулы килеш түгел, ә бәлки бер яки ике куплет күләмендә, әйтерсең теге яки бу җырны искә төшерү өчен кирәк булган кадәр күләмдә генә бирелгән. Аларның күбесе сюжетлы җырлар. Ул җырларның билгеле бер нәтиҗә ясау рәвешендә китерелә торган кушымталарында композицион һәм тематик яктан бер эзлеклелек, логик бәйләнеш нык сизелә» [1]. Мисалга «Сакмар көе»н алып карыйк:

**Һаваларга ла очкан аккошлар әйтә:**
**Агач башлары ла безгә бостан, дип, Газизәкәй,**
**Үсәсең лә син Сакмар су буенда —**
**Кемне генә күрсәң, шулар ук әйтә**
**Аерылмаек иске дустан, дип.**

Көйле җырларның байтагы мәхәббәт хисләре турында. Ләкин аларның эчтәлеге тар, интим гыйшык рамкалары белән генә чикләнми, аларда чор-заман, шул чакта яшәгән кешеләр чагыла:

**Без китәбез илләргә лә,**
**Бадьян чәчкән җирләргә.**
**Ай, җаный, каласың,**
**Әллә озата барамсың!**
**Һич кайтмыйбыз бу илләргә,**
**Михнәт күп бу җирләрдә.**

**[«Әй, җаный, каласың».]**

Җырлар белән бергә, Ф. Туйкин халык иҗатының башка төрләрен, аерым алганда, мәкаль-әйтемнәрне һәм такмазаларны җыю эшенә дә күп көч түгә. Аның такмазаларга биргән фәнни бәясе аеруча зур әһәмияткә ия. «Әлегә кадәр тикшерүчеләр такмазаларны уйнап-көлеп сөйләүче бер сүз боткасы итеп кенә калдыра килделәр, — ди ул, — ләкин күбрәк җыеп, эченә кереп тикшерә карасаң, анда халык тормышының

[1] Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967 ел, 219 бит.

халык идеологиясенең бик тирән нәрсәләре ятканлыгы аңлашыла»[1]. Үз сүзләренең дөреслеген раслар өчен ул түбәндәге такмазага туктала:

**Алатыр,**
**Мулатыр,**
**Тау ягыннан таң атыр.**
**Чистай — чигәнәк,**
**Алабуга — бигәнәк;**
**Татарски,**
**Мирски...**
**Яланнан ялпак,**
**Тәти куян...**

«Халык әдәбиятын тикшерү юлында» исемле мәкаләсендә Ф. Туйкин йола җырларына, арбауларга да кагылып үтә. Билгеле булганча, элек туй вакытларында, кияү кертү һәм киленне алып кайту белән бәйләнешле бик күп гадәт һәм йолалар булган.

**Исән генә килдеңме, балам!**
**Ак күңелдән сиңа арбау салам:**
**Төкле аягың белән.**
**Талмас кулың,**
**Таймас табаның белән кил!**
**Юраганың юш булсын,**
**Курыкканың буш булсын,**
**Янушагың юл булсын,**
**Эшең-көнең уң булсын,**
**Ашың-суың мул булсын.**
**Йөзең айдай,**
**Сүзең балдай,**
**Күңелең майдай булсын;**
**Арысландай алты батырың,**
**Җиләктәй җиде матурың тусын.**
**Батырларың мал тапсын,**
**Матурларың яр тапсын.**
**Алтының алтындай игелеген,**
**Җиденең ефәктәй изгелеген күреп картай!**[2]

Ф. Туйкин мәкаләсендә бу арбау «тормыш аналарыннан тормыш анасы булачак киленгә әйтелгән»[3] диелә.

1928 елның 6 мартында Казанда халык әдәбиятын тәртипкә салу буенча фольклорчылар киңәшмәсе үткәрелә. Бу киңәшмәдә Ф. Туйкин фольклор жанрларын төрле бүлекләргә бүлеп, аларга исемнәр бирү турында тәкъдим белән чыга. Мәсәлән, ул такмаза (частушка), арбау (народная поговорка), көлдерт (анекдот) шикелле терминнар тәкъдим итә. Ф. Туйкинның кайбер терминнары бүгенге фольклорчылар өчен дә кызыклы. Алыйк «каргышлар»ны. Ф. Туйкин бу бүлеккә «муеның астыңа килгере», «бабаң тонгыры» кебек сүз тезмәләрен кертә. Аннары ул, «каргышка» капма-каршы буларак, «төуфыйгың арткыры», «рәхмәт төшкере» шикелле теләкләрне берләштерә торган «алкыш» терминын кулланырга тәкъдим итә.

Унынчы елларда ук фольклор әсәрләрен җыя башлаган Ф. Туйкин, әнә шул рәвешчә, Октябрь революциясеннән соң да бу өлкәдә актив эшли. Бөек Тукай: «Әйе, бу кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмүр болгар шәһәрләре, болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидегебез халык шигырьләрен туплар да ватмады... алар сәламәт әле, алар яңгырый әле», — дигән иде. Шул кыйммәтле мирасны, «халкыбыз күңелендә һич тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгесен» саклауда, бер буыннан икенче буынга илтүдә Фазыл Туйкинның да өлеше бар.

**ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНА.**

---

[1] Ф. Туйкә. Халык әдәбиятын тикшерү юлында. «Безнең юл» журналы, 1927 ел, 8 сан, 36 бит.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.

# РӘШИТ ГӘРӘЙ ЛИРИКАСЫ

Шигырьләре кыска, ихлас күңелдән язылган лирик шигырьләр. Алар миңа бала чактан таныш. Кечкенәдән, тальян гармун моңы сыман, күңелгә якын, үз лирика. Шагыйрьнең без мәктәп елларында яттан сөйләп йөргән шигырьләре үк туган яктай иркен, сабыр, табигать кебек ягымлы булулары белән күңелне тартты. Нәкъ әнә шуңа күрә алар, хыялны җанландырып, якты шигърият иленә әйдәделәр. Алай гына да түгел, гап-гади булып тоелган туган җиребез үзе дә, әлегә кадәр без күреп өлгермәгән төсләре белән балкып-уйнап, тылсым дөньясына әверелде. Минемчә, бу әсәрләр бигрәк тә безгә — сугыштан соң әтисез үскән һәм үзебезне яшьтәшләр арасында дөньяның ачысын-төчесен берникадәр күбрәк тоярга өйрәнгән дип санаган укучыларга — якынрак иде. Әйе, аларда өшегән күңелләргә дә жылы өрерлек шигъри җан, йөгерек кан кайнарлыгы бар. Рәшит Гәрәй китапларын мин кат-кат укыдым һәм бу сүзләремә дәлилләр таптым. «Елгалардан түгел, туңмый торган Чишмәләрдән үрнәк алам мин»,— ди ул.

Нинди генә кешенең йокысыз үткәргән төннән соң таң атуын зарыгып көтеп алганы, шул таңга карап күңел юатканы яки ерак офыктагы соңгы шәфәкъ нурларын күзәтеп моңланганы-уйланганы юк микән? Андый чакларда нигәдер үзеннән-үзе шушы юллар искә төшә:

**Ык суларын кичтем таңнарда,**
**Ык суларын сиптем талларга.**
**Истәлегем булып үссеннәр,**
**Сагынганда кайтып карарга.**

(«Ык сулары».)

«Нигәдер» дип күрәләтә, белеп яздым. Бу сүз әлеге юлларның лирик сурәт, ритм-төзелеш көче белән йөрәккә үтеп керүен, кайдадыр аяз киңлектә йолдызлар аулаган хыялый күңелне дә конкрет җиргә — туган почмакка кайтарырлык, инандырырлык булуын аңлата. Шагыйрьнең 25 еллык иҗатыннан мондый мисалларны күпләп китерергә була. Шул вакыт эчендә аның төрле күләмдәге унөч шигырьләр җыентыгы дөнья күргән. «Беренче хисләр» китабы 1952 елда басылып чыккан. Менә без аның беренче битен ачабыз.

**Шушы җир безне үстерде,**
**Шушы җир кадерләде;**
**Шушы җир анабыз булып**
**Көрәшкә хәзерләде.**

**Шушы җиргә багышланып,**
**Якты җырларым тусын;**
**Яшьлегемнең дәрте, көче**
**Туган җир өчен булсын.**

(«Туган җиремә».)

Бу юлларны егерме яшьлек егет яза. Һәм ул шигырь гүяки шагыйрьнең иҗат программасы булып китә. Чыннан да, авторның кайсы гына әсәрен алып укысаң да, туган җиргә яки аның кешеләренә юлыгасың. Туган як матурлыгы белән горурланасың, кешеләрен таныйсың, аларны, хәтердә яңартып, күреп сөйләшкәндәй, аксакалларына сәлам биреп, хәл-әхвәл сорашып торгандай буласың...

Шагыйрьләрне еш кына изге гөлбакча хуҗасы, яисә, гомумән, җиһанны агартырга килгән көрәшчеләр белән чагыштыралар. Һәр очракта да ул Җиргә, кешеләргә, халыклар язмышына битараф түгел. Шагыйрь җаны гамьсез була алмый. Рәшит Гәрәйне исә иҗаты белән мин игенче итеп күз алдына китерәм. Әйтерсең лә аның алдына чор, заман үзе шундый олы бурыч куйган. Һәм иксез-чиксез иген кырларыннан, томаннар сарган урман-болыннардан, эңгер төшкән су буйларыннан урап, талгын гына тальян тавышы килә. Шагыйрьне бөтен иҗаты буйлап озата бара ул моң. Анда — борынгы крестьян тормышының сагыш-кайгылары, бүгенге дәртле җырлар. Анда кеше өчен борчылу һәм горурлану, Җир иминлеген кайгырту. Һәм офыкка тоташкан киңлектә «көндезен ерактан күренми» торган учаклар яна. Шигъри учаклар...

Шунысы шатлыклы: шагыйрь кайчан да үз геройлары арасында. Ул каһарманнар һәр вакыт диярлек гади авыл кешеләре — игенчеләр. Р. Гәрәй шигырьләрендә шушы гади булмаган гадиләр — аерым шәхесләр еш кына гомумиләшеп китә, тулы канлы халык вәкиленә әверелә һәм, бераз гына таныш та шикелле елмаеп, күз алдына килеп баса. Алар — җыр чыгаручы Фәрит һәм Хәйбуллалар, алтын куллы, җор күңелле тимерче һәм көтүчеләр, кибән куючы картлар.

Шагыйрь иҗатының башлангыч чорында ук:

**Мин синеке, илем!**
**Син минеке!**
**Синең иминлегең хакына**
**Мин кирәргә әзер, курыкмыйча,**
**Дөрләп янган утка, ялкынга! —**

(«Мин синеке, илем!»)

дип яза. Рәшит Гәрәй иҗатында шушы мөкатдәс патриотик хис шигырьдән-шигырьгә үсә бара. Аның хәтта «кочаклашып үскән яшь чыршылар»ы да «әйтерсең лә сакка куелган».

Шагыйрь җаны җир белән сөйләшә. Ул үзәннәр, кырлар буйлап җир авазын тыңлап килә.

**Җир авазы тиздән ишетелер,**
**Уҗымнардан, яшел үләннән...**

(«Үзәннәрдә йөрим».)

Ул кешеләрнең җан авазын да ишетә. Шуның өчен дә лирик герой әле ындыр табагында, әле фермага барып чыга.

**Кышкы көннәрдә дә һаман шулай**
**Хәтерләтеп яшик язларны...—**

ди ул аларга. Ә кеше белән табигать һәр даим бәйле. Шуңа күрә халык сыкраса, бу авырлык тауларга да күчә:

**Кыю ирләр шулай ирек өчен**
**Яуларда үлә икән.**
**Алар иртә үлгән өчен сыкрап,**
**Таулар да иңә икән.**

(«Таулар да иңә икән».)

Шагыйрь күңеле тынгысыз, анда хисләр давылы, романтика. Туган як романтикасы. Аның йөрәге һәртөрле җилләргә-давылларга ачык. Әгәр шулай булмаса, халкының, Ватанының җанны сыкратырлык кайгылары, күзгә шатлык яше китерердәй

куанычлары йөрәгеңне телеп үтмәсә... Андый кешенең (хәтта ул талантлы булса да!) кулына каләм алуы кешелек өчен артык бер мәшәкать-борчу гына булыр иде.

Шигырь сөючеләргә мәгълүм ки, Рәшит Гәрәй Себердә Кузбасс шахтерлары янында байтак кына вакытлар яшәп кайтты. «Радищевлар эзе калган җир» уйландырды шагыйрьне. Биредә аның таланты бөтенләй яңа яктан ачылып-ялтырап китте. Яңа кешеләр, яңа характерлар белән танышуның бер генә әдипкә дә комачаулаганы юк бугай әле. Ә бәлки, киресенчә, мондый очрашулар язучы күңелен баета һәм шуның нәтиҗәсендә, шигърият полотнасына яңа, якты төсләр өстәлә. Бу очракта да шулай булды. «Таулар яна» дип аталган шигырьләр бәйләме шуны раслый. Цикл авторы үзе дә Себердә яшәүче якташларыбызга болай дип дәшә:

**Йөрәгемдә нәрсә дөрли дисез,**
**Сез үзегез яккан ут бит ул!**
(«Кунак булып үзегез кайтыгыз».)

«Туган як көе», «Мендәр», «Тальян гармун», «Әткәм киңәше», «Җырчы малай, дисәләр...», «Мусалар искә төшкәндә» кебек шигырьләр, яки «Беренче мәхәббәт» поэмасы укучы белән җылы сөйләшү булып хәтердә кала. Автор укучысы белән гражданин буларак сөйләшә. Ул укучыга да, үзенә дә бер үк дәрәҗәдә таләпчән, күңелендәге ирләрчә турыдан-туры ачып бирә.

**Җиңелгәнне кем соң куккә чөйсен,—**
**Башым минем түбән иелгән.**
**Сөяллəнгән куллы аксакаллар**
**Килеп кага шунда иңемнән.**
**Якын итеп биргән киңәшләрен**
**Гомер буе юлдаш итәрлек:**
**— Җырларыңны өйрәт көрәшергә,**
**Сабан туйлар алда җитәрлек!**
(«Сабан туйда шигырь укыттылар».)

**Казлар турында мин бик күп яздым,**
**Тик барысын ашыгып язганмын.**
**...Зират коймасына бәрелә-сугыла**
**Очып уза бәбкә-казларың.**
(«Әнкәй үлгәч» циклыннан.)

Инде шундый юллардан соң укучылардан да шулай ачыклану таләп итәргә мөмкиндер, шәт:

**Шатлыгың булса, кызганма,**
**Кайгың булса, яшермә.**

Дөнья булгач, кайгысы да булмый калмый. Шагыйрьнең үзендә дә бар ул. Язучы Газиз Мөхәммәтшин истәлегенә багышланган шигырендә Рәшит Гәрәй:

**Без болай да күбәү түгел идек,**
**Бер кешегә тагын кимедек,—**

дип боега. Шулай, җирдә кайгылар, боегулар да бар. Ләкин шунысы хак:

**Боексак та бары боегабыз**
**Елмаюлы таңнар хакына!**

Шагыйрь Рәшит Гәрәйнең без матур-матур тәрҗемәләрен укыйбыз, күңелгә ятышлы җырларын тыңлыйбыз. Сөенәбез, борчылабыз. Аның бар булган иҗатына күз салып, башкалардан, һичшиксез, аерылып торган үзенчәлекле шагыйрь барлыгын тоябыз. Ә һәрбер үзенчәлек фәкать халыктан, халык авыз иҗатыннан килә, әлбәттә.

**ФӘННУР САФИН.**

# ЗАМАНДАШ ТУРЫНДА УЙЛАНЫП...

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары күп милләтле совет әдәбияты һәм бигрәк тә тәнкыйте үсешенә никадәрле көчле этәреш ясавы һәркемгә мәгълүм. Әлеге карардан соң зур җанлану кичергән әдәби тәнкыйтебезнең уңышлары соңгы вакытта газета-журнал битләрендә шактый киң яктыртылып килә. Татар әдәби тәнкыйте фәннилеге һәм идея-эстетик сизгерлеге белән дә яңа баскычка күтәрелде. Вакытлы матбугат битләрендә чыгып килгән күп санлы мәкалә, күзәтү һәм рецензияләр шул хакта сөйли. Ләкин заман тәнкыйтенең йөзен билгеләүдә агымдагы тәнкыйть материалларына үзәк урынны биреп, без әлегә әдәбият-сәнгать мәсьәләләре өстендә җитди эзләнүләр алып барган фән эшлеклеләребезнең күләмле тәнкыйть хезмәтләре яисә монографияләренә игътибар биреп җиткермибез кебек. Дөрес, андый хезмәтләр бездә әлегә сан һәм, билгеле бер очракларда, сыйфат ягыннан да үзләренә булган ихтыяҗны канәгатьләндереп җиткермиләр. Шунда ук мондый тәнкыйтьнең, нигездә, әдәбиятыбызның үсеш темпларыннан бераз калышып килүен дә танымый ярамас. Әмма бу очракта сөйләшү аерым бер хезмәт турында гына бара, шуңарга сүзне дә конкретлаштыра төшик.

«Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» (Азат Әхмәдуллинның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан тәнкыйть хезмәте шулай исемләнгән). Бу яңа сорау түгел, ул әдәбият-сәнгать язмышы өчен янып яшәүчеләрне элек-электән борчып килгән сорау. Һәр чорның әдип һәм шагыйрьләре үз замандашларының кабатланмас образларын сурәтләргә омтылып иҗат иткән һәм, чын художник булганнары, нигездә, максатларына ирешә килгән.

Әдәбиятыбызда хезмәт кешесенә — замандашка булган игътибар аеруча соңгы елларда бермә-бер арта бара. КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Л. И. Брежнев партиябезнең XXV съездында билгеләп үткәнчә, соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрдә «илебез тормышының нигезен, асылын тәшкил иткән, совет кешеләренең шәхси язмышларының бер өлешенә әверелгән төп әһәмиятле нәрсәләр торган саен ешрак, ә иң мөһиме — тирәнрәк яңгыраш таба».

«Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» — Укучыларның күз явын алу нияте белән уйлап чыгарылган купшы исем түгел бу, шагыйрьләр, язучылар һәм драматурглар кебек үк тәнкыйтьчеләрнең дә әлеге сорау өстендә җитди уйлануларын тормыш үзе таләп итә. Соңгы елларда театр тәнкыйте өлкәсендә иң актив эшләп килүче авторларның берсе Азат Әхмәдуллин хезмәтенең нәкъ менә шулай аталуы урынлы булса кирәк.

Драматургиябез Г. Камал, М. Фәйзи, К. Тинчурин һәм Т. Гыйззәтләр заманыннан килә торган тотрыклы һәм бай традицияләрне ничек дәвам итә һәм ничек үстерә, заманга тиң адымнар белән атлыймы ул? Китапның кереш өлешендә үк шундый сорау куеп, автор бу мөнәсәбәттә әдипләребез арасында ике төрле фикер яшәвен күрсәтеп уза. Әмма үзе теге яки бу карашка кушылырга ашыкмый, шул рәвешчә, тәнкыйтьтә конфликтлы ситуация туа — автор укучыны фикер алышуга чакырып, аның үзен уйланырга мәҗбүр итә.

Заманыбызның уңай герое — ул кем? Бәхәссез, хезмәт кешесе — чын иҗатчы,

гаять актив һәм коммунистларча принципиаль шәхес булырга тиеш ул. Аның өчен җәмгыять һәм халык мәнфәгатьләре өчен янып яшәүдән дә зуррак бәхет юк. Бу кадәресе һәркемгә мәгълүм. Ләкин менә шундый замандашның укучы һәм тамашачыларны тирән дулкынландырырлык тулы канлы образын иҗат итү, практика күрсәтүенчә, җиңел эш түгел. Моңа ничек һәм нинди чаралар ярдәмендә ирешергә соң, тәнкыйтьче шул характердагы сораулар өстендә уйлануларга зур әһәмият бирә. Әйе, уйлануларга! Әлеге очракта ул һич кенә дә турыдан-туры юл күрсәтүче ролен үти алмый. Заманыбызның уңай героен һәр драматург үзенчә эзли, үзенчә күрә, үзенчә иҗат итә — гаять дәрәҗәдә катлаулы һәм җаваплы процесс бу. Шуны тирәнтен аңлаган тәнкыйтьче заманыбызның уңай героен эзләүче драматургларны диңгез төбеннән энҗе-мәрҗән чыгаручыларга тиңли, зур тирәнлекләрдән энҗе-мәрҗән чыгару өчен никадәрле кыюлык һәм ихтыяр көче кирәк булса, замандаш образын уңышлы иҗат итү өчен дә драматургтан, әлбәттә, талантлы драматургтан, шул хәтле үк иҗади эзләнүләр, сизгерлек һәм тырышлык таләп ителә.

Уңай геройны эзләү юлында яшь драматург Диас Вәлиев ирешкән уңышлар игътибарга лаеклы дип таба тәнкыйтьче. Мәсәлән, драматик конфликтның катлаулыгы, тирәнлеге һәм оригинальлеге белән аерылып торган «Дәвам» драмасыннан Гайнан Саттаров образын хәтергә төшерик. Саттаровка хезмәт кешесенең тормышын яхшырту теләге, коммунизм идеаллары өчен көрәшкә ахыргача бирелгәнлек, бу юлда үз интересларын исәпкә алмау хас — болар исә безнең замандашта очрый торган иң гүзәл сыйфатлар түгелмени?.. Автор Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт»еннән Тәлгат, Г. Ахуновның «Чикләвек төше» буенча эшләнгән инсценировкадан Саматов образларын да 70 нче еллар татар сәхнәсенең казанышы дип таба.

А. Әхмәдуллин тәнкыйтенең иң әһәмиятле һәм отышлы якларыннан тагы берсенә игътибар юнәлтәсе килә. Сүз драматургиянең үсеш тенденцияләре турында барамы, конкрет сәхнә әсәре турындамы, автор һәрчак идея һәм эстетик анализларның бөтенлегенә омтыла. Пьесаларны бәяләгәндә ул турыдан-туры марксизм-ленинизм теориясе, методологик принциплар һәм классикларның иҗат үрнәкләре, партиянең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге карарларына таяна. Бер үк вакытта тәнкыйтьче драматургларны, нинди генә жанр һәм җитди тема өстендә эшләүгә дә карамастан, сәнгатьнең специфик үзенчәлекләреннән, сурәтләү чараларыннан киңрәк файдаланырга чакыра. «Лирик-поэтик чаралар ярдәмендә сурәтләнгән геройлар тамашачыга якынрак та, аңлаешлырак та, рухи яктан баерак та була, —дип яза ул.— Иң мөһиме, андый геройлар ирлек-батырлык ягыннан да, сәнгать образы буларак гүзәллек җәһәтеннән дә башка алымнар белән иҗат ителгән образлардан бер дә ким түгел». Идея һәм эстетик анализларның бөтенлегенә ирешү исә тәнкыйтьнең берьяклылыктан азат булуын гына тәэмин итеп калмый, аның әдәби процесска тәэсир итү көчен дә бермә-бер арттыра төшә.

«Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» хезмәте белән автор, драматургиябезнең аерым жанрларына махсус тукталып, аларның үсеш тенденцияләре турында җитди сөйләшү кузгатып җибәрә. Безнең уйлавыбызча, бу сөйләшү әле дәвам иттерелергә тиеш. Шул ук вакытта тәнкыйтьче замандаш образын сурәтләүдә һәр жанрның үз мөмкинлекләре булуга басым ясап узуны да кирәк таба. Әйтик, бүгенге драма дәвернең фәлсәфи һәм әхлакый проблемаларын, яңа җәмгыять төзүнең, яңа кеше тәрбияләүнең катлаулы мәсьәләләрен хәл итүгә зур өлеш кертә икән, бу әле һич кенә дә аңардан күп үзгә булган комедия жанры сәхнәдә үзенең урынын югалта бара дигән сүз түгел. Комедияда бүген дә гаять җитди проблемалар күтәрү һәм аның үзенчәлекле алымнары белән коммунистик идеалларның бөеклеген раслау мөмкинлекләре никадәрле зур булуны автор конкрет мисалларда күрсәтеп чыга. «Уңай герой да көлә белә» дип исемләнгән бүлектә Туфан Миңнуллин комедияләре турында барган сөйләшү —шуның ачык мисалы.

Хезмәт формасының оригинальлеге белән дә игътибарга лаек. Татар совет драматургиясе һәм аның аерым жанрлары үсешендә традицияләр һәм новаторлык, аларның үзара мөнәсәбәте, сәхнә әсәрләре өчен аеруча характерлы булган сюжет, конфликт, композиция һәм стиль кебек мәсьәләләр турындагы сөйләшүнең фәнни-теоретик югарылыкта алып барылуы китапның мавыктыргыч һәм җиңел укылуына зыян китерми. Тәнкыйтьче моңа ни-

чек ирешкән соң? Ул теге яисә бу теоретик мәсьәлә турында язганда, укучы белән аңарга таныш булган сәхнә әсәрләре турында гади генә итеп фикер алыша белә. Автор мөрәҗәгать иткән пьесаларның байтагы әле бүген дә республикабыз театрлары репертуарларында булу шулай ук әлеге сөйләшүгә булган игътибарны һәм хезмәтнең актуальлеген бермә-бер арттыра төшә. Тәнкыйтьче әледән-әле пьесаларның сәхнәләштерелүе уңаена газета һәм журнал сәхифәләрендә басылган рецензияләргә, җәмәгатьчелек фикеренә, театр белгечләре һәм драматургларның чыгышларына мөрәҗәгать итә, кирәк икән, алар белән бәхәскә керергә дә күп сорамый. Болар исә, үз чиратында, тәнкыйть хезмәтенең авторитетын күтәрәләр.

Дөрес, аерым очракларда тәнкыйтьченең үзе белән дә бәхәсләшәсе килеп ала. Мәсәлән, Хәй Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» пьесасы һәм Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» водевиле уңаеннан әйтелгән кайбер фикерләр белән мин, тамашачы буларак, килешеп бетмәс идем. Әйтик, Диләфрүзнең шаянлыгын, үтә чаялыгын кызның намуслыгы һәм саф күңеллелегенә каршы кую бик үк дөрес булыр микән?..

Әлбәттә, тәнкыйть хезмәтендә кимчелекләр яки кимчелек дип кабул ителерлек нәрсәләр дә бар... [illegible]

Әлбәттә, тәнкыйть хезмәтендә кемнеңдер күңеленә ярамаган яисә кемгәдер бәхәсле тоелган урыннарның булуы гаҗәп түгел. Бу табигый күренеш, шуңа күрә алар китапның һәм практик, һәм фәнни әһәмиятен һич кенә дә киметмиләр. Ниһаять, бүгенге драматургиябезнең йөзен чагылдырган һәм аның алдында торган катлаулы проблемаларны билгеләгән, эчтәлеге белән актуаль, формасы белән оригиналь хезмәт дөнья күрде дип чын күңелдән шатланырга урын бар. Китап әдәбият-сәнгать белгечләре һәм драматурглар белән бер үк дәрәҗәдә театр сәнгатен сөюче замандашларны да үзенә җәлеп итәр дип ышанабыз.

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ.**

# ЖОРЖ САНДНЫҢ РОМАНТИЗМЫ

Наталья Трапезникованың Казан дәүләт университеты нәшриятында чыккан монографиясе[1] хәзерге әдәбият белеменең иң әһәмиятле проблемаларыннан саналган романтизмга һәм аның XIX йөз француз язучысы Жорд Санд иҗатында нинди формаларда чагылуын өйрәнүгә багышланган. Ул Ж. Сандның иҗат эволюциясен тәфсилләп күзәтү белән бергә, романтизмга кагылышлы күп кенә теоретик мәсьәләләр дә күтәрә. Аның бу карашлары татар әдәбиятындагы романтизм алымнарын өйрәнүче галимнәр өчен дә кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

Хезмәтнең «Сафка басу» дип исемләнелгән беренче бүлегендә Сандның матур әдәбият өлкәсендәге тәүге адымнары, аның ничек итеп Руссо һәм Гете иҗатыннан өйрәнүе турында сөйләнә. XIX йөзнең утызынчы еллары француз әдәбиятында классицизм һәм романтизмның үзара көрәше белән характерлы. Шактый озакка сузылган бу көрәштә романтиклар җиңеп чыга. Нәтиҗәдә билгеле бер чорга кадәр француз әдәбиятында романтизм методы хакимлек итә һәм төп рольне уйный. Романтизм вәкиле буларак, Санд яңа методның асылын болай аңлата: «Мин үземнең әсәрләремдәге персонажларны идеал буяуларга буядым һәм аларның психологик кичерешләрен дә мул итеп күрсәтергә тырыштым». Әйе, Санд иҗат иткән образлар гаять нечкә хисләр, шуның өстенә алар һәр вакыт идеал максатка омтылалар. Гомумән, классицизмның «салкын канлылыгыннан» үзгә буларак, романтизм әдәбияты төп игътибарны образларның психологик кичерешләренә юнәлтә, ә реалистик детальләр биредә теге яки бу вакыйганы, персонажны конкрет җирлектә күрсәтү өчен кулланыла.

Жорж Санд иҗаты XIX йөзнең 40 нчы елларында аеруча нык чәчәк ата. Аның әсәрләре берсе артыннан икенчесе өзлексез басылып торалар. Шушы чорда ул үзенең иң характерлы романнарыннан «Орас»ны, «Консуэло» һәм «Графиня Рудольштадт» дигән тарихи дилогиясен иҗат итә. Әйтергә кирәк, бу еллардагы революцион хәрәкәт Франция тарихында онытыл-

[1] Н. С. Трапезникова. Романтизм Жорж Санд. Рус телендә. Казан университеты нәшрияты, 1976 ел.

маслык сәхифәләр калдыра. Халык массаларының Июль монархиясеннән ризасызлыгы, эшчеләрнең стачка хәрәкәте, фәнни коммунизм һәм социализм идеяләренең киң таралуы — бу чор өчен иң характерлы күренешләр. Санд иҗаты шулар тәэсирендә үсә.

Авторның югарыда санап үтелгән романнарын әдәби тәнкыйть төрлечә бәяли. Тәнкыйтьчеләрнең күбесе аның әсәрләренә тискәре мөнәсәбәт белдерә. Шуларга җавап йөзеннән үзенең «Валентина» романына кереш сүзендә Санд болай яза: «Романның тасвирый өлеше яхшы дип табылды. Ләкин аның фабуласы шактый кискен тәнкыйть утына юлыкты. Биредә мине инде «Индиана» романында үк чагылган нәрсәдә — хатын-кызларга каршы доктриначылыкта гаепләделәр. Ә бит, бактың исә, биредә мин, беренче романымдагы кебек үк, алдан ныклап уйламыйча корылган гаиләнең киләчәктә таркалу куркынычы барлыгын күрсәтергә теләгән идем. Тәнкыйтьчеләр сүзенә колак салсаң, мин роман язмаганмын, бәлки, үзем дә сизмәстән, Сен-Симон тәгълиматен алга сөргәнмен икән».

Жорж Сандның бу сүзләре аның әдәби-эстетик карашларын да ачып бирә. «Валентина» һәм «Жак» романнары да нәкъ әнә шуны күрсәтәләр. Аннары язучы кырыгынчы елларда идея ягыннан җитлегү чорына аяк баса. Шуңа күрә гаилә тормышы, ирекле мәхәббәт кебек мәсьәләләр аны элекке шикелле үк кызыксындырмый башлый. Бу чорда язган романнарында мондый проблемалар бөтенләй яңача яңгыраш алалар.

Кырык сигезенче елда эшчеләрнең восстаниесе буржуазия тарафыннан зур шәфкатьсезлек белән бастырыла. Бу — романтик язучы иҗатына нык йогынты ясый. Санд элекке идеалларының чәлпәрәмә килеп җимерелүен күрә. Шуңа ул үз иҗатында патриархаль крестьяннар тормышын тасвирлауны максат итеп куя, шушы мохитта юаныч һәм идеаллар эзли. Әсәрләрен халыкчарак итеп яза, аңлау өчен җиңелрәк формалар сайлый. Нәтиҗәдә элекке әсәрләренә хас булган лирик чигенүләр, фәнни һәм фәлсәфи идеяләр кими төшә. Автор авыл халкын югары әхлакка ия булган кешеләр итеп саный, «зур шәһәрләрнең бозык гадәтләреннән аермалы буларак, авылда чиста әхлак традицияләре нык сакланган» дип яза. Шуңа күрә авыл кешеләрен язучы йомшак холыклы, түземле һәм итагатьле итеп тасвирлый, ярлы крестьяннар ифрат соклангыч сыйфатлар белән күрсәтелә. Аның крестьян образлары тупаслыктан, эгоизмнан бөтенләй азат. Табигатьтән килә торган гадилек крестьянны үз шәхесе белән мавыгудан, мин-минлектән саклап калган, ди. Шуңа күрә алар мәхәббәт өлкәсендә дә бик самими. Әнә шундый булганга алар политик һәм социаль проблемалар турында уйланып тормыйлар. Нәтиҗәдә әдип ярлылык проблемасын да бик гади формада хәл итә һәм аның әсәрләрендәге персонажлар һәр вакыт очраклы рәвештә баеп китәләр.

Жорд Санд иҗатының төп мәгънәсе нидән гыйбарәт соң? Монография авторының күзәтүләреннән аңлашылганча, романтизм вәкиле буларак, ул үз заманының алдынгы акыл ияләре белән берлектә, хатын-кызны азат итү проблемасын күтәрә һәм әсәрләрендә шушы идеяләрне гәүдәләндерергә омтыла. Аннары Санд үз иҗатында 1848 ел революциясен алдан сиземләү дәрәҗәсенә күтәрелә («Ян Жижка» һәм «Олы Прокоп» очерклары). Чөнки аның иң зур теләге бүгенге көрәше белән киләчәкне якынайтудан гыйбарәт була. Дөньяга карашы вак буржуазия идеаллары белән сугарылганга күрә, язучы пролетариатның тарихи миссиясен аңлау югарылыгына күтәрелә алмый. Шуңа күрә ул җәмгыятьне үзгәртеп коруның социаль-политик нәтиҗәсен гомуми тигезлектә күрә.

Билгеле булганча, Сандның иҗат эшчәнлеге XIX йөзнең утызынчы елларында әхлак мәсьәләләренә багышланган романнар язудан башланып китә. Кырыгынчы елларда аны күбрәк политик проблемалар кызыксындыра. Аннары 1848 ел килә һәм бу чорда язучы үз әсәрләрендә революция һәм реализм идеяләрен алга сөрә. Ж. Санд романтизм методының күренекле вәкиле була. Аның нинди художество чаралары сайлап алуы шуның белән аңлатыла. Романтизм эстетикасына таянып ул якты киләчәк турында хыяллана, әсәрләрендә шул максатны тормышка ашырырга өнди.

Монографиянең художество эшләнеше дә күркәм. Аны художник Э. Зарипов башкарган. Бу китапны язучылар, китап сөючеләр һәм тел-әдәбият укытучылары зур кызыксыну белән укып чыгарлар.

**РЕЙН ГАНИЕВ.**

# ЗАМАН ТАЛӘБЕ

Сез татарча ничек сөйләшәсез? Алар ничек? Тегеләр? Әйдәгез, сөйләмгә колак салыйк:

— И подконец тегеләр вракны атаковать итәргә поднимаются...

— Ул недавно диссертация защищать итеп кайтты...

— Кайсы старанага киткәнне как знать?

— Мин интересоваться ителәм...

Кызганычка каршы, биредә китерелгән сөйләм бүгенге көндә татарлар арасында сирәк күренеш түгел. Кайберәүләр сөйләм культурасына игътибар итми башладылар, ничек әләкте шулай «сукалыйлар»...

Әлбәттә, мондый күренеш белән һич кенә дә килешеп булмый. Чөнки без — коммунизм төзүчеләр. Коммунизм исә — ул матурлык законнары нигезендә яши торган җәмгыять. Аның байрагында тормыш матурлыгын, кеше матурлыгын раслау язылган. Бүгенге көндә партиябез барлык хезмәт ияләрен нәкъ менә шул матурлык законнары нигезендә яшәргә өйрәтә, әйди, чакыра. КПССның XXV съезды бу юлда партия алдына, халык алдына яңа бурычлар куйды. Ул бурычларны хәл итүнең төп максаты шул: совет кешесе — коммунистик җәмгыять төзүче кеше тагын да матуррак яшәсен, тагын да матурырак эшләсен, тагын да матуррак хис итсен!

Әйтергә кирәк, сөйләм культурасына карата югарыда китерелгән мисаллардагы кебек игътибарсызлык совет кешесенең матурлык хисләре, эстетик зәвыкләре белән сыеша алмый. Андый сөйләм кешене кимсетә, түбәнәйтә, аны зәвыксез, шапшак, ялкау, ана телен санга санамаучы итеп күрсәтә. Әйе, башкача булырга да мөмкин түгел.

Сөйләм — ул шәхес көзгесе. Син нинди кеше? Уңганмы, әллә ялкаумы? Зәвыклеме, әллә түгелме? Таләпчәнме, әллә талымсызмы? Болар иң әлек сөйләмдә чагыла. Әйе, син нинди кеше? Белемлеме, әллә наданмы? Матурлыкны раслаучымы, әллә ямьсезлекнеме? Бу сыйфатлар да беренче чиратта сөйләмдә чагыла. Кыскасы, зур әһәмияткә ия ул сөйләм. Шуңа күрә дә сөйләм культурасына даими игътибар һәркемнең көндәлек кайгыртуына лаек булырга тиеш. В. И. Ленин үзенең «Рус телен чистарту турында» исемле хезмәтендә безне нәкъ менә шуңа чакыра. «Рус телен без бозабыз»,— ди В. И. Ленин. «Чит сүзләрне кирәксезгә кулланабыз... Недочеты яки недостатки, яки пробелы, дип әйтергә мөмкин чакта, нигә «дефекты» диярга?» Аннары В. И. Ленин сорау куя: «Безгә инде чит сүзләрне кирәксезгә куллануга каршы сугыш игълан итәргә вакыт түгелме икән?» Мәкалә ахырында бу сорау тагын да катгыйрак булып яңадан кабатлана: «Рус телен бозуга каршы сугыш игълан итәргә вакыт түгелме икән?» [1].

Әлбәттә, сөйләм культурасын күтәрү өстендә эш иткәндә барыннан да элек ана телен яхшы белү кирәк. Бу — зарури. Хәлбуки, кайберәүләр уенча, татар телен яхшы белү хәзерге чорда кирәк түгел, аны бераз «сукаларлык» белсәң, имеш, шул җиткән. Андыйларның үзләренчә дәлилләре дә бар: әйтик, тугандаш халыклар белән аңлашу, аралашу өчен һәркемнән рус телен яхшы белү таләп ителә. Бу — бәхәссез. Ләкин менә шушы хакыйкатькә таянып, әлеге кешеләр ашыгыч нәтиҗә ясыйлар: рус телен белгәч, башкасын, янәсе, белеп бетермәсәң дә, яки бөтенләй белмәсәң дә гаеп түгел. Чөнки, алар уенча, рус теленнән тыш тагын ана телен дә өйрәнеп ятсаң, имеш, мәшәкать өстенә мәшәкать өелә. Ә инде адәм баласының хәзерге чорда — фән, техника революциясе чорында аннан башка да эшлисе эшләре муеннан.

Ләкин төптән уйлаганда бер телне яхшы белү белән чикләнеп калуны акларга теләүчеләр хаклы түгел. Асылда бу — зарарлы караш. Беренчедән, аның зарары шунда ки, ул югарыда китерелгән сөйләм «үрнәкләренең» гамәлгә керүенә сәбәпче булып тора. Икенчедән, әлеге караш совет кешесенең иҗтимагый аңы белән сыеша алмый.

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 30 том, 294 бит.

Мәгълүм ки, совет кешесе үзенең бөтен барлыгы белән — интернационалист. Ләкин социалистик интернационализм хисе — ул башка халыкларны хөрмәт иткән хәлдә, туган халыкны, туган телне, туган культураны санга санамау дигән сүз түгел. Остазыбыз В. И. Ленин күрсәтмәсен искә төшерик: «Безгә, великоруслардың аңлы пролетарийларына, милли горурлык хисе чит нәрсәме соң? Әлбәттә, юк! — ди В. И. Ленин.— Без үз телебезне һәм үз ватаныбызны яратабыз...» [1].

Бирелән аңлашыла ки, интернационалист кеше — ул үз халкының күркәм сыйфатларын хөрмәт итүче, ул сыйфатларны кайнар рәвештә пропагандалаучы. Интернационалист — ул беренче чиратта үз телен яхшы үзләштергән һәм аны пропагандалаучы кеше. Ниһаять, интернационалист — ул үз халкының культурасын яратучы, аны үстерү, баету буенча актив эшләүче кеше. Нәкъ менә үз халкын, үз телен, үз культурасын ярату, белү, пропагандалау аша кеше интернационализмга — башка халыкларны яратуга, аларның телен, культурасын хөрмәт итү, белү, пропагандалауга килә.

Әйтелгәннәргә өстәп, тагын ике цитата китерик. Шагыйрь Сибгат Хәким: «...үз халкын яратмаучы язучы интернационалист язучы була алмый». Әдип Атилла Расих: «Әгәр дә кешедә үз халкы белән горурлану хисе юк икән, ул инде интернационализм хисенә дә ия була алмый» («Социалистик Татарстан», 5. 10. 1975).

Менә ни өчен бары тик рус телен белү белән чикләнеп калуны алга сөрү, шул ук вакытта ана теле кирәклеген танымау, аны аңлашу-аралашуда кулланмау совет кешесенең интернационалистик рухы белән сыеша алмый. Чөнки үз телеңне танымау — ул туган халкыңны танымау, аны санга санамау дигән сүз.

Шулай ук тел өйрәнүне «өстәмә мәшәкать» дип санау да хата фикер. Үзенә эш бирүдән курку, өстәмә йөктән качу — ул шәхеснең рухи яктан баюына, сәләтләренең үсүенә тышау салу, аяк чалу һәм башка һични түгел. Эш болай тора: кешенең физик һәм рухи сәләте катып калган нәрсә түгел, сәләтне үстерергә, камилләштерергә мөмкин, һәм аны тутыктырырга, юкка чыгарырга мөмкин. Һәр ике якка үзгәреш кешенең эшчәнлегенә бәйле. Сәләтеңне ачарга телисең икән, эштән, хезмәттән, өстәмә йөктән курыкма. Чөнки барлык югары казанышлар, бөек ачышлар, гүзәл архитектура корылмалары, ниһаять, бөтен матурлык шушы җирлектә дөньяга килгән. Алыгыз Мисыр пирамидаларын! Аларның иҗатчысы бит Тырышлык, Эшчәнлек, Хезмәт! Яки менә бу мисалга игътибар итегез: хәзер һәркемгә билгеле булган аккумуляторны уйлап табу өчен Эдиссон 2 меңнән артык тәҗрибә ясаган. Ул көн саен унтүгызар сәгать бирелеп эшләгән. Ниһаять, тагын бер мисал. Жюль Верннның әдәби мирасында 100 дән артык калын роман хисаплана. Ә бит алар көн саен иртәнге биштән алып кичке сәгать 8 гә кадәр дәвам иткән киеренке иҗади эшчәнлек нәтиҗәсендә туганнар.

Китерелгән мисалларның сабагы шул: кеше йөктән, мәшәкатьтән курыкмаска тиеш. Юк, мәшәкать кешене баета, матур итә. Ана телен өйрәнүне «мәшәкать өстенә мәшәкать өстәү» дип санаучылар менә шушы хакыйкатьне истән чыгаралар һәм шулай итеп үзләрен артка сөйриләр. Бигрәк тә шунысы кызганыч: еш кына алар балаларны да «өстәмә йөктән» азат итәргә омтылалар. Әйтик менә: рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен дәүләтебез татар теле укытуны гамәлгә кертте. Тик, кызганычка каршы, ул дәресләргә кайбер балалар теләксез йөриләр, биремнәрне үтәмиләр, ялкаулык күрсәтәләр. Чөнки әти-әни әйтеп тора: «Балам, син өстәмә тел өйрәнеп, үзеңә көч китерә күрмә!» Әлеге дә баягы: «Көч китермә, кызым! Баш ватма, улым!»

Әйтергә кирәк, балага мондый киңәшләрне бирүчеләр белепме, белмичәме бик зур хата ясыйлар.

Эш шунда ки, тел — ул халык байлыгы. Телдә халык үзе — аның акыл эшчәнлеге, зирәклеге, уй-тойгылары... гәүдәләнә. Шуңа күрә дә бу хәзинәне хөрмәт итәргә, аны күз карасы кебек сакларга кирәк. Чөнки... «тел бетә икән,— дип күрсәтә бөек рус педагогы К. Д. Ушинский,— халык та юкка чыга». Аннары К. Д. Ушинский болай дип өсти: «Халык сөйләмендә тел яшәсә, халык үзе дә яши. Халык сөйләмендә тел үлдеме, халык үзе дә үлә» [2].

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 21 т., 94 бит.
[2] К. Д. Ушинский. Изб. пед. произведения, Москва, 1968 г., стр. 328.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар: баланы «көч китерүдән» саклап калырга юнәлтелгән киңәшләр бу очракта бала өчен үтә зарарлы. Алар баланың сәләтләре ачылмый калуга сәбәпче булалар. Чөнки сәләт эштә, хезмәттә, көч түккәндә ачыла. Шуңа күрә дә баланы баш ватмаска түгел, бәлки күбрәк баш ватарга димләргә, күнектерергә кирәк. Әйдә тырышсын — сәләтле булыр! Баш ватсын — башлы булыр! Көч түксен — көчле булыр! Тик бер генә шарт бар: йөк исә бала күтәрмәслек йөк булмасын!

Өстәмә йөктән курыкмаучы ата-аналар шулай эшлиләр дә.

...Бүгенге көндә Бакуда 20 яшьлек физика-математика фәннәре кандидаты яши. Аның исеме — Илһам, фамилиясе — Мамедов. Ике яшьтә чакта әнисе Илһамга шигырь ятларга куша. Яшь бала өчен бу — зур йөкме? Әйе. Ләкин күтәрмәслек түгел. Шуңа күрә дә ана кеше: «башың ватма, улым!» — дими, «өйрән»,— ди. Һәм бала өйрәнә. Моннан соң яңа эш — пианинода уйнарга өйрәнү башлана. Бусы да — зур эш, шулай бит? Ләкин күтәрмәслек түгел. Шуңа күрә дә ана курыкмый, баланы көч түгәргә димли. Нәтиҗәдә бу юлы да эш барып чыга: Илһам 4 яшендә пианинода уйный башлый. Бирем һаман үзгәрә, үсә. 5 яшендә Илһам тапкырлау таблицасын үзләштерә. 15 яшьтә — ул студент, егермедә — фәннәр кандидаты.

Телләрне өйрәнү өлкәсендә дә үзенә йөк бирүдән куркырга кирәк түгел. Киресенчә, эшләт үзеңне, өйрән, бел! Тел белү — ул кешене көчле итә. Башка телләрне өйрәнү юлында исә татар телен белү эшне бермә-бер җиңеләйтүче корал булып тора.

Мәгълүм ки, телләрне өйрәнгәндә кеше беренче чиратта чит телнең үзенчәлекле аваз системасы белән очраша. Алыйк немец телен: бирелә һ, ң, ә, ... ү кебек авазлар бар. Аларны дөрес әйтергә өйрәнү җиңел түгел. Ана телендә мондый авазлар булмаган очракта эш тагын да читенләшә. Ә менә татар телен белүче өчен андый кыенлык юк, чөнки әлеге сузыклар татарның үз телендә дә бар.

Инглизчә өйрәнгәндә дә татар теленең ярдәме — бәхәссез. Әйе, Тукай бик белеп әйткән:

**И туган тел, и матур тел — әткәм, әнкәмнең теле,**
**Дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы.**

Безнең остазларыбыз — бөтен дөнья хезмәт ияләренең даһи юлбашчылары К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин күп телләрне белгәннәр һәм төрле телләрдә эш иткәннәр.

Хәзерге чорда — халыкларның үзара аңлашу-аралашу мөмкинлекләре көннәнкөн арта барган фән-техника революциясе чорында һәр милләт кешесенә, безнеңчә, кимендә өч телне яхшы белергә кирәк. Без — татарларга — туган телне, аннары — рус телен һәм Европа халыкларының бер телен. Туган телне өйрәнү исә беренче урында торырга тиеш. Чөнки ана теле — бала өчен туган халкының рухи һәм иҗади байлыкларын үзләштерү, кабул итү юлында иң көчле, иң үтемле корал. Шул ук вакытта ана теле — ул остаз һәм тәрбияче дә. Халык тормышын, әйләнә-тирәдәге мөнәсәбәтләрне тиз һәм ачык итеп балага беренче булып кем җиткерә? — Ана теле! Әти-әнигә карата — хөрмәтне, халык эшчәнлегенә — ихтирамны, культура казанышларына аңлы мөнәсәбәтне балада беренче булып кем тәрбияли? — Ана теле! Ниһаять, матурлык хисен, хыял эшчәнлеген балада беренче булып кем кабыза һәм тәрбияли? — Туган тел.

Менә шуңа күрә дә үткән заманнарның бөек педагоглары — Я. А. Коменский, И. Г. Песталоцци, Н. Г. Чернышевский, Н. А. Добролюбов, К. Д. Ушинский, Каюм Насыйри һәм башка бик күпләр бала укыту-тәрбияләүне ана теле мәктәбеннән башлап китәргә чакырдылар.

Әлбәттә, хәзер фән һәм техника революциясе чорында бер генә кеше дә үз халкының казанышлары эчендә генә йомылып яши алмый. Коммунистик җәмгыять төзү практикасы һәркемне тугандаш халыклар белән бергә кулга-кул тотышып уртак мәйданда эш итәргә тарта. Бирелә инде милләтара аңлашу-аралашу коралы вазифасын рус теле үти. Һәр тугандаш милләт вәкиле өчен рус теле ул фән казанышларын үзләштерү, коммунизм төзү тәҗрибәсен уртаклашу коралы булып тора. Шуңа күрә дә без, ана теле белән бергә, рус телен яхшы белергә тиеш.

Ләкин хәзерге заман совет кешесенә боларны белү генә дә җитми әле. Бу-

генге көндә коммунизм төзү идеалы дөньяның барлык почмакларында яшәүче халыклар аңына үтеп керде. Бу идеал тормыш агышын, барлык милләт кешеләре эшчәнлеген, фән-техника үсешен үз орбитасына туплый. Менә шушы коллектив эшчәнлеген, дөнья фәне казанышларын белү, өйрәнү, файдалану өчен безгә Европа халыкларының һәм бүтән илләрнең дә кайсы да булса бер киң таралган телен белергә кирәк.

Заман таләбе шундый! Ләкин нинди генә тел белергә теләмә, аны үзләштерү юлында нигез ташы булып ана теле тора. Чөнки үз телеңне — ана телен белми торып, чит телне үзләштерергә омтылу — ул арифметикадан дүрт гамәлне өйрәнмичә торып турыдан-туры тигезләмәләрне чишәргә маташу кебек үк мәгънәсезлек.

Хәзерге чорда татар теле — һаман үсә, чарлана, камилләшә баручы тел. Ул бүген дөнья әдәбиятының бөек казанышларын тулы канлы итеп тәгъбир итәрлек көчкә ия.

**Без телибез: саф гүзәллек арта барсын,**
**Шунда аның нәфис гөле һич тә шиңмәс,—**
**Җимеш пешеп, өзелеп төшсә — орлык калсын,—**
**Шунда аңар мәңге-мәңге үлем килмәс.**
**Әмма син — буш, үз-үзеңә гашыйк булып,**
**Дәрт утына гел үз маең салырсыңмы!**
**Муллыгыңны ачлык итеп, яшьли сулып,**
**Үз-үзеңә дошман булып калырсыңмы!**
**Син — дөньяда бер саф бизәк, бәхет гөле,**
**Матур язның хәбәрчесе — үзең һаман.**
**Тик ачылмый, йомык тора синең бөре,**
**Чөнки җаның чүл төсле буш, дымга саран.**
**Табигатьне кызгансана, кылма җәбер,**
**Чибәрлегең йотар юкса тирән кабер [1].**

Китерелгән юллар — Шәрәф Мөдәррис тәрҗемәсендә басылып чыккан бөек Шекспир сонетларыннан бер мисал. Күренә ки, әлеге сонет, оригиналдагы кебек үк, татар телендә дә тирән мәгънәле, көчле, тәэсирле яңгырый.

Әгәр дә инде без төгәллек, конкретлык, образлылык дибез икән, бүгенге татар телендә ул сыйфатлар да җитәрлек. «Ул яшь чакта имән кебек таза, лачын кебек үткен, арыслан кебек гайрәтле булган, дип сөйлиләр» [2]. Менә сезгә Г. Ибраһимов таланты татар теле ярдәмендә кешенең конкрет образын «ыһ» иткәнче сурәтләде дә куйды. Шулай ук бүгенге татар теле кеше күңелен иркәләрлек нәфислектән, самимилектән дә мәхрүм түгел. Менә Г. Бәшировтан берничә юл:

«Аксыл зәңгәр күктән, мул булып, яз кояшының саргылт нуры коела; тау кырыйларында, каралты түбәләрендә, күз иярмәслек тизлек белән, җылы дулкыннары тирбәлә, кырлар өстендә, күзне камаштырып, язгы карның көмеш бизәге балкып тора» [3]. Ниһаять, бүгенге татар теле — ул көрәшче, сугышчы. Аның бу сыйфаты Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»нә кергән шигырьләрдә аерата калку булып чагыла.

**Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,**
**Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,**
**Кирәк икән, үләм аягүрә,**
**Балта белән башым киссәң дә.**

Әлбәттә, югары тел культурасы кешегә үзеннән-үзе килми. Моның өчен язучыларыбызның әсәрләрен, татар телендәге газета-журналларны даими укып барырга кирәк. Бигрәк тә көндәлек аралашуда телне бозмыйча, кадерләп куллану зарури булып тора. Заман таләбе шундый.

**ШӘРӘФ ӘХМӘДУЛЛИН,**
**Казан педагогия институтының чит телләр**
**кафедрасы мөдире, доцент.**

---

[1] В. Шекспир. Сонетлар. Ш. Мөдәррис тәрҗемәсе. Казан, 1961 ел, 7 бит.
[2] Г. Ибраһимов. Алмачуар. Казан, 1967, 6 бит.
[3] Намус. Казан, 1962, 15 бит.

# «ПАНЧАТАНТРА»

Борынгы һинд әдәбиятында мәсәл язу акыл өйрәтүле вәгазь сөйли һәм киңәш бирә торган «Шастра» исемле жанрдан башланып китә. Мәсәлләр нигездә кешеләрне тормышта үзләрен акыллы һәм гадел, яхшы холык-фигыльле булырга өндәп языла. «Панчатантра»га кереш сүздә дә бу турыда легенда телгә алына: имештер, ниндидер бер патша үзенең надан һәм ахмак улларының башында акыл уятырга тели. Шушыны гамәлгә ашыру өчен Вишнушарман исемле зирәк бер зат нәкъ менә шушы «биш китап»ны (1. Дусларны бер-береннән аеру. 2. Дуслар табу. 3. Каргалар һәм ябалаклар турында. 4. Тапканны югалту. 5. Акылсыз кыланышлар) яза. «Панчатантра» — санскритча биш китап дигән сүз. Әсәрләрдә кешеләрнең үз-үзен тотышы тормышның ул чактагы төп максатлары итеп сайланган дүрт күзлектән карап сурәтләнә: дхарма — гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге бурычлар, артха — мал-табышка омтылу, кама — хис ләззәтләре, мокша — фани дөнья эшләреннән ваз кичү. Алар, башланыш белән бетемнең очын очка ялгаган форма белән, фольклор сюжетларын яки дөнья әдәбиятында булган шундый бүтән сюжетларны файдаланып иҗат ителгәннәр. һәр очракта диярлек шигъри афоризмнар яки читләтүле тапкыр чигенүләр белән тасвирланган фактлар «Биш китап»та, гәрчә алар күбрәк җәнлек-җанварлар тормышыннан алынсалар да, кешеләр дөньясының реаль вакыйгаларын чагылдыра: җәмгыятьтә гаделсезлекләр эшләүче, мал һәм дан артыннан куучы комсыз, намуссыз затларны сатира уклары белән кейдерә. Аларда кешеләрне аңлы яшәргә өндәп, көчлеләргә каршы көрәшү өчен көчсезләрне бердәм булып берләшергә чакыру рухы көчле. Шуңа күрә дә аның бөтендөнья әдәбиятына йогынтысы зур. Инде VI гасыр урталарында ук аны фарсы теленә (пехлеви) тәрҗемә итәләр, шул вариант исә соңыннан Сүрия һәм башка гарәп илләрендә чыга. Гарәп телендә «Кәлилә һәм Димнә» дигән исем белән басылган язманың исә грек («Стефанит һәм Ихнилат»), славян һәм рус, аннары латин, немец, француз, инглиз, төрек, яван, лаос, тхай телләренә тәрҗемә ителгәне билгеле. Гомумән, «Панчатантра»ның 60 телдә басылган 200 ләп тәрҗемәсе бар.

Безнең замангача 3—4 гасырларда иҗат ителгән һәм таралган бу җыелманың төп нөсхәләре сакланмаган.

Укучыларыбызга бу санда атаклы биш китапның һәрбереннән берәр хикәят-мәсәл тәрҗемәсе тәкъдим итәлә.

## Унынчы хикәят

Бер патшаның гаять затлы ятагында, түшәк япмасы бөрмәсенә ышеренеп, Мандависарпини исемле бет яшәгән, ди. Үзенең күп санлы нәселдәшләре һәм туганнары — уллары-кызлары һәм оныкларыннан бер дә яшермичә, ул йокыга талган патша канын гына эчә икән. Шуңа күрә дә ул күзгә күренеп симерә һәм бүтәннәр күзенә затлырак кыяфәттә күренә башлый. Көннәрнең берендә нәкъ шул ятакка Дундука исемле бер кандаланы җилләр китереп ташлый. Ике мендәрле, Джахнавиның комлы ярларын хәтерләткән юка җәймәле гадәттән тыш булмәгә керүгә кандаланың исе китә. Хәтта акылыннан язарлык хәлдә кала ул.

Шулай аптырап әрле-бирле йөргән арада язмыш аны әлеге Мандависарпини белән очраштыра.

Һәм әйтә икән теге:

— Патша үзе генә торырга тиешле бинага каян килеп кердең әле син? Тизрәк табан ялтырат биредән!

Кандала үз җавабын өзеп әйтә:

— Алай димә, хөрмәтлем. Һәм миңа ни өчен артыгын да әйтмә:

Мәҗүсиләр утны ничек ярата,
Дин башлыгын һәркем шулай яратсын.
Ир кадерен белү — хатын бурычы,
Кунак килсә — елмай аңа карап син.

Мин синең кунагың. Күп төрле каннар эчеп ләззәтләнгән җан иясемен: брагманнар, шкатрилар, вайшьялар һәм шудрлар канын да татып карадым. Алар каны нигәдер тозлы һәм лайлалы икән, шуңа күрә дә аны эчеп кенә туеп булмый. Ә әнә теге зиннәтле ятакта йоклаучының каны, һичшиксез, ширбәтләрнең дә ширбәте, җимнәрнең дә җимнәре кебек татлыдыр. Аңа бернинди сырхау йокмаска тиеш, чөнки табиблар аңа төрле-төрле дарулар эчертә, төрле-төрле үләннәр кайнатып эшләнгән шифалы сулар каптыра, ә оста пешекчеләр исә аның җанына һәм тәненә көч кертә торган тәмле-тәмле ашларны шикәр, гранат, имбир һәм борыч кебек тәмләткечләр кушып әзерлиләр. Ул безнең туклыклы, уңдырышлы җирләре, иң яхшы сулары булган һәм иң яхшы һавалы илнең иң симез итләрен ашый. Аның каны — яшәү өчен кирәкле иң көчле дәваларның берсе саналырга тиеш. Мәрхәмәтле бул да, шуны тагын бер кабат татып карарга рөхсәт ит миңа — чөнки ул хуш исле дә, татлы да, туклыклы да, шатлыклы да бит.

Бет җавап бирә:

— Юк. Синең шикелле ут авызлы һәм теш-телле бөҗәккә моны рөхсәт итү мөмкин түгел. Әйтелгән бит:

Кем акылсыз һәм уйламый эш итә,
Уңай чакны, тиеш җирне белмичә,
Кайгыртмыйча эш ни белән бетәсен —
Андыйлар бит бары юкка көч түгә.

Әмма кандала, аның аякларына түбәнчелек белән баш иеп, шәфкатьрәхим көтә.

Ә бет әйтә:

— Әйдә, алайса, булса шулай да булсын, ди. Ләкин син патша канын бары тик җайсыз урында һәм бары тик уңайсыз чакта эчәргә тиеш буласың.

Кандала сорау бирә:

— Ә моны кайчан һәм кайда эшләргә мөмкин соң? Мин бит бирегә әле күптән түгел генә иялаштем һәм сездәге гадәт-йолаларны бик төгәл белмим.

Бетнең җавабы менә нинди була:

— Әгәр дә патша исереп, арып яки йокыга талып ава икән, син бик сак кына аның аягын тешләргә тиешсең. Иң җайлы вакыты да, иң тиешле урыны да шул булыр.

Кандала аның белән килешә. Әмма ничектер кичен ул, карыны бик ачыккач, үзен-үзе тыя алмыйча, патшаның аркасын тешли. Ә патша исә, әйтерсең, аның йокыга талган гәүдәсенә кызган таш салалар, әйтерсең, аны көтмәгәндә чаян чага — кинәт каты сискәнеп сикереп тора да, аркасын угалый-угалый, кычкыра башлый:

— Ой-ой-ой! Кем чакты мине, кем тешләде? Хәзер үк табып китерегез миңа шул бөҗәкне!

Бу сүзләрне ишетүгә, курка калган Дундука бик тиз чабып китә һәм караваг ярыгына кереп кача. Ә аннары шул бүлмәгә патша әмерен үтәүчеләр килеп чыга һәм, утлар яктыртып, эзләнә башлыйлар. Язмыш шулай кушкандыр, күрәсең, алар киемнәр арасына кереп поскан Мандависарпинины табалар һәм аны, барча туган-тумачалары белән бергә, сытып бетерәләр.

Шуңа күрә дә әйтәм мин: «Кемгә дә булса җылы почмак яки түр урын тәкъдим итүләре куркыныч...» һәм моннан тыш илаһи кешеләр үзләренең булышчыларын һәм нәселдәш асрауларын түбәнсетмәскә тиешләр. Юкка гына әйтелми бит:

Кем дустан, туганнан бизеп,
дошман белән әшнәләшә,
Юләр Чандарава кебек,
шул кеше үлемгә атлый.

## Икенче китаптан

## Беренче хикәят

Биредәге бер күлдә бхарунда исемле кошлар яшәгән. Һәркайсының бер ашказаны һәм ике муены булган. Ничектер бер көнне, болын-сәхрәгә чыгып йөргәндә, бхарунда бер муенын сузып чәчәктән җим суыра башлый. Шул чакны аңа икенче муен үзенекен әйтә:

— Бүлешик әйдә, мин дә авыз итимче шуны.

Беренче муен җим татуны рөхсәт итмәгәч, икенчесе каяндыр агу табып ала да шуны йота. Күп тә үтми, муеннарның икесе дә үлеп-сәлперәеп салынып төшә — чөнки аларның ашказаннары бер үк була бит.

Шуңа күрә дә әйтәм мин: «Бер ашказаны, ике муен...» Безнең көч — тик берлектә.

## Өченче китаптан

### Унбишенче хикәят

...Бер урман читендә Кхаранакхара дигән арыслан тора икән. Ничектер берчакны ачтан интегеп, муеннары нечкәреп беткән шул арыслан үзенә ризык эзләп урман буйлап йөри, ләкин тамак ялгарлык берни дә таба алмый. Кичен исә ул чиксез дәү бер тау куышына барып керә һәм мыегына шундый бер катгый фикерне урый: «Төнен бу ояга, һичшиксез, нинди дә булса бер җанвар кайтып керәчәк. Бер почмакка посып мин шуны көтәм». Һәм менә кичен куышның хуҗасы — Дадхимукха исемле шакал үзе кайтып, ишек төбендә туктый да бик каты итеп кычкыра башлый:

— Әй, куыш! Куыш! — шулай ди дә ул, бераз тынып тора һәм яңадан үзенекен тезеп китә: — Ничек сүз куешканыбызны әллә оныттыңмы син? Һәр вакыт, каян да булса кайтып җитүемә, мин сиңа ишек төбеннән торып кычкырам, ә син эчтән җавап бирәсең. Әгәр бернинди тавышың-тының чыкмаса, мин бүтән куышка китәм — ә андагы минем белән, әлбәттә, сөйләшәчәк.

Шакалның шул сүзләрен ишетә дә уйга кала арыслан: «Күрәсең, бу куыш аны һәр кайтуында шулай сәламләп каршылыйдыр. Ләкин куыш исә, минем биредә булуымнан куркып, бүген дәшми. Димәк ки, сәлам сүзен мин үзем әйтергә тиешмен. Ә ул, чакыру авазын ишетеп, монда килеп керәчәк һәм мин аны тотам да ашыйм»...

Шулай хәл итә дә, шакалны тәбриkләп, бик каты улый башлый арыслан. Шул тавышның яңгырашы, хәтта урмандагы куыштан еракта яшәүче барча җан ияләрен дә куркытып, бөтен тирә-якка тарала. Ә куыш янынннан качып киткән шакал исә шундый шигырь укый: «Саклана беләсең икән — гомерле була аласың...»

## Дүртенче китаптан

### Җиденче хикәят

Бер авылда буяучы Шуддхапата исемле кеше була. Аның көн саен диярлек ач торып интеккән ишәге бар икән. Бервакыт, урман аша узганда, шул буяучы юлда яткан үле юлбарысны күрә. Күрә дә уйлый: «Менә ничек шәп булды бит әле! Бәхетем аяк астында аунап ята. Шушы юлбарыс тиресен мин үз ишәгемә кидерәм дә, төнлә аны арпа кырына чыгарып җибәрәм. Каравылчылар аны, юлбарыс бит бу дип уйлап, кырдан, әлбәттә, кумаячаклар». Һәм шулай эшли дә. Төннәрен ишәк арпа ашап йөри, ә таң алдыннан исә буяучы аны өенә куып китә. Һәм күпмедер вакыт узуга ишәк дигәнебез хәтта үз абзарына сыймаслык булып симереп тә өлгерә.

Ләкин көннәрнең берендә ул каядыр еракта бүтән бер ишәк улавын ишетә һәм, шуңа җавап бирергә ашыгып, үзе дә акыра башлый. Нәкъ шул чакны, ят кием кигән ишәк икәнен аңлап алып, каравылчылар аны күсәк белән кыйнап, ташлар атып һәм тәненә уклар кадап үтерәләр...

## Җиденче хикәят

Бер калада Свабхавакрипана исемле брахман яшәгән, ди. Аның хәер эстәп җыйган ярма белән тулы бер чүлмәге була. Шушыны ул стенадагы бер кадакка элеп куя һәм гел шуңа гына карап караватында ята икән. Төннәрнең берендә аның башына менә шундый уй килә: «Чүлмәк тулы ярмам бар. Шуның акчасына мин ике кәҗә сатып алам. Алар елына икешәр мәртәбә бәтилиләр дә минем бер көтү кәҗәм була. Аннары ул кәҗәләрне сыерларга алыштырам. Сыерларның бозауларын сатып исә мин буйволлар алам, ә буйволларны саткач — бияләр... Бияләр колынлагач минем бик күп атларым була, шуларны саткач исә мин бер өем алтын иясе булам. Шул алтынга йорт салам. Аннан соң миңа кем дә булса бик зур бирнә белән үзенең гүзәл кызын бирә. Шул хатыным малай таба да мин аңа Сомашарман дигән исем кушам. Ул инде итәккә утырырлык булып үскәч, мин кулыма китап алам да, аран артына утырып, шуны игътибар белән укый башлыйм. Ә шул чакны әнисенең итәгендә утырган Сомашарман мине күреп ала да, әти, сикертеп уйнат әле дип, атлар янына якынрак килә башлый. Шунда мин ачу белән хатыныма кычкырам: «Ал баланы, хәзер үк килеп ал!» Ә ул, өй эшләре белән мавыгып, мине ишетми. Шунда мин урынымнан сикереп торам да аны аяк белән тибәм...» Нәкъ менә шул минутта, үз уйларына чиксез бирелеп, аягын бик югары күтәрә брахман һәм әлеге чүлмәкне бәреп вата — аның бөтен өстенә ап-ак ярма сибелә.

Күңеленә һичкайчан булмас нәрсәләрне өмет итәргә котыртучы иблис оялаган һәр кеше шулай көлкегә кала. Бик дөрес әйтәләр бит:

Булмаганны булдырам дип, кем бушка азап чиккән,
Сомашарман әтиседәй, ярманы әрәм иткән.

Гамил Афзал

## Сәфәргали сәфәрдән кайтты

...Дөньяны гиз, дус-дошманны таны,
Ник йөрмәскә форсат булганда.
Без дә күрдек аны Европаны —
Һуш китәрлек нәрсә юк анда.

Туң кәбестә күчәннәре түгел,
Культурасыз димәс беркем дә, —
Авыл хуҗалыгы эшчәннәре
Кунак булып йөрдек чит илдә.

Европа дип килеп төшкән шәпкә,
Ух-ах итте сезнең кебекләр.
Манаралы йортлар биекләр дә,
Өйрә сыек анда, егетләр.

Тәре походлары сугышларын,
Музейдагы тутык кылычларын
Карыйсың да, мыек борасың,
Пардон, пардон дигән буласың...

Рестораннар болай ярыйсы да,
Көзгесенә карап туясың.
Бер песилек кәтлит ялыйсың да,
Мерси, мадам, дигән буласың...

Мамзельләре йөри терек-терек,
Танышырга телен белмисең,
Күзне кыссаң гаеп булыр кебек,
Культураңны саклап йөрисең.

Буржуй сүзен тыңлап нинди файда,
Талашмагач авыз тутырып,
Сарык боты кимерүләр кайда,
Аякларны бөкләп утырып!

Эч пошканда ачы су да сыра
Исән-саулык өчен күтәрдек.
Кая инде ул безнең «Экстра» —
Табаныңа төшеп җитәрлек!

Үзебезнең стансаны күргәч,
Коргаксыган артель туярлык
Беләк буе колбаса һәм күмәч,
Теге-буны алып юандык.

Дөньяны гиз, дус-дошманны таны,
Вакыт җитеп, форсат булганда.
Без дә күрдек аны Европаны —
Шаккатарлык нәрсә юк анда...

## Эч пошканда

Рия тулы теләкләрне олы сүзләр белән каплап,
Эч пошыргыч типлар йөри эшне ваклап, җанны ваклап.

Уңда-сулда әшнәләре эш кыралар биеп кенә,
Миңа файда, сиңа файда, алдым-бирдем диеп кенә.

Кызу канлы кайберәүләр телен тешләп эчтән тына,
Вак күңелле юашларга вакланырга сәбәп чыга.

Алга таба юл якты дип, җырлап алыйк бу чакны дип,
Көлә-көлә макташабыз син яхшы дип, мин яхшы дип.

Игътибарлы, инсафлы без үткәннәргә-сүткәннәргә —
Кечеләргә күз төшерми, тел озайтмый өлкәннәргә.

Берәү булса туры сүзле, кыю акыл, җаны тапсыз,
Тиле, дибез, яши белми, фикер йөртә масштабсыз.

Начальниклар ни әйтер дип, авыз ачып тик торганда,
Төрле-төрле уйлар килә эч пошканда, борчылганда.

●

Туры әйткән ярамый шул туганына,
Уйлый күңел ул ягын да, бу ягын да.
Урап-урап, кыек атып туры тигән
Эзоп теле ярдәм итә шул чагында.

## БӨЕК ӘДИП ИСТӘЛЕГЕНӘ

* * *

Март аенда татар әдәбияты классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 90 ел тулу уңае белән СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Татарстан Язучылар союзы фәнни конференция үткәрде.

Галимнәр, язучылар һәм әдәбият сөючеләр «Татар совет культурасы үсешендә Г. Ибраһимовның роле» дигән темага филология фәннәре докторы М. Х. Хәсәнов, «Г. Ибраһимов — марксизм-ленинизм идеяләре пропагандисты» дигән темага философия фәннәре докторы К. Ф. Фасеев, «Г. Ибраһимов эстетик карашларының эволюциясе» дигән темага филология фәннәре докторы Г. М. Халитов, «Әдәбиятлар дуслыгы мәсьәләләре һәм Г. Ибраһимов» дигән темага филология фәннәре докторы Л. И. Климович (Мәскәү), филология фәннәре докторы А. Гаджиев (Баку), филология фәннәре кандидаты Ш. Турдыев (Ташкент), филология фәннәре кандидаты Р. Баимов (Уфа) һәм филология фәннәре кандидаты Р. Ганиева чыгышларын тыңладылар.

Г. Ибраһимов әсәрләренең рус теленә тәрҗемәсе турында филология фәннәре кандидаты Г. Хантимерова (Мәскәү), «Татар иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүдә Г. Ибраһимовның роле» дигән темага философия фәннәре кандидаты Я. Абдуллин, Г. Ибраһимовның журналистика өлкәсендәге эшчәнлеге турында филология фәннәре кандидаты Р. Нуруллина, «Г. Ибраһимов — тел галиме» дигән темага филология фәннәре кандидаты Ф. Фасеев, «Г. Ибраһимов әсәрләрендә психологизм» дигән темага филология фәннәре кандидаты Ф. Хатипов, Г. Ибраһимовның хикәяләү стиле үзенчәлекләре хакында филология фәннәре кандидаты Ф. Сафиуллина һәм Г. Ибраһимовның иҗади лабораториясе турында язучы Ә. Мөхәммәдовaларның чыгышлары да тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты.

Конференцияне кереш сүз белән Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының директоры, тарих фәннәре докторы М. Мөхәррәмов ачты һәм докладлардан соң фикер алышулар тәмамлангач, конференция эшенә йомгак ясады.

* * *

М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында Галимҗан Ибраһимовның тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы кичә узды.

Кичәне ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты. Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыкты.

Тантаналы кичәдә ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты секретаре Ф. Г. Гайнуллин, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары А. М. Котов, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре Р. М. Мусин, республикабызның хезмәт алдынгылары, студент яшьләр, иҗат көчләре, тантанага килгән кунаклар катнашты.

* * *

Республикабыз шәһәрләрендә, авылларында бөек әдип истәлегенә багышланган әдәби-музыкаль кичәләр дәвам итә.

Әлмәт шәһәренең 1 номерлы татар урта мәктәбендә уздырылган юбилей кичәсендә Татарстан Язучылар союзы Әлмәт бүлегенең җаваплы секретаре Әдип Маликов бүгенге татар совет прозасында Г. Ибраһимов традицияләренең дәвам итүе турында сөйләде. Өлкән класс укучылары әдипнең әсәрләреннән өзекләр укыдылар.

Язучылар һәм яшь язучылар катнашында Г. Ибраһимовка багышланган әдәби кичәләр Лениногорский районының Муса Җәлил исемендәге колхозында һәм Азнакай районы мәктәпләрендә үткәрелде.

* * *

«Васильево» санаториясендә ял итүчеләр Г. Ибраһимовның тууына 90 ел тулуга багышланган кичә уздырдылар. Язучы Габдрахман Минский әдипнең әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында сөйләде, аның әсәрләреннән өзекләр укылды.

## ҖИТДИ СӨЙЛӘШҮ

СССР Язучылар союзының яшь язучылар белән эшләү советы үзенең беренче пленумын үткәрде. Анда КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карары нигезендә зур сөйләшү булды. Совет члены Зәки Нури республикабыз яшь язучылары белән эшләү практикасы турында чыгыш ясады.

## ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР

«Литературная газета» һәм Казагыстан Язучылар союзы идарәсе «Милли әдәбиятлар турында түгәрәк өстәл янында сөйләшү» дигән очрашу үткәрде.

Октябрь революциясенең 60 еллыгына багышланган бу очрашуда рус, казакъ, үзбәк, таҗик, кыргыз, төркмән, татар

әдәбиятларының күренекле вәкилләреннән 25 язучы катнашты.

Татар язучыларыннан Сибгат Хәкимнең татар һәм казакъ әдәбиятлары дуслыгы һәм аның традицияләре турындагы чыгышын кызыксынып тыңладылар. Сибгат Хәким Алма-Ата хезмәт ияләре каршында үткәрелгән дуслык кичәсендә рус һәм татар телләрендә үзенең шигырьләрен укыды.

## ХАЛЫКАРА КҮРГӘЗМӘДӘ

Март-апрель айларында Мәскәүдә, Художество академиясе залларында, «Сатира — тынычлык өчен көрәштә» исемле халыкара күргәзмә булып үтте.

Күргәзмә СССР Культура министрлыгы, СССР Художество академиясе, СССР Художниклар союзы, СССР Журналистлар союзы, Тынычлыкны яклау Совет Комитеты, Совет тынычлык фонды һәм РСФСР Художниклар союзы тарафыннан оештырылган иде.

Мондый күргәзмәләр уздыру традициягә керде. Быелгысы — өченче.

Дөньяның иң күренекле карикатура осталарыннан торган халыкара жюри Польша һәм Франция, Венгрия һәм Дания, Чехословакия һәм Япония, Монголия, АКШ һәм барлык континентлардагы башка илләрнең прогрессив рәссамнары җибәргән карикатуралардан, плакатлардан, сатирик скульптуралардан иң яхшыларын гына сайлап алды.

Советлар Союзы вәкилләре булырак катнашкан рәссамнар арасында Татарстан республикасыннан да зур бер төркем карикатура осталары бар иде.

Рәссамнарыбыз И. Әхмәдиев, И. Бобровицкий, Л. Бочкова, Ю. Денисов, Л. Елькович, В. Игнатьев, Л. Насыйров, С. Насыйрова, И. Хантимеров тарафыннан башкарылган сугышчан, үткен политик сатира әсәрләре зур бәя алды.

Татарстан осталары экспозициясе Тынычлыкны яклау Совет комитеты **Почет грамотасы** белән бүләкләнде. Аңа «Тынычлыкны яклаучылар хәрәкәтендә актив хезмәт иткән өчен» дигән сүзләр язылган.

Политик плакатлар сериясе өчен **Лотфулла Насыйров бронза медаль, Юрий Денисов ГДР Журналистлар союзының махсус призы** белән бүләкләнделәр.

Бу — республикабыз карикатура осталарының зур һәм лаеклы уңышы.

Мәскәүдән соң күргәзмә чит илләр буйлап сәяхәткә чыга.

## БАШКАЛА КИТАПХАНӘСЕНДӘ

Мәскәүдә Н. А. Некрасов исемендәге Үзәк шәһәр китапханәсенең «СССР халыклары әдәбияты» филиалында Муса Җәлилгә багышланган бүлек оештырылды. Анда герой шагыйрьнең китаплары, төрле документларның фотокүчермәләре, фоторәсемнәр, әдәби журналларның, үзәк һәм республика газеталарының Муса Җәлил турында материаллар басылган саннары, «Муса Җәлил» фотоальбомы куелган. «Муса Җәлил турында истәлекләр» китабы, Рафаэль Мостафинның герой-шагыйрь турындагы китаплары, Гази Кашшафның «Муса Җәлил», Әнвәр Давыдовның «Муса абый», Шәйхи Маннурның «Муса», Юрий Корольковның «Кырык үлемне җиңеп» әсәрләре, Роберт Бикмөхәммәтовның «Муса Җәлил», Фоат Мостафинның «Муса Җәлил — педагог» дигән гыйльми хезмәтләре шагыйрь бүлеген тулыландырып торалар.

## КОММУНИСТЛАРНЫҢ ПАРТИЯ УКУЛАРЫ

КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында республикабыз иҗат көчләренең чираттагы укулары булды. Язучылар, композиторлар, художниклар, артистлар «Фәнни-техник революция һәм дөньяны эстетик үзләштерү» дигән темага философия фәннәре кандидаты Р. В. Мөрсәлимовның докладын зур кызыксыну белән тыңладылар. Докладтан соңгы фикер алышуларда язучы Диас Вәлиев, тәнкыйтьче Флүн Мусин, музыка белгече Земфира Сәйдәшевалар катнашты.

## ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ БАШКА ТЕЛЛӘРДӘ

* * *

Мәскәүнең «Современник» нәшрияты Гариф Ахуновның «Хәзинә» исемле китабын бастырып чыгарды. Китапка «Хәзинә» романы һәм «Ардуан батыр» повесте тупланган. Әсәрне рус теленә Рәшит Ахунов тәрҗемә иткән.

[illegible] ...йловлар катнаш[illegible]

* * *

**Балалар язучысы Шамил Рәкыйповның «Кызлар-йолдызлар» повесте буенча Арча педагогия училищесы укучылары конференция үткәрделәр. Хәрби-патриотик тема-** [illegible]

Балалар язучысы Җәвад Тәрҗемановның «Шуктуган» повесть-әкияте литва теленә тәрҗемә ителеп чыкты. Китапны Вильнюс шәһәренең «Вага» нәшрияты чыгарган.

* * *

Мәскәүдә немец телендә чыга торган «Нойес Лебен» («Яңа тормыш») үзәк газетасында Вахит Монасыйповның балалар өчен язылган «Кире беткән кадак», «Тапкыр Сережа» һәм «Сүз тыңлаучан Әбүбәкер» исемле шаян хикәяләре дөнья күрде.

* * *

Мурманск өлкә драма театрында Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасы сәхнәгә куелды. Әсәрне русчага Ю. Мочалов тәрҗемә иткән. Режиссеры — РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. Киселев.

Премьерада автор үзе дә катнашты, театр коллективы белән очрашып, дусларча иҗади сөйләшүләр алып барды.

* * *

Алма-Ата шәһәрендәге Уйгур республика музыкаль-драма театры Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасын сәхнәләштерде. Әсәрне театрның баш режиссеры Кадыйр Җетписбаев куйган, музыкасын Казагыстан ССРның халык артисты композитор Латыйф Хәмиди язган.

## СЕКЦИЯ УТЫРЫШЛАРЫНДА

* * *

Поэзия һәм тәнкыйть секцияләренең берләштерелгән утырышында Ренат Харисовның «Рәссам» поэмасы тикшерелде. «Казан утлары» журналында басылган бу әсәрне Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Нәби Дәүли, Илдар Юзеев һ. б. шагыйрьнең иҗади уңышы дип бәяләделәр.

* * *

Татарстан язучыларының тәнкыйть секциясе утырышы театр белгече, тәнкыйтьче Ильтани Иляловаың иҗатын тикшерде. Филология фәннәре докторы Хәмит Ярми, РСФСРның халык артисты Шәүкәт Бикчимеров, филология фәннәре кандидаты Флүн Мусин, тәнкыйтьчеләр Фарваз Миңнуллин, Мансур Вәлиев Ильтани Иляловаың иҗатына төпле анализ ясадылар, аңа күп кенә файдалы киңәшләр бирделәр.

* * *

Балалар әдәбияты секциясе чираттагы утырышын башлап язучы С. Хәсәновның табигать турында хикәяләрен тикшерүгә багышлады. Фикер алышуларда катнашкан Кыям Миңлебаев, Вахит Монасыйпов, Шәүкәт Галиев. Шамил Рәкыйпов, Саимә [illegible]

Г. Ибраһимов әсәрләренең [illegible] рус теле[illegible] тәрҗемәсе турында филология фәннәр[illegible] кандидаты Г. Хантимерова (Мәскәү), «Татар иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүдә Г. Ибраһимовның роле» дигән темага философия фәннәре кандидаты Я. Аб[illegible] Г. Ибраһимовның [illegible], «Безнең проза[illegible] [illegible] җитми» дигән темага иҗади бәхәс оештырдылар. Флүн Мусин, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Илдус Ахунҗановларның бүгенге татар әдәбиятына ясаган күзәтүләреннән соң кызыклы фикер алышулар башланды.

С. Хәким, М. Юныс, Ф. Хөсни, Җ. Тәрҗеманов, И. Нуруллин, Ф. Ганиева, Ф. Хатипов, Х. Вахит, И. Бәширова, М. Хәбибуллин, Т. Әйди, Х. Сарьян үзләренең чыгышларында заманчалык, конфликт, сәнгатьлелек, тормышчанлык һ. б. мәсьәләләргә кагылып, хәзерге татар прозасын олы мәйданга алып чыгарлык мөмкинлекләр турында сөйләделәр.

«Казан утлары» журналының проза бүлеге мөдире, Татарстан Язучылар союзының партия оешмасы җитәкчесе В. Нуруллин язучыларның иҗади бәхәсенә йомгак ясады.

## ИҖАДИ СӨЙЛӘШҮЛӘР

* * *

Республикабыз художникларының зур җыелышы булды. Анда РСФСР Художниклар союзының II пленум йомгаклары, Татарстан сынлы сәнгать осталарының Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгына әзерлеге һәм РСФСР художество фондының Татарстан бүлеге эше турында докладлар тыңланды.

Җыелыш «60 ел Ленин юлы белән» һәм «Зур Волга-79» күргәзмәләренә әзерлек эшләрен тагын да активлаштыру, художество фонды бүлеге чыгара торган сынлы сәнгать әсәрләренең сыйфатын яхшырту буенча чаралар билгеләде. Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

* * *

Актерлар йортында «Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының бүгенге иҗади торышы» дигән темага багышлап конференция үткәрелде.

Анда Ленинград консерваториясе доценты, Башкортстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Г. Л. Ержинский, Ленинград Кече опера театры режиссеры С. И. Лапиров, Ленинградтагы театр, музыка һәм кинематография институты хезмәткәре, сәнгать фәннәре кандидаты А. А. Соколов татар опера һәм балет театрының үсеш проблемалары, театрның былелгы репертуарындагы спектакльләр турында докладлар ясадылар.

* * *

Казанның М. Горький исемендәге культура йортында үткәрелгән Татарстан хор җәмгыятенең алтынчы республика конференциясендә җәмгыятьнең 1975—76 еллардагы эше тикшерелде.

Конференция яңа идарә һәм Бөтенроссия хор җәмгыятенең III съездына делегатлар сайлады.

## НӘТИҖӘЛЕ КОНКУРСЛАР

* * *

«70 нче еллар Корчагиннары» дип исемләнгән бу ярыш бер ел дәвам итте. Аны ВЛКСМ өлкә комитеты, ТАССР Культура министрлыгы коллегиясе, ТАССР Язучылар һәм Художниклар союзлары, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге бергәләп оештырганнар иде.

Нәтиҗәдә: **«Күз карасы»** дигән поэмасы өчен **Рөстәм Мингалимов**, **«Зирек бөдрәләре»** дигән шигырьләр җыентыгы өчен **Гәрәй Рәхим**, **«101 нче могҗиза»** дигән шигырьләр җыентыгы өчен **Камил Мостафин**, **«Кеше юлга чыкса»** дигән китабы өчен **Фәннур Сафин**, **«Өлешемә тигән көмешем»** повесте өчен **Җәмит Рәхимовлар** җиңүче дип табылды. Шулай ук рәсем сәнгате өлкәсендә: **«Кама өстендә акчарлаклар»** картинасы өчен **Валерий Скобеев**, **«Безнең бригада»** картинасы өчен **Илдар Әхмәдиев**, **«КамАЗ туганда»** дигән графика эшләре өчен **Рәшит Госманов**, **«КамАЗ булачак»**, **«Рәхим ит, КамАЗ»** дигән плакатлары өчен **Илдус Закиров** һәм **Нәҗип Сәләхиевләр** дә җиңүче исеменә лаек булдылар.

Театр сәнгате өлкәсендә **А. Салынскийның** **«Барабанчы»** әсәрен сәхнәләштергән

өчен Әлмәт драма театрының режиссеры **Зәкия Туишева, Г. Боровикның «Канлы күләгәләр»** әсәре буенча эшләнгән спектакль өчен Г. Камал исемендәге академия театрының режиссеры **Ришат Хажиәхмәтов, М. Ибраһимбәковның «Барысына да үч итеп»** пьесасын сәхнәгә куйган Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театрының режиссеры **Александр Клоков,** үзенең **«Баһадирлар»** әсәрен сәхнәләштергән **Роберт Батуллин** (Казан курчак театрының режиссеры)нар да бу ярышта җиңеп чыктылар.

* * *

Агитбригадаларның зона смотры да күңелле нәтиҗәләр бирде. Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгына багышланган бу смотрда Татарстан, Башкортстан, Удмуртия республикалары һәм Ульяновск өлкәсенең агитбригадалар коллективлары көч сынашты.

Бу ярышта Татарстанның Буа районы Адав-Толымбай авылы һәм Сарман, Мөслим, Аксубай район культура йорты бригадалары, Казан шәһәре С. Сәетгалиев исемендәге культура сарае агиттеатры җиңеп чыкты, аларга Бөтенсоюз, Бөтенроссия смотры лауреатлары исеме бирелде һәм I дәрәҗәдәге дипломнар белән бүләкләнделәр.

* * *

Казанда халык театрларына зона ярышлары үткәрелде. Бер айга барган бу смотрда башкорт драматургы Н. Әсәнбаевның «Рәйсә» әсәрен сәхнәләштереп, Әлмәт халык театры һәм М. Әблиевнең «Шәмсекамәр» драмасын куеп, Бөтенроссия смотры лауреаты булган Азнакай халык театры, М. Әмирнең «Миңлекамал» әсәрен куеп Әтнә, шул ук авторның «Хөррият» драмасын сәхнәләштереп Чаллы халык театрлары, М. Горькийның «Тормыш төбендә» пьесасын куеп Чистай районының сәгать заводы халык театры җиңүчеләр булып чыктылар һәм Чаллы, Азнакай, Чистай халык театрлары Ульяновскида үткәреләчәк Бөтенроссия ярышына катнашу хокукын яулап алдылар.

* * *

Казан Яшьләр үзәгенең кино-концерт залында «Кышкы эстрада-77» дип аталган республика конкурсына йомгак ясалды.

Конкурсның жюри председателе, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Алмаз Монасыйпов Казан Төзүчеләр культура сараеның (җитәкчесе А. Серпов) һәм Химиклар культура сараеның (җитәкчесе А. Василевский) эстрада симфоник оркестрларына, А. Н. Туполев исемендәге Казан авиация институтының «Зеркало» инструменталь ансамбленә (җитәкчесе А. Лопай) һәм «Калейдоскоп» вокаль-инструменталь ансамбленә (җитәкчесе В. Березин), В. В. Куйбышев исемендәге завод культура сараеның «Саз» (җитәкчесе Р. Гомәров), Зеленодольск шәһәренең «Аэлита» һәм Арча педагогия училищесының «Егетләр» вокаль ансамбльләренә җиңүче дипломнары тапшырды.

## КҮҢЕЛЛЕ ОЧРАШУЛАР

Күренекле татар язучысы Ибраһим Газн истәлегенә багышлап, Арча педагогия училищесында әдәби кичә узды. Анда язучы Фатих Хөсни Ибраһим Гази турында истәлекләр сөйләде. Кичәдә катнашкан язучы Абдулла Шәрәфи үзенең яңа хикәяләрен укыды.

* * *

А. М. Горький музее каршында күп еллардан бирле инде «Китап дуслары» клубы эшләп килә. Бу клубның соңгы айда булган утырышына язучы Шамил Бикчурин чакырылган иде. Автор үзенең «Каты токым» романы турында китап сөючеләрнең фикерләрен тыңлады, язылып ята торган яңа әсәре хакында сөйләде.

* * *

Казан шәһәренең 35 нче мәктәбендә шагыйрьләрдән Зәки Нури һәм Радиф Гатауллин, прозаик Михаил Скороходов Идел буе районы мәктәпләренең уку-укыту бүлеге мөдирләре белән очраштылар. «Әдәби Казан» дип аталган бу очрашуда әдипләр республикабыз әдәбиятындагы яңалыклар турында сөйләде, үзләренең яңа әсәрләрен укыды.

* * *

Октябрь революциясенең 60 еллыгына багышлап, шәһәребезнең Вахитов районында хатын-кызлар очрашуы үткәрелде. Хезмәт алдынгылары белән очрашуда язучы Нәби Дәүли, РСФСРның халык художнигы Харис Якупов, ТАССРның халык артисты Һидият Солтановлар катнашты.

* * *

Балалар язучысы Шамил Рәкыйповның «Кызлар-йолдызлар» повесте буенча Арча педагогия училищесы укучылары конференция үткәрделәр. Хәрби-патриотик темага багышланган бу сөйләшүдә автор үзе дә катнашып, укучыларыбыз яратып кабул иткән күп кенә әсәрләренең язылу тарихын сөйләде.

* * *

Питрәч районының Шәле урта мәктәбендә «Яшь ленинчы» газетасы укучылар конференциясе үткәрде. Редакция хезмәткәрләре Саимә Ибраһимова, Мәҗит Вәлиуллин, шагыйрь Шәүкәт Галиев, драматург һәм шагыйрь Илдар Юзеев һәм газетаның фотокорреспонденты Николай Седов укучыларга газетаның ничек эшләнүе, аның киләчәктәге планнары турында сөйләделәр, шагыйрьләр яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *


Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында республикабызда иҗат итүче чуваш язучыларының әдәби-музыкаль кичәсе булды. Чуваш язучылары секциясе җитәкчесе В. Юдин Татарстандагы чуваш язучылары иҗаты турында сөйләде. Соңыннан Казан һәм Чабаксар язучылары яңа әсәрләрен укыдылар.

# ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ




**РӘШИТ АБДУЛЛИН**
музыкасы

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ**
шигыре




Акчарлак канат кага,
Идел тын гына ага.
Акчарлактай ак шәһәрем
Карый елгага.
Үткән еллар, гасырлар,
Шаулаган усал чорлар.
Акчарлаклар елавыдай
Ул җырлар.

К у ш ы м т а:

Җырлыйм борынгы җырлар —
Җырымның юк азагы.
Шул җырларда — гасырларның
Газабы.
Кышны куып илемнән,
Кош китерә язларны.
Син — Иделем акчарлагы,
И Казаным!
Акчарлак канат кага,
Иделем ярсып ага.
Акчарлактай ак шәһәрем
Керә җырларга.
Аклыгын ул, сафлыгын
Алды яуларда даулап.
Иделемдә уйнап оча
Акчарлак.

К у ш ы м т а:

Җырлыйм яңа җырларны —
Җаным тора атлыгып...
Бу җырларда — заманымның
Шатлыгы.
Кышны куып илемнән,
Кош китерә язларны.
Син — Иделем акчарлагы,
И Казаным!

## *Хөрмәтле укучыбыз*

Илебез бөек бәйрәм — Октябрь революциясенең 60 еллыгын каршылауга әзерләнә. Һәркайда эш һәм җиңү тантанасы. Бу көнгә республикабыз Татарстан да зур уңышлар белән киләчәк. «Казан утлары» журналының җиденче санында басылган әдәби әсәрләр, фәнни хезмәтләр, документаль материаллардан сез әнә шул иҗади күтәренкелекне күрерсез.

Журналыбызның бу саны Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыевның «Октябрь һәм Татарстан» дигән мәкаләсе белән ачыла. Габделхәй Сабитовның «Чулпан таңны уята» дигән пьесасы ирек өчен көрәшүче бабаларыбызның фаҗигале язмышларын сурәтли.

Бу санда Мирсәй Әмирнең «Без бәләкәй чакларда» исемле повесте тәмамлана.

Укучыларыбызга Наҗар Нәҗминең «Иблис» дигән зур поэмасын һәм Мөхәррәм Каюмовның «Казаным» дигән шигырьләр циклын тәкъдим итәбез.

Мәрди Рәфиковның «Урманым — һәйкәлем» дигән очеркында табигатьне саклау проблемалары яктыртыла.

Июль аенда күренекле тәнкыйтьче Галимҗан Нигъмәтинең тууына 80 ел тула. Шул уңай белән Хатип Госманның «Онытылмас остазыбыз» һәм Флорид Әгъзәмовның «Күренекле журналист» дигән мәкаләләре урнаштырыла.

Абдулла Сәләхетдиновның «Төньяк җилилчеләре» дигән язмасында Северодвинск шәһәрендәге эзтабарларның мавыктыргыч эшләре турында сөйләнә.

Бу санда да яңа китапларга рецензияләр, юмор һәм сатира әсәрләре, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары бирелә.

Хөрмәтле укучыбыз!

Елның яртысы үтеп тә китте. Әгәр сез журналга ел ахырына кадәр язылмаган булсагыз, алдагы саннарны алдыру турында кайгыртыр вакыт җитте. Елның икенче яртысында журналыбызда Гәрәй Рәхимнең «Көннәр язга авышкач», Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы», Әхәт Гафаровның «Кашан җыры», Әхсән Баяновның «Тавыш — табигать бүләге» дигән повестьлары һәм Габдрахман Әпсәләмовның «Агыла да болыт агыла» дигән романы басылачак.

Саҗидә Сөләйманова, Нәби Дәүли, Рәдиф Гатауллин, Шәүкәт Галиев, Марс Шабаев һ. б. шигырьләрен, Илдар Юзеевның «Өзелмәс кыллар» исемле поэмасын да алдагы саннарда укырсыз.

Илебезнең һәр элемтә бүлегендә журналга язылуны дәвам итәргә мөмкин. «Казан утлары» журналының бөтен союз каталогындагы индексы — 73210.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210